Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең
Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты

Институт языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова
Академии наук Республики Татарстан

Казан • Казань
2022

# РУХИ МИРАС

## Эзләнүләр һәм табышлар

*16 нчы чыгарылыш*

**Г. Рәхим, Г. Газиз**

**Татар әдәбияты тарихы**

**Борынгы дәвер. XVII–XIX гасырлар**

# ДУХОВНОЕ НАСЛЕДИЕ

Поиски и открытия

*Выпуск 16*

**Г. Рахим, Г. Газиз**

**История татарской литературы**

**Древний период. XVII–XIX века**

УДК 82.0
ББК 83.3(2=632.3)
Р 82

*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең
Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты
Гыйльми советы карары нигезендә нәшер ителә*

Проект «Татар халкының милли үзтәңгәллеген саклау (2020–2024)»
ТР Дәүләт программасы кысаларында
Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе
Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының
Язма мирас үзәге тарафыннан гамәлгә ашырыла

**Редколлегия:**
***Д. Ф. Заһидуллина*** *(җаваплы мөхәррир),* ***Ә. М. Закирҗанов,***
***И. Г. Гомәров*** *(проект җитәкчесе һәм фәнни мөхәррир)*

**Төзүчеләр һәм текстларны әзерләүчеләр:**
***Л. Ш. Гарипова, Л. Р. Надыршина, А. М. Ахунов, И. Г. Гомәров, Г. А. Хөснетдинова***

**Р 82 Рухи мирас: эзләнүләр һәм табышлар. Г. Рәхим, Г. Газиз. Татар әдәбияты тарихы. Борынгы дәвер. XVII–XIX гасырлар = Духовное наследие: поиски и открытия. Г. Рахим, Г. Газиз. История татарской литературы. Древний период. XVII–XIX века.** Т. 2 / төз., текст., иск. һәм аңл. әзерл.: Л. Ш. Гарипова, Л. Р. Надыршина, А. М. Ахунов, И. Г. Гомәров, Г. А. Хөснетдинова. – Казан: ТӘһСИ, 2022. – 16 нчы чыг. – 300 б.
ISBN 978-5-93091-452-8

Җыентык татар халкы рухи мирасының нигезен тәшкил иткән әсәрләрне өйрәнү, аз билгеле язма чыганакларны бастырып чыгару, археографларның яңа табышлары белән укучыларны таныштыру традициясен дәвам итә.

Сериянең чираттагы санында татар галимнәре Гали Рәхим (1892–1943) һәм Газиз Гобәйдуллин (1887–1938) тарафыннан әзерләнгән һәм 1922–1924 елларда 3 том булып нәшер ителгән «Татар әдәбияты тарихы» тәкъдим ителә. Бу хезмәтнең беренче томы һәм икенче томының бер бүлеге «Рухи мирас: эзләнүләр һәм табышлар» сериясенең 15 нче чыгарылышында дөнья күрде. Әлеге чыгарылышта басманың икенче томыннан «Идел буенда чыгтай әсәрләре» кисәгенең дәвамы («Рәүнәкъ әл-ислам», «Мәхзән әл-әсрар», «Кыйссаи Сәйфелмөлек», «Сөбат әл-гаҗизин», «Кисекбаш китабы», «Йосыф китабы»), «Идел буенда госманлы әсәрләре» бүлеге, «XVII, XVIII һәм XIX гасырларда иске әдәбият» дип аталган өченче томы туплап бирелә.

Хезмәт, гарәп язуыннан гамәлдәге хәрефләргә күчерелеп, беренче тапкыр нәшер ителә. Басма белгечләр, татар тарихы һәм мәдәнияте белән кызыксынучы киң катлау укучылар игътибарына тәкъдим ителә.

ISBN 978-5-93091-452-8
© ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, 2022

# ИДЕЛ БУЕНДА ЧЫГТАЙ ӘСӘРЛӘРЕ[1]

## «Рәүнәкъ әл-ислам»

Бу китапның бөтен исеме – «Китабе мөстәтаб рәүнәкъ әл-ислам»[2]. «Китабе мөстәтаб» сүзе бик күп борынгы китапларның исеменә кушылып йөртелеп, «газиз китап» мәгънәсенә туры килә. «Рәүнәкъ әл-ислам» – баштан ахырына кадәр бәхре рәмәл (фагыйләтен фагыйләтен фагыйләт) вәзенендә язылган дини мәүзугта булган көйле бер китап. Зурлыгы – басмада урта кул 46 бит. Беренче мәртәбә Казанда 1850 елда басылган.

«Рәүнәкъ әл-ислам»ның ахыргы бәйтләре шушы:

«Бу китаб хәтемендә[3] ул ирде сәнәт[4]
Тисгы вә ситтун вә сәмания миәт[5]
Вәзен эчендә мәзбут улмыш бу бият[6]
Фагыйләтен фагыйләтен фагыйләт».

Димәк, бу китап һижри 869 (милади 1464–1465) елларда язылган. Язучысының кем булуы һәм кайда язылуы китапның үзеннән аңлашылмый. Ләкин мөстәшрикъ[7] Самойлович[8] бу мәсьәләне ача төшә торган бәгъзы материаллар тапкан. «Рәүнәкъ әл-ислам» китабы Хәзәр диңгезе белән Арал күле арасында торучы төрекмән халкы арасында мәктәпләрдә дәрес китабы итеп укыла икән. Хуҗа Мулла исемле бер галим-

[1] Дәвамы. Башы алдагы чыгарылышта.

[2] «Китабе мөстәтаб рәүнәкъ әл-ислам» («Ислам нуры хакында кадерле китап») – төрекмән суфи шагыйре Вафаи әсәре.

[3] Бу китаб хәтемендә – бу китапны язып бетергәндә.

[4] Сәнәт – ел.

[5] Тисгы вә ситтун вә сәмания миәт – сигез йөз алтмыш тугызынчы.

[6] Мәзбут улмыш бу бият – язылган бу икеюллыклар.

[7] Мөстәшрикъ – Көнчыгышны өйрәнүче.

[8] Самойлович Александр Николаевич (1880–1938) – шәрыкшинас, төрки дөньяны өйрәнүче, СССР Фәннәр академиясе академигы (1929). Идел буенда, Кырымда, Кавказда, Урта Азиядә, Казакъстанда, Алтайда яшәгән төрки халыкларның телен, мәдәниятен өйрәнгән галим.

төрекмән, бу китапның тәэлифе[1] хакында халык арасында шаигъ булган[2] бер хикәяне язып, Самойловичка җибәргән. Бу хикәяне гайнән[3] күчерәбез: «Шәех Шәриф дигән бер вәлиулла[4] кадим заманда булыбдыр Хивада Хиваның сахрасында кәзан[5] чарваһ убалар[6], ак сакаллары Шәех Шәриф вәлигә тәваккыг итеб дурлар[7]: безгә төрки телендә мөселманлыкны яхшы укыб билүрали[8] китаб язып бир дикәнин[9] Шәех Шәрәф вәли «Рәүнәкъ әл-ислам»ны төзеб языб биребдер, шул чарваһ[10] байлар Шәех Шәрәф вәлигә шуның гузынә[11] утуз кушаклы тивә[12] биребдерләр, анлары һәм Шәех вәли алыб фәкыйрь-фокараларә сарыф итебдер. Шәех Шәрәфнең гадәте һәмишә ишәк мениб[13], кәзармиш көнләрдә бер көн бер бай бер ат Ходай йулы бирди әүвәлкы[14] ишәкне кыйуб[15], атны мениб убадин чыкды, күңеле белендлик[16] итеб һава һәвскә кәтди[17], ул вакыт ат башыны чекиб[18], Шәех Шәрәф вәлигә бу бәйтне укыды:

«Атың синең – Шәех Шәрәф,
Асылың тат[19] булса кирәк.

[1] Тәэлифе – төзүчесе, язучысы.
[2] Шаигъ булган – таралган.
[3] Гайнән – үзгәртмичә.
[4] Изге, әүлия. *(Авт. иск.)*
[5] Гизгән, күчеп йөргән. *(Авт. иск.)*
[6] Хайван асрау белән көн итә торган күчмә авыллар. *(Авт. иск.)*
[7] Үтенгәннәр. *(Авт. иск.)*
[8] Белдерерлек, белдерердәй. *(Авт. иск.)*
[9] Дигәч, дигәнгә күрә. *(Авт. иск.)*
[10] Хайван асраучы. *(Авт. иск.)*
[11] Бәрабаренә. *(Авт. иск.)*
[12] Балалы дөя. *(Авт. иск.)*
[13] Ишәкккә атланып. *(Авт. иск.)*
[14] Әүвәлге. *(Авт. иск.)*
[15] Куеп, ташлап. *(Авт. иск.)*
[16] Олуглык. *(Авт. иск.)*
[17] Һава һәвәскә кәтди – ауга китте.
[18] Сузып. *(Авт. иск.)*
[19] Таҗикларны төрекмәннәр «тат» дип атыйлар. *(Авт. иск.)*

Ягыйрь[1] ишәк дуран йирдә[2]
Бәдәу[3] ат сәңа нә[4] кирәк?» –

тиб изинә[5] убайә кайтыб атны янә фәкыйрә бәриб[6], әүвәлкы ишәкне мениб китде. Соңра шөйлә[7] нәкыль[8] әйтүрләр ки, бер еланны мениб, бер еланны камчы итеб Хивадин Нәхурга[9] килебдер. Хәзер Шәех Шәрәф вәлинең кабуре[10] Нәхурда булыр вә берничә өйле Нәхурлы Шәех Шәрәфнең нәселемез дийарлар[11], үзләри хуҗа хисаб идәрләр».

Менә бу риваять буенча, «Рәүнәкъ әл-ислам» китабын, төрекмәннәр өчен хаслап, Шәех Шәрәф аталган бер ишан язган булып чыга. Бу кешегә халык кәрамәтләр иснад кыла[12] икән. Югарыдагы бәйттән күренгәнчә, нәсел ягыннан ул таҗик булырга кирәк. Мәшһүр Урта Азия мөәррихе[13] Әбелгазый Баһадур хан үзенең «Угызнамә»дән[14] үзгәртеп язган «Шәҗәрәи төрекмән»[15] («Төрекмәннәр шәҗәрәсе») атлы китаптан Шәех Шәрәфнең исемен зикер кыла[16]. Аныңча, Үргәнечтә булган бу шәех, Арсары исемле бер байның үтенүе буенча, төрекмәннәр

[1] Корчаңгы. *(Авт. иск.)*
[2] Булган чакта. *(Авт. иск.)*
[3] Аргамак, бәдәви (?). *(Авт. иск.)*
[4] Нигә. *(Авт. иск.)*
[5] Кире. *(Авт. иск.)*
[6] Бәриб – биреп.
[7] Шөйлә – шулай.
[8] Нәкыйль – телдән телгә сөйләү.
[9] Хивадин Нәхурга – «Нәхур» – Ашхабад өязендә бер авыл.
[10] Кабере. *(Авт. иск.)*
[11] Диярләр, дип әйтерләр. *(Авт. иск.)*
[12] Иснад кыла – нисбәт итә.
[13] Мөәррихе – тарихчысы.
[14] «Угызнамә» («Угыз кыйссасы») – 1) төрки-угызларның легендар шәҗәрәсе һәм аларның атасы Угыз каган (Угыз хан) турында эпик истәлекләр комплексы. XVII йөздә Хива ханы Әбелгазый Баһадур хан, әлеге эпоска таянып, «Төрекмәннәр шәҗәрәсе» («Шәҗәрә-и тәрәкимә»), «Төркиләр шәҗәрәсе» («Шәҗәрә-и төрк») исемле версияләрен иҗат итә.
[15] Әбелгазый Баһадур хан (1603–1663) «Шәҗәрәи төрк» («Төркиләрнең нәсел агачы»). *(Авт. иск.)*
[16] Зикер кыла – искә ала.

өчен «Мөгайин әл-мөрид» исемендә бер китап язып биргән. Төрекмәннәр шул китап буенча гамәл кылалар икән[1].

Әбелгазыйда Шәех Шәрәфнең «Рәүнәкъ әл-ислам» китабын язуы хакында бер сүз дә әйтелмәгән. Ләкин Шәех Шәрәф исемле бер тарихи затның булуы, аның төрекмәннәр өчен китаплар язуы шөбһәсез. «Рәүнәкъ әл-ислам»ның да шул кешенеке булуына һич истихалә[2] юк.

Мөндәриҗәсе[3] ягыннан «Рәүнәкъ әл-ислам» гади «Гыйльме хәл» китапларына охшый. Мөкаддимәсендә[4] мөәллиф, Алланың, пәйгамбәрнең сыйфатларын бәян кылганнан соң, «Фи мөнакыйб әл-голәма» дигән кыйсемендә гыйлемгә мәдхия укый:

«Гыйлем ушалдыр инде күкдин ул йирә,
Раушан улсын дин тию пәйгамбәрә.
Ул гыйлемне сүзләмеш кодрәт тиле,
Аның илә биленүр ислам юлы.
Гыйлем иләндер ике дөнья рәүнәкы,
Гыйлем иләндер танымаклык ул Хаккы.
Гыйлем иләндер васыйл улмак ул Хакка,
Коллуг әйләб ярлыканмак мотлакан».

Галимнәр хакында ул әйтә:

«Чөнки Хак кылмышдыр ул гыйлеме шәриф[5],
Гыйлем иясе галиме һәм күр шәриф,
Дин ичүн галимләрә хезмәт кылың,
Мостафа урынында монларны белең».

Монда сөйләнгән гыйлем – әлбәттә, дин гыйлеме.

Шул гыйлемне өйрәтү йөзеннән китапта игътикад, гыйбадәт һәм бәгъзы бер шәригать хөкемнәре хакында сөйләнә. Китапның кырыена язылган баб вә фасыл[6] исемнәренә бер күз

[1] [А.Н.] Самойлович. «Светоч Ислама». *(Авт. иск.)*
[2] Истихалә – шик.
[3] Мөндәриҗәсе – эчтәлеге.
[4] Мөкаддимәсендә – керешендә.
[5] Шәриф – кадерле.
[6] Баб вә фасыл – бүлек һәм бүлекчәләр.

йөртеп чыксак, аның мөндәриҗәсе безгә ачык булыр. Анда, мәсәлән, шушындый баблар бар: «Алланы мәгърифәт бәянында», «Иман бәянында», «Ислам бәянында», «Ихсан бәянында», «Әхкяме шәригать[1] бәянында» (фарыз, важиб[2], сөннәт, ... хәрәм, мәкруһ[3] вә ... илх[4]), «Коега кан тамса я хәмер төшсә аның хөкеме», «Майга эт тиксә аның хөкеме», «Тәһарәтханәгә кермәк әдәпләре», «Тәһарәт бәянында», «Намаз бәянында», «Сәфәр хөкемене бәян идәр», «Йокламак әдәбе бәянында», «Тәгам йийү[5] әхкямене бәян идәр», «Хайван бугазламак хөкеме», «Хайванда ничә нәрсәне ашамак хәрәмдер», «Ат итеннең кәраһәте[6] бәянында», «Берничә эшләр эшләсә фәкыйрьлек китерер», «Ун нәрсә күңелгә кайгы килтерер», «Хатыннар сохбәтендә[7] әдәп бәяны», «Оҗмахның сыйфатлары бәянында» вә башкалар. Бөтен китап 30 баб үзәренә бинаән кылынып[8], бәгъзы баблар берничә фасылларга аерылалар. Без монда, мөндәриҗәнең характерын күрсәтү өчен, аларның кайберсен генә алдык.

«Рәүнәкъ әл-ислам»да рәсми шәригать хөкемнәре генә түгел, бәлки байтак кына хорафи гадәт вә ырымнар да дин исеменнән, пәйгамбәр әйтте, дип сөйләнә. Мәсәлән, фәкыйрьлек китерә торган, күңелгә кайгы китерә торган эшләр шул җөмләдән. Бу эшләрдән безнең татар халкы чын шәргый гөнаһлардан да болайрак качына[9], тормышның бөтен вак-төяген эченә ала торган шул ырымнарны шәригать хөкемнәреннән дә болайрак мөкаддәс санап әда кыла[10]. Мәгълүм ки, бу кагыйдәләр, хакыйкый ислам шәригатеннән тыш, тагы үзенә махсус бер «татар

[1] Әхкяме шәригать – шәригать хөкемнәре.
[2] Важиб – үтәлергә тиешле.
[3] Мәкруһ – дин тарафыннан кискен тыелмаган, әмма кулай күрелмәгән эшләр.
[4] Илх (Иля ахриһи) – һәм башкалар.
[5] Тәгам йийү – ашау.
[6] Кәраһәте – чиркәнгеч, җирәнгеч булуы.
[7] Сохбәтендә – үз-үзен тотышында.
[8] Үзәренә бинаән кылынып – нигезендә ясалып.
[9] Качына – кача, читләшә.
[10] Әда кыла – башкара.

шәригате» тәшкил итәләр. «Рәүнәкъ әл-ислам», мәсәлән, түбәндәге эшләрдән бик сакланырга куша: ата-ананың исемен әйтү, үрмәкүч авын өзү, бусага өстенә утыру, суган кабыгын утка ягу, өстә килеш киемне тегү, утны өреп сүндерү, ыштанны аягүрә торып кию, йомырка кабыгын таптау, сул кул белән ашау ... иля ахриһи[1], иля ахриһи... Менә шушындый «канун»нарның татар өчен нинди мөкаддәс булулары аз гына үз халкының тормышы белән таныш кешегә бик мәгълүм. Кечкенә чагыбызда төрле хатыннар, карчыклар безнең үзебезнең дә колакларыбызга шул кагыйдәләрне мөттасил[2] тукып торганнар, хәтта ки, шуларның бәгъзылары безнең рухыбызга да сеңеп өлгергән; ышанмасаң да, өйрәнгән буенча бәгъзан шундый юк эшләрдән сакланыла. «Рәүнәкъ»ның мөхәррире өчен дә бу кагыйдәләр иң әһәмиятле, хәтта ул аларны сөйли башлар алдыннан:

«Тыңла имди, һәрберин әйдәм сәңа
Ярый булса Хакның илһамы миңа», –

дип, Алладан илһам да көтә. Безнең халык, хосусан муллалар, остабикәләр арасында мәгъруф[3] булган мәктәпләрдә дәрес итеп тә укылган бу китапның шул хорафи «татар шәригате»нең ясалуы юлында күп хезмәте тигән булырга кирәк.

«Рәүнәкъ әл-ислам»ның телендә игътибар итәрлек бер нокта булса, ул да аның XV гасырда чыгтай әдәбиятының урта дәверендә, Нәваиләр заманында язылган булуына карамый, борынгы чыгтай сүзләре, хәтта борынгы чыгтай телендә дә очрамый торган борынгы төрк сүзләре белән тулы булуыдыр. Мәсәлән, анда «карауш» (карабаш – җария), «укуш» (мәдех[4]), «сәч» (суч – гөнаһ), «уза» (үзрә, үзәренә), «кот» (бәхет), «козуг» (кое), «азак» (аяк), «кузмак» (куймак), «кадгу» (казгу – кайгы), «әйүр» (әйтә) шикелле бик иске лөгатьләр[5] очрыйлар ки, аларны бары

[1] Иля ахриһи – һәм башкалар.
[2] Мөттасил – туктаусыз.
[3] Мәгъруф – билгеле.
[4] Мәдех – мактау.
[5] Лөгатьләр – сүзләр.

чыгтай әдәбиятының борынгы дәверендә генә очратырга мөмкин. Аннан соң фигыльләрнең киләчәк заман сыйгасы[1] бәгъзан «билисәр», «улисәр», «кәлисәр» формасында истигъмаль ителгәли[2]. Бу форманы без бәгъзан бары борынгы госманлы әдәбиятында да, мәсәлән, «Мөхәммәдия»дә табабыз; чыгтай телендәге иң иске китапларда бу форма кулланылмый. Таки[3], әгәр дә «Рәүнәкъ»ның кайчан язылуы тәгаен мәгълүм булмаса иде, без аны, бер дә уйлап тормый, борынгырак гасырларда язган әсәрләрдән санар идек. Аның теленең тагын бер игътибар итәргә тиеш ягы шулдыр ки, анда «әл» (кул), «курт» (бүре), «чук» (күб) шикелле җәнүб төрк теленә махсус сүзләр, «улмак, сайрайур, ярадан, кемләрнең, кемләре, нигъмәтә, үгрәннә (өйрәнгәнгә)» шикелле җәнүб төркчәләрендәге сарфи[4] формалар бик еш очрыйлар. Менә китапның телендә бик нык хөкем сөргән бу «госманлычалык»ны аңлар өчен, аның төрекмәннәр өчен язылган булуын искә төшерергә кирәк. Төрекмәннәр төрк халыкларының җәнүби төркеменә керәләр. Аларның теле госманлы төркләренең теленә бик якын, ләкин Урта Азия телләре аңар беркадәр тәэсир иткәннәр. Бу китап, гәрчә нәсел ягыннан ирани (таҗик) булса да, төрекмәннәр арасында торып, аларның телен белгән бер дин галиме тарафыннан язылган. Китабын халык гаммәсе өчен атап язганга күрә, ул аны, әлбәттә, мөмкин кадәр төрекмән телендә язарга тырышкандыр. Ләкин әдәбиятта чыгтай традицияләре куәтле булганга, ул, әлбәттә, чыгтай теле тәэсиреннән котыла алмаган; безнең татарча язабыз дип язган борынгы язучыларыбыз шикелле, ул да чыгтай әдәби теле белән катыш төрекмән телендә язгандыр. Гарәп-фарсы сүзләре бу китапта XV гасыр чыгтай әдәбиятындагы күк күп очрамый; аның теле, шигырь булуга карамый, яхшы ук садә[5] вә саф. Бу да, әлбәттә, аның халык өчен язылган булуыннандыр.

[1] Сыйга – төрләнеше.
[2] Истигъмаль ителгәли – кулланыла.
[3] Таки – шуның өчен.
[4] Сарфи – морфологик.
[5] Садә – гади.

Мөндәриҗәсенең тәказа кылуы[1] буенча «Рәүнәкъ әл-ислам»-ның өслүбе дә, әлбәттә, садә вә шигъриятсез. Аның көйле булуы язучысының шагыйрь булуына дәляләт итми[2], чөнки һәрбер китапны нәзым белән язу – шәрык язучылары өчен бер гадәт ул. Бу китап, билгеле, балаларга дәрес итеп укыту өчен язылган. Шәрыкта исә сабакны балаларга күбрәк күңелдән бикләтеп укыталар. Көйләп язган әйберне хифыз кылу[3], әлбәттә, җиңелрәк була. Ләкин шулай да безнең мөхәррир, алган мәүзугының коры, шигъриятсез булуына карамый, вакыт-вакыт намаз шикелле гади нәрсәләрдән дә илһамланып, канатланып китеп:

«Бу намаздыр – Аллаһның хушнудлыгы[4],
Бу намаздыр – дин, иманның шадлыгы,
Бу намаздыр ул сыйратдин кичүрән,
Бу намаздыр тәмуг утын сүндерән,
Бу намаздыр – гүр эчендә ул чираг[5],
Бу намаздыр – оҗмах эчрә ул чираг», –

шикелле халис[6], үз күңеленнән чыккан мәдхияләр дә укып ташлый; яки «бинамазлар» (ягъни намазсызлар) хакындагы бәйтләр шикелле шиддәтле сәтырларны[7] яза:

«Бинамаз ул[8], бинамаз ул, бинамаз,
Мөэмин ирсәң, улма нәһар[9] бинамаз.
Бинамаздыр – җөмлә колларның пәсе[10],
Бинамазның юк тәнендә арусы[11].

---

[1] Тәказа кылуы – таләбе.
[2] Дәляләт итми – дәлилләр булып тормый.
[3] Хифыз кылу – ятлау, күңелдән белү.
[4] Хушнудлыгы – разыйлыгы.
[5] Чираг – яктылык, ут.
[6] Халис – саф, чын.
[7] Шиддәтле сәтырларны – көчле юлларны.
[8] Намазлы бул. *(Авт. иск.)*
[9] Нәһар – көн.
[10] Начар. *(Авт. иск.)*
[11] Арулыгы. *(Авт. иск.)*

Бинамаздыр – дошмане Хак бигөман[1],
Бинамаз – кяфер, монафикъдыр һәман[2].
Бинамазның йөзе шомдыр, буе шом,
Бинамазның сохбәте[3], дидары шом.
Бинамазның илкендә[4] йимәң тәгам,
Бинамазга ләгънәт әйләң мөстәдам[5].
Бинамаз кәсебе хәрамдыр мотлакан,
Аның ичүн тәсбихе юкдыр Хакка.
Бинамаз – иблис ләгыйньнең ләшкәре[6],
Йире юкдыр оҗмах эчрә эчкәре».

## «Мәхзән әл-әсрар»

Бу китап – бәхре рәмәл (фагыйләтен фагыйләтен фагыйләт) вәзенендә нәзым белән язылган, басмада урта кул 31 битле бер әсәр. Беренче мәртәбә Казанда 1858 елда басылган.

«Мәхзән әл-әсрар» («Серләр хәзинәсе») аталган бу китапның кайчан һәм кем тарафыннан язылуы аның үзеннән ачык күренми. Ләкин ул, шөбһәсез, XV гасырдан да элек язылмаган, чөнки анда Аксак Тимернең яшьлек заманына гаид[7] бер хикәя (легенда) бар. Бу хикәядә, бер биек әйбер өстенә менәр өчен, чиксез сәбат белән[8] тырышкан аксак кырмысканы күреп, Тимернең гыйбрәт алуы сөйләнә. (Шушы ук хикәяне без «Әхвәле Чыңгыз хан вә Аксак Тимер» китабында очраткан идек.) Бер-бер тарихи шәхес хакындагы легендалар исә, гадәттә, аның үлеменнән беркадәр заман үткәннән соң гына ясалалар.

[1] Шиксез Аллаһ дошманыдыр. *(Авт. иск.)*
[2] Һәман – өзлексез, һәрвакыт.
[3] Сохбәте – сөйләгән сүзе.
[4] Кулыннан. *(Авт. иск.)*
[5] Бертуктаусыз. *(Авт. иск.)*
[6] Гаскәре *(Авт. иск.)*
[7] Гаид – караган.
[8] Сәбат белән – көч куеп.

«Мәхзән әл-әсрар»ны алтын гасырдагы чыгтай шагыйре Мирхәйдәргә нисбәт бирәләр[1]. Китапның берничә җирендә «Хәйдәр» яки «Хәйдәр Кәррар» (?) исеме зикер кылына[2]. Мәсәлән:

«Туты[3] җиһан зөмәрмәэ[4] Хәйдәри
Тулды садә көнбәз нилүфәри[5].
Дин эчидә Әхмәд мохтар дик,
Көн эчидә Хәйдәр Кәррар[6] дик.
Ул ки бу хәлгатка сәзавар[7] ирү,
Талиб кеше Хәйдәр Кәррар ирүр.
Суга – балигъ,[8] утка сәмәндәр[9] кирәк.
Гамьгә – мөхиб[10], дәрдегә Хәйдәр кирәк».

Мөәллиф[11], үзенең китабын язган вакытында, шагыйрь Низаминың әсәрләреннән файдаланган, шулардан илһам алган булырга кирәк, чөнки бер урында без шушы сәтырларны[12] укыйбыз:

«Мин ки пешердем бу ләзиз ашны,
Шәех Низамидин алып чашны[13],
Шәех Низами дәмедин[14] җан табып,
Мәгънәседән ярлыг[15] вә борһан[16] табып».

[1] «Мәхзән әл-әсрар» (1409–1414) – Мирхәйдәр (Харәзми, Хәйдәр) тарафыннан Низаминың шул ук исемдәге әсәренә ияреп язылган поэма.
[2] Зикер кылына – телгә алына.
[3] Тотты. *(Авт. иск.)*
[4] Күк күкрәү авазы. *(Авт. иск.)*
[5] Ягъни «төнбоек чәчәге төсле күк гөмбәзенә аваз тулды». *(Авт. иск.)*
[6] «Тәкрарлаучы» мәгънәсендә булган «кәррар» түгелме икән? *(Авт. иск.)*
[7] Лаек. *(Авт. иск.)*
[8] Балык. *(Авт. иск.)*
[9] Саламандра – кәлтә елан кыяфәтле бер хәйван булып, борынгыларның игътикадынча, утта янмау хассәсенә малик булган. *(Авт. иск.)*
[10] Сөюче. *(Авт. иск.)*
[11] Мөәллиф – язучы, автор.
[12] Сәтырларны – юлларны.
[13] Татымак (проба пищи). *(Авт. иск.)*
[14] Канынннан. *(Авт. иск.)*
[15] Әмер. *(Авт. иск.)*
[16] Дәлил. *(Авт. иск.)*

Низами[1] Иран шагыйрьләренең зурларыннан хисаплана, төп ватаны Азәрбайҗанда Ганҗә (Елизаветполь) шәһәре булганга, аны «Ганҗәви» дип тә атаганнар. Вафаты һиҗри VI–VII гасырлар арасында (милади XIII гасыр башында). Низаминың барысы берлектә «Пәнеҗ гәнеҗ» («Биш хәзинә») аталып йөртелә торган биш мәнзумәсе[2] бар; исемнәре «Мәхзән әл-әсрар», «Ләйлә вә Мәҗнүн», «Хөсрәү вә Ширин», «Һәфт пәйкәр»[3], «Искәндәрнамә». Безнең Хәйдәр, ихтимал, үзенең китабын шул Низаминың «Мәхзән әл-әсрар»ыннан бераз гына үзгәртеп (яки кыскартып) тәрҗемә кылгандыр, яисә, югарыдагы бәйтләрдән аңланганча, ул үзенең фикерләрен, китапның төп рухын, идеясен һәм кайбер кыйссаларын гына аннан алып, бөтенләй яңабаштан, үзенчә язып чыгарып, Низами әсәрен «тәкрарлаучы»[4] гына булгандыр. Хәйдәрдә Низамида булуы мөмкин булмаган мәүзугларның[5] (Тимер хакындагы хикәянең) булуы да соңгы фикерне куәтли. Ләкин Низаминың «Мәхзән әл-әсрар»ы белән таныш булмаганга, башка урында да кирәкле мәгълүматны таба алмаганга, бу турыда төпле бер фикер бәян итә алмыйбыз.

«Мәхзән әл-әсрар» – әхлакый бер әсәр. Мөндәриҗәсенең тәртибе шушы рәвешчә: элек бер гыйбрәтле кыйсса сөйләнә, аннан соң шул кыйссаның хиссасы итеп[6], бер-бер әхлакый мәүзугка мөхакәмә[7] ясала. Бу әхлакый фәлсәфә сатуларны

[1] Җәмаледдин Ильяс ибне Йосыф Низами Ганҗәви (якынча 1141 – якынча 1209) – күренекле шагыйрь, Азәрбайҗан, Таҗикстан, Иран һәм Әфганстанда милли әдәбиятлары классигы. Тумышы белән Азәрбәйҗанның Ганҗә шәһәреннән. Әсәрләрен, нигездә, фарсы телендә иҗат иткән. Низамига дөньякүләм танылуны «Хәмсә»се алып килә. Ул түбәндәге әсәрләрне берләштерә: «Серләр хәзинәсе», «Хөсрәү вә Ширин», «Ләйлә вә Мәҗнүн», «Җиде гүзәл, «Искәндәрнамә». Моннан тыш, аның тагын 20 мең бәетне берләштергән «Диван»ы булганлыгы билгеле. Безнең көннәргә аннан 116 газәл, 30 робагый, берничә касыйдә һәм кыйтга килеп ирешкән.

[2] Мәнзумәсе – монда: поэмасы.

[3] «Һәфт пәйкәр» – «Җиде чибәр».

[4] Тәкрарлаучы – кабатлаучы.

[5] Мәүзугларның – сюжетларның.

[6] Хиссасы итеп – гыйбрәтле сүзе итеп.

[7] Мөхакәмә – хөкем-нәтиҗә.

«Котадгу белег» китабындагы шундый ук фәлсәфәләр белән беркадәр тиңләштерергә мөмкин. Ләкин, әлбәттә, аның ифадә вә өслүбендә[1] тәсаувыф әдәбиятында хөкем сөргән гадәт вә тасвиратның тәэсире күренә. Суфи шагыйрьләрдәге гаувас[2] булып, «бәхре гәмман»га чуму, диңгез төбеннән гәүһәр вә энҗе чыгару, чәрхе[3], фәләк[4], гәнеҗ сакый[5], ширбәт, җам[6], гөл, былбыл, читлегеннән очкан тутый шикелле гомуми мәҗаз вә кинаяләр[7] монда да очрыйлар. Ләкин, шуның белән бергә, бу китапта тырыш диһканнар (игенчеләр) вә бакчачылар мәмләкәте булган Мавәраэннәһергә махсус тәшбиһләрне[8] дә очратып була. Мәсәлән: «Түкмәсә диһкан гарык пай бил[9] / Мивәсенең[10] файдасын табмас ил», «Тәрбият васига[11] кылур багбан[12] / Таза булып, мивә бирер бостан[13]», «Арпа игеп, богдай урырмын, дигән / Күрмәдүк ашлыгчыны[14] богдай йийгән[15]».

«Мәхзән әл-әсрар» – чыгтай әдәбиятыннан безгә кергән әсәрләрнең иң авыр тел белән язылганы. Аның кайбер бәйтләрен шулкадәр күп әҗнәби[16] сүзләр баскан ки, алар арасында төркчә сүзләр бөтенләй югалып калганнар. Хосусан, башта китапның ни өчен «Мәхзән әл-әсрар» аталганын, әллә нинди хәрефләрнең серләрен сөйләгән урыны бик чуалчык вә аңлар өчен авыр. Теленең авырлыгы сәбәпле, бу китап татар халкы арасында күп

[1] Ифадә вә өслүбендә – аңлатуында һәм ысулында.
[2] Гаувас – диңгезгә чумып энҗе эзләүче; водолаз.
[3] Чәрхе – хәйлә.
[4] Фәләк – язмыш.
[5] Гәнеҗ сакый – шәраб коеп биреп торучы яшь егетләр.
[6] Җам – бокал, касә.
[7] Мәҗаз вә кинаяләр – метафора һәм метонимияләр.
[8] Тәшбиһләрне – чагыштыруларны.
[9] Игенче аяк һәм бил тирен түкмәсә.
[10] Мивәсенең – җимешенең.
[11] Тәрбият васига – киң тәрбия.
[12] Бакчачы. *(Авт. иск.)*
[13] Бакча. *(Авт. иск.)*
[14] Ашлыкчы, игенче. *(Авт. иск.)*
[15] Йийгән – ашаган.
[16] Әҗнәби – чит.

укыла торган китаплардан булып китә алмаган. Укысалар да, аны күбрәк муллалар гына укыганнардыр. Шунысы гаҗәп ки, бу китапта чыгтай әдәбиятында истигъмаль ителми торган борынгы сүз формалары очрый. Мәсәлән, «күчкүсе» формасын без «Йосыф китабы»нда гына очратабыз.

## «Кыйссаи Сәйфелмөлек»

«Сәйфелмөлек кыйссасы»[1] – чыгтай әдәбиятыннан безнең Идел буе татарлары арасына кергән бердәнбер чын дөньяви мәүзугтагы шигъри әсәрләрдән. Бу дастанның охшашларын чыгтай әдәбиятында, хосусан Нәваи шикелле мәшһүр шагыйрьләрнең әсәрләре арасында байтак очратырга мөмкин. Бу китап исә безгә әллә ничек, иттифакый[2] гына кереп калган, чөнки безнең Урта Азия әдәбияты белән танышлыгыбыз муллалар аркылы булганга, алар күбрәк дини әсәрләрне, әдәби булганда да тәсаувыф әдәбияты әсәрләрен генә алып кайтып таратканнар. Аларның да таралуы бигрәк мәктәп аркылы булган. Шуңар күрә бу поэма чыгтай әдәбиятыннан безгә кергән әсәрләр арасында аерым бер урын тота.

«Кыйссаи Сәйфелмөлек» – бәхре һәзәҗ (мөфагыйлен, мөфагыйлен, фагыйлен) вәзенендә нәзым белән язылган, басмада урта кул 72 битле бер китап. Ул бездә бик иртә басылган китаплардан. Аның беренче мәртәбә 1807 елда ук басылуы бу китапның татар халкы арасында электән үк бик укылган әсәр булганлыгын күрсәтә. Ул һичбер вакыт мәдрәсә-мәктәпләрдә дәрес китабы итеп укытылмаган; халык аны бары «хикәят китабы» булу йөзеннән күңел ачар өчен генә укыган. Теленең авырлыгына карамастан, аның халык арасында таралган булуы,

---

[1] «Кыйссаи Сәйфелмөлек» – XV гасыр ахыры – XVI гасыр башында яшәгән шагыйрь Мәҗлиси әсәре. Тумышы белән Харәземнән, аннан Бохарага күчкән, Гобәйдулла хан һәм аның улы Габделгазиз ханнар сараенда хезмәт иткән дип фаразлана.

[2] Иттифакый – очраклы.

халкыбызның әдәбият сөюенә дәлил булып, татарның дөньяви әдәбиятка никадәр сусаган булуын күрсәтә.

«Сәйфелмөлек»нең кайчан язылуы мәгълүм түгел. Теленә караганда ул чыгтай әдәбиятының кәмаләт[1] дәверендә, XV гасырларда язылган булырга тиеш, чөнки аның теле – шул дәвер шагыйрьләре тарафыннан вөҗүдкә китерелгән[2], гарәп-фарсы сүзләре белән ифрат чуарланган әдәби чыгтай теле. Борынгы сүзләр дә анда очрамый, «торур» урынына күбрәк «дур» һәм «дыр» истигъмаль ителә. Аның шушы заманда язылуына тагын бер дәлил бар: ул да булса хикәядә шаһ Гасыймның углы Сәйфелмөлек өчен ясаттырган бакчасын тасвир иткән урындыр. Бу чарбаг[3] кәеф-сафа өчен махсус ясалган. Бу гаҗәеп бакча җәннәт бакчаларыннан бер дә ким түгел. Анда:

«Ачылып йөз түмән[4] гөлләр эчендә,  
Укып хушхан[5] былбыллар эчендә,  
Сөрек сузлар[6] акыб һәр сари[7] шәр-шәр,  
Тулубән хәвызлар мәнында кәүсәр[8],  
Тотыб мәйдан чукушлар голголындин[9],  
Хәбәр бирер Ирамның[10] былбылындин».

Шул бакчада бер күшәк (җиңелчә сарай, павильон) була. Бу күшәк гаҗәп матур һәм искиткеч зиннәтле: ул кыйммәтле ташлар, мозаикалар вә һәртөрле сурәтләр белән бизәлгән:

«Ничә төрле ләтафәтләр[11] дисәң бар,  
Мөляхәт[12] берлә сурәтләр дисәң бар,

[1] Камәләт – камиллек, өлгергәнлек.  
[2] Вөҗүдкә китерелгән – монда: иҗат ителгән.  
[3] Чарбаг – гүзәл бакча.  
[4] Түмән – ун мең.  
[5] Матур сайраучы. *(Авт. иск.)*  
[6] Сөрек сулар булырга кирәк, ага торган сулар. *(Авт. иск.)*  
[7] Һәр тарафка. *(Авт. иск.)*  
[8] Кәүсәргә охшаган. *(Авт. иск.)*  
[9] Голгол – шау-шу, гам. *(Авт. иск.)*  
[10] Шушы хикәядәге хыялый бакча. *(Авт. иск.)*  
[11] Ләтафәтләр – гүзәллекләр.  
[12] Мөнәкъкаш, бизәлгән. *(Авт. иск.)*

Гаҗәеп һәм гарәиб күп мөнәкъкаш,
Ничә баксаң бакарсән хуб дилкәш[1].
Гаҗәеп каср[2] бәләндә[3] сафи алтун,
Морәссаг[4] энжү-мәрҗәндер мәкнүн[5],
Чу якут, гакыйк[6] хишт пәрчин[7] –
Болар берлә гыймарәт кылды[8] рәнгин[9].

Шул гаҗәеп бакчада, гүзәл сарай эчендә шаһзадә яшьлеген «пәри рохсар»лар (гүзәл җарияләр) арасында үзенең дус егетләре белән шәраб эчеп исереп, гыйш-гыйшрәт кылып[10] үткәрә. Менә бу тасвирлар «Сәйфелмөлек» китабында бик җанлы вә матур булып чыкканнар. Ни өчен? Чөнки бу бакчаларны, бу сарайларны, бу тормышны күз алдына китерер өчен, шагыйрьгә бер дә үзенең хыялын көчләргә кирәк булмаган, болар һәммәсе – аның күз алдында булган нәрсәләр. Әгәр без XV гасырда Мавәраэннәһердә хөкүмәт сөргән Тимер нәселеннән килгән әмирләрнең, бәк вә мирзаларның тормышларын күз алдына китерсәк, әгәр без «Бабурнамә»дә[11] тасвир ителгән Сәмәрканд шикелле зур шәһәрләр тирәсендә котчыккыч исрафлар белән мәйданга китерелгән матур бакчаларны (чарбагларны), андагы алтынга, кыйммәтле ташларга манчылган, чынаяк кирпечләрдән эшләнгән, эчләре әнваг[12] төрле паласлар, вазалар, кытай рәссамнары тарафыннан ясалган сурәтләр белән бизәлгән күшәкләрне, сарайларны искә төшерсәк, «Сәйфелмөлек»тәге тасвирларның шул замандагы хакыйкый тормыштан күчерелгән булуында шөбһә калмаячак. Тормышның әдәбиятка тәэсире исә – бик

[1] Йөрәкне өзә торган матур. *(Авт. иск.)*
[2] Каср – сарай.
[3] Зур, олуг. *(Авт. иск.)*
[4] Кыйммәтле ташлар утыртылып ясалган. *(Авт. иск.)*
[5] Тезелгән энҗе. *(Авт. иск.)*
[6] Ахак. *(Авт. иск.)*
[7] Чынаяк, кирпеч. *(Авт. иск.)*
[8] Гыймарәт кылды – төзеде, корды.
[9] Рәнгин – төрле төсле. *(Авт. иск.)*
[10] Гыйш-гыйшрәт кылып – ашап-эчеп, типтереп.
[11] «Бабурнамә» (Бабирның юлъязмалары). *(Авт. иск.)*
[12] Әнваг – төрле.

мәгълүм вә бар нәрсә. Гомумән, һәрбер заманның тормышы шул дәвердә иҗат ителгән сәнаигы нәфисә[1] әсәрләрендә күзгедә гакес итеп[2] күренгән шикелле күренә. Ничек, мәсәлән, Ренессанс дәверендәге[3] Италия рәссамнары үзләренең Тәүрат вә Инҗилдән алынган мәүзугларга ясаган рәсемнәрендәге кешеләрне шул үз гасырларында Италиядә хөкем сөргән мода буенча киендереп, Италия табигате арасында, шул замандагы биналар эчендә итеп ясасалар, шулай ук Урта Азиядә булган, Ренессанс дәверендәге шагыйрь дә үзенең хикәясендәге хыялый Мисыр шаһзадәсенең тормышын үз заманындагы Мавәраэннәһер аристократиясенең тормышына охшатып тасвир иткән.

«Сәйфелмөлек»нең мөәллифе Мәҗлиси имзасы белән яза. Бу Мәҗлиси кем булгандыр, бу кемнең тәхәллүседер, Мәҗлиси дигән шагыйрь чыгтай әдипләре арасында нинди урын тота торгандыр – бу безгә мәгълүм булмады. Чыгтай әдипләренең исемнәре арасында без бу кешене очратканыбыз юк. Ихтимал ки, ул икенче вә өченче дәрәҗәдәге шагыйрьләрдәндер. Китапның берничә төшендә ул үзен Мәҗлиси дип атый. Мәсәлән, «Ходая Мәҗлисигә гашыйк уты сал», «Илаһи Мәҗлисигә кыл гыйнаять[4]», «Шөкер кыл Мәҗлиси, булгыл өмидвар» шикелле.

Шул заманның әдәби гадәте буенча, мөәллиф китабын Аллага хәмед-сәна[5] белән башлый:

«Сәна вә хәмед өчүн тил бирде гүя,
Күңелгә гыйшык бирде, кылды шида[6].
Гаҗәп кадир[7] торур, кодрәтләрен күр,
Гаҗәп санигъ[8] торур, сәнгатьләрен күр».

---

[1] Сәнаигы нәфисә – матур сәнгать.

[2] Гакес итеп – чагылдырып.

[3] Италиядә XV–XVI гасырларда булган интибаһ (уяну, мәдәни күтәрелү) дәвере (эпоха Возрождения). Бу вакытта анда бигрәк тә рәсем сәнгате тәрәккый иткән. *(Авт. иск.)*

[4] Гыйнаять – ярдәм.

[5] Хәмед-сәна – мактау.

[6] Нурландырды. *(Авт. иск.)*

[7] Кадир – көчле.

[8] Санигъ – ясаучы, эшләүче.

Шагыйранә сүзләр белән Алланы тәүсыйф итә[1]:

«Корыган гонҗәләрне[2] хәндан кыладыр[3],
Чу рәхмәт камәрне[4] налән кыладыр[5];
Кылыб былбылы уйкудин пәйдар[6],
Ки кылгай гыйшыкдин бер зәррә изһар
Гыйнаять бәхридин[7] рәхмәт йибәргән,
Фәсахәт[8] суыдин ширбәт йибәргән».

Аннан соң пәйгамбәрне мәдех итеп[9], аның нәгытен[10] сөйләгәннән соң, Ходага мөнәҗәт укый:

«Сәңа төз бакгалы йөздә күзем юк,
Сәңа колмән дикәли һәм йөзүм[11] юк», –

дип тәвазыйглык[12] кыла.

«Мәни[13] мескин оятлыйг өммәте мән,
Якыйн өммәтләренең һәм аты мән», –

дип, үзен хурлый. Шуннан соң гына ул «сәбәбе тәэлиф[14]», ягъни китапның ни өчен һәм ничек язылуы хакында сөйләргә керешә.

Шагыйрь Дантега мәгъшукасы Беатриченың хыялы заһир[15] булып, «Илаһи комедия»не[16] илһам иткәне күк, безнең Мәҗлисигә дә җананының[17] хыялы гәүдәләнеп килеп, бу кыйссаны

[1] Тәүсыйф итә – сыйфатлый.
[2] Чәчәк. *(Авт. иск.)*
[3] Тергезә. *(Авт. иск.)*
[4] Айны. *(Авт. иск.)*
[5] Йөртә. *(Авт. иск.)*
[6] Йокысыз итеп. *(Авт. иск.)*
[7] Гыйнаять бәхридин – ярдәм диңгезеннән.
[8] Фәсахәт – тәмле.
[9] Мәдех итеп – мактап.
[10] Нәгытен – әхлакый сыйфатларын.
[11] «Йөзем» булуы да ихтимал. *(Авт. иск.)*
[12] Тәвазыйглык – түбәнчелек.
[13] Мән, мин; вәзен өчен «и» арттырылган. *(Авт. иск.)*
[14] Сәбәбе тәэлиф – язылу сәбәбе.
[15] Заһир – пәйда.
[16] «Божественная комедия».
[17] Җананының – сөйгән ярының.

язарга әмер итә. Ләкин бу җанан суфиларның җананы булган Алламы, әллә юкса шагыйрьнең мәгъшукасы булган бер-бер кызмы – бу кирәгенчә аңлашылмый. Бер караганда ул – Алла, бер караганда кыз булырга тиешле. Башта Мәҗлиси ничә көннәр буенча хәле пәришан[1] булып, Ходага гыйшкыннан аһ-ваһ итеп, аның фирагыннан[2] күз яше кипми, күзләренә йокы кермичә йөри. Менә көннәрдән бер көнне төшендә аңар җанан килә. Ул гәүдәләнеп («җисем берлә») килә дә, шагыйрьдән сорый: «Хәлең ничек, Мәҗлиси? Фирак утында әхвәлең ничек?» – ди. Шагыйрь аңар күңелен ачып күрсәтә. Җанан шунда язылганнарны укый да, шагыйрьнең күңелендә «төрки теле белән» язылган пакь нәзымнарны күргәч, аңа билгеле бер юл күргәзә: куеныннан шушы дастанны чыгара да әйтә: «Әй Мәҗлиси, юкка вакыт уздырма, кулыңда һөнәрең булса, күрсәт, шушы дәфтәрне төрки теленә төзәт (күчер)», – ди; хәтта нәзымның вәзенен дә күрсәтә. Шулай итеп, җананы күңеленә йөз төрле кайгы салып киткәннән соң, шагыйрьнең күңеле шушы диңгезгә кереп бата. Ходайдан һиммәт теләп эшкә тотына да, язып тәмам итә. Язган вакытында да аңар һаман шул «пәрие яр була»[3]. Шулай итеп, ахырысында аның хыял дигәннәре чәчәклек – гөлзарга әверелә. Менә бу, халис[4] дөньяви гыйшкый бер поэманы илһам кылырга килүче җананны да Алла дип аңларгамы инде? Әллә юкса ул шәрыкның «муза»сымы[5]? Тәсаувыф әдәбияты ноктаи назарыннан караганда, әлбәттә, аны Алла дип тәэвил итәргә имкян[6] юк түгел. Бәгъзы бер суфи шагыйрьләр моннан да болайрак дөньяви җананнарны Алла мәгънәсендә аңларга кушалар. «Сәйфелмөлек» язылган вакыт исә – чыгтай әдәбиятында тәсаувыф идеяләренең

[1] Хәле пәришан – һәлакәткә төшкән, таркау, харап булган хәлдә.
[2] Фирагыннан – аерылышуыннан.
[3] Ягъни мәгъшукасы иптәш була. *(Авт. иск.)*
[4] Халис – саф, чын.
[5] Музалар – борынгы юнан-румалылар игътикадында сәнаигы нәфисә тәңреләре. Алар Аполлонның кызлары булып, 12 кыз сурәтендә тәҗәссем иттерелгәннәр. Шагыйрьләргә илһам бирүче аерым бер муза булган. *(Авт. иск.)*
[6] Тәэвил итәргә имкян – аңлатырга мөмкинлек.

бөтен куәте белән хөкем сөргән вакыты. Чын дөньяви булып, тәсаувыфка һичбер катнашы булмаган бер кыйссаны язганда да, күрәсең, шагыйрь суфилыкка махсус аллегорияләрне кертми котыла алмаган. Тәсаувыф-мистика һәрвакыт бертөсле ул. Мистик Дантеда Беатриченың үзенә «Илаһи комедия»не илһам иткәнен сөйләгәндә, Беатричедан тәкъвалыкны[1] морад итеп ала бит (beatrica – «тәкъвалык» мәгънәсендә). Вәхаләнки[2], Дантеның җанлы-тәнле, хакыйкый Беатричесы да булган. Шулай булса да, ул үзенең пакь әфләтуни[3] гыйшкының идеалын «Илаһи комедия»сендә бер мәҗаз – аллегория итеп кенә ала. Теләгән кеше аны шагыйрьнең мәгъшукасы, Беатриче исемле бер кыз дип, теләгән кеше шагыйрь гашыйк булган тәкъвалыкның мөҗәссәм[4] сурәте дип аңлый ала. Бу да менә безнең Шәрык шагыйрьләренең «Алла» белән «мәгъшука»ны саташтырулары, «яр» яки «җанан» дип тәгъбир кылып[5], бәгъзан аңлашмаслык дәрәҗәдә болгатулары шикелле бернәрсә инде.

Шул ук «Сәйфелмөлек» хикәясен без «Әлфе ләйлә вә ләйлә» хикәяләре арасында да очратабыз. Мөндәриҗәсе, кешеләре, аларның исемнәре анда да нәкъ без тикшерә торган китаптагы белән бертөсле; аерма бары әһәмиятсез тәфсиләттә генә. Шуңар караганда, бу кыйсса «Мең дә бер кичә»дән алынып язылмады микән дип уйларга мөмкин. Әмма мөәллиф үзе бу хакта бер сүз дә әйтми. Хикәяне дә ул башкачарак башлый. Мәҗлисинең хикәясе менә шушы мөкаддимәгә ялганып китә: ниндидер Солтан Мәхмүд[6] бервакытны кәефсезләнеп эче поша башлый. Аның ике вәзире була. Солтан шуларга әйтә: «Мин эч пошудан гаҗиз булдым. Миңа шундый матур бер кыйсса табып китерегез, аны укып, минем күңелем ачылсын. Тик ул кыйсса мин ишетмәгән, мин белмәгән булсын», – ди. Ике вәзир шаһ өчен

[1] Тәкъвалыкны – диндар булуны.
[2] Вәхаләнки – чынлыкта.
[3] Әфләтуни – платоник.
[4] Мөҗәссәм – гәүдәләнгән.
[5] Тәгъбир кылып – бер мәгънә биреп.
[6] Солтан Мәхмүд Газнәви булырга кирәк. *(Авт. иск.)*

йөз данә хикәя язалар, ләкин ул аларның берсен дә кабул итми. Ахырысында, ачуланып, вәзирләрне зинданга яптыра. Вәзирләр хибестә[1] кайгырышып утыралар-утыралар да, бер фикергә килеп, патшага ялваралар: «Син безне чыгарып, фәлән икълимгә[2] җибәр, анда «тансык» хикәятләр бар дип әйтәләр, без табып алып кайтырбыз», – диләр. Шаһ разый була. Вәзирләр бүләкләр белән чит илләргә барып, шушы «Сәйфелмөлек» хикәясен язып алып кайталар. Курка-курка гына кайтсалар да, патша аны яратып, вәзирләренә ирекләрен кайтара. Үзе, кәефләнеп, дастанны укуга мәшгуль була. Шуннан соң Мәҗлиси әйтә:

«Вәли[3] ул нөсхәде[4] фарси вә нәсер[5]
Ирер садә хикәят, сүзе һәм касыр[6]
Кылыбтыр Мәҗлиси бу сүзи пәрваз[7],
Укысаң кылыр җан кошы пәрваз[8]».

Димәк, бу бәйтләрдән аңлашылуынча, Мәҗлисинең күз алдында булып, Солтан Мәхмүд исеме белән бәйләнгән нөсхә фарсы телендә нәсер белән язылган һәм кыскарак булган. Мәҗлиси аны үзенең хыялы белән эшләп чыгарып, шушы поэма хәленә куя. Уйларга мөмкин ки, фарсыча нәсер белән язылган «Сәйфелмөлек» кыйссасы чынлап та булгандыр, ихтимал ки, ул, шул ук «Әлфе ләйлә»дән алынып, берәү-берәү тарафыннан үзгәртелгән булгандыр. Мәҗлиси аның кыска булуын әйтеп китә; «Әлфе ләйлә»дәге хикәядә Мәҗлисинең дастанына караганда өч өлеш чамасы кыска. Ләкин кыйссаның мөкаддимәсе[9] «Әлфе ләйлә»дә бөтенләй башка төрле; ул анда Солтан Мәхмүдкә

---

[1] Хибестә – зинданда.
[2] Икълимгә – җиргә.
[3] Ләкин. *(Авт. иск.)*
[4] Нөсхәде – нөсхә иде.
[5] Дөреслектә «нәсер» (نثر) булып, хатаян «с» (س) белән басылган булырга кирәк. *(Авт. иск.)*
[6] Кыска. *(Авт. иск.)*
[7] Канатландырды. *(Авт. иск.)*
[8] Очар. *(Авт. иск.)*
[9] Мөкаддимәсе – кереше.

нисбәт бирелми. Түбәндә хикәянең кыскача мөндәриҗәсен сөйләп, аермалы урыннарын «Әлфе ләйлә»дәге вариант белән чагыштырып китәбез.

Мисырда Гасыйм бине Сафуан атлы бер патша була. Яше йөз җитмешкә җиткән булса да, аның баласы юк икән, шуңар ул бик кайгыра. Бәкләр, җыелып, бу хакта киңәшәләр дә, мөнәҗҗимнәргә[1] мөрәҗәгать итәргә мәгъкуль[2] табалар. Мөнәҗҗимнәр исә, патшага Йәмән солтанының кызын алырга кушалар. Шаһ шул кызны алып, аннан бер углы була, атын Сәйфелмөлек куялар. «Әлфе ләйлә»дә хикәянең башы башка төрлерәк башлана: анда шаһның хатыны булса да, баласы булмый. Ул, киңәш сорап, Сөләйман пәйгамбәргә мөрәҗәгать итә. Сөләйман аңар бу хакта бер киңәш биреп, нәтиҗәсендә шаһның углы була. Безнең «Сәйфелмөлек» китабында патшаның Йәмән солтанының кызын алуы ничек тәфсилләп сөйләнсә, «Әлфе ләйлә»дә вәзире Фарисның Сөләйман хозурына илче булып баруы шулай озыннан сөйләнә. «Әлфе ләйлә»дә шаһ углын үз урынына патша итә, әмма безнең китапта бу юк. Бәлки атасы Сәйфелмөлеккә бакча ясатып биреп, шаһзадәнең шунда гыйш-гыйшрәт кылуын тасвир шактый урын ала. Һәр ике вариант буенча, вәзир углы Сәгыйд шаһзадәнең дусты вә иптәше була. Көннәрдән бер көнне атасы Сәйфелмөлеккә бер кием белән бер йөзек бүләк итеп бирә. Безнең «Кыйсса» буенча, бу әйберләрне Сөләйман пәйгамбәр, үлгәндә, шаһ Гасыймга васыять итеп калдырган була, әмма, «Әлфе ләйлә» буенча, үзе исән чагында бүләк итеп бирә.

Менә «Мең дә бер кичә»дәге Сәйфелмөлек хикәясе белән безнең китап арасында шундый әһәмиятсез генә аермалар бар. Алар да хикәянең ахырына якынлашкан саен азаялар. Шулай булса да, бу аермалар безне Мәҗлисинең «Әлфе ләйлә»дән турыдан-туры файдаланып язуы хакында шөбһәгә төшерү өчен җитәрлек. Без монда, әлбәттә, мөндәриҗә ягыннан булган аермаларны гына күрсәттек, әмма өслүб вә тасвирларда Мәҗлиси

[1] Мөнәҗҗимнәргә – йолдыз күзәтүчеләргә, астрономнарга.
[2] Мәгъкуль – кирәк.

бөтенләй үз юлы белән бара. Мәсәлән, алыйк Зәнки кызының тәүсыйфын: бу шигъри тәүсыйф тәмамән шагыйрьнең үз хыялыннан туган булырга кирәк, чөнки «Әлфе ләйлә»дә аның эзе дә юк. «Әлфе ләйлә»дә булмаган шундый гүзәл тасвирларны «Сәйфелмөлек» китабында без бик күп очратабыз (мәсәлән, шаһзадәнең чарбагы[1], диңгез өстендә давыл, диюләр белән пәриләр[2] гаскәренең сугышы шикелле). Гомумән, Мәҗлисинең дастаны, әдәбилек вә шигърият ягыннан коры вакыйгаларны тезүдән гыйбарәт булган «Әлфе ләйлә» хикәясенә караганда бик күп алда тора. Хасыйле кәлям[3], мәүзугының мөстәгар[4] булуы Мәҗлисинең поэмасына кимчелек китерми, аның үзенә бертөрле әсәр булуына манигъ[5] булмый.

Кыйссаның мөндәриҗәсен сөйләүдә дәвам итәбез: Сәйфелмөлек атасы биргән кием өстенә ясалган бик матур бер кыз сурәтен күреп, шәрык хикәяләрендәгечә гашыйк була. Ашау-эчүдән калып, саргаеп, тәмам авыруга сабыша. Бу кыз пәриләр патшасы Шаһбалның Бәдигыльҗәмал исемле кызы булып, дөньяда инсаннардан һичкемгә мәгълүм булмаган Ирам багы дигән бакчада тора икән. Шаһ Гасыйм, углының хәле дәвасыз гыйшык сәбәпле көннән-көн начарланганын күреп, шул яшерен мәмләкәтне эзләргә дөньяның дүрт тарафына сәйяхлар[6] җибәрә. Ләкин аларның һичберсе бернәрсә белә алмый кайталар. Шуннан соң Сәйфелмөлек үзе эзләргә чыкмакчы була. Дүрт йөз кораб, йөз мең кеше белән юлга чыгалар. Кытай мәмләкәтенә барып җитәләр, анда да тукталмый юлларында дәвам итәләр. Сәйфелмөлек, диңгез өстендә барганда, бертуктаусыз гыйш-гыйшрәт, шәраб эчү белән мәшгуль була, иптәшләре белән бер көймәдән бер көймәгә күчә-күчә эчәләр. (Ихтыяр-

[1] Чарбагы – гүзәл бакчасы.
[2] Иран мифологиясендә диюләр – явыз рухлар, пәриләр – яхшы рухлар. *(Авт. иск.)*
[3] Хасыйле кәлям – кыска гына әйткәндә.
[4] Мәүзугының мөстәгар – сюжетының алынган.
[5] Манигъ – киртә.
[6] Сәйяхлар – сәяхәтчеләр.

сыз, моны Бабир патшаның көймә өсләрендә ясаган «чагыр мәҗлесләре» белән чагыштырасы килә.) Менә көннәрдән бер көнне давыл чыгып, һәммә кораблар баталар. Шаһзадә берничә хезмәткәрләре белән бер тактага ябышып котыла. Шуннан соң аның төрле мәшәкатьләре башлана. Нинди, нинди генә бәлаләргә очрамыйлар алар! Аларны зәнгиләр[1] (зәнҗиләр) тотып алып, зәнги патшасының котчыккыч ямьсез кызы Сәйфелмөлекне үзенең гыйшкы белән гаҗиз итә. Мәймуллар мәмләкәтенә эләгеп, анда аңар, көчләп, эт башлы кызны никахлап бирәләр. Ул кош аягына ябышып та оча, аждаһа белән дә сугыша, юлбарыска очрап, аны да үтерә, таки[2] аның эшләгән каһарманлыкларына «Мирих афәрин кыла»[3]. Бу маҗараларда безнең кыйсса белән «Әлфе ләйлә» варианты арасында шактый үзгәлек бар, гомумән, бу маҗаралар (сәяхларның юлда һәртөрле бәлаләргә очраулары) – Шәрыкта ясалган хикәяләр өчен бик характерлы әйбер. Бер «Әлфе ләйлә»дә генә шул төрле хикәяләрне бик күп очратып була. (Алар арасында иң типичный булганы «Синбад бәхре»нең сәяхәтләре[4]). Риваядә (эпос) бу – бик таралган жанр. Борынгы юнан[5] мифологиясендәге Тезейның вакыйгалары, борынгы юнан шагыйре Һомәрнең «Одиссея» исемле мәшһүр поэмасы – шул җөмләдән булган типичный әсәрләрдән.

Күп йөри торгач, ахырысында Сәйфелмөлек бер бакчада бер дию тарафыннан тоткын ителгән, Бәдигыльҗәмалнең сөт кардәше – Мәликә исемле кызны очрата («Әлфе ләйлә»дә аның исеме – Дәүләт-Хатын). Кулындагы Сөләйман пәйгамбәр йөзеге аркасында ул, диюне үтереп, кызны коткара. Мәликә белән икесе аның мәмләкәтенә кайтып, шунда Бәдигыльҗәмал да күрешә килеп, Сәйфелмөлек белән очрашалар. Туй була дип

[1] Зәнгиләр – кара тәнлеләр.

[2] Таки – шуның белән.

[3] Мирих (мерих) – Марс – җиде сәйярәдән *(планетадан)* берсе. Фарсыда Тимердән киная итеп тә әйтелә. Борынгы румалыларда Марс сугыш тәңресе булган. Монда юнан тәэсире юк микән? *(Авт. иск.)*

[4] «Приключения Синбада-морехода». *(Авт. иск.)*

[5] Юнан – грек.

кенә торганда, тагын бер бәла чыга. Теге, Сәйфелмөлек үтергән дию – Кылзәм шаһының углы икән. Аның үчен алу өчен, диюләр аны, Ирам багыннан урлап алып китеп, хибес итәләр[1] һәм үтермәкче булалар. Сәйфелмөлек өчен диюләр белән пәриләр арасында бик каты сугыш булып, ахырда пәриләр җиңеп, шаһларының киявен коткаралар. Шулай итеп, ахирел әмер[2] ике гашыйк кавышып, Сәйфелмөлек патша булып, бик рәхәт гомер сөрә башлыйлар. Мәҗлиси үзенең дастанын шактый гына озын бер хатимә[3] белән тәмам итә; бу китапны укып, үзен яд итәргә[4] үтенә; кыйссадан хисса чыгарып, түбәндәге бәйтләрне яза:

«Җәфа чикмәй кешегә рәхәт улмас,
Әгәр көймәс утынга җуш[5] булмас.
Чу диһкан[6] чәкмәсә җәүр[7] вә җәфасын,
Йимешләрнең кеше күрмәс вафасын[8]».

Мәшһүр маҗар[9] мөстәшригы Вамбери үзенең «Чыгтай теле дәресләре» исемле китабында «Сәйфелмөлек кыйссасы»ннан берничә кыйтга китерә[10]. Ул аларны бу китапның Лондондагы «Шәркый Һиндстан көтебханәсе» аталган көтебханәдә саклана торган нөсхәсеннән күчергән. Менә шул кыйтгаларны безнең Казанда басылган «Сәйфелмөлек»нең шул ук урыннары белән кара-каршы китереп караганда, ике нөсхәнең текстында бик зур аерма булганлыгы күренә: аерым сүзләрдә генә түгел, хәтта бөтен-бөтен җөмләләрдә үзгәлекләр бар. Мөндәриҗә бер үк булган хәлдә, бу ике нөсхәдә бер-берсенең нәкъ копиясе булган ике бәйтне очратуы читен. Язма китапларның күчерүчеләр кулы белән никадәр үзгәртелүенә бу бик ачык бер мисал булса кирәк.

[1] Хибес итәләр – ябып куялар.
[2] Ахирел әмер – иң ахырда.
[3] Хатимә – эпилог.
[4] Яд итәргә – искә, телгә алуны.
[5] Җуш – төтен.
[6] Диһкан – игенче.
[7] Җәүр – газап, рәнҗеш.
[8] Вафасын – тугрылыгын. Монда: рәхәтен.
[9] Маҗар – венгр.
[10] H.Vamberi. «Die dschagataische Sprachstudien. *(Авт. иск.)*

**«Сөбат әл-гаҗизин»**

Чыгтай әдәбиятының соңгы дәверендәге әсәрләрдән булган «Сөбат әл-гаҗизин»[1] китабы – безнең Идел буе татарлары арасында бик таралган, бик мәшһүр китаплардан берсе. Ул күптәннән бирле безнең ысулы кадим мәктәпләрендә дәреслек итеп кулланылган. «Сөбат әл-гаҗизин» – бездә иң иртә басылган китаплардан: ул Казанда «Азиатская типография» ачылгач та, 1802 елда «Устувани» һәм «Пиргули» китаплары белән бер елны басылган. Шуңар караганда күренә ки, бу китап безнең халык арасында XVIII гасырда ук укыла килгән һәм кирәге зур булган. Ихтимал, ул безнең Идел буена язылуыннан бик аз гына соң килгәндер.

«Сөбат әл-гаҗизин»ның язылуына, булса да, 200 елдан аз гына артык булырга кирәк; чөнки аның мөәллифе[2] Суфи Аллаяр милади XVIII гасыр башында вафат булган. Аллаяр Суфиның тәрҗемәи хәленә гаид[3] мәгълүматны без үзебезнең Идел буенда «Сөбат әл-гаҗизин»га шәрех итеп язылган «Рисаләи Газизә» исемле китаптан алабыз. Ул мәгълүмат менә шуннан гыйбарәт: Сәмәрканд илендә Миңлән дигән авылда Тимерьяр исемле бер кеше торган. Аның төп нәселе нугайдан (ягъни татардан) булган, имеш. Менә шул кеше үзенең Аллаяр исемле углын, Бохарага китереп, мәдрәсәгә укырга сала. 25 яшенә хәтле укып, күп гыйлем тәхсил иткәч[4], Бохара әмире аны Баҗ мәхкәмәсе дигән мәхкәмәгә түрә итеп куя (бу – сатудан пошлина җыя торган мәхкәмә булырга кирәк). Аллаяр ифрат холыксыз, явыз, кан түгүче бер түрә булып чыгып, бөтен эше «фисык, фөҗүр[5] вә гыйсъян»

---

[1] «Сөбат әл-гаҗизин» («Гаҗизләргә терәк») – суфи шагыйрь Суфи Аллаһияр (Аллаяр, 1616, яки 1630–1713, яки 1723) иҗат иткән әсәр. Бохара шәһәрендә яшәгән. «Морад әл-гарифин» («Укымышлыларның максаты»), «Мәсләк әл-мөттәкыйн» («Тәкъвалар юлы»), «Мәхзән әл-мотыйгыйн» («Күндәмнәрнең хәзинәсе») кебек суфичылык рухындагы әсәрләре мәгълүм.

[2] Мөәллифе – язучысы.

[3] Гаид – караган.

[4] Гыйлем тәхсил иткәч – гыйлем алгач.

[5] Фисык, фөҗүр – начарлык, закон бозу.

була; халыкны бик рәнҗетә. Бу вакытта Бохарада хөкүмәт күзеннән яшерен рәвештәрәк мөридләр тәрбия итә торган шәех Хәбибулла атлы бик изге бер ишан бар икән. Көннәрдән бер көнне шул ишанның мөридләреннән берсе Ристан базарыннан бер әйбер сатып алып кайтып барганда, юлда Аллаяр түрә очрый да: «Ни өчен Баҗ мәхкәмәсендә тамгалатмыйча базардан әйбер алдың?» – дип, мөриднең башларын ярганчы камчы белән кыйный. Мөрид шәехе хозурына барып түрәдән зарлангач, шәех: «Бу түрәне дә шушы мөридләр күк гариб күңелле кыл», – дип дога кыла. Шул сәгатьтә Аллаяр түрәнең вөҗданы газаплана башлап, кылган явызлыкларына үкенеп, җыларга тотына. Шул вакытта ул, беренче мәртәбә «телен ачып», түбәндәге бәйтләрне әйтә:

«Бәнем башымга хуш сәүда[1] дөшебдер,
Күңел базарына гауга дөшебдер,
Дидем: «И тән, нә сәүдадыр, нә эшдер?
Сәпәһеңә[2] кылыч берлә орышдыр».

Шуннан соң ул Хәбибулла ишанның ханәкасына[3] барып, хозурында тез чүгеп, аның сабагына утырырга иҗазәт тели[4]. Шәех, башта: «Сезнең күк түрәләрнең урыны монда түгел, бу – гарибләр урыны», – дип, аны кире какса да, Аллаяр зар-зар елагач, мөридлеккә кабул итәргә риза була, ләкин аның горурдан ваз кичүен имтихан өчен ике эш куша: иң элек ул, шәһәрдә булган бөтен өйләргә кереп, теләнчелек кылып чыгарга тиеш; икенчеләй – касабәгә[5] барып, бер куйның башын, аягын, эчәкләрен Бохара урамнары буенча күтәреп алып килергә тиеш. Аллаяр бу эшләргә риза була. Аның хәер соравын, шакшы эчәгеләрне баш түбәсенә күтәргән хәлдә урамда йөрүен күреп, бөтен белеш-танышлары һәм гаиләсе Аллаяр түрә акылдан язган дип

[1] Гамь, кайгы, гыйшык хәсрәте. *(Авт. иск.)*
[2] Гаскәр. *(Авт. иск.)*
[3] Ханәка – суфиларның, дәрвишләрнең тора торган урыны.
[4] Иҗазәт тели – рөхсәт итүен сорый.
[5] Касабәгә – шәһәргә.

уйлыйлар. Шушы тәҗрибәдән соң гына шәех аны мөридлеккә кабул итеп, Аллаяр анының хезмәтендә унике ел тора. Тәсаувыфта югары дәрәҗәләргә ирешеп, «суфи» ләкабен[1] ала. Суфи Аллаяр милади 1713 елда Бохарада вафат булган. Үз гомерендә ул дүрт китап тасниф иткән[2]; ул китапларның исемнәре шушы: «Мәсләк әл-мөттәкыйн», «Мәхзән әл-мотыйгыйн», «Морад әл-гарифин», «Сөбат әл-гаҗизин». Бу дүрт китаптан соңгы икесе Казанда басылган.

Менә бу тәрҗемәи хәлдә легендага охшаган вакыйгалар булса да, башка шәехләрнекендәге шикелле харикылгадә[3] эшләр юк. Хәтта, киресенчә, залим түрәнең бер ишанның рухани тәэсире астында тәүбә итеп дәрвишкә әверелүе – моннан ике-өч йөз ел элекке Бохара галәме өчен бик гади (типичный, характерный) вакыйга. Бу заманда (Тимер сөләләсе[4] гасырыннан соң) Бохарада мәдәни бер түбәнләшүгә таба бару белән бергә, бер яктан, һәртөрле бозыклык вә золымның көчәюен, икенче яктан, дини тәгассыбның[5] чиксез куәтләнүен, тәсаувыф идеологиясенең чын мәгънәсе белән тормышка кереп баруын күрәбез. Бохара ханнарыннан өч хан, бер-бер артлы тәхетләрен ташлап, дәрвишләр киеме киенеп, хаҗга китәләр. Соңгы Мангыт сөләләсенең беренче ханнарыннан Мәгъсүм хан белән улы Сәгыйд хан, икесе дә таҗлы дәрвишләр буларак, Бохара тәхетендә хөкем сөрәләр. Үзләре патша булуга карамастан, алар һәрвакыт, өсләренә ертык, иске дәрвиш киемнәре киеп, дәрвишләрчә яшәгәннәр. Ләкин шул ук вакытта дәрвишлекләре аларның халыкка җәбер-золым кылуларына, сугышларда меңнәрчә дин кардәшләренең канын агызуга тамчы кадәр дә уңайсызламаган. Заманасының мәшһүр шәехләреннән шәех Кәзим Газизәнне зиярәт өчен Кәрминәгә барганда, Шәйбани Габдулла хан җәяү, яланбаш, муенына аркан тагып, арканның очын бер

[1] Ләкабен – кушаматын.
[2] Тасниф иткән – язган.
[3] Харикылгадә – гадәттән тыш.
[4] Сөләләсе – династиясе.
[5] Тәгассыбның – фанатизмның.

атлыга тоттырып барганын риваять итәләр[1]. Гомумән, соңгы гасырларда Бохарада руханиларның тәэсире шулкадәр куәтләнгән ки, халык гаммәсе[2] каршында гына түгел, хәтта югары – хаким сыйныфлар каршында да аларның авторитеты камил булган. Хакимиятләре һичбер нәрсә белән чикләнмәгән ханнар, әмирләр, үзләре алардан котлары чыгып, сүзләренә буйсына торган булганнар. Менә шундый мохитне күз алдына китергәндә, залим түрә Аллаярның көннәрдән бер көнне тәүбә итеп суфилыкка салышуы, тәүбә йөзеннән үзенә һәртөрле хурлыклы вазифалар йөкләве бер дә искиткеч эш булып күренми. «Рисаләи Газизә» язылган вакытта Суфи Аллаярның вафатына бер гасырдан артык булмавына карап та, аның мөхәрриренең биргән мәгълүматы хакыйкатьтән артык ерак булмавы белән хөкем итәргә мөмкин. Әмма бу мәгълүматны ул кайдан алгандыр – безгә мәгълүм булмады.

«Сөбат әл-гаҗизин» – бәхре һәзәҗ (мөфагыйлен, мөфагыйлен, фагыйлен) вәзенендә нәзым белән язылган, басмада урта кул 64 битле бер китап. Аның эчендәге бәйтләрдән аңлашылуына күрә, Суфи Аллаяр элек фарсы телендә 12 мең бәйттән гыйбарәт зур бер әсәр язган булган. Соңыннан, дусларының үтенүе буенча, ул аны кыскартып, төрки телендә шушы китапны тасниф кылган. Китапның башында, «сәбәбе тәэлиф»не[3] сөйләгән урында, без шушы бәйтләрне укыйбыз:

«Язылды фарсы теле берлә мәктүб,
Гакыйдәт вә фөруг вә кариб мәхбүб[4]
Ани ким күрдиләр төрки яранлар[5]
Диделәр гәр дога кылса ирәнләр[6],

[1] Вамбери. «История Бухары». *(Авт. иск.)*
[2] Гаммәсе – массасы.
[3] Сәбәбе тәэлифне – төзүне, язуның сәбәбен.
[4] Мәхбүбнең якынлыгы. *(Авт. иск.)*
[5] Дуслар. *(Авт. иск.)*
[6] Ирләр, кешеләр. *(Авт. иск.)*

Бителсә[1] төрки тел берлә гакыйдә[2],
Күңелләр булса андин әрамидә[3],
Тәмәллык кылдылар[4] чөн берничә яр,
Каләм таратай Хода булсын мөдәдкяр[5].
Вә ләкин әйлаян сүзләрне иҗмал[6],
Мәңа юкдыр мөфассал[7] кылгалы хәл».
..................................................
«Аларның сүзләрене бозмаен зар
Сәвад иттем[8] ничә мәнзумә нәчар[9].
Гакыйдә сүзләрене кылдым исбат,
Аңа куйдым «Сөбат әл-гаҗизин» ат».

Китапның ахырындарак мөәллиф әйтә:

«Әгәр булса күңелне[10] ихтыяры,
Нә булгай калса мәндин ядкәре.
Битебсән[11] фарсы теледин китабы,
Тәмам анда мәсаилне җавабы[12].
Һәммә фәтва вә тәкъва ни җавабы,
Унике меңдин артык бәйт аны.
Диден шәй калилне[13] төрки телдин
Кич имди, әлбәттә, бу каль вә кыйльдин[14]».

«Сөбат әл-гаҗизин» китабы төрле зурлыкта вә төрле исемдә булган вак-вак бүлекләргә – фасылларга аерыла. Фасылларның

[1] Бителсә – язылса.
[2] Гакыйдә – ышану, иман.
[3] Шат. *(Авт. иск.)*
[4] Кечелек һәм мөлаемлык белән үтенделәр. *(Авт. иск.)*
[5] Ярдәмче. *(Авт. иск.)*
[6] Иҗмал – кыскартып.
[7] Мөфассал – тулы, җентекле.
[8] Караладым. *(Авт. иск.)*
[9] Чарасыз. *(Авт. иск.)*
[10] Күңелнең. *(Авт. иск.)*
[11] Язгансың. *(Авт. иск.)*
[12] Тәмам анда мәсаилне җавабы – барлык мәсьәләләргә дә (сорауларга) тулы җавап бар.
[13] Аз нәрсә сөйләдең. *(Авт. иск.)*
[14] Каль вә кыйль – имеш-мимеш, юк-бар сүз.

иң озыны ике биттән артык түгел, арада берничә генә юллы булганнары да бар. Китапның мөндәриҗәсе белән таныштыру өчен, түбәндә берничә фасылның сәрләүхәләрен[1] язып китәбез: «Аллаһы Тәгаләнең мәгърифәтененең бәяны», «Фәрештәләрнең бәяны», «Газабе кабернең бәяны», «Сыйрат күпере бәяны», «Салик[2] риза мәкамин[3] итмәкнең бәяны», «Салик казага разый булмак, бәлага сабыр кылмак бәяны», «Тәмугтан качмак хакында», «Дөньядан тәҗәрред[4] хакында», «Тәкәбберлек галимнәрнең бәяны», «Ике мөэмин бер-берегә хәер кылмакның бәяны», «Талибның[5] хирыс гыйшыкта булмагының бәяны», «Гомернең фани улмакының бәяны», «Яхшы юлдашның бәяны», «Фәкыйрьләрне хәкыйрь күрмәмәк вә диндарны артык күрмәк».

Күренә ки, «Сөбат әл-гаҗизин»нең мөндәриҗәсе күбрәк тәсаувыф буявына буялган вәгазь-нәсыйхәттән, кешене яхшы булырга өндәүдән гыйбарәт икән. Моннан башка тагын анда чын тәсаувыфи лирикага керә торган шигырьләр дә юк түгел. Мәсәлән, «Мосаннифның[6] шикәстә нәфеслек[7] кылганы», «Мосанниф карилыкдин пошаман булганының[8] бәяны» шикелле фасыллар, мосаннифның васыяте һәм углына хитабән[9] язган шигыре, мөнәҗәтләре – шул җөмләдән. Бу шигырьләрдә язучы, суфи шагыйрьләр гадәтенчә, үз хиссиятен, үз халәте руханиясен сөйли. Аннан башка тагы арага байтак кына вак-вак хикәятләр дә сибелгән. Күбесенчә, һәрбер фасылдан соң шунда сөйләнгән вәгазь өчен иллюстрация итеп, бер-бер гыйбрәтле хикәя китерелә. Бу хикәяләр күбрәк изге кешеләр, әүлия вә суфилар тормышыннан алынган төрле вакыйгаларны тасвир итәләр. Бәгъзан

[1] Сәрләүхәләрен – исемнәрен.
[2] Салик («сөлүк»тән) – тәсаувыф юлы белән баручы. *(Авт. иск.)*
[3] Алланың ризалыгын. *(Авт. иск.)*
[4] Дөньядан аерылу. *(Авт. иск.)*
[5] Алланы эзләүче мөрид. *(Авт. иск.)*
[6] Мосаннифның – китап төзүченең.
[7] Нәфесне сындыру. *(Авт. иск.)*
[8] Карилыкдин пошаман булганының – картлыкта үкенгәненең. *(Авт. иск.)*
[9] Хитабән – эндәшеп.

бер-бер кешенең бер-бер сөальгә[1] биргән җавабы да «хикәят» урынына тора.

Хуҗа Әхмәд Ясәвинең «Диване хикмәт»ендә булган тәсаувыфи тирәнлекне без «Сөбат әл-гаҗизин»дә таба алмыйбыз. Гами[2] мөселманнар өчен халыкны «туры юлга күндерү» максаты белән язылган бер китапның шулай булуы, әлбәттә, табигый дә. Ләкин Аллаяр Суфины бөтенләй үк шигърияттән буш кеше дип әйтеп булмый. Тәсаувыфның шигъриятен тәшкил итә торган гыйшык идеясе бу китапка да керми калмаган. Мәсәлән, бер урында Суфи Аллаяр әйтә:

«Бер Ходай гыйшкыда диванадыр мән гакыйбәт[3],
Хуш гаҗәиб сәүдәне салды башыма анд[4].
Бикарар[5] вә бинәва[6] вә мозтариб[7] идәрәмен,
Ләйлә-Мәҗнүн кеби әфсанәдер[8] мән дәрҗиһан[9]».

Икенче җирдән аның шәраб вә мәхәббәт хакындагы шушы сәтырларын күчерәбез:

«Кил, әй сакый, икәүлән[10] әйләлиң шәраб[11],
Ушал шәрбикә халык андин табар кариб[12],
Шәраби бир ки, дел[13] андин булур саху[14],
Кылыр бер мөддәгадин[15] үзгәне мәхү[16].

---

[1] Сөальгә – сорауга.
[2] Гами – надан.
[3] Гакыйбәт – ахыр.
[4] Анд – шулкадәр күп.
[5] Карарсыз. *(Авт. иск.)*
[6] Азыксыз. *(Авт. иск.)*
[7] Взволнован. *(Авт. иск.)*
[8] Әфсанәдер – хыялыйдыр.
[9] Дөньяда. *(Авт. иск.)*
[10] Икәү. *(Авт. иск.)*
[11] Эчик. *(Авт. иск.)*
[12] Шундый эчү ки, халык аннан (Аллага) якынлык табар. *(Авт. иск.)*
[13] Күңел. *(Авт. иск.)*
[14] Саху – аек булу.
[15] Дәгъва кылынмыш нәрсә (Алла). *(Авт. иск.)*
[16] Юк итә. *(Авт. иск.)*

Әгәр Фагфур Чин[1] дәр Кайсар Рум[2],
Мәхәббәт әһленең алдында мәгъдүм[3].
Мәхәббәт җамидин[4] тапса кеше бәһер[5],
Нә кылсын милек вә мал Мавәраэннәһер[6].
Күңел гел милкегә бер гали сыйфатдыр,
Мәхәббәт кәнеҗ баг мәгърифәтдер[7]».

Суфилыкка махсус булган үз-үзеңне хурлау, шелтәләү, иң начар, хәкыйрь[8], гөнаһлы бәндәләрдән хисаплауны да без Аллаярның шигырьләрендә очратабыз. Мәсәлән, ул углын нәсыйхәтләп әйтә:

«Билеңне багла мөхкәм[9] бәндәлеккә,
Атаңдәк[10] куйма йөз шәрмәндәликкә[11].
Мәхәббәт фүтәсин[12] багла билкә,
Атаңдәк гомереңне үткәрмә йилгә».

Әхлак мәсьәләсенә килгәндә, «Сөбат әл-гаҗизин» мөхәррире бу яктан бик «югары» тора. Аның әхлакый кагыйдәләре христианлыктагы кагыйдәләр белән бер: ул һәрбер авырлыкка, җәза-җәфага кәмале тәхәммел[13] вә сабыр белән җавап бирергә, зарланмый чыдарга куша:

«Кил, әй инсан, әгәр булсаң чын ирдәк[14],
Агыйрлык пишә кыл[15] дөньяда йирдәк[16].

[1] Кытай патшасы. *(Авт. иск.)*
[2] Рума императоры. *(Авт. иск.)*
[3] Юк. *(Авт. иск.)*
[4] Касәсеннән. *(Авт. иск.)*
[5] Өлеш. *(Авт. иск.)*
[6] Мавәраэннәһернең бөтен малы вә байлыгы белән нишләсен. *(Авт. иск.)*
[7] Мәхәббәт мәгърифәт бакчасының хәзинәседер. *(Авт. иск.)*
[8] Хәкыйрь – кадерсез.
[9] Мөхкәм – таза, чыдам.
[10] Атаң шикелле. *(Авт. иск.)*
[11] Оятсызлыкка. *(Авт. иск.)*
[12] Пута, билбау. *(Авт. иск.)*
[13] Кәмале тәхәммел – чыдам.
[14] Ир күк. *(Авт. иск.)*
[15] Күтәр. *(Авт. иск.)*
[16] Җир шикелле. *(Авт. иск.)*

Әгәр типсә сәне һәркайсы мәүҗүд[1],
Зыян итмә тәкый тикүр[2] анга сүд[3]».

Дошманнар белән мөгамәлә хакында сөйләгәндә ул әйтә:

«Атаң сәнең ирдәк кылыйк кыл[4],
Яманлык әйләгәнгә яхшылык кыл,
Кеше таш орса башә, әй хоҗәстә[5],
Көлеб бакгыл йөзигә мисле бәстә[6]».

Аныңча, шул вакытта гына син чын кеше вә яхшы мөселман буласың:

«Әгәр дошманга дустлык кылсаң изһар,
Башың ярган кешеләрне дисең яр».

Бу хакта сөйләгәннән соң, ул, үзенең сүзенә куәт бирү өчен, Мөхәммәд пәйгамбәрнең Өхед сугышында Мәккә кяферләре белән булган мөгамәләсен китерә:

«Өхед тагында пәйгамбәр төшене[7]
Шәһид итде янә йитмеш кешене.
Гаҗәб көн төште мөэминләр башына.
Гомәр кылды пәйгамбәрнең кашыга,
Диди еглаб: «Әйя солтан әбрар[8],
Дога кылгыл, кырылсын барча кяфер».
Вә ләкин кылмады ул дәгъват бәд[9]
Һидаяткә[10] дога кылды Мөхәммәд».

Ләкин шундый гали әхлак кагыйдәләре белән бергә үк Аллаярның хатыннарга карашы бик түбән, чын-чын шәрыкча. Ул

[1] Кем генә булса да. *(Авт. иск.)*
[2] Тибәр. *(Авт. иск.)*
[3] Файда. *(Авт. иск.)*
[4] Гамәл кыл, эшлә. *(Авт. иск.)*
[5] Мөбарәк. *(Авт. иск.)*
[6] Оялган күк. *(Авт. иск.)*
[7] Өхед сугышы алдыннан Мөхәммәд пәйгамбәрнең төш күрүенә ишарә.
[8] Әбрар – изге.
[9] Бәддога. *(Авт. иск.)*
[10] Һидаяткә – туры юлга керүгә.

аларны ирләрнең колы гына түгел, хәтта мәхыз[1] аларның рәхәте өчен булган җансыз җиһаз хөкеменә төшерә:

«Хуш[2], ул зән[3] белмәсә биһүдә дирне[4],
Сөчүк ләфзы[5] белән шад итсә ирне,
Әгәр ун ел аенда булмаса ун,
Өне[6] чыкмас уны[7] әйтергә бер көн,
Билүраер алдыдә дадәк[8] үзене
Вә гәр йөз тибсә, кайтармас йөзене[9]».

Менә Аллаярның хатыннар хакындагы идеалы шушы. Шушындый, ире йөзенә типкәндә дә йөзен читкә тайчылдырмый торган хатынны ул «бу дөньяның җәннәте» дип атый. Матурлыкларына кызыгып, шул идеалга туры килмәгән кызларны алмаска киңәш итә; «яман хатын – шайтан камчысыдыр», ди. «Сөбат әл-гаҗизин» хиҗаб мәсьәләсендә безнең татар мөтәгассыйбларына рәһбәр[10] булып килгән. Качу мәсьәләсендә алар бу китаптагы сүзләрне Коръән аяте урынында дәлил итеп китергәннәр. Татар хатынының чапан астына яшерелеп, дүрт стена арасына тыгылуы юлында бу китап иң зур роль уйнаган гамилләрдән[11] саналырга тиеш. Суфи Аллаяр хатыннарга йөзләрен яшерергә куша, моңар дәлил итеп, ул пәйгамбәрнең хатыннарына сукыр хәерчедән дә качарга боеруы хакындагы мәшһүр хикәяне китерә. Гайрәт сахибе[12] булган ирләргә ул хатыннарын туй мәҗлесенә дә җибәрмәскә, ишектән аяк та атлатмыйча, ябып асрарга боера:

[1] Мәхыз – фәкать.
[2] Яхшы. *(Авт. иск.)*
[3] Хатын. *(Авт. иск.)*
[4] Юк сүз сөйләүне. *(Авт. иск.)*
[5] Тәмле теле. *(Авт. иск.)*
[6] Өне-тавышы. *(Авт. иск.)*
[7] Аны. *(Авт. иск.)*
[8] Кол, җария. *(Авт. иск.)*
[9] Йөзен кире бормас. *(Авт. иск.)*
[10] Мөтәгассыйбларына рәһбәр – фанатикларына юлбашчы.
[11] Гамилләрдән – сәбәпләрдән.
[12] Сахибе – иясе.

«Ушал хатын ки яшермәс йөзене,
Ки намәхрәмгә[1] күрсәтер үзене.
Аны манигъ итмәс ирер бихәммият[2]
Хөласада[3] ирер мондаг сәвит[4]...
Булыр разый кара йиргә тыкарга
Качан разый булыр уйдин чыкарга».

«Сөбат әл-гаҗизин»нең теле чыгтайча. Ягъни XV гасырдагы шагыйрьләр тарафыннан эшләнеп калдырылган, бик күп гарәп-фарсы сүзләре катышкан әдәби тел. Анда борынгылыклар күп очрамыйлар, хәтта юк дияргә ярый; төркчәсе хәзерге сөйләшү теленә якынрак; «торур» урынына күбесенчә «дыр» истигъмаль ителә[5]. Гомумән, әҗнәби[6] сүзләрнең күплеге аркасында бу китапның теле шулкадәр авыр ки, хәтта безнең иске татар язучыларыннан Таҗетдин Ялчыгол углы[7] дигән мулла аңар татар телендә шәрех[8] язарга тиеш күргән. Коръәнгә тәфсир язган күк, ул аның һәрбер бәйтенә аерып шәрех баглап, «Рисаләи Газизә» китабы килеп чыккан. «Рисаләи Газизә» мөәллифе «Сөбат әл-гаҗизин»не Суфи Аллаярның тасниф иткән[9] китаплары арасында гүзәлрәге һәм мөшкелрәге дип саный; мөшкел булуының да сәбәбе – теленең авырлыгында, – ди.

Аллаяр Суфиның өслүбе үзенә махсус бертөрле шигърияттән хали[10] түгел. Аның шигъри ифадәсенә[11] мисал итеп, түбәндәге

[1] Намәхрәм – ерак кардәш (Шәригать буенча өйләнешергә ярый торган кеше).

[2] Хәмиятсез. *(Авт. иск.)*

[3] Хөласада – нәтиҗәдә.

[4] Бәрабәрлек, чагыштыру.

[5] Истигъмаль ителә – кулланыла.

[6] Әҗнәби – чит.

[7] Таҗетдин Ялчыгол (якынча 1768–1838) – татар дин әһеле, тарихчы. Аның «Рисаләи Газизә» (1806) китабы «Сөбат әл-гаҗизин»гә шәрехләү буларак иҗат ителгән.

[8] Шәрех – аңлатма.

[9] Тасниф иткән – язган.

[10] Хали – буш.

[11] Ифадәсенә – сүз сөрешенә.

сәтырларны алырга мөмкин: «Әҗәл тартып торыптыр йәй[1] белән ук / Яшеренер, бер качар дәрманымыз юк», «Күтәрептер кылыч безгә салырга / Кеше белмәс куярмы дәм алырга»[2]. «Билүрсән юк бу дөньяның вафасы / Кадәм куйган[3] йирнекдер ярикасы».

Үлгәч кабергә куелу хакында ул әйтә:

«Аерып кәрвандин кундырырлар,
Кызыл гөл дик йөзеңне сулдырырлар».

Үзенең әйткән фикере артыннан ук аңар капма-каршы куелган тасвирый чагыштырулар аның ифадәсен куәтләндерәләр. Мәсәлән: «Гамәл кылмай сафа булмас күңелдә / Аяксыз һич кеше йөрмәде юлда», «Кирәк табигъка мәтбуг мөкәммәл / Олуг тәндин булыр пәйда олуг зыйлл»[4], «Кирәк күп талиб эчрә бер никүдәй[5] / Ярутмәс[6] монча йолдыз, булмаса ай».

Тәсаувыф әдәбиятының «мәхәббәт касәсеннән вәхдәт[7] мәе эчү» шикелле гомуми мәҗазлар[8] «Сөбат әл-гаҗизин»дә дә хөкем сөрәләр. Ләкин XII гасыр шагыйрьләренең садәлеге[9] инде монда юк. Шагыйрьнең тәкәллефле өслүб[10] белән язарга мәеле[11] бар, «ямандин кач, ямандин кач, ямандин», «сәгадәттер, сәгадәттер, сәгадәт» шикелле тәкрарларны[12] истигъмаль итү – аның яраткан эше. Тәҗнис тә аның сөйгән формаларыннан[13]. Мәсәлән: «Ялың

[1] Җәя. *(Авт. иск.)*
[2] *Тын (сулыш)* алырга ирек бирерме? *(Авт. иск.)*
[3] Аяк баскан. *(Авт. иск.)*
[4] Күләгә. *(Авт. иск.)*
[5] Никү – яхшы, тырыш.
[6] Яктыртмас. *(Авт. иск.)*
[7] Вәхдәт – берлек, ялгызлык.
[8] Мәҗазлар – метафоралар.
[9] Садәлеге – гадилеге.
[10] Тәкәллефле өслүб – ясалма стиль.
[11] Мәеле – теләге, кызыксынуы.
[12] Тәкрарларны – кабатлауларны.
[13] «Тәҗнис» дип аваз вә тәләффызлары бер булып, башка мәгънәләр аңлата торган сүзләрне бер үк бәйттә истигъмаль итеп уйнауга әйтәләр. Тәҗнис күбрәк кафиядә (*рифмада)* була. *(Авт. иск.)*

аты асәр кылмады халә / *Ояла* күр, бакыб һәр дәм *у ял*». Беренче мәртәбәдә «ояла» – «ояла» мәгънәсендә, икенче мәртәбәдә «ояла», ягъни ул «ялга» (чәчкә) мәгънәсендә. «Тәвәккәл бәхренә[1] *бат*, әй күңел, *бат*» – соңгы мәртәбәдә «бат» чыгтайча «тиз» мәгънәсендә. «Әгәр *туксан*га йитсәң, күңеле *тук сән*», «*Кыл эч*не халис андин соң *кылыч* ал». «*Сәман*е булса һәм белгел *сәм аны*» – сәман – саман – салам, сәм – гарәпчә «агу» мәгънәсендә. Югарыда китерелгән «Әгәр ун ел аенда булмаса ун / Уны чыкмас уны әйтергә бер көн» бәйтендә бер үк төрле языла торган «ун» сүзе дүрт җирдә дүрт төрле мәгънәдә истигъмаль ителә. Менә шулай итеп Аллаяр Суфи үзенең шигырьләрендә сүзләр белән уйнарга ярата.

«Сөбат әл-гаҗизин» безнең татар язучылары арасында үзенә тәкълидчеләр[2] дә тудырган. Мәсәлән, шагыйрь Габдерәхим Утыз Имәнинең шигырьләрендә аның өслүбенең тәэсире сизелә.

**«Кисекбаш китабы»**

«Кисекбаш китабы» – безнең татар халкының иң яратып укыган китапларыннан берсе. Ул бик күп заманнардан бирле безнең мәктәпләрдә дәрес китабы итеп тә укытылып килгән. Басмада кечкенә кул 16 битле, бәхре рәмел (фагыйләтен, фагыйләтен, фагыйләт) вәзенендә көйләп язылган бу хикәя беренче мәртәбә Казанда 1846 елда басылган.

Кисекбаш китабының кем тарафыннан, кайчан һәм кайда язылуы мәгълүм түгел. Китапның ахырында без шушы бәйтләрне укыйбыз:

«Мәүланә Шәмс Тәрази ярына
Сән тикергел гаҗизләр морадына
Фагыйләтен, фагыйләтен, фагыйләт,
Пишкадәм остазымызның рухы шад».

[1] Бәхренә – диңгезенә.
[2] Тәкълидчеләр – иярүчеләр.

Моннан, әлбәттә, аның язучысы кем булганлыгын чыгарып булмый. Әгәр «пишкадәм остазымыз» дигәне шул Шәмс Тәрази булса, аны шул кешенең шәкертләреннән берәү дияр идек. Әмма «Мәүланә Шәмс Тәрази»нең кем икәнлеге безгә мәгълүм булмады. Китапның башындагы

«Башла Гали сүзи бисмилла илә,
Дорышалем төне-көне Аллаһ илә», –

дигән бәйткә карап, мөәллифнең Гали исемле булуы белән хөкем итеп була. Бу хитаб[1], әлбәттә, хикәянең каһарманы Галигә түгел, чөнки ул вакытта бу хитаб урынсыз һәм мәгънәсез булыр иде. Шуңар күрә дә, Мәрҗани «Башла Гали» урынына «Башлагали» дип укыган. (Башлагали – чыгтайча «башларга кирәк» мәгънәсендә). Мәрҗани бу китапны бик борынгы заманнарда Идел буенда язылган әсәр булырга кирәк дип уйлаган, хәтта аны борынгы болгарлардан калган дип әйтергә теләгән. Моңар дәлиле шул: бу китап безнең Идел буеннан башка җирләрдә очрамый, имеш[2]. Димәк, бик күп еллар Бохарада торып укыган Мәрҗани Урта Азия төркләре арасында бу китапны очратмаган. Бу безнең өчен бик әһәмиятле бер факт. Мөстәшрикълар да «Кисекбаш»ны чыгтай әдәбияты әсәрләре арасында санамыйлар. Һәрхәлдә, без аны чыгтай әдәбиятыннан кергән әсәрләр артына теркәп сөйләдек. Әмма аның Урта Азиядә (Мавәраэннәһердә) язылган булуына һичбер төрле дәлил юк.

«Кисекбаш»ның теленә килсәк, ул үзе бик шөбһәле, дөрес. Аның асыл телен чыгтайча дияргә мөмкин. Анда «азак», «кызгу, тәпуг, ус, тәкый, берлә» шикелле бәгъзан бик иске чыгтайча сүзләр дә очрыйлар, күбесенчә «торур, ирүр, ирсә, еглау, сүзлә кали, бараен» шикелле чыгтай формалары истигъмаль ителәләр[3]. Ләкин шунда ук без байтак кына җәнүб төркчәсендәге сүз вә формаларны күрәбез; мәсәлән, «гаурәт (хатын), әсмар-

---

[1] Хитаб – эндәшү, мөрәҗәгать.
[2] «Мөстәфад әл-әхбар», җилд 1, бит 15. *(Авт. иск.)*
[3] Истигъмаль ителәләр – кулланылалар.

ләмәк, чагырышмак, дорушалем, күрәлем, күрмешем, сахрая, сүзи (сүзне), илә, иди, дур (дыр)» шикелле. «Кул» мәгънәсендә булган сүз төрле җирдә төрлечә – «әл, ил, илек» формаларында язылган. Хәтта анда «барисәрем, күрисәрем» шикелле борынгы җәнүб төрк китапларында («Мөхәммәдия»дә) очрый торган фигыль формалары да истигъмаль ителгәләгән. Шуның белән бергә, без анда «туфрак, күз камашыр, фәрештәләр катына кавышдылар» күк татарчалыкларны да очратабыз. Әлхасыйль[1], «Кисекбаш»ның теле нәкъ «Рәүнәкъ әл-ислам», «Ахырзаман» һәм «Йосыф» китапларының теле шикелле чуалчык вә «корама»[2]. Теленә карап, бу китапның кайда язылуын кәшеф итәргә[3] мөмкин түгел.

Мөндәриҗәсе ягыннан «Кисекбаш китабы» хәзрәте Галинең каһарманлыкларын сөйли торган сугыш китапларына охшый. Аның баш каһарманы Гали диюләр белән сугыша. Хикәя, шул жанрдагы әсәрләр өчен характерный булган рәвештә, Мөхәммәд пәйгамбәрнең сахабәләре белән җыелышып утыруларын тасвир белән башлана. Шул вакытта мәҗлескә ап-ак сакаллы киселгән бер адәм башы тәгәрәп керә дә, елап, пәйгамбәрдән ярдәм сорый. Ул үзе бик изге кеше булган: Алланың дидарын[4] күргән, төне-көне Алла белән сөйләшә, фәрештәләр катына күккә дә чыга икән; гомерендә илле тапкыр хаҗга барган һәм башка бик күп изгелекләр кылган. Ләкин аңар бер дию мөсәлләтъ булып[5], углын һәм үзенең гәүдәсен ашаган, сөекле хатынын урлап

[1] Әлхасыйль – нәтиҗәдә.

[2] Г. Газиз «Йосыф китабын», мөстәшрикъларның сүзләренә таянып, чыгтай телендә язылган әсәрләр рәтеннән санаса да, мин бу турыда аерым фикердә калам. Минемчә, аның теленең асылы – җәнүб төркчәсе. Ул төрекмәннәр яки борынгы сәлҗук (угыз) төркләре арасыннан чыккан бер-бер язучы тарафыннан язылган булырга кирәк. «Йосыф китабы»ның да мөхәррире «Гали» исемле бер кеше икәне мәгълүм, ләкин аның кем булуы, кайда яшәгәне билгеле түгел. Безнең «Кисекбаш китабы» да шул ук кешенең каләме белән язылмады микән дигән фикер ирексез башка килә. *(Авт. иск.)*

[3] Кәшеф итәргә – билгеләргә.

[4] Дидарын – йөзен.

[5] Мөсәлләтъ булып – җиңеп, үз кулы астына алган, (берәүнең өстеннән) үзе теләгәнне эшләргә ирекле булган.

киткән. Гали, пәйгамбәрнең бармаска киңәш бирүенә карамый, Дөлдөлгә атланып, мәзлум[1] Кисекбашның үчен кайтарырга китә. Дию тирән бер коеда тора икән. Шунда бик күп мөселманнарны ябып тотып, көн дә бишесен суеп ашый икән. Гали, җиде көн, җиде төн бертуктаусыз коега иңеп, дию белән баһадирларча сугышып, аны һәм аннан башка тагы өч йөз диюне үтереп, Кисекбашның хатынын һәм биш йөз мөселманны тоткыннан коткара. Пәйгамбәрнең догасы бәрәкәтендә Кисекбаш бер яшь егеткә әверелә, углының да корыган сөякләре яңадан тереләләр. Хикәя шуның белән тәмам була.

## «Йосыф китабы»

Бөтен җиһан әдәбиятында бөтен халыкларга уртак булган мәүзуглар бар. Ул мәүзугларның каһарманнары күбесенчә җефетле (җөп, пар) булалар, Таһир вә Зөһрә, Фәрһад вә Ширин, Ләйлә вә Мәҗнүн, Ромео һәм Джульетта вә башкалар, шуларның эчендә Шәрыкта иң күп таралганы – «Йосыф вә Зөләйха» мәүзугыдыр.

«Йосыф вә Зөләйха» мәүзугысы башта бәни Исраил хорафатыннан булып, соңра яһүдләрнең көтүби мөкатдәсәләренә[2] дә кергән. Соңра бу хикәя бөтен бәни Сам кавемендә сәяхәт кылып йөри торган бер кыйсса булып китеп, сүриялеләр вә гарәпләр арасында таралган. Коръәндә бу хакта аерым «Йосыф» сүрәсе булып, бу кыйсса анда «Әхсән әл-кыйссас» дип аталган. Табари, Зәмәхшәри күк мөфәссирләр[3] бу хикәягә шәрехләр, яңадан да бәгъзы әйберләр арттырганнар. Табари вә Ибн Әсир күк мөәррихләр бу бабта киң фантазияле хикәяләр язганнар. Безнең төрк әдәбияты да бу юлда артта калмады, гаять киң хыяллы «Кыйссас Робгузи»да бу мәүзуг матур бер кыйссада урнаштырылган. Билгеле, мондый матур мәүзуглар шагыйрь вә әдипләрнең сазларының кылларына тиз тәэсир итүчән була. Шуңарга күрә дә

[1] Мәзлум – рәнҗетелгән.
[2] Көтүби мөкатдәсәләренә – изге китапларына.
[3] Мөфәссирләр – бар нәрсәне аңлатып бирүчеләр.

без бөтен ислам кабул иткән халыкларның әсәрләре арасында диярлек бу мәүзугга язылган романтик поэмалар очратабыз.

Иран шагыйрьләре Фирдәүсидән башлап Җамигә кадәр бу мәүзугта берәр әсәр язганнар иде. Иран шагыйрьләренә тәкълид кылучы госманлы чыгтай вә азәрбайҗан шагыйрьләре дә аны онытмадылар.

Шуның өчен дә госманлыларның борынгы шагыйрьләреннән Чәләбинең (1448–1509) «Йосыф-Зөләйха»сы хакында:

«Мөрес зәвыкдер[1] әһле деләсаданың Зөләйхасы[2]
Битәрәддед җәля виреб[3] кидерер күңел айнәсендәге[4] пасе[5] –

дигәннәр иде. Шулай ук 940 һиҗридә үлгән Ибн Камал Паша исемендәге госманлы шагыйре дә бер «Йосыф вә Зөләйха» язган иде.

XIV–XV гасыр госманлы шагыйрьләреннән Яхъя бәй, хаҗга барышлый Фәләстыйнда Йосыфның туган җирен вә Мисырда аның торган җирен күргәч, илһамланып, «Йосыф вә Зөләйха» намында бер дастан тасниф кылган[6], шулай ук башка госманлы шагыйрьләре дә бу мәүзуг өстендә эшләгәннәр иде. Хәтта Испаниядә XIV гасырның икенче ярымында испан телендә гарәп хәрефе белән «Йосыф хакында поэма» («Poema de Jose») сәрләүхәсе[7] белән бер мөселман мориски[8] тарафыннан да бер әсәр язылган иде[9]. Ләкин төрк телендә бу мәүзугтагы иң борынгы поэмабызның татар арасында бик таралган «Йосыф китабы» яисә «Кыйссаи Йосыф галәйһиссәлам» дип мәгълүм булган әсәрдер.

[1] Йөрәк әһеленә кадерле булган. *(Авт. иск.)*
[2] Саданың Зөләйхасы – Зөләйханың тавышы.
[3] Шөбһәсез төрләндереп. *(Авт. иск.)*
[4] Күңел айнәсендәге – күңел көзгесендәге.
[5] Кәшф әз-зөнүн, 2 җилд, 661 сәхифә. *(Авт. иск.)*
[6] Тасниф кылган – язган, иҗат иткән.
[7] Сәрләүхәсе – исеме.
[8] Испаниядә гарәпләр белән испаниялеләрнең катнашуыннан хасил булган кешеләрне «мориски» дип атыйлар. *(Авт. иск.)*
[9] Zu Iussuf und Suleicha (Z.D.M.G), 1889, с. 27. *(Авт. иск.)*

Безнең Казанда нәшер ителгәннәрендә бу әсәрнең кайда вә кайчан язылганлыгы хакында һичбер мәгълүмат юк. Берлин вә Дрезден шәһәрләрендәге көтебханәләрдә бу әсәрнең кулъязмалары бар. Шуның икесенең дә ахырларында шундый сүзләр язылган:

«Бәни коша[1] зәгыйфь бәндә ады Гали
Екерме дүрт рәкым эчрә салды гасый.
Ярлыкагыл, йә Рәхим, ул хата колы[2],
Рәхмәтеңдә миһербанлык[3] умар имди», –

дисәк, бу әсәрнең мөхәррире – Гали исемле кеше. Әмма аның кайчан язылуы мәсьәләсенә килсәк, шул ук әсәрнең кулъязмаларындагы «нәтиҗә»сендә шундый сүзне укыйбыз:

«Мәүладан мәдәд носрәт йитүрендән[4],
Рәҗәб ае җәлаб утузындан[5],
Тарих нитәк алты йөз утузындан
Бу зәгыйфь бу китабы дөзде[6] имди».

Димәк, әсәр һиҗри беләк 630 да (1233 миладида) язылган буладыр, ягъни иң иске чыгтай әсәрләреннән булган Робгузидан (710 һиҗри) 80 ел элек язылган булып чыга.

«Йосыф китабы»ның мөндәриҗәсенә килсәк, анда шул хакта Коръәндәге «Сүрәи Йосыф»та сөйләнгән кыйссадан күп артык нәрсә юк. Булса да, бары шигъри манзара, шигъри өслүб, шигъри тарызы, ифадә[7] генә башка. Безнең Казанда басылган Йосыф китаплары да Яурупа көтепханәләрендәге кулъязмалар да, гадәтчә, хәмед, салават, чәһриярны[8] мактау, имам Әгъзамнан мәдәд сорау, укучылардан дога өмет итү, Алладан илһам сорау

[1] Берлинныкында: «бән ушал». *(Авт. иск.)*
[2] Хата колы – хаталы колны.
[3] M. Hantsina, Ein altturkische Gedichle. (Z.D.M., 1889, с. 97). *(Авт. иск.)*
[4] Аллаһы Тәгаләдән ярдәм, җиңү килгән чакта.
[5] Изге рәҗәп аеның нәкъ утызында.
[6] Дөзде – төзеде; язды.
[7] Ифадә – аңлатып бирү.
[8] Чәхрияр – Мөхәммәд пәйгамбәрнең тугрылыклы дүрт сахабәсе: Әбү Бәкер, Гомәр, Госман, Гали.

белән башлана. Соңра әсәр фасылларга бүленә. Анда без шундый фасыллар табабыз: «Йосыф галәйһиссәлам дөше», «Фасыл фи сыйфат Йосыф галәйһиссәлам», «Рожуг ихвәт Йосыф галәйһиссәлам»[1], «Фасыл Малик бине Дәгыйр дөше», соңра әсәрнең иң шагыйранә булган урыннарыннан «Фасыл фи бәяне Зөләйха»ның драматик урыннарыннан «Зөләйхадин дайә әхвәле сорамакы», шәрык өчен иң типичный булган «Зөләйха ягыйбәт идән гаурәтләр бәянында», соңра «Йосыф галәйһиссәламнең зинданнан чыкмакы», «Кыйссаи вәзир Йосыф галәйһиссәлам» иң илһамлы вә сөенечле урыны «Зөләйханы никах кылмак бәянында», «Ягъкуб галәйһиссәлам угланнары Мисырә вармакы», соңра Иран рухы белән сугарылган матур рәсемнәр хакында сөйли торган «Йосыф галәйһиссәлам сарай бина кылдыкы», «Ягъкуб сәүчинең Мисырдан чыкмакы», «Йосыфның Мисырдан чыкмакы», «Вафате Йосыф галәйһиссәлам». Дрезден вә Берлин кульъязмаларында исә кыска гына «нәтиҗә» бар. Монда мөхәррир Гали укучылардан дога үтенә һәм:

> «Аh, дәрига[2], дикмә кеше дәрмәде[3].
> Фәһем идәрсең кемсәләр (?..)[4] язмады», –

дип мактана. Соңра әсәрнең кем тарафыннан вә кайчан язылганлыгын белдерә.

«Йосыф китабы» робагый тарызында язылган. Мөхәррир үзе нәзари яктан да гаруз белән таныш кеше булырга кирәк. «Робагый вәзен иҗра орса имди», ди. Аның шигырьләрендә өч мисраг кафиядәш[5] булып килә дә, дүртенче мисрагы һәр җирдә «имди» белән бетә. Вәзен һәр җирдә бертөсле.

«Йосыф китабы»ның шигърияте ягына килсәк, аны без Яурупа үлчәве белән түгел, бәлки Шәрык, бигрәк тә төрк әсәрләре

---

[1] Йосыф галәйһиссәлам туганнарының әйләнеп кайтуы.

[2] Дәрига – ни үкенеч!

[3] «Җыймады», «җыю» мәгънәсендә булган «дәрмәк». «Мөхәммәдия»дә – «тәрмәк». Орхон язмаларында да очрый. *(Авт. иск.)*

[4] Чыганакта шул рәвешле бирелгән.

[5] Кафиядәш – рифмадаш.

белән чагыштырып карап, нәтиҗә чыгарырга тиешбез. Бу әсәрдә рухи халәтләрдән гыйшык тасвир ителә. Ләкин бу гыйшыкны суфиларча аңларгамы, әллә кинаясез аңларгамы? Безнең фикеребезчә, бу әсәрдә суфилык тәэсире бик аз. Йосыф белән Зөләйханың бер-берсенә гыйшыкларын гадәтчә аңларга тиеш. Шулай булса да, мөхәррире Галинең фикеренчә, гашыйк чын мәгънәсендә заһид аскет булырга тиеш. Аның фикеренчә, «Җөмлә галәм көләр исә гашыйк көлмәз – һәр дәм мәгъшука кайгысын тартар имди» һәм «Гашыйк мал-мөлкәтдән тәмам күңеле бизмәк кирәк...»

Шулай ук без бу «зөһед»не Йосыфның нәфесен тыюында, никадәр күңеле җилкенсә дә, Зөләйхадан качуында күрә алабыз. Шулай ук Йосыфның гаҗәеп сабыры да бер дәрәҗә шуны күрсәтә. Әмма бу кадәр генә зөһед Коръәндәге Йосыфта да бар. Аны чын суфилык дип әйтеп булмый. Моның сәбәбе бик мәгълүм: бу әсәр язылган заманда әле суфилыкның классик заманы килеп җитмәгән иде.

Монда рухи яктан икенче бер кызык җәһәт булса, ул да Зөләйханың Шәрык хатыннарынча ифрат каты гыйшкы, шуның белән бергә, аның кол гыйшыкка ифрат сәдакатедер[1]. Ул шуның аркасында фәкыйрьләнә, картая, әмма Йосыфны сөюен ташламый. Шул юлда әсәрдә без ифрат дәрәҗә драматизм күрәбез.

Йосыф китабында без бик матур, чын тойгылы (лирический) урыннар да очратабыз. Мисал итеп, Шәрык өчен бик типичный булган саба җиленә мөрәҗәгатене генә алыйк. Ягъкуб әйтә:

«Акрын искел саба йиле нә үтәрсән,
Сән хакыйкать Йосыфымдан ис дотарсән,
Җәрәхәтем үткәрмәгә сән йитәрсән,
Сән ис әле, бән мөфәррих[2] улдым имди».

Бер дә шиксез, бу мисрагларда без шагыйрь Галинең гаять назик рухын, чын шагыйранә табигатен вә бик зур талантын

---

[1] Сәдакатедер – тугрылыгыдыр.
[2] Мөфәррих – сөенечле, шат.

күрәбез. Без мондый урыннарны әсәрдә күп җирдә очратабыз. Текст белән аз гына таныш булган укучы моны күрер.

Әсәр тасвирлар ягыннан да бик бай. Моның өчен без баш каһарманнарның Йосыфның фаҗигалы рәвештә зинданга салынуы белән тәмам булган вакыйгаларын хәтерләсәк җитәр, әлхасыйль, без иске төрк шагыйрендә гаҗәиб бер истигъдад күрәбез.

Шагыйрь Гали бик диндар кеше булырга кирәк. Ул, вакыйгаларны тасвир кылганда, Коръәндә бу хакта сөйләнгән кыйссаның рамкасыннан чыкмый. Шулай бер киртә эченә кереп тә, шулкадәр шагыйранә манзара бирә алуы – Галинең зур истигъдадлы[1] шагыйрь булуына көчле дәлилдер.

«Йосыф китабы»ның теле мәсьәләсенә килсәк, без аның төрк телләренең кайсы шивәсенә мәнсүб[2] булуы мәсьәләсен хәл кылуда читенлек очратабыз. Элек бу хакта төрле галимнәрнең фикерләрен тикшереп карыйк. Немец галиме Флейшер[3] үзенең латинча язган бер әсәрендә аны татарча яисә угыз шивәсендә язылган, ди[4]. Ләкин Һоутсма[5], туры рәвештә язылган бер документны тикшереп, аның теленең нинди шивәгә мәнсүблеген тәгъриф кылырга[6] тырышканда, аны хәзерге сөйләшә торган тере телләр белән чагыштырырга ярамый, ди. Чөнки, аның фикеренчә, һәрвакытта язу теле белән сөйләшә торган тел арасында аерма зур була. Без моны башка язма документларның телендә дә күрдек. (Ярлыкларның вә болгар кабер ташларының телләрен генә алырга кирәк.) Шуның өчен дә татар теле дип

---

[1] Истигъдадлы – сәләтле.

[2] Мәнсүб – мөнәсәбәтле.

[3] Флейшер Генрих Леберехт (1801–1888) – немец шәрыкшинасы. 1831 елда Дрезден китапханәсендә сакланган поэманың күчермәсен Шәрык кульъязмалары каталогына кертә.

[4] Hautsma, Tatariko et eandem seu Oghuzicam dialecturn refshens, c. 64. *(Авт. иск.)*

[5] Һоутсма Мартин Теодор (1851–1943) – Голландия тарихчы-шәрыкшинасы һәм ислам белгече. 1889 елда «Кыйссаи Йосыф» текстының берничә кульъязмасы нигезендә әсәргә сюжет һәм тел үзенчәлекләре ягыннан анализ ясый.

[6] Тәгъриф кылырга – ачыкларга.

әйтү хата, чөнки татарның әдәби теле ул вакытта эшләнеп бетмәгән, әмма сөйләшә торган теле хакында сөйләсә, ул чагында Флейшердан кайсы вә нинди татарның теле дип сорарга кирәк булыр иде, чөнки татар дип атала торган халыклар бик күп.

Шул ук Һоутсманың фикеренчә, бу әсәрнең теле «Котадгу белег» һәм 710 һиҗридә язылган Робгузи теленә дә бик якын: димәк, уйгур вә чыгтай телләренә якын Урта Азия төрк шивәсе. Хәтта Рье[1] туп-туры бу әсәр Бохара яисә Урта Азия халыкларының берсе арасында язылган булырга кирәк, ди[2].

Һәрхәлдә, әсәрнең Кечек Азиядә вә сәлҗукыйларда язылган булу ихтималы юк. Чөнки бу заманда әле госманлы дәүләте мәйданга чыкмаган: әмма сәлҗукыйлар заманында «каба»[3] төрки теле белән язу гадәте юк иде. Боларның соңгы заманнарыннан солтан Вәләднең «сәлҗук шигырьләре» калган булса да, ул да берничә генә данә[4]. Икенче җәһәттән, әгәр бу әсәр сәлҗукыйларда Кечек Азиядә язылган булса иде, анда без гадәттәгечә бер солтан исемен һәм бик куәтле рәвештә Җәлаледдин Руми тәэсирен күрер идек[5] – болар икесе дә юк. Бинаән галәйһи[6], әсәр Кечек Азиядә язылмаган, әсәрдә очрый торган бик күп фигыль формалары вә күп сүзләр әсәрнең чыгтай теленә якын бер тел белән язылганын күрсәтәләр. «Айгыл», «әсиркән», «уйлук», «тутургучы», «дагый», «исеркәбен»[7], «иллик» вә башка бик күп сүзләр әсәрнең теленең чыгтай теленә якын икәнен күрсәтәләр. Шулай ук Урта Азиядәге Иран тәэсире астында мәйданга килгән тавышлы авазларның гармониясенең югалуын да күрәбез:

---

[1] Рье, Шарль Пьер Анри (1820–1902) – швецарияле шәрыкшинас. Британия музеенда сакланган гарәп, фарсы, төрки кульязмаларның каталоглары авторы.

[2] Catalogue of Turkish Manuscripts in British Museum, c. 270. *(Авт. иск.)*

[3] Каба – коры.

[4] Бу хакта беренче бүлектәге госманлы әдәбияты хакындагы мәкаләдән карагыз. *(Авт. иск.)*

[5] Hautsma, s. 73. *(Авт. иск.)*

[6] Бинаән галәйһи – шуның өчен, шуңа күрә.

[7] Радлов «исеркәмәк»не «быть сострадальцем» дип тәрҗемә кыла. *(Авт. иск.)*

мәсәлән, «кемсәләр» урынына «кемсәлар» язылган. Ләкин шул чыгтай сүзләре арасында коман һәм уйгурча сүзләр дә очрый[1]. Мәсәлән, «усы китүб» диелгән. «Ус», Радлов фикеренчә, уйгурча һәм команча, ләкин әсәрдә чын Казан татарчасы төсле җөмлә вә сүзләр дә очратабыз:

«Илемездә безем хәйр һич калмады
Йиремездә игенләре һич уңмады».

Шулай ук әсәрдә бик сирәк очрый торган сүзләр дә бар. Мәсәлән, акча исеме – «ярмак»[2].

Әсәрдә без әллә ничә төрле фигыль формаларын табабыз. Бигрәк тә киләчәк заман фигыльләрен ясауда бик күп төрлелек күреләә. «Уласын, кортыласын, вирерсен, улырсын, кортылырсын[3]» кайсы вакытта киләчәк заман «дачы» әдате[4] кушылып ясала. «Улдачысын, юлдачысын, алдачысын» – мондый форма фигыльләрне без Йосыф китабы теленә бик күп яктан охшаган «Коман мәҗмугасы»нда таба алмыйбыз. Әмма Орхон язуларында бу форма очрый. Янә без бу әсәрдә Урта Азиянең бәгъзы шивәләрендә очрап та, әдәбиятта бер дә булмаган «минлек» сыйгасының[5] берлегенең «вән» белән кушылып ясалган бер формасын табабыз. «Вән» кушымтасы төрле заман фигыльләренең артында килгән була, ләкин моны «бән» я «мин» белән бер нәрсә дип әйтеп булмый. Чөнки «вән» «бән» соңында да килгәли. Бу кушымтаның истигъмаленә даир[6] берничә мисал алыйк: «Йосыф әйдер анларә белең баек / Бәнвән сезнең кардәшеңез

[1] Аның уйгурлар арасында язылган булуы да бик ихтимал, чөнки монда христианлык тәэсире дә юк түгел, мәсәлән, анда «Исхак зәбех» диелгән, әмма Коръәндә «зәбех» Исхак түгел – Исмәгыйль, Тәуратта – Исхак. *(Авт. иск.)*

[2] Моны Һоутсма «көмеш акча» дип тәрҗемә кыла. Радлов лөгатендә бу сүз уйгур һәм чыгтай сүзе булып, Кытайның бакыр акчасы дип тәрҗемә кылына. *(Авт. иск.)*

[3] Кайбер кульязмаларның имлясында «سن» урынына тәнвин белән «سأ» язылган.

[4] Әдате – кушымчасы.

[5] Сыйгасының – фигыль төрләнешенең.

[6] Истигъмаленә даир – кулланылышына караган.

Йосыф сиддыйк», «Бән сезә мөдам[1] хезмәт кылдачывән / Сез киденчә йитүкездә улдачывән», «Йосыф әйдер шимди илә кыйлмайәвән / Йөземдән тәкабен суймайәвән».[2]

Бу китапта башкалар тарафыннан игътибарга алынмаган бик борынгы әсәрләрдә – «Кисекбаш» һәм «Мөхәммәдия»дә табыла торган киләчәк заманны «сәр» белән ясый торган форма да бар. Мәсәлән: «хикмәт таба кәчисәрмән», «мәрҗан сачисәрмән», «ачисәрмән».

Әсәрнең телен фонетика җәһәтеннән тикшереп чыгып, хәзерге төрк шивәләренең кайсына мәнсүб[3] икәнен хәл кылырга имкян юк. Безгә Һоутсманың мәкаләсе аркылы мәгълүм булган кульязмаларның имлялары төрле-төрле: берсендә «д», икенчесендә «т»; «к» белән «х» да шулай. Димәк, яңа кульязмалары кәшеф ителеп[4], тагын да әтрафлырак тикшерергә юл ачылмаган сурәттә, бу хакта һичбер төрле төпле нәтиҗә чыгарырга мөмкин түгел.

Безнең фикеребез бу әсәр хакында шулай: ул Урта Азиядә бер-бер төрк мәркәзендә язылган булыр. Ләкин, һәрхәлдә, Мавәраэннәһердә түгел, чөнки Мавәраэннәһер төркисе, Вамбериның фикеренчә, бик Иран теле тәэсиренә төшкән. Үзенең асыл табигатен югалткан.[5] Әмма без бу әсәрдә андый фарсы тәэсирен күп күрмибез. Теле бик садә. Ифадәсе бик асат. Табигате халык әдәбиятына бик якын булганга, бу әсәр күп төрк кавемнәре тарафыннан бик тиз кабул ителгән. Бик күп кульязмалары пәйда булган. Шуның аркасында әсәргә күчерүчеләр, соңра бастыручылар тарафыннан үз шивәләрендәге сүзләр кертелгәндер дип уйлана.

[1] Мөдам – өзлексез.

[2] Бу турыда Һоутсма «вән» исеме замир (алмаш) түгел, бәлки «онемелое образование» (eine erstarrte Bildung ist) ди. *(Авт. иск.)*

[3] Мәнсүб – мөнәсәбәтле, караган.

[4] Кәшеф ителеп – табылып.

[5] Vambery H. Dschagalaische Sprachstndien, с. 5. *(Авт. иск.)*

# ИДЕЛ БУЕНДА ГОСМАНЛЫ ӘСӘРЛӘРЕ

## «Мөхәммәдия»

Әле Истанбул төрекләр тарафыннан алынмаган, мәңгелек хисапланган Шәркый Рум империясе соңгы сулышын ала; гасырларча Юнан җире булып килгән Дарданел буйларына инде госманлы тугы[1] эленгән иде. Шунда борынгы Юнан вә Рум[2] шагыйрьләре тарафыннан макталган Калипулис[3] (госманлыча «Кәлибули») шәһәрендәге бер челләханәдә госманлы суфи әдәбиятының иң якты йолдызларыннан берсе, үзенең шигъри, әхлакый җылысын безнең шималь илләренә кәдәр җиткергән, «Язычы углы» яисә «Шәех Мөхәммәд Биҗан» ләкабе белән мәшһүр Мөхәммәд Чәләби гомер итәдер иде. Аның атасы Салих кятиб булып хезмәт итүче, заманасында зыялы бер кеше булган. Заманасының модасы буенча, Мөхәммәд Чәләби дә тәсаувыф вә гыйлем юлына кергән иде. Ул мәшһүр Хаҗи Бәйрәм[4] исемле кешенең мөриде вә шәкерте булып, аның тарикатенә мәнсүб иде.

Мөхәммәд Чәләби Рум илендә Мәлгарә исемле касабә[5] тирәсендә Казый Көйдә туган, яшь вакытында ул чакның гыйлем мәркәзе булган Иран вә Мавәраэннәһергә барып укыган, соңра Кәлибулига килеп җирләшеп, төрле тәсаувыфка даир[6] гарәби вә төрки әсәрләр язу белән мәшгуль булган иде. Суфиларның философы Мөхеддин әл-Гарәбинең[7] «Фусус»[8] атлы

[1] Тугы – флагы.

[2] Рум – Византия.

[3] Хәзерге Төркиядәге Гелиболу шәһәре.

[4] Хаҗи Бәйрәм Вәли (1352–1430) – суфи шагыйре, Бәйрәмия тарикатенә нигез салучы.

[5] Касабә – кечкенә шәһәр.

[6] Даир – караган.

[7] Мөхетдин Әбү Габдулла Мөхәммәд ибн Гали әл-Андалуси (1165–1240) – мөселман дин белгече, суфичылык гыйлеменең күренекле вәкиле һәм теоретигы. Аллаһ белән дөнья арасындагы аермаларны кире кагучы яшәеш бердәмлеге (*вәхдәт әл-вөҗүд*) турында тәгълимат төзи, камил кеше (*әл-инсан әл-камил*) концепциясе яклы була.

[8] «Фусус әл-хикәм» («Кыйммәтле хикмәтләр») – Ибн әл-Гарәбинең мәшһүр фәлсәфи трактаты.

китабына шәрех язган; соңра «Мәгариб әз-заман»[1] атлы әсәрен дөньяга китергән иде. Бу әсәрне башта гарәпчә язган булса да, соңра аны энесе Әхмәд Биҗан шәех Бәйрәминең кушуы буенча, «Әнвәр әл-гашыйкыйн»[2] исемендә нәзым белән төрекчәгә тәрҗемә кылган. Бу әсәр дә безнең борынгы татар укучысының яратып укый торган бер китабы булып киткән иде. Әхмәд һәм Мөхәммәд соңра, «Мәгариб әз-заман»нан алып, яңа әсәр язарга керештеләр. Әхмәд Биҗан табигать вә Коръәндә булган гаҗәибәтне җыеп, нәсер белән «Дөрр әл-мәкнүн»[3] дигән әсәрне, соңра Мөхәммәд Чәләби мәшһүр «Мөхәммәдия»не язды[4].

«Мөхәммәдия» 853 һиҗридә (милади 1449) тәмам булды[5]. Китапның «Мөхәммәдия» дип Мөхәммәдкә нисбәт бирелүендә госманлы голәмасы ихтиляф иткәннәр[6]. Бәгъзылары – солтан Мөхәммәд Фатихка, кайсылары – пәйгамбәргә, бертөрлесе үзенә нисбәт биргән, диләр. Ләкин, безнең фикеребезчә, бу әсәр пәйгамбәр Мөхәммәдкә нисбәт бирелгән булырга кирәк. Әгәр без бу әсәрне поэма – дастан дисәк, аның каһарманы да Мөхәммәддер. Классик вә ялган классик әсәрләрне каһарманының исеме белән атаганнары шикелле, моны да каһарманының аты белән исемләгәннәр булыр.

Мөхәммәд Чәләбине госманлы халкы бик яратты. Шуның өчен аны үз хыялында харикылгадә[7] кәрамәт иясе итеп

[1] «Мәгариб әз-заман» – «Заман кояшының баешы».

[2] «Әнвәр әл-гашыйкыйн» – «Гашыйклар нуры».

[3] «Дөрр әл-мәкнүн» – «Энҗеләр тезмәсе».

[4] Бу хакта мәгълүмат Кятиб Чәләбинең «Кәшф әз-зөнүн»ендә бик аз, берике сатыр гына. Мөхәммәд Чәләбинең әдәби хезмәтләре хакында 1261 һиҗридә Казанда профессор Казембек тарафыннан нәшер ителгән нөсхәнең башындагы мәкаләсендә һәм Сәми бәйнең «Камус әл-әгъләм»ендә бераз мәгълүмат бар. Без күбрәк мәгълүматны Һаммер-Пургштальнең «Geschichte des osmanischen Reiches, Bd. I, s. 127–128» дигән әсәреннән алдык *(Авт. иск.)*

[5] Шагыйрь үзе китабында бу хакта: «Әгәр забыт итмәк эстәрсәң тәварих, сикез йөз илле өчдә диде тарих», – ди. *(Авт. иск.)*

[6] Ихтиляф иткәннәр – каршы булганнар, бәхәсләшкәннәр.

[7] Харикылгадә – гадәттән тыш.

ясап куйды. Аның хакында әллә никадәр легендалар ясалды. Аның тәрҗемәи хәлен язучы шулай сөйли: «Язычызадә[1] шул кадәр Аллага гашыйк иде ки, ул бер вакытта үзенең мәгъшукы хакында сөйләп утырганда аһ итеп җибәргәч, авызыннан гыйшык уты чыгып, алдындагы шигырьләр язган кәгазен яндырды». Янә берсе: «Риязәт вә мөҗаһиддә, намдан гозләт вә Хакка тәүҗиһендә шулкадәр газәл вә икдам итмешдер ки, йиде ел тәнавел шөбһәнәдә кәмаль ихтиразыннан наши атәш күрмеш»[2] (күзенә утлар күренгән). Ул үзе дә кәрамәт иясе булуына ышана, үзенең бөтен шигъри илһамын шул кәрамәттән күрәдер иде. Бу әсәрне язуында да, шагыйрьнең фикеренчә, бер зур кәрамәт бар. Әсәрнең ахырында шагыйрь әйтә:

«Язылынҗа китап ул нур заһир,
Бәңа өч кәррә[3] төшемдә улды заһир».

Бу – пәйгамбәрне төшендә күрү иде. Ул бу хакта китапның дибаҗәсендә[4] бик матур итеп сөйли: бер көнне, тәкъдирнең кушуы буенча, Мөхәммәд Чәләби Кәлибулида, шул борынгы юнан шагыйрьләренә илһам биргән Дарданел буенда утыра, бөтен халыктан бизгән, телендә – үзенең мәгъшукы Алланың зикере генә икән. Аның бу моракабәсен[5] бүлдереп, Кәлибулиның гашыйклары (суфилары) килеп тезеләләр. Алар аннан: «Ни өчен рәсүлнең сыйфатларын халыкка белдермисең?» – дип сорыйлар. Аларга шагыйрь бик кыска гына:

«Төзелмешдер ничә мәүлед китабы,
Язылмышдыр ничә әүсаф кибри[6].

---

[1] Язычызадә – Мөхәммәд Чәләбинең «Язычы углы» тәхәллүсе.

[2] Теләкләрен тыеп тору, дан-шөһрәттән читләшү, Хакны мактап, аңа йөз тотуда шулкадәр тырышлык куйган ки, җиде ел ашаудан саклануыннан күзеннән утлар күренгән.

[3] Кәррә – тапкыр.

[4] Дибаҗә – кереш сүз.

[5] Моракабә – уйга чуму.

[6] Әүсаф кибри – күркәм сыйфатлары.

Беленмешдер, динелмешдер, укынмыш,
Аңламышдыр каму сыйгъри вә кибери[1]»? –

дип җавап бирә... Менә бер көн шагыйрь төш күрә: пәйгамбәр, нур эчендә балкып, сахабәләр арасында утыра. Ләкин ни өчендер исә һәммәсе дә йөзләрен каплаганнар... Шагыйрьнең исе китеп, берәүдән: «Ни өчен бу халәт?», – дип сорый. Ул шәхес: «Кемгә никаб ачсыннар?» – дип җавап бирә. Бу сүзне ишеткәч, шагыйрь елый башлый, якасын парә-парә итеп ерта... Бу халәтне пәйгамбәр күреп: «И күңелләрне рәхәтләндерүче (диләра), күңелеңнең пәрдәсен ач, күтәр дә, җаныңда минем нурымны эзлә. Хикмәт шәрабын өммәтемә эчерт, сүземне халыкка игълам ит!», – ди. Шуннан соң Мөхәммәд Чәләби бу әсәрне язарга керешә...

«Мөхәммәдия» – тәсаувыф әсәре. Ләкин аның суфилыгы Җәлалетдин Руми[2], Хәллаҗларныкы[3] төсле шәригать кануннарыннан өстә тора торган суфилык түгел: бәлки аның тарикате – рәсми исламга якын бер суфилык... Шуның өчен анда тойгының күплеге белән бергә гакыл, дәлил дә куәтле... Ләкин аның эчендә дә, башка тәсаувыф әсәрләрендәге төсле, гашыйкның мәгъшуклары булган Алла вә Мөхәммәдкә гимннар, серенадалар тулган. Шәраб, visаль[4], гөл, былбыл вә сакыйлар[5] – һәммәсе дә бар.

Бу әсәрнең мәркәзе вә каһарманы – Мөхәммәд. Башка нәрсәләр исә – аны тәүсыйф кылгандагы[6] аккомпанементлар гына, бары Мөхәммәд рәсеменә фон гына.

---

[1] Каму сәгыйри вә кәбири – ничә кечкенәсе вә зурысы.

[2] Җәлалетдин Руми (1207–1273) – шагыйрь, суфи шәех, философ. Фарсы һәм төрки телләрдә язган. Иң дәрәҗәле, иң абруйлы дин әһелләренә генә бирелә торган «Мәүләна», «Мәүләви» («хуҗабыз», «остазыбыз») дигән исем йөртә. Шул исемдәге мәүләвия суфичылык тарикатен төзи. «Руми» тәхәллүсе Румга нисбәтле кабул ителгән.

[3] Әбү әл-Могыйс әл-Хөсәен бине Мансур әл-Бәйзави (Мансур Хәллаҗ) (858–922) – суфи, шагыйрь. Ислам тарихында «Әнә әл-Хак» *(Мин – Хак)* дигән сүзләре белән билгеле. Вәгазьләре һәм фәлсәфи чыгышлары өчен үлем җәзасына тартылган.

[4] Висаль – сөйгән яр белән кавышу.

[5] Сакый – шәраб салучы.

[6] Тәүсыйф кылгандагы – сыйфатлагандагы.

Мөстәшрикъ[1] Һаммер[2], китабыны ике зур кисәккә бүлеп, шуның беренчесендә – һәрнәрсәнең башы, зоһуры[3], икенчесендә һәрнәрсәнең ахыры, ниһаяте тасвир ителде. Язычызадәнең фәлсәфәсенә күрә, бөтен галәм шул Мөхәммәд өчен ясалган. Чөнки:

«Диде: бәс, Хак Тәгалә, Аллаһ, Җәлалем, Гыйззәтем, Хаки,
Бәңа сәндән газиз кемсә яратмадым дәр истихбаб[4]».

Шуның өчен дә бөтен галәмдәге иң мөһим нәрсәләр:

«Мөхәммәд чөн[5] улынмышдыр бу хиссият, ходсият[6],
Мөхәммәддән беленмештер бу гаклыять[7], шәргыять[8]».

Гомумән, шагыйрь фикеренчә, хәтта:

«Бонча җәннәт ул Хәбибулла өчен,
Бонча миннәт[9] ул Рәсүлулла өчен,
Бонча нигъмәтләр Нәбиулла өчен,
Бонча рәхмәтләр Сафиулла өчен...»

Менә шул сәбәпле дә «Мөхәммәдия»дә сөйләнә торган бөтен нәрсә Мөхәммәд өчен, аның васыйфын[10] аңлату, тасвир итү өчен сөйләнә. Хәтта Мөхәммәд хакындагы тантаналы урыннарны укыгач, «Алламы безнең шагыйрьгә якынрак, әллә Мөхәммәдме?» дигән сөаль башка килә.

Мөхәммәд Чәләбинең энҗе шикелле тезелгән нәзымнары мәгънә җәһәтеннән самимият, шигърият белән, әмма тышкы җәһәтеннән вәзеннең[11] төрлелеге, тигезлеге белән аерылалар.

---

[1] Мөстәшрикъ – шәрык белгече.

[2] Йозеф фон Һаммер-Пургшталь (1774–1856) – австрияле шәрыкшинас, тарихчы, дипломат, Көнчыгыш әдәбияты үрнәкләрен, шул исәптән Мөхәммәд Чәләби әсәрләрен дә беренчеләрдән булып Европа телләренә тәрҗемә итүче.

[3] Зоһуры – барлыкка килүе.

[4] Дәр истихбаб – алга куеп, өстенлек белән.

[5] Чөн – өчен.

[6] Ходсият – вакыйгалар.

[7] Гаклыять – уйлап беленгән, табылган фикерләр; философик төшенчәләр.

[8] Шәргыять – шәригатькә караган бар фикерләр, кануннар.

[9] Миннәт – ярдәм.

[10] Васыйфын – сыйфатларын.

[11] Вәзен – шигъри үлчәм, ритм.

Әсәрнең мөндәриҗә[1] җәһәтенә килсәк, мөәллиф[2] китапның сәбәбе, тәэлифе[3] хакында, дөньяны, Адәмне ярату, башка пәйгамбәрләр хакында сөйләгәннең соңында, Мөхәммәднең тәрҗемәи хәленә күчә, мигъраҗ, һиҗрәт күк мөһим вакыйгалар хакында ялкынлы шигырьләрен сибә. Сахабәләрнең иман китерүе, чәһриярлар хакында бер эпик шагыйрь төсле салкын канлылык белән сөйләп килеп, тагын пәйгамбәргә кайта... Моңарга сүз ирешә исә, шагыйрь «котырып» китә. Нәкъ чабыш аты яки гашыйк егет күк хәрәкәтләнә. Йөрәгеннән тойгылары коела башлый. Ниһаять, безнең шагыйрь бер лирик вә елак романтикка әйләнеп китә... Шуннан соң китапның кайгылы сәхифәләре башлана. Бу исә – пәйгамбәрнең, аның кызларының, сөекле сахабәләренең үлүе. Менә шуның белән китапның Һаммер әйткән икенче бүлеге – инкыйраз-бетүне тасвир кылган кыйсеме[4] башлана. Шуннан кыямәт галәмәтләре, Дәҗҗал, Гайсәнең иңүе, Яэҗүҗ-Мәэҗүҗ, Дәббат әл-Арызларның чыгуы, Кыямәт көне, үлекләрнең терелүе, җир вә күкнең алмашуы, әгъраф[5], мизан[6], хисап, гыйтаб[7], сират, Пырак[8], җәннәт-җәһәннәм, хур, вилдан[9], гыйльман[10] шикелле нәрсәләрне тасвир итә башлый. Шуның арасында тагы Үлемне сую – «зәбех әл-мәүт»[11] күк миф, пәйгамбәргә мәдхия вә гимннар, касыйдә, раббания күк одалар[12] башлана. Ниһаять, пәйгамбәрне ахыргы мәртәбә мактап, шагыйрь үзенең сазының иң соңгы аккордын ала...

[1] Мөндәриҗә – эчтәлек.
[2] Мөәллиф – автор.
[3] Тәэлифе – төзүе, язуы.
[4] Кыйсеме – кисәге.
[5] Әгъраф – җәннәт белән җәһәннәм арасындагы урын.
[6] Мизан – үлчәү.
[7] Гыйтаб – шелтә, орышу.
[8] Пырак – җәннәттә фантастик ат.
[9] Вилдан – җәннәт хезмәтчеләре.
[10] Гыйльман – җәннәт хезмәтчеләре.
[11] Зәбех әл-мәүт – үлемне юк итү. Ислам эсхатологиясендә Кыямәт көне җиткәч, ак бәрән сурәтендә Үлемне тотып китерәчәкләр һәм корбан итәчәкләр, «үлем» төшенчәсе гомумән юкка чыгачак дип уйланыла.
[12] Кирилл хәрефләре белән язылган.

Гомумән, «Мөхәммәдиянең» мөндәриҗәсе белән танышкач, хәтергә Дантеның «Илаһи комедиясе» килә. Ләкин Һаммер бу әсәрне шулай атаса да, госманлы әдәбиятының Яурупа интибаһ (Ренессанс) дәвере һәм аның әдәбияты белән бертөрле дә галякасе[1] юк. Бу охшау – бары тәсадеф[2] кенә.

«Мөхәммәдия», Шәрык әдәби гадәтенчә, газәл, мәснәви, касыйдә формаларында язылган. Шул аерым кисәкләрнең кафияләре[3] исә күбесенчә һәммәсе хоруфы һиҗаның[4] бер хәрефе белән генә тәмамланалар. Кафияләр исә әлифба тәртибенчә тезелеп, әсәр шул хәрефләрнең исеме белән төрле баб вә фасылларга бүленә.

Әсәрдә вәзеннәр[5] дә бик төрле-төрле. Шагыйрьнең иң зур истигъдады[6] шул вәзеннәр белән туп белән уйнаган шикелле уйнавыдыр. Ул үзе дә бер урында мактанып:

«Хоруф үзрә килүр әбьйат мәргуб[7],
Ара йирләрдә тәрҗигъ[8] бәнд[9] [и]лә хуб.
Йиде бәхер[10] өстенә нәзымы мосаннаг[11],
Сигез оҗмак кеби бәземе морәссаг[12]!» –

ди. Аның иң күп истигъмаль иткән[13] вәзене – «һәзәҗ» аталган «мөфәгыйлен» вәзенедер. Икенче төрлесе – рәмел: «фагыйләтен». Өченчесе – мөтәкариб: «фагулен». Дүртенчесе – «фагыйләтен мөфагыйлен фагыйлен». Бишенчесе – рәҗәздән «мөсәммән матви» аталган вәзен, ягъни дүрт мәртәбә «мөстәфагыйлен». Алтынчысы – сәригъдән «матви мәксүр» үлчәве:

[1] Галякасы – бәйләнеше.
[2] Тәсадеф – туры килү.
[3] Кафияләре – рифмалары.
[4] Хоруфы һиҗа – әлифба.
[5] Вәзен – шигъри үлчәм, ритм.
[6] Истигъдад – сәләтлелек, булдыклылык.
[7] Әбьйат мәргуб – яхшы сыйфатлы бәйтләр.
[8] Тәрҗигъ – кайтаваз; яңгыраш.
[9] Бәнд – шигырьдә һәр строфадан соң кабатланган юллар, кушымта.
[10] Бәхер – шигъри үлчәм.
[11] Мосаннаг – гүзәл, сәнгати яктан матур итеп эшләнгән.
[12] Бәземе морәссаг – җыелмасы, тупланмасы бизәлгән.
[13] Истигъмаль иткән – файдаланган.

«мөстәфагыйлен мөстәфагыйлен фагыйлен», җиденчесе – мөҗтәстән «мөфагыйлен фагыйләтен мөфагыйлен фагыйлен» вә башка вәзеннәрдер. Болардан күрелә ки, Мөхәммәд Чәләби гарәп, иран вәзеннәрен истигъмаль кыла. Әмма халык вәзене булган бик борынгы төрк шагыйрьләре язган «бармак хисабы» аталган үлчәүне кулланмый.

«Мөхәммәдия»нең теле – борынгы госманлы теле. Ләкин ул заманда модадагы төрк шивәсе булган чыгтай теле дә аңар шактый тәэсир иткән. Анда чыгтайча сүзләр вә формалар бик еш истигъмаль кылына. Ихтимал, мөхәррирнең Мавәраэннәһергә барып укуы да аның теленә чыгтай тәэсире керүгә сәбәп булгандыр. «Мөхәммәдия»дә төрк теленең бик борынгы сарыфы формаларыннан киләчәк заман фигыльләренең «ср» (сәр, сар) кушымтасы белән ясалуы күзгә бәрелә (булысар, кәлисәр). Бу фигыль формасы борынгы төрк әдәбиятында да бик сирәк очрый[1]. Бу форма кай заманнарда кайсы төрк халкының сөйләшү телендә истигъмаль кылынып, әдәбиятка кереп калган «борынгылык»тыр – бу тикшерелергә тиешле мәсьәлә. Безнең «Йосыф китабы»ндагы очрый торган байтак иске сүз вә формаларны «Мөхәммәдия»дә дә очратып була. Гомумән, тел мәсьәләсендә бу китап – төрк әдәбиятында әһәмиятне хаиз булган[2] әсәрләрдәндер.

«Мөхәммәдия» яхшы ук авыр тел белән язылган. Гарәп-фарсы сүзләре анда шулкадәр күп ки, бәгъзы урыннарның әдат[3] вә бик мәшһүр фигыльләрдән башкасы бөтенләй чит сүзләрдән төзелгән: шуның өчен дә «Мөхәммәдия»не укыр өчен бик яхшы гарәп-фарсы телләрен, хәтта аның әдәбиятын белергә кирәк. Мәсәлән, ул бәгъзы урында сүзләр белән уйнап тәҗнисләр[4] ясый. Монда уйнала торган сүзнең төрле мәгънәләрен белергә кирәк була. Шул ук чакта шагыйрь киная белән бәгъзы Иран шагыйрьләренә дә җавап биреп китә. Менә бер мисал:

[1] Аны без «Рәүнакъ әл-ислам»да, «Кисекбаш» һәм «Йосыф» китапларында очратабыз. *(Авт. иск.)*

[2] Хаиз булган – җыйган, эченә алган.

[3] Әдат – кисәкчәләр, кушымчалар.

[4] Тәҗнисләр – омонимия күренешеннән файдаланып сүз уйнатулар.

«Әгәр Румың рәванында күрерсәм бән диларaи,
Рәванына рәван идәм Сәмәрканд вә Бохараи.
Диларадыр тотан хәрәм күзем, күңлем җиһаныны
Вә илля[1] ниятә булайды дил арайы, дил арайы».

Монда «дилара» әллә ничә мәгънәдә истигъмаль ителә[2]. Шул ук вакытта бу – мәшһүр Иран шагыйре Хафизга җавап[3]. Әгәр Хафиз бу гүзәлнең миңе өчен Сәмәркәнд вә Бохараны бирсә, Чәләби андый нәрсәләр белән чуалмый. Ул аларны пәйгамбәрне күрер өчен генә бирергә хәзер... Монда Мөхәммәд Чәләбинең чын рәсми мөселман булуы, Хафиз шикелле хәддән[4] ашкан суфи булмавы күренә.

Шулай укырга читен була торып та, «Мөхәммәдия»не безнең халык бик яратып укыды. «Мөхәммәдия» көе дип, берничә төрле көйләр дә чыгарды. Аның кайсы җырлары бөтенләй халыкныкы булып китте. «Мөхәммәдия» безнең ысулы кадим мәктәпләрнең программларына да кереп, билхасса[5] кызлар өчен дәрес китабы ролен уйнап килде. Безнең хатын-кызларыбыз, карчыкларыбыз аны укып яисә укыганны тыңлап җылыйлар; Башкортстанда хәтта авылларда муллалар тарафыннан мәҗлесләрдә Коръән белән бергә «Мөхәммәдия» дә укылу фарыз шикелле бер эш хисаплана иде. Башка ислам халыклары да «Мөхәммәдия»не югары урынга куйдылар. Аңар гарәп вә төрк илләрендә җилдләрчә[6] шәрехләр яздылар.

«Мөхәммәдия»нең безнең арада кайчаннан бирле укылып йөргәне билгеле түгел. Ул беренче мәртәбә Казанда 1865 елда

[1] Вә илля – югыйсә.

[2] Беренче вә икенче «дилара»дан морад – Мөхәммәд пәйгамбәр. Гомумән, бу сүз «дил» (йөрәк), «ара» (сөенеч) дигән сүзләрдән ясалган «дилара», гарәбчә «мөфәррих әл-калеб» (радующий сердце) мәгънәсендә. *(Авт. иск.)*

[3] «Әгәр ан түрк-е Ширази бә-дәст арад дил-е мара, нәҗал-е Һиндүиш бәхшәм Сәмәрканд-у-Бохарара» тәхминән: әгәр Иран төреге кулы белән минем йөрәгемне тотса, Һиндүнең миңе өчен мин Сәмәрканд вә Бохараны бирермен. (Һиндү – хатыннар исеме.) *(Авт. иск.)*

[4] Хәддән – чиктән.

[5] Билхасса – махсус рәвештә.

[6] Җилдләрчә – күп томнардан торган.

мөстәшрикъ[1] Казембек тарафыннан зур кулда, яхшы кәгазьдә, кырыенда читенрәк сүзләрнең вә урыннарның шәрехләре белән заманасына күрә әгъля[2] рәвештә бастырылды. Шуннан соң ул тагын ничә мәртәбәләр табигъ ителде[3]. 1891 елгы басмасы тагы да тулырак вә матуррак иде. Хәтта аның рәсемле басмалары да булды. Зур китап булып шулкадәр күп басманы күтәрүе үзе бу әсәрнең безнең халык арасында мәкъбулиятен[4] вә тоткан урынын күрсәтәдер.

## Сугыш китаплары

### I

Безнең халыкның сөеп укый торган әсәрләре арасында үзенә бер төрле типтагы «сугыш китаплары» атала торган хикәяләр бар. Бу хикәяләрнең мәүзугысы[5] – төрле каһарманнарның далилек[6], дилавәрлек[7] вә баһадирлыкларын тасвирдыр. Бу тип кыйссалар бездә матбугат туганчы, мөселман хәрефләре белән китаплар басыла башлаганга кадәр кульязмаларында халык арасына таралып укылган[8]. Ләкин, тәәссефкә каршы[9], ул кульязмалар җыелмаган: башка кульязмаларыбыз шикелле тәләф[10] булып бетәләр инде...

---

[1] Мөстәшрикъ – шәрык белгече.

[2] Әгъля – бик яхшы, югары.

[3] Табигъ ителде – бастырылды.

[4] Мәкъбулиятен – хуш күрелүен.

[5] Мәүзугысы – темасы.

[6] Борынгы җәнүб төркчәсендә «дали» – батыр, гайрәтле дигән сүз. Мәсәлән, «Китабе Коркыд»та Дали Домрул бар. *(Авт. иск.)*

[7] Дилавәрлек – батырлык.

[8] Бу мәкаләне язучының Сөләйман Аитов көтепханәсендә бөтен галәм әдәбиятында гомуми мәүзуг булган Искәндәр хакында бик калын, матур каләм белән язылган «Искәндәрнамә»не күргәне бар. Шулай ук Казандагы бер карттан, Захарьевский урамда бер кешедә берничә җилдле бер сугыш китабы булып, шуны күрше-күлән укыр өчен алып тора торган булуын ишеткәнебез бар. *(Авт. иск.)*

[9] Тәәссефкә каршы – кызганычка каршы.

[10] Тәләф – әрәм-шәрәм булу.

Сугыш китаплары безнең Казанда иске госманлы төрк шивәсендә яки татарчалашкан казакъ, кыргыз телендә басылганнар. Боларның саф татар шивәсендә булганнары юк. Шулай да, соңгы елларда яңа әдәбият чыккач та, халык бу әсәрләрне укуны ташламады. Хәтта «Каһарман катыйль», «Фәттахеддин» шикелле мөһимнәре соңрак елларда саф татарчага тәрҗемә кылынып басылдылар. Без бу урында госманлы шивәсендә генә булган сугыш китаплары хакында сөйләячәкбез. Шуны гына әйтеп китәргә кирәк ки, һәм госманлыча, һәм казакъчаларының мәншаләре[1] бердер. Алар икесе дә Иран шигалегенең[2] вә Иран хорафатының куәтле тәэсире астында язылганнар яисә ясалганнар, җыелганнар.

Сугыш китаплары мөндәриҗә[3] җәһәтеннән ике сыйныфка бүленәләр: берсе – хәзрәте Гали вә аның угылларыннан Хәсән, Хөсәен яисә Мөхәммәд Хәнифәнең[4] һәм аларның нәселеннән киткән Сәид Баттал вә аның угылларының сугышларын тасвир. Икенче бертөрлесе – һич Галигә мөнәсәбәтләре булмаган милли Иран вә госманлы каһарманнарының сугышлары хакындагы хикәяләр. Беренче бүлекнең идеологиясе «әгълаи кәлимәтулла»[5] вә исламның рәваҗе[6] өчен, икенчесе исә коры батырлык өчен сугыш; ләкин соңгыларында да бәгъзы вакытта «әгълаи кәлимәтулла» идеологиясе күренеп китә. Соңгы тип сугыш китапларының каһарманнары борынгы Иран геройлары Рөстәм, Дара, Әфрасияб күк кешеләр нәселеннән киләләр.

Сугыш китапларының зоһуры[7] хакында бер катгый фикер сөйләр өчен, Төркиянең йөрәге булган Кечек Азиягә барып,

---

[1] Мәншаләре – чыганаклары.

[2] Шигалегенең – шигыйлыгының.

[3] Мөндәриҗә – эчтәлек.

[4] Мөхәммәд Хәнифә (637–701) – күренекле рухани, Гали бине Әбү Талибның өченче улы. Аның нәсел дәвамчылары Урта Азия җирләрендә ислам динен таратуга зур өлеш кертәләр.

[5] Әгълаи кәлимәтулла – Аллаһ сүзенең өстенлеге.

[6] Рәваҗ – таралуы.

[7] Зоһуры – килеп чыгуы.

шундагы мәддах[1] вә дастан сөйләүчеләрне күрү, тыңлау, аларның сөйләгән әкиятләрен язып алу тиешле. Шуның соңында гына аларның ничек килеп чыгулары вә маһиятләре[2] хакында гыйльми нәтиҗә чыгарырга мөмкин булачак. Ходавәндигяр вилаятенең телен тикшерүче вә анда сәяхәт кылучы рус мөстәшрикы Марковның[3] әйтүенә күрә, Кечек Азиядә дастанчылар бик күп булып, шулар калаларга килеп, төрле каһарманнар хакындагы кыйссаларны сөйләп, җырлап йөриләр, имеш.

Госманлы телендә булган сугыш китаплары, тел, өслүб вә язу рәвешләренә күрә, һәммәсе дә – асылда, халык әсәрләре. Безнең фикеребезчә, халык телендә сөйләнеп йөри торган кыйссаларны алып, госманлы китапчылары нәшер иткәннәр. Соңра ул әсәрләр әллә безнең арабызга басылган килешме, кулъязма хәлендәме, хаҗилар аркылы яисә махсус китап сәүдәгәрләре аркылы килеп таралганнар. Соңра безнең наширләребез, үткәннәрдә ифрат яңгыш басылган яисә язылган госманлы оригиналыннан тагы да фахишрәк итеп күчереп бастырып, безнең арабызга таратканнар.

## II

Беренче тип дип атадыгыбыз, каһарманнары Гали вә аның угыллары булган сугыш китаплары Казанда әллә никадәр басылып тордылар. Боларның кайсысы берничә кыйссаны эченә алган мәҗмуга шәкелендә булып, кайберсе исә шул кыйссаларны аерып басудан гына гыйбарәт иде. Шулар эчендә иң күп басылган вә укыла торган ике китап бар. Берсе – «Кыйсса-и Фәттахетдин», икенчесе – җиде газаватны: 1) Кан кальгасындагы, 2) Хәйбәр кальгасындагы сугышларны, 3) «Бә Замр Аташпәрәст», 4) «Газават-е Мөхәммәд Хәнифә бә Газнәфәр», 5) «Баждарһа дәр мәгъриб», 6) «Газават-е имам Хәсән»,

[1] Мәддах – ода язучы.
[2] Маһиятләре – үзенчәлекләре.
[3] Марков Е.Л. (1835–1903) – рус язучысы, сәяхәтчесе, этнографы.

7) «Газават-е имам Хөсәен» аталган вакыйгаларны эченә алган бер мәҗмуга.

Бу сугыш китаплары бөтен төрк-татар арасында таралган дини хикәя вә догалык хасиятләре күк башланалар: пәйгамбәр, бер намазны укып бетергәч, аркасын михрабка биреп утыра; шуннан Җәбраил аңар вәхи[1] китерә. Шуның нәтиҗәсендә бер җирне фәтех итәргә[2] яисә бер илнең башына мөсәлләт булган[3] булган бер явыздан я бер бәладән котылдырырга, яисә аның җаны бер киек кәбабы[4] тели дә, шуны ауларга бер батыр сахабәсен җибәрә. Менә шул киткән кешенең башыннан үткән эшләре, «сәргезәшт»[5]ләре белән хикәя башланып китә.

«Фәттахетдин китабы» шулай башлана: бер вакытта рәсүл вәгазь әйтеп мәчеттә утырганда, аның киек ите ашыйсы килә. Пәйгамбәрне сыйлар өчен, Сәгъд ибн Вәкъкас, Әбү әл-Миһҗан атлы ике батыр сахабә ауга китәләр. Ауда күп йөри торгач, кызып китеп, алар бик ерак җирләргә баралар. Кяферләр белән очрашып сугыша башлыйлар. Ниһаять, шунда Сәгъд ибн Вәкъкас, бер патша кызына гашыйк булып, аны мөселман итеп өйләнә. Үзе зур сугышлар кыла: әллә ничә мәртәбә әсир төшә. Әбү әл-Миһҗан да бик авыр хәлдә кала. Шушы читен чакта «җир төрелә» дә, пәйгамбәр мәчет манарасыннан аларның кяферләр тарафыннан чолганып калуларын күрә. Менә пәйгамбәр, бик ашыгып, аларга булышырга Малик Әждәр исемле бер батырны күндерә. Ләкин эш һаман үсә. Бөтен кяфер дөньясының башлары, патшалар, каһарманнар мөселманнарга һөҗүм итәләр. Ниһаять, пәйгамбәрнең әмере белән хәзрәте Гали китәргә мәҗбүр була. Эш зурайганнан-зурая. Иранның иске хорафи каһарманнары эшкә катышалар. Бер яктан Иранның мәҗүс көче, икенче яктан мөселманнарның көчләре бер-берсенә каршы килә. Берсенең башында Җәмшит торса, икенчесенең башында Гали тора.

[1] Вәхи – берәр фикерне Аллаһ тарафыннан пәйгамбәрнең күңеленә салу.
[2] Фәтех итәргә – яулап алырга.
[3] Мөсәлләт булган – җиңеп үз кулы астына алган.
[4] Кәбаб – куырма.
[5] Сәргезәшт – баштан үткән хәл, вакыйгалар, маҗаралар.

Ниһаять, Галигә каршы җитмеш аршын буйлы Салсал ләгыйнь куела. Шулай ук мөселманнарның ифрат хәйләкәр, Исхак галәйһиссәлам догасын белүче, дошман күзенә Адәм пәйгамбәрнең кабереннән алган туфракны сибеп сукыр итүче Галинең дусты Гомәр гайярга[1] каршы Җәмшиднең сахирләре[2] куела. Ниһаять, галәбә[3] Гали белән мөселманнар ягында кала. Гали Иран зәминне[4] мөселман итеп, сахабәләр белән бергә тантаналы рәвештә Мәдинәгә кайта.

Без монда пәһлеваннар, әүлияләр, патшалар, җазу вә сахирләр типлары белән бергә бер гайяр тибын күрәбез. Бу тип бары Гали катышкан хикәяләрдә генә була. Әмма башкаларында исә баһадирлык белән гайярлык бергә җыела.

Бу әсәрдә без атәшпәрәст[5], потпәрәст мәҗүс Иран галәме белән ислам галәменең, сихер белән кәрамәтнең, тылсымнар белән догаларның («Исме әгъзам», Исхак галәйһиссәлам догасы) тартышуын күрәбез. «Фәттахетдин»дә бөтен төрк вә гайре төрк халыкларының халык эпикасында булган гонсырлары[6] табыла: «җиде», «җитмеш» саннарының күп истигъмале; мантыйксызлык, бер генә төрле дә табигый уңайсызлыклар, заман, урын, сан, көч белән хисаплашмау шикелле; гаскәр булса, җитмеш мең, дүрт йөз мең, хәтта дүрт йөз җирдә дүрт йөз меңгә җитә; Гали вә башка батырларның, ач арыслан күк акылга сыймаслык күп гаскәр эченә кереп, сансыз кяфер кыруы; зөлфикаре белән сукканда, дошманны аты белән бергә ярып төшеп, җиде кат җирне үтеп килгәндә, җирне күтәреп торучы үгез белән балыкны кисмәсен дип, Алланың Җәбраилне җибәреп, кылычны тоттыруы – һәммәсе дә шул халәтнең, садә акылының көзгеләредер. Галинең – дошманы Салсалның күзенә тимер кыздырып басуы аркасында җиңүе, коелар, андагы җыланнар,

[1] Гайяр – гайрәтле кеше, батыр.
[2] Сахирләре – сихерчеләре.
[3] Галәбә – җиңү, өстенлек.
[4] Зәминне – җирен.
[5] Аташпәрәст – утка табынучы.
[6] Гонсырлары – өлешләр, элементлары.

диюләр, «Әлфе ләйлә»дәге күк еланнар патшасы – менә болар да шул халык әдәбиятының элементларыдыр.

«Фәттахетдин»гә иң күп тәэсир иткән нәрсә – Иран мифологияседер. Җәмшид шаһ, утка табынучылар[1] белән сугыш, Иранның милли ярым мәгъбүдләре[2] диюләр, Рөстәм бине Заль белән батырларны чагыштырулар, аждаһаларның эшкә катышулары – һәммәсе шул иранизм галәмәтләредер. «Фәттахетдин»нең теленә кергән фарсы сүзләре янә шул иранизмны куәтлиләр.

## III

Галинең Кан кальгасындагы сугышларына килсәк, анда да шул «Фәттахетдин»дәге гонсырларны күрәбез. Ләкин вакыйга гына башкачарак башлана. Пәйгамбәрнең яңа гына Мәдинәгә һиҗрәт итеп килеп, Мәдинәнең хорафи[3] патшасы Сәгыйд бине Гыйбадның хакимиятне пәйгамбәргә тапшырган көне. Сәгыйд пәйгамбәрне углының сөннәт туена чакыра. Һәрбер сахабә туйга үзе белән бер бүләк алып килә. Ләкин Гали шулкадәр ярлы ки, бүләк итеп алып барырлык бернәрсәсе дә юк. Ул хатыны Фатыйма белән дә киңәшеп карый, ләкин бернәрсә дә таба алмыйлар. Аны кызганып, хәтта фәрештәләр елашалар. Ләкин Алла аларны юата: «И бәнем мәляикләрем, сезләр сакин[4] улалың. Хикмәт вар. Янә бән белүрем, зира хәбибем Мөхәммәд Мостафаның ахыр заманда бер белүк гасый[5] өммәтләре киләләр, бәнем әмереме, аның сөннәтене тәрк итеп[6], җәһәннәм газабына лаек улалар. Анлары гафу итеп, җәннәте әгъляда гали мәкам[7] вирәм», – ди. Шуның соңында фәрештәләр туктыйлар. Менә төнлә белән Гали, Фатыймага да әйтмичә, бүләк өчен мал табып

[1] Гәрчә бәгъзы урыннарда «Атәш» урынына иске гарәп тәңреләре Лат вә Мәнат телгә алыналар, ләкин бу сирәк очрый. *(Авт. иск.)*

[2] Мәгъбүд – пот.

[3] Хорафи – иске; элеккеге.

[4] Сакин – хәрәкәтсез.

[5] Гасый – гөнаһлы.

[6] Тәрк итеп – ташлап, кире кагып.

[7] Гали мәкам – югары дәрәҗә, урын.

кайтырга чыгып китә. Иртәгесен, аталары югалганга кайгырып елаган Хәсән вә Хөсәеннең үтенүләре аркасында, пәйгамбәр Галине эзләргә Халид бине Вәлид атлы тарихи батырны җибәрә. Гали исә күп сугышлар кылып, харикылгадә[1] шәхесләр белән сугышып йөри торгач, еракта-еракта «Кан кальгасы» дигән, һәр җире кызыл алтыннан эшләнеп, кырыйлары тылсымнар белән тутырылган бер шәһәргә барып җитә, шунда озак сугышлар кылган соңында, Халид бине Вәлид белән бергә күп мал төяп, Мәдинәгә алып кайтып, Сәгыйд бине Гыйбадка һәдия итә.

«Җиде газават» эчендә тарих тәэсиренә иң күп бирелгәне, азмы-күпме тарихи вакыйгага терәлгәне – Галинең Хәйбәр кальгасен мөхасарә кылгандагы[2] баһадирлыкларыдыр. Анда шул һәрбер халык хикәяләрендә булганы шикелле җазулар[3], манара күк озын каһарманнар белән сугыша.

Мәҗмугада бу хикәя бетүгә, икенчесе башлана. Ул хикәянең исеме «Газават имам Гали дәр Бәрбәр бә Замр Атәшпәрәст». Бер көнне пәйгамбәр аркасын михрабка биреп утырганда, теле киселгән гаять матур бер егет килеп кереп, Бәрбәр илендәге Замр Атәшпәрәст дигән бер явыз кешедән зарлана.

Мәсьәлә болай булган була: егет Инҗилдә Мөхәммәд пәйгамбәр вә ислам дине хакындагы бәшарәтне[4] күреп, гаибанә[5] иман китергән була. Замр аның мөселман булганын белеп, телен кисә. Шуннан соң ул Мәдинәгә качып килә. Менә пәйгамбәр батырларга мөрәҗәгать кылып, егетнең үчен алырга һәм Бәрбәр илен фәтех итәргә[6] кем бара дип сорый. Малик Әждәр, Гомәр бине Мәгад һәм Халид бине Вәлид чыгалар да, фатиха алып китәләр. Ләкин китүчеләрдән Гомәр вә бик күп кешеләр әсир төшәләр. Алты йөз кеше үтерелә. Менә шул эшне Җәбраил ки-

[1] Харикылгадә – гадәттән тыш.
[2] Мөхасарә кылгандагы – камап алгандагы.
[3] Җазу (җаду) – сихерче, күрәзәче.
[4] Бәшарәт – хәбәр.
[5] Гаибанә – читтән торып.
[6] Фәтех итәргә – яулап алырга.

леп пәйгамбәргә хәбәр биргәннән соң, ярдәмгә Гали китә. Ул барып сугышып, Бәрбәр илен мөселман итеп кайта.

Татар арасында Гали мөшарәкәт кыла[1] торган яңадан берникадәр хикәяләр йөри (мәсәлән, «Кисекбаш китабы» вә башкалар); ләкин без мисал өчен аларның иң әһәмиятлеләреннән югарыда сөйләнгәннәрне генә алып, шуның белән канәгатьләнәбез. Болар, гомумән, һәммәсе дә бертөсле: һәммәсендә Гали, аның Дөлдөле, зөлфикары, аның «Санчо Панса»сы булган Канбәр иштиракь кылалар[2]. Дөлдөл вә зөлфикар – сугыш китабында бик мәшһүр нәрсәләр. Аны аңлау өчен безгә бары Галинең шушы сүзен генә алырга кирәк: «Бу кылычка узан[3] дисәм, узар биш колач, әгәр аждәрһа ул дисәм, аждәрһа улыр, әгәр ут ул дисәм, ут улыр, җиһаны якар». Шуның өчен әле дә халык балаларның кәләпүшенә шул кылычның калайдан ясаганын тага. Дөлдөл дә – бик гаҗәеп хайван: «Ул аттыр кем, боңа Дөлдөл дирләр, кырык көнлек юлы бер көндә алыр вә кырык көн йимә[4] дисәм, йимәз вә эчмәс, вә куәте зәгыйфь улмаз вә сикертмәктән йөрелмәс, усанмаз вә сахибене кыюб китмәс вә бән чакырдыгым вакыт булынур вә һәр нәрәйә кирәксә варыр вә бәндән гайре кеше дөньяда улдыкча өстенә бенмәз».

Бу сугыш китапларының идеологиясе дә һәммәсендә бер: кяфер илен алу, кәлисәләрен егу, ягу, алар урынына мәчет вә мәдрәсә бина кылу. Димәк, бөтен икътисади куәтен сугышка баглаган борынгы госманлы төркнең сипаһы[5] вә янычәриләренең идеалы бу әсәрләрнең төп нигезләре буларак яткан.

---

Галинең угыллары катышы белән булган вакыйгалар хакындагы хикәяләр дә нәкъ беренче нәүгълары[6] шикелле. Аларның

[1] Мөшарәкәт кыла – катнаша.
[2] Иштиракь кылалар – катнашалар.
[3] Узан – озынай.
[4] Йимә – ашама.
[5] Сипаһы – гаскәре, армиясе.
[6] Нәүгълары – төрләре.

мөһимнәреннән берсе – шул ук «Җиде газават»тагы «Газават-е Мөхәммәд Хәнифә бә Газнәфәр кяфер галәйһи ләгънәт» аталган хикәядер. Монда да бер вакытта пәйгамбәр «иртә намазын укып бетереп, аркасын михрабка биреп утырыр иде». Гали кайсар-е Рум[1] белән булган сугышыннан кайтып керә. Кайсарның башын кискән, кызы Хәнифәне әсир итеп алып кайткан була. Кыз мөселман була да, Гали аңар өйләнә. Аннан бер ир бала туа. Баланы Мөхәммәд Хәнифә кушалар. Ул бик батыр, бик куәтле булып чыга. Дүрт яшенә җиткәндә, йөз егерме төрле һөнәр өйрәнеп җиткән була. Бер көнне ул ауга чыгып китеп, адашып кала. Йөри торгач, күрә: бер чатырның эчендә бер кыз утыра. Аңарга җан-дилдән гашыйк була. Кыз да шулай ук. Бер-берсен күрүләре белән, гаять көчле тойгыларыннан икесенең дә һушлары китә. Дәфгатән[2] Газнәфәр кайтып килә. Мөхәммәд Хәнифә аның сиксән мең гаскәре белән сугышырга тотына. Кяферләрне кыра-кыра гаҗиз була, һич бетерә алмый. Мәдинә дә Гали углының кайтмаганына кайгыра башлый. Шуннан Җәбраил килеп, пәйгамбәргә баланың әсир булганлыгын белдерә. Гали еларга тотына. Ул шулкадәр кайгыра ки, «бер аһ итеп ... агызыннан бер томан чыгып, Мәдинәнең эче караңлык булды». Шуннан соң ул углын котылдырырга юлга чыга. Тагы шул, гадәттәгечә, Галинең батырлыклары башлана. Ниһаять, ул углын котылдырып кайта.

Шул ук мәҗмугада Галинең өч углы – Хәсән, Хөсәен вә Мөхәммәд Хәнифәнең батырлыкларын тасвир иткән бер хикәя бар. Галинең бу өч углы бергә ауга чыгып китәләр. Бөтен төрк вә башка халык хикәяләрендәге шикелле, монда да юл өчкә бүленә. Һәрбер юлның башына язылып куелган була: «Саг юла кидән сәламәт килә. Урта юла кидән килә я килмәя. Сул юла кидән һич килмия» дип[3]. Сул юлга Хәнифә агаларын җибәрми,

---

[1] Кайсару Рум – Рум императоры.

[2] Дәфгатән – кинәт, көтмәгәндә.

[3] Бу тәфсилатны русларның халык хикәяләрендәге ошашы белән чагыштыруны тәүсия итәбез (киңәш бирәбез). *(Авт. иск.)*

үзе китәргә карар бирә. Васыятьләрен дә әйтә. Аерылышыр алдыннан Хәсән аңар бик каба[1], чын Анатулы төркчәсе белән бер шигырь укый. Өчесе өч юлга кереп китәләр. Ниһаять, күп мәшәкатьләр күреп, әйләнеп кайталар.

Мәшһүр Сәид Баттал китабы да – шул ук өслүбтә вә тарызда[2] язылган иң типичный бер «сугыш китабы», ләкин аерата мөһим әсәр булганлыгы өчен, аның хакында аерым мәкалә булачак.

## VI

Без хәзер сугыш китапларының каһарманнары нә сахабә, нә изге, нә Гали вә аның угыллары булмаган, сугышлары дини максат өчен булмыйча, чын дөньяви мәнфәгать вә идеаллар өчен булган, исламият тәэсиренә аз бирелгән хикәяләргә күчәбез. Аларның берсе генә безнең күзебезгә чалынды, ул исә «Мәлик Дараб углы Фируз шаһның җазулар[3] белә газа кыйлганның[4] кыйссасы». Бу әсәр – 140 сәхифәлек зур гына бер китап, аның мөндәриҗәсе шактый чуар вә чуалчыклы. Халык әсәрләрендә табыла торган садәлек тә монда аз[5].

Вакыйгалар шулкадәр күп, иштиракь кылучы каһарманнар шундый төрле ки – чуалып бетәргә мөмкин. Иран шаһы Мәлик Дараб (Дара – Darius) Рум кайсары кызына өйләнә. Шуннан бер ир бала туа. Шул ук чакта шаһның Иран каһарманы «Шаһнамә»нең мәркәзи шәхесе булган Рөстәм Заль нәселеннән килә торган Пилруз исемле пәһләванның углы Фәрхзад да дөньяга килә. Менә әсәрнең күп геройлары арасында шушы ике шәхес беренче скрипка урынын ишгаль итәләр[6]. Ләкин Фәрхзад үзе аерым роль уйнамый. Бәлки ул күбрәк Фәйруз шаһка

[1] Каба – начар, бозык.
[2] Тарызда – үрнәктә.
[3] Җазу (җаду) – сихерче, күрәзәче.
[4] Газа кылганның – сугышканының.
[5] Янә шул ук типтагы бер сугыш китабының башсыз, ахырсыз вә исемсез кульязмасы Каюм Насыйридан калган таркау кәгазьләр арасында табылды. *(Авт. иск.)*
[6] Ишгаль итәләр – алып торалар.

булышчылык кыла. Фәйруз шаһ, җәннәт мисаллы бакчада үзенең иптәшләре белән назик[1] тәрбия алып үскәндә, бер кичә төшендә ифрат матур бер кыз күреп гашыйк була. Ул төшне Тыйтус хәким юрый. Йәмән патшасы Шаһсорурның Гайнелхәят исемле кызы булганлыгын белдерә. Менә Фәйруз шаһ яшерен генә үзенең ике иптәшен ияртеп сәфәр кыла. Юлда зур сугышлар, авыр мәшәкатьләр, тылсымлы урыннар, җазулар очраталар. Әлхасыйль, томанлы, романтик шәрык хыялы безгә ифрат матур, колак ишетмәгән, күз күрмәгән хикәятләр, гүзәл манзаралар вә тасвирлар бирә. Чынлап та, бу әсәр укырга бик рәгъбәтле[2], ләкин, күренеп тора ки, ул чын халык әсәре түгел, бәлки аны бер үткен каләмле, хыялга бай госманлы төреге Иран хөдүдендә[3] халык авызында йөргән хикәяләрдән алып язгандыр яисә фарсыча бер-бер әсәрдән тәрҗемә иткәндер дип уйлана. Теленең сонгыйлыгы[4], гарәп-фарсы сүзләренең күплеге шуны ук күрсәтәләр. Ләкин шулай уйларга мөмкин булса да, әсәрдә халык әдәбияты гонсырлары[5] да күп очрыйлар. Ихтимал ки, бу гонсырлар үзләре «Әлфе ләйлә», «Шаһнамә» шикелле әсәрләр аркылы кергән булалар. Мәсәлән, «Әлфе ләйлә вә ләйлә»дәге бер хикәянең каһарманы рух кошының аягына эләгеп очса, Фәйрүз шаһның дусты Кадир шаһ та, кошка ябышып очып, бер бәладән котыла. Шулай ук әсәрдә Фирдәвеснең «Шаһнамә»се тәэсире дә бар: мәсәлән, Пилруз, Рөстәм исемнәре шикелле.

Шунысы искитәрлек ки, бу әсәрдә ислам тәэсире бик аз. «Сәид Баттал» китабында каһарманнар шәраб эчмәгәннәре хәлдә, мондагы геройлар һич тарсынмыйча эчәләр. Хәтта бу эш шул кадәрлегә җитә ки, каһарманнар исереп китеп, әсир дә төшкәлиләр. Монда сугышлар да «әгъла кәлимәтулла»[6] өчен

[1] Назик – гүзәл.
[2] Рәгъбәтле – кызыктыргыч.
[3] Хөдүдендә – чигендә.
[4] Сонгыйлыгы – ясалмалылыгы.
[5] Гонсырлары – элементлары.
[6] Әгъла кәлимәтулла – Аллаһ сүзләренең өстенлеге.

түгел. Шулай да бер урында Фәйрүз шаһ дошманын, үтергәнче, дингә өндәп ташлый.

Башка сугыш китапларында гыйшык гонсыры булса да, ул беренче роль уйнамый. Каһарманнар хәзер висалга[1] ирешеләләр, әмма монда драматизм куәтлерәк, мәгъшукасына кавышканчы, каһарманнар зур мәшәкатьләр күрәләр.

Әсәрнең теле госманлы шивәсе булса да, анда чыгтай тәэсире дә бераз күренә. Мәсәлән, бер урында «Бәңа гасый вә ягый уласән»[2] диелә. Ләкин шунысы кызык: ифрат тантаналы бер госманлы теле белән язылып килгән арада, без анда соңгы татар күчерүче яисә басучылары тарафыннан кертелгән рус сүзләре очратабыз. Мәсәлән, «Ат әрыз көррәидә[3] мәгълүм дәгел ки, бер падишаһның стойлосында аның кеби ула». «Шул гөл күк тай кем һичбер падишаһның стойлосында юкдыр». Бу, билгеле, татар мосаххихларының[4] эшедер. «Гөл күк тай» гыйбарәсе дә шуны күрсәтә. Моннан башка да Казан татар шивәсендәге сүзләр очрыйлар. Мәсәлән, бер урында госманлыча «атә» урынына «атау» языла.

Гомумән, бу әсәр тасвири вә шигъри җәһәтләреннән башка сугыш китапларыннан өстен тора. Андагы ифрат матур тасвирлар шәрык тормышын безнең күз алдыбызга китерәләр. Хәтта бу яктан ул «Сәид Баттал» китабына караганда да югарырак тора.

## «Сәид Баттал» китабы

### I

Безнең Идел буе татарларының, шулай ук бөтен төрк халыкларының сөеп укый торган китаплары арасында янә бер сугыш китабы бар: ул исә «Мәнакыйбе[5] Сәид Баттал гази» яки, безнең

[1] Висалга – кавышуга.
[2] Бәңа гасый вә ягый уласән – Миңа каршылык күрсәтүче һәм дошман буласың.
[3] Әрыз көррәидә – Җир шарында.
[4] Мосаххих – төзәтүче, корректор.
[5] Мәнакыйб – мактаулы эшләр язылган әсәр.

халык әйткәнчә, «Сәид Баттал китабы»дыр. Бу – госманлы төркисе телендә язылган зур гына бер китап: алты кисәккә бүленеп, бер төптә басылган. Һәр кисәген «җилд» дип атаганнар. Бу әсәр Истанбулда ташбасма вә типография белән берничә мәртәбә басылган. Безнең Казанда да берничә басмасы булган. Шулай ук Яурупа көтепханәләрендә дә аның кульязмалары бар.

Бу мөһим әсәрне өйрәнүнең тарихын сөйләп китәбез. Билгеле, ничә йөз еллар дәүләт төзеп торган госманлы төркләре үзләре аны иң элек тикшерә башларга тиеш иделәр. Ләкин аларның галимнәре тарафыннан язылган китапларда да, «Тәзкират-е шугараи» исемендә әдәбият тарихына даир XVI–XVII гасырларда чыккан әсәрләрдә дә без аның хакында бер сүз дә күрмибез. Әлхасыйль, төркләр үзләренең мондый «каба»[1] телле әсәрләренә әһәмият бирмәгәннәр.

Әмма Яурупа голәмасы тик ятмаган. Бу әсәрне дә тикшерергә керешкән. XVIII гасырның Яурупа мөстәшригы д'Эрбело[2] үзенең «Шәрык көтепханәсе» («Orientalische Bibliotek») исемле әсәренең беренче җилдендә Сәид Баттал хакында булган хикәяләрнең барлыгын белдереп китә. Һаммер-Пургшталь 1836 елда нәшер ителгән «Госманлы әдәбияты тарихы»нда («Geschichte der Osmanischen Gedichte»), бу «Мәнакыйбе Сәид Баттал» хакында сөйләп, аның гарәпчә «Гантәрә» исемле әсәр күк «шевалье» романнарыннан[3] берсе булганлыгын һәм аның мәгълүм бер мөхәррире булмаганлыгын әйтеп китә. Ләкин Һаммерда шуннан артык сүз юк. Шул рәвешчә, госманлы әдәбиятын тикшерүчеләрнең күбесе «Мәнакыйбе Сәид Баттал гази»га да туктап киткәннәр. Ләкин бу хакта чын классик әсәр 1848 елда

[1] Каба – бозык, начар.

[2] Бартелеми д'Эрбело де Моленвиль (1625–1695) – француз шәрыкшинасы, мөселман илләре тарихы һәм әдәбияты турында 8600 дән артык мәкаләне үз эченә алган «Шәрык көтепханәсе» энциклопедиясенең авторы. Шәрык мәдәниятен фәнни нигездә беренче өйрәнгән Европа галимнәреннән.

[3] Русча – рыцарские романы. *(Авт. иск.)*

чыккан доктор Флейшернекедер (Dr. Fleischer)[1]. Бу тикшерүдәге фикерләрнең кыскачасы шул: Сәид Баттал хикәясенең төп кыйссасы – яңа гарәп хикәятләреннән берсе. Әсәр бер тарихи әсаска[2] да салынмаган: бинаән галәйһи[3], тарихи бер факт хакында сөйләми. Чын шигъри хыял үзәрендә салынып эшләнгән нәрсә. Сәид Батталның үзенең кайсы заманда булган зат икәнлеге мәсьәләсендә Флейшер VIII гасырның соңгы яртысы белән IX гасырның урталарында булган кеше булырга кирәк, ди. Флейшер фикеренчә, кыйссадагы Сәид Баттал – үзенең фикере, рухы, табигате җәһәтеннән чын госманлы каһарманы. Аның эчендә сөйләнә торган вакыйгаларның бик иске заманнан алынганлыгы исә – бары госманлы шагыйрьнең борынгылыкны идеализация ясый торган романтизмыннан гына килгән нәрсә. Әсәрдә сөйләнә торган хикәянең төп вакыйгасы – исламның шәркый Рума империясенә каршы сугышыдыр. Әсәрнең теле госманлы шивәсенчә булса да, анда «ягъ» (җау, дошман) шикелле чыгтай сүзләре дә табыла. Аның теленә гарәп вә фарсы сүзләре дә катышкан. Өслүбе бик садә, әсәрнең кайчан зоһуры мәсьәләсенә даир мөндәриҗәсе, өслүбе вә теленә карап, Флейшер әсәрнең госманлы дәүләтенең Кече Азиядә тамыр җәя башлаган заманда, XIV яки XV гасырларда зоһур иткәнлеге яисә шул заманда халык авызыннан язылып алынганлыгын бәян кыла. Менә Флейшернең фикерләре кыскача гына шуннан гыйбарәт.

1871 елда «Мәнакыйбе Сәид Баттал»ның доктор Херман Эте (Ethe)[4] тарафыннан ителгән бер тәрҗемәсе килеп чыга[5]. 321 сәхифәлек, вак хәреф белән басылган бу тәрҗемә Яурупа тәнкыйд методының иң каты зарбәсе[6] астыннан чыккан. Эте

[1] Бу әсәр Sitzangberichte der Königlichen Saclisischen Akademic дә басылган. *(Авт. иск.)*

[2] Әсаска – нигезгә.

[3] Бинаән галәйһи – шуңа күрә.

[4] Карл Герман Эте (1844–1917) – немец шәрыкшинасы. Ислам кульязмалары каталогларын төзи һәм фарсы әдәбиятын немец теленә тәрҗемә итә.

[5] Die Fahrten des Sajjd Battal, Leipzig, 1871. *(Авт. иск).*

[6] Зарбәсе – зыяны.

тәрҗемә кыла башламас борын, «Мәнакыйбе Сәид Баттал»ның Яурупаның төрле көтепханәләрендә булган биш кульъязмасын һәм Казан мөстәшригы Готвальдның Флейшергә (Казаннан булырга кирәк) күндергән бер татарча кульъязмасын алып тикшереп чыга[1]. Бу галим күрә ки, кульъязмалары бер төсле түгел. Кайсында бер урын, кайсында икенче бер урын җитешми. Шуның соңында ул һәммәсенә уртак булган урынын тәрҗемә кыла. Әмма әсәрнең ахырында артык булган нөсхәләрнең урыннарын китереп үтә. Шунда ук бәгъзы аңлашылмаган урыннарын шәрех кылып та китә. Эте тәрҗемәнең мөкаддимәсендә, Флейшер фикеренә кушылып, Сәид Баттал китабы госманлы төркләренең гадәт тасвир кылучы романы (Sitterromane) икәнен әйтеп китә.

Руслар да без тикшерә торган әсәрне бөтенләй игътибарсыз калдырмадылар. Профессор Смирнов[2] үзенең госманлы әдәбияты хакындагы әсәрендә[3] «Сәирате Сәид Баттал гази»ны (ул аны шулай атый) төрк халкының каһарман дастаны (героический эпос)[4] дип тәгъриф кыла. Аның фикеренчә, госманлы халкы арасында шундый бик күп дастаннар бар. Аларның бик азы җыелган. Әмма күбесен җыючы кеше юк. Әгәр мондый каба төрки әсәрләр хакында госманлы зыялысыннан сорасак, кыланып гримаса ясый да: «Фи, пис!» – дип җавап бирә. Менә шул дастаннарның берсе – «Сәирате Сәид Баттал гази». Аның теле хакында Смирнов Флейшер белән бер фикердә: иске госманлы төркисе, ди.

Ниһаять, мәшһүр мөстәшрикъ Бартольд та бер урында Сәид Батталга кагылып уза. Ул аны Коркыд белән чагыштыра. Ул әсәр турында түгел, ләкин Сәид Батталның характеры хакында

[1] К. Этенең бу сүзеннән моразы нидер – мәгълүм түгел. Ул үзе бер урында (Bd. I 3, 251) татарча нөсхәдә «күстәрделәр» (gösterdilar) дигән сүзнең булганын әйтә; вә халәнки, бу чын госманлы сүзедер. *(Авт. иск.)*

[2] Василий Дмитриевич Смирнов (1846–1922) – рус шәрыкшинасы, тюрколог.

[3] История Всеобщей литературы под редакцией Корша, т. IV; статья Смирнова «История Турецкой литературы». *(Авт. иск.)*

[4] Кирилл хәрефләре белән язылган.

яза. Шулай да сүз арасында бу әсәрне ул «Баһадирлар дастаны» (богатырский эпос)[1] дип атый. Һәм әсәрдә китап вә язма әдәбият тәэсиренең күп икәнен әйтеп уза[2].

## II

Сәид Баттал китабының мөндәриҗәсе бик садә. Сугыш китапларының бик күбесендә булган күк, монда да эш Мөхәммәд пәйгамбәрдән башлана. Бер көн иртә намаздан соң пәйгамбәр үзенең сахабәләре белән утыра. Җәбраилнең аның янына күптән килгәне юк. Шуның өчен ул бераз кәефсез. Менә шунда ул: «Йа әсхабләрем, диләрем ки, өчегездән берегез бер ләтыйф хикәят яисә сәргезәшт[3] идәсез, бераз аңа мәшгуль улаем», – ди. Шуннан соң әсхаб арасыннан бер яшь кенә, ләкин күпне күргән Габделваһаб исемле егет торып, Рум илен мактый, аның табигать вә һавасын сөйли, соңра аның халкының кяфер булганлыгын бик тәэссеф итеп[4] бәян кыла. Менә шул вакытта Җәбраил фәрештә килә. Алладан бүләк – бәшарәт[5] китереп, Румның бер вакыт мөселман булачагын белдерә; Алланың «Бән дәхи ул вилаятьне өммәтенә рузи кылсам кирәкдер ки, кәлисәләрен йыкалар, йиренә мәсҗед вә мәдрәсә бөнияд итәләр[6]» дигән сүзен вә Румны фәтех кылачак[7] кеше Җәгъфәр исемле булып, аның да Гали нәселеннән килгән адәм булачагын аңлата. Менә Габделваһабның: «Шул вакытка кадәр тора алачак кеше булырмы?» – дип соравына каршы, Җәбраил, яңадан килеп, Алланың Габделваһабка ике йөз ел гомер биргәнен вә аның шул Җәгъфәр белән бергә сугышлар кыласын белдерә. Пәйгамбәргә Алланың: «Габделваһабның авызына төкерсен дә шул төкерекне Габделваһаб Җәгъфәрнең авызына салсын», – дигән әмерен

[1] Кирилл хәрефләре белән язылган.

[2] Зап. Восточ. Отд. Имп. Рус. Арх. Общ., том VIII, вып. III–IV (1893–1894), Бартольд, «Китаби Коркуд». *(Авт. иск.)*

[3] Сәргезәшт – маҗаралар.

[4] Тәэссеф итеп – кайгырып, үкенеп.

[5] Бәшарәт – шатлыклы хәбәр.

[6] Бөнияд итәләр – төзиләр.

[7] Фәтех кылачак – яулап алачак.

сөйли. Менә шуннан соң кыскача гына пәйгамбәр, аннан соң килгән хәлифәләр, Гали, Хәсән вә Хөсәеннең шәһит булулары сөйләнә. Соңра Җәгъфәрнең яшь вә сабый чагын, аның тәрбиясен сөйләп, турыдан-туры Җәгъфәрнең мәнакыйбенә[1] тотыла. «Мәнакыйб»тә Сәид Баттал күбрәк румлар һәм мәҗүсләр белән газа кыла[2]: сахир[3] вә җазулар, диюләр белән сугыша: әллә ничә мәртәбә әсир төшә: авырый, тагын терелә. Бик күп осталыклар вә кәраматләр күрсәтә.

Бу «Мәнакыйб»тә сөйләнә торган Сәид Баттал чынлап та тарихи шәхесме, әллә хыялмы – уйдырма гынамы?

Мондый кыйссалардагы каһарманнар һәрвакытта тарихи шәхесләр булалар. Ләкин бу Сәид Батталның шәхесе безгә шактый караңгы. 748 нче һиҗридә вафат булган мөәррих Зәһәбинең[4] сөйләвенә күрә, «әл-Баттал» ләкабендәге[5] бу Мөхәммәд нам затның[6] корал куәте белән эшләгән эшләре хакында бик күп хыялый кыйссалар сөйлиләр. Аның хәяты хакында зур гына китап та язылган, ләкин ул кыйссалар бик хыялый вә хакыйкатьтән ерак[7]. Шулай ук мөстәшрикъ д'Эрбелоның әйтүенчә, «Сира әл-мөҗаһидин» намындагы гарәпчә бер кыйсса китабында (26 нчы бабында) бу батыр хакында бераз гына мәгълүмат бар. «Тарихы Табари»ның госманлы теленә тәрҗемә кылынганының 3 нче җилдендә дә без Сәид Баттал хакында шактый гына кызык әкиятләр табабыз[8]. Шәмседдин Саминең «Камус әл-әгълам»енең 4 нче җилдендә: «Сәид Баттал гази мөшаһир каһарманан

---

[1] Мәнәкыйбенә – мактаулы эшләренә.

[2] Газа кыла – сугыша.

[3] Сахир – сихерче.

[4] Әбү Габдуллаһ Мөхәммәд ибн Әхмәд ибн Госман ибн Каймаз Шәмседдин әз-Зәһәби (1274–1348) – имам, мөхәддис, галим.

[5] Ләкабендәге – тәхәллүсле.

[6] Нам затның – исемле кешенең.

[7] Orientalische Bibliothek, Bd. I, s. 605. *(Авт. иск.)*

[8] Бу хакта Кәтиб Чәләбинең берникадәр мәгълүмат биргәне мәгълүм булса да, без «Кәшф әз-зөнүн»да бу хакта бер нәрсә дә таба алмадык. Бәлки башка бер әсәрендә сөйләгәндер. *(Авт. иск.)*

исламидан[1] бер гази намдар[2] улып, риваятә күрә 121 тарихында румларә каршы улан газада[3] шәһид улмышдыр. Ходавәндигяр вилаятенең Искешәһәр казасында вакыйг[4] Сәид гази касабәсендә[5] кабере кәшеф улынарак[6] мөлүк сәлҗукән Галәэддин валидәсе тарафыннан бина улынмыш», дип әйтеп китә. Профессор Смирнов Сәид Баттал хакында бәгъзы төрк тарихчылары госманлы сөляләсе[7] чыкканчы хөкем сөргән Данешмәнд сөләләсенең башы дип әйтәләр, ди[8].

Әсәрнең үзендә аның кайчан язылуы хакында турыдан-туры бер хәбәр дә юк[9]. Алай да аның эчтәге вакыйгаларны тикшергәндә, бер нәтиҗә чыгарырга мөмкин. Әсәрдә Бабәк[10] хакында сөйләнә. Бу исә 837–[8]38 милади елларда булган вакыйга. Шуның өстенә дә әсәрнең башында шундый бер сүз бар: «Чын хаким рисаләт тәмам ула ике йөз елдан соңра бер егет куба». Бабәк вакыйгасы белән бу ел туры килә. Димәк, Баттал – IX гасыр кешесе.

Бу кеше кайсы җенестән, төркме, гарәпме, иранлымы? Анысы мәгълүм түгел. Шулай да гарәпләшкән бер төрк булуы бик мөмкин. Ихтимал, Баттал хәлифәләр янындагы төрк хасса ала-

---

[1] Мөшаһир каһарманан исламидан – мәшһүр мөселман каһарманнарыннан.

[2] Гази намдар – атаклы, шөһрәтле батыр.

[3] Газада – сугышта.

[4] Казасында вакыйг – идарәсенә караган.

[5] Касабәсендә – шәһәрчегендә.

[6] Кәшеф улынарак – билгеле булып.

[7] Сөләләсе – династиясе.

[8] История турецкой литературы, стр. 448. *(Авт. иск.)*

[9] Сәид Батталның Гали вә Фатыйма аркылы пәйгамбәргә барып тоташканы хакында хәбәр әсәрнең үзендә дә бар. (Дрезден көтепханәсендәге нөсхәдә Сәид Батталның шәҗәрәсе дә яшерелгән. Ул шәҗәрә буенча Сәид Баттал сигезенче буында – пәйгамбәргә, илле бишенче буында Адәм пәйгамбәргә барып терәлә. Ләкин бу ифрат хыялый бер шәҗәрә (Ethe, Geschlechtsregis ter des Sultan S. Battahl, s. 218–219). *(Авт. иск.)*

[10] Бабәк (789–800 ел тирәсе – 838) – Төньяк-Көнбатыш Иранда, Азәрбайҗан провинциясендә Гарәп хәлифәлегенә каршы баш күтәргән хуррамитлар восстаниесе җитәкчесе.

ен (гвардия)[1] булып хезмәт иткән «голәм»лардан[2] яисә шулар җенесеннәндер.

Зәһәбинең Сәид Баттал хакында хыялый зур бер китап язылган дигән сүзеннән, һәрхәлдә, бу кыйссаның бер төрлесе XIV–XV гасырларда ук булганын күрсәтә. Шул ук фикерне куәтли. Ләкин бәгъзы нөсхәләрдә «ук» белән бергә «туф»ның[3] (мылтык) дигән сүзнең истигъмаль кылынуы[4], һәрхәлдә, әсәрнең XIV гасырдан иртә язылмаганын (дөресрәге, җыелмаганын) белдерәдер: чөнки мылтык Шәрыкта аннан иртә истигъмаль кылына башламаган.

## III

«Мәнакыйбе Сәид Баттал гази» бер аерым мөхәррир әсәре булмаска тиеш. Ул, башка сугыш китаплары шикелле, халык әсәре.

Рус мөстәшрикъләреннән Максимовның әйтүенә күрә[5], әле дә Истанбулда бер кызык вакыйга очрый: вилаятьләрдән төрле дастанчылар килеп, халык җыеп, төрле сугыш хикәяләре сөйлиләр: аларны халык бик сөеп тыңлый. Бизанес[6] вә гарәпләрнең, гомумән, ислам халыкларының гарәп христианнары белән озак канлы мөҗадәләләре[7] дә халык күңелендә калган, хыялга бай халык дастанчылары бу сагынмалыкларга тагы үзләреннән дә арттырганнардыр. Кечек Азия төреге үзенең христиан галәме белән булган сугышларын кушкан шул кыйсса авыздан авызга, атадан балага сөйләнеп йөргән. Менә Сәид Баттал хикәясе дә – шуларның берсе. Ниһаять, шуны язып алганнар да. Күп кулъязмаларында йөри торгач, аны наширләр бастырганнар. Шундый

[1] Кирилл хәрефләре белән язылган.
[2] «Голәм»лардан – ир-егетләрдән.
[3] Туф – туп; пушка.
[4] Истигъмаль кылынуы – кулланылуы.
[5] Без алдагы бер мәкаләдә дә бу хакта әйткән идек, ул әсәрнең исеме: «Опыт исследования турецких диалектов Худавендикарского вилаята». *(Авт. иск.)*
[6] Бизанес – Византия.
[7] Мөҗадәләләре – бәхәсләшүләре.

кыйссаларның Кечек Азия телендә иң мәшһүре, бик табигый булганы «Китабе дәдам Коркыд илә лисане таифәи огузан» аталган кыйссада безнең фикеребезне куәтли торган шундый бер урын очратабыз: «Кулҗа купыз күтәреп илдән илә, бәкдән бәкә узан кизәр. Ар җумрдин ар нәкисен узан белүр»[1]. Без шундый ук урынны «Мәнәкыйб»ның башында очратабыз:

«Җәмигъ идәнләр кыйссаның һәнгямәсен,[2]
Бөйлә язмышлар хикәятнамәсен».

Моннан аның халык иҗаты бер әсәр икәне бик ачык күрелә. Шуның өстенә әсәрнең эчендәге күп сүзләрне тәкрарлау Һомәрнең «Илиада» вә «Одиссея»сын искә төшерәләр[3]. Чөнки хикәят сөйләүче кеше никадәр тиз сөйләсә дә, никадәр мәддах[4] сүзгә оста булса да, ул хикәяне хәтеренә төшереп торырга мәҗбүр була; әмма аңар туктап торырга ярамый; шуның өчен ул, бер яктан, уйлый, икенче яктан, машина шикелле хәзер җөмләләрне тәкрарлап тора.

Шулай ук әсәрдә, иҗатчының язуыннан бигрәк, сөйләү белдерә торган башка урыннар да юк түгел; күп җирдә «әмма сән кыйссаи башка йөздин дыңла», «нә кыйссаи дираз[5] идәлем» күк сүзләр әйтә. Әсәрдә әдәби булмаган чын халык сүзләре дә очрыйлар. Мәсәлән, Баттал китә башлагач, хатыны да аның белән бергә китәсе килә. Аңар ул бик каба гына: «Һәләюк улмаз сән, унда утыр», – ди. Халык мәкальләре дә бик еш очрыйлар: «Илчийә үлем юкдыр», «Язылмышта бозылмыш юк» күк.

[1] Бу хакта мәгълүмат: Зап. Восточ. Отделения Императ. Археолог. Общ., том VIII, 1893–94, вып. III и IV. Шунда Бартольдның «Китабе Коркыд» дигән мәкаләсе бар. Бу урынны шулай тәрҗемә кылырга кирәк: «Кулына кубыз тотып, җырчы халыктан халыкка, биктән биккә йөри, кем гайрәтле, батыр, куркак икәнен җырчы белә». *(Авт. иск.)*

[2] Һәнгямәсен – тупланмасын.

[3] «Култыгы алтындан шөйлә җалдикем», «Әленең дөресе гөрзү кабында калды», «Варалым, мөхәммәдиләре кылычтан кичерәлем», «Кайсар таҗын җуйды, кинә тотты», «Таҗын йирә орды», «Батталым кярләрә каналым» вә башка шуның күк тәкрарлар. *(Авт. иск.)*

[4] Мәддах – мактаучы.

[5] Дираз – озын, дәвамлы.

Шулай ук «каныды» (ачуланды), «бәҗид-бәҗид[1] сөйләр» күк[2] халык сүзләренең, җиде, җитмеш, кырык, кырык мең, ике йөз мең шикелле халыкның иң сөя торган саннарын истигъмале дә – әсәрнең халык иҗаты икәненә дәлилдер. Шулай ук анда күчмә төрк халыкларында бик күп очрый торган кан дошманлыгы (родовая вражда)[3] бик мәгълүм вә гади нәрсә итеп сөйләнә. Димәк, монда шәригать тәэсире ул кадәр күп юк. Бөтен милләтләрнең халык хикәяләрендә очрый торган зәнкиләрнең (великан)[4] булуы; шәрык халык дастаннарының каһарман вә җәгърафия мәүкыйгларыннан[5] булган Искәндәр Зөлкарнәйн, Җәзу, Каф тавы, Сәмругларның бик күп очравы да шул фикеребезне куәтли. Ниһаять, әсәрнең аһәңенең балаларча садә булуы, мантыйксызлыгы да безнең гипотезага көч бирә.

Менә шушы дәлилләргә бинаән[6], без шулай уйлыйбыз: «Мәнакыйбе Сәид Баттал» – халык әсәре. Аның мөхәррире юк. Рус былиналары[7], «Илиада» ничек тәртип ителгән булса, ул да шулай ук килеп чыккан. Без дә моны госманлы төркләрнең «каһарман эпосы» (героический эпос)[8] дибез.

Мондый әсәрләрдән безнең арада таралганнары арасында тагын берсе бар. Ул исә госманлыларның фәрәнкләр[9] белән сугышын тасвир итүче «Сары Салтык гази»дыр.

«Сәид Баттал китабы» – халык әсәре булса да, ул китап вә, гомумән, әдәбият тәэсиренә бирелгән бер әсәр. Бу – әсәрне тәртип итүчеләрнең укымышлы кешеләр булуыннан килми, бәлки

[1] Бәҗид-бәҗид – кызып-кызып.

[2] Бәгъзы сүзләрне «Мәнакыйб» борынгы мәгънәсендә, мәсәлән, «чалды»-ны хәзерге госманлыларда булган «урлады» мәгънәсендә түгел, безнең шималь төркләре истигъмаль кыла торган мәгънәдә куллана (инәр көн чалды, ике парә әйләде). Шулай ук бәгъзы урында «гөнаһ» урынына чыгтай сүзе «үч» кулланыла. *(Авт. иск.)*

[3] Кирилл хәрефләре белән язылган.

[4] Кирилл хәрефләре белән язылган.

[5] Мәүкыйгларыннан – урыннарыннан.

[6] Бинаән – нигезләнеп.

[7] Кирилл хәрефләре белән язылган.

[8] Кирилл хәрефләре белән язылган.

[9] Фәрәнкләр – французлар; европалылар.

Сәид Баттал хикәясенә тәэсир иткән фикерләр Шәрыкта шулкадәр тәгъмим кылынганнар[1] ки, аларны һәркем белә: алар хәтта үзләре халыкныкы булып беткәннәр. Шул тәэсирләрдән берсе – ислам дине вә аның хорафатының тәэсиредер. Мәсәлән, без анда Рабига Годувия дигән бер изге хатынны очратабыз. Монда без, бер яктан, китап тәэсирен күрсәк, икенче яктан, бу изгенең халык арасында шөһрәте бик таралган бер кеше булганлыгын беләбез. Әсәргә шактый гына «Шаһнамә» вә «Әлфе ләйлә вә ләйлә» тәэсир иткән. Билгеле, бу тәэсир турыдан-туры түгел: алар бары хикәяләрне тәртип итәргә материаллык хезмәтен иткәннәр.

Бу әсәргә без ике мөселман халкының тәэсирен күрәбез: иран вә гарәп. Беренчесенең тәэсире күбрәк. Бәгъзы нөсхәләрдә бөтенләй фарсыча җөмләләр дә бар. Бөтен Иран мифологиясе әсәрнең түренә кереп утырган. Сәид Батталны Иран каһарманнары белән бер дәрәҗәгә куйдыру өчен, төрк халкы аны Рөстәм балаларыннан берсе белән сугыштырып җиңдертә. Шул Иран мифологиясендәге күк монда да ике төрле куәт хәрәкәт кыла: диюләр һәм пәриләр. Пәриләр алар бит-табигъ[2] кабахәт нәрсәләр түгел. Аларның Сәид Батталга иганәт кылучы мөселманнары да бар, әмма кайсыларын ул үзе мөселман итә. Алар дәүләт ясап торалар, патшалары да бар. Хәтта бервакытта пәри патшалыгының башында Сәид Батталның угыллары да торалар. Диюләр исә – монда да «Шаһнамә»дәге күк явыз куәтләр. Сәид Баттал алар белән Һиндстанга барып сугыша. Аларның кыяфәтләре дә яман: «Башы тоңуз башына бикзәр[3], колаклары фил колагына бикзәр, пәнҗәләре[4] арыслан пәнҗәсенә бикзәр, койрыгы аждарһа койрыгына бикзәр, вә ике арыслан вә ике әленә алмыш илә орды кем, парә-барә улдылар». Гомумән, Иран тәэсире шулкадәр куәтле ки, исемнәрене алганда да, Иран исемен алырга маил[5] күренә. Мәсәлән, Хушнасиб вә башкалар. «Мәнакыйб»тәге

[1] Тәгъмим кылынганнар – таралганнар.
[2] Бит-табигъ – табигате буенча.
[3] Бикзәр – охшаш.
[4] Пәнҗә – ерткыч хайванның алгы аяклары.
[5] Маил – тартым.

кяфер каһарманнар да нары нурга[1] табыналар: алар да «Шаһнамә»дәге каһарманнар күк атәшпарәстләр, мәсәлән, Рум каһарманнары да шул ук нары нурга табыналар, гәрчә әсәр Рум халкының нәсрани икәнен бик яхшы белә. Баттал аларның кәлисәләрен ягасы килә; аларга барып, Инҗил аятьләре укып, кәшиш вә рәһбаннарның[2] исләрен китерә.

## IV

«Мәнакыйбе Сәид Баттал»ның төп каһарманы – Сәид Баттал үзе. Анда башка затлар: Әхмәд Тәран (Таран) Габделваһаб, Габдессәлам, Әмир Гомәр, Мәэмүн вә башка хәлифәләр. Кайсарлар һәммәсе дә – әһәмиятле кешеләр түгел: алар операларда, хорда җырлаучы җырчылар кабиленнән генә, алар бары Сәид Батталның каһарманлыкларын күрсәтә торган манзараның фоны гына. Шуның өчен без Сәид Батталның шәхесен тикшереп карыйк.

Сәид Баттал үзе тарихи шәхес булу җәһәтеннән гарәп булырга бик мөмкин булса да, ул төрк дастанчыларының йөрәгеннән чын төрк булып чыккан. Ул Рум белән сугышта чыккан төрк рыцаре – гази кеби. Аның идеалы – Румны мөселман итмәк. Кәлисәләрен якмак, йиренә мәсҗед вә мәдрәсә япмак, шушы госманлы төркенең империализм фикере бөтен әсәргә сеңгән[3]. Сәид Батталның икенче идеалы – шәһит булу. Менә шул фикер вә омтылу аңар курку бирми, шуның аркасында ул ничә йөз мең дошман гаскәренә берьялгызы һөҗүм итә. Аның иң зур идеалларыннан берсе – кешегә иганәт[4] кылу. Ул үзенең дусларына зур булышлыклар ясый: аларны котылдыру өчен әллә нинди куркынычлы вакыйгалар арасына атыла, әсир төшә, зинданга

---

[1] Нары нурга – утка.

[2] Кәшиш вә рәһбаннарның – монахларның.

[3] Баттал соңра бу идеалына берникадәр ирешә дә. Кайсар Аматур ислам кабул итә. Аның углы Тәкфур мөселман кайсар булып тора. Хәтта, бер нөсхәгә караганда, Тәкфур белән Сәид Батталның углы Бәшир икесе бергә кайсар булып торалар. *(Авт. иск.)*

[4] Иганәт – яхшылык, изгелек.

ябыла. Ул хәтта үзенең хосусый дошманына да булышлык кыла: аның мохалифе (сопернигы)[1] Малатьянең (Меллатия) сәргаскәре[2] Габдессәлам Сәид Батталның яшь заманасында аңар әллә никадәр начарлыклар эшләгән була. Сәид, моңарга карамыйча, аның әсир төшкәнен белгәч, Румга барып, аны хәляс итә[3]. Бу да гомум Урта гасырлар рыцарьлыгы таифәтенең[4] мөһим ноктадарыннан берседер. Сәид Баттал кяферләр арасындагы хокуксызлык (бесправие)[5] һәм явызлыкларга да чыдый алмый. Бер вакытта Багдад хәлифәсе янында баш казый булып торган, Сәид Батталга әллә никадәр явызлыклар эшләгән бөтен хилафәтнең[6] яшерен серләрен кайсарга белдереп торган, тыштан – мөселман, эчендә нәсрани булган Гокбәне махсус Истанбулга барып җәза кыла. Җәза кылып кыйнаган чагында ул: «Истанбулда казый булып торган вакытта ник Рум халкын алдадың, хыянәт иттең, ришвәт алдың, ни өчен син халыкка кәҗәне – сыер, сыерны кәҗә дип әйттең», – дип кыйный һәм Рум халкын яман казый кулыннан хәляс итә.

Сәид Баттал ифрат диндар, ул һичбер вакытта намазын куймый, кяфер гаскәре чолгап алып, ук сырпап торганда, намазын бозмый. Ул зинданда да гыйбадәт белән мәшгуль була. Ул ифрат сабыр, һичбер бәла вә казадан нәразыйлык[7] бәян итми. «Һәр ни әйләрсәм, Алла ризасы өчен әйләрем», – ди. Сәид Баттал – чын дәрвиш, заһид кеше. Ул фәкыйрь. Акча вә байлыкны сөйми. Ганимәт малыннан[8] бернәрсә дә алмый. Аны халыкка, газиларга өләшә. Аның хәтта балаларын укыта торган хәлфә – хуҗага бирергә бер әйбере юк. Бервакытта аның хатыны хәлфәгә сәдака – һәдия бирәсе килә. Шул вакытта ул «аркасына кидеге каф-

[1] Кирилл хәрефләре белән язылган.
[2] Сәргаскәре – гаскәр башлыгы.
[3] Хәляс итә – коткара.
[4] Таифәтенең – төркеменең.
[5] Кирилл хәрефләре белән язылган.
[6] Хилафәтнең – хәлифәлекнең.
[7] Нәразыйлык – ризасызлык.
[8] Ганимәт малыннан – сугышта кулга төшерелгән малдан.

танын чыкарды, угылларына һәдия өчен вирде». Аның хатыны Гөләндәм баерга мәслихәт итә. Ләкин ул Гали вә Мөхәммәдләрнең фәкыйрь булганлыкларын, аларга тәкълид кылырга теләгәнлеген белдерә. Баттал һичбер вакытта шәраб эчми, ялган сөйләми. Ләкин шулай булса да, ул бик хәйләкәр кеше, шуның өчен ул бер урында: «Йа гам[1]! Ирлек ундыр, токузы хәйләдер», – ди. Әмма ул – бик үзен сөя торган кеше. Үзенең каһарманлыкларында кешене шәрик[2] ясамас өчен, иптәшләр алмыйча, зур сугышларга берүзе генә китә.

Сәид Баттал – сыйныфташлары (гарәп рыцарьлары) шикелле бик гыйшыкчан кеше. Ул гомерендә берничә мәртәбә гашыйк була. Аның гыйшкы чын шәрыкча – ут шикелле кабына. Ләкин күп тә узмый, ул сөйгәнен оныта, яңаны сөя башлый. Гомумән, бу чын эпика (ривая) әсәре гыйшык мәсьәләсенә килгәч тә башкарып китә. Анда лирика гонсырлары катыша башлый. Матур тасвирлар очрарга тотына. Менә мисал өчен Батталның беренче гыйшкы тасвир иткән урынны күчереп китик: «Кыш кичде, бәһар[3] килде, галәм гөл, гөлзар, уҗымга дүнде[4]. Әмир Гомәр, Баттал гази атларә бенделәр, тәфәррež[5] идә-идә, бер су кәнаренә[6] килделәр, түнделәр. Сәид Баттал гази дилдекем[7] суйә керә атына бенде, суйи үтә кичде, бер йирә килде, керде, судан чыкды, әсвабларын[8] кидектә күрде: каршыда бер биек баг[9]. Эчиндә бер күшек[10], урта йирендә дивар япылмыш, эчрәсе ту[п] тулы дөрле әнваг[11] йимешләр, рәйханнар... Нәгяһ[12]

[1] Гам – халык.
[2] Шәрик – иптәш.
[3] Бәһар – яз.
[4] Уҗымга дүнде – яшеллеккә төренде.
[5] Тәфәррež – күңел ачу.
[6] Кәнаренә – читенә.
[7] Дилдекем – дигәне, исемлесе.
[8] Әсвабларын – киемнәрен.
[9] Биек баг – зур бакча.
[10] Күшек – сарай.
[11] Әнваг – сорт, төр.
[12] Нагяһ – кинәт, көтмәгәндә.

касрың[1] бер пәнҗәрәсе[2] ачылды, Сәид назар әйләде[3], күрде ки бер мәхбүбә кыз, буены, колагы ачык, сим[4] вә зәррә[5] эчендә мөстәгъръкъ улмыш[6], биленә дәкен тышрә чыкмыш, әтрафына бакар. Бең-бең[7] Йосыф Мысри вә Зөләйха уның катыда сәргәрдан[8] үлә, һәман сәгать[9] ул бакышда йөзинә җан күңелдән Сәид Баттал гази гашыйк улды». Шуннан соң Сәид әмир Гомәр янына киләә: «Бәкри[10] сорармыш гыйшык орды у[л]ды җанга кяр әйләмеш[11]».

Менә ул пәйгамбәрне төшендә күрә. Ул аңар өйләнергә куша, шуннан соң Сәид Баттал беренче мәртәбә Зәйнәп хатынга өйләнә. Менә шуннан соң ул мөттасил[12] өйләнергә тотына. Шуның өчен әмир Гомәрнең хатыны аның хакында: «Һәркайда варыр исә – үләнер», – ди. Ләкин Сәид үзе дә аннан оялмый. Аның дәлиле бар: «Рәсүлең токуз иде, бәнем ике улурсә нә лязим килүр», – ди. Ләкин кызлар аннан качмыйлар. Сораса, кияүгә барырга хәзер торалар: аларның фикеренчә, Батталның «һәр гозуына бер гаурәт кирәк», – диләр. Сәид Баттал дошманнар арасында бер арыслан шикелле хәрәкәт кылса, гыйшык тота башлады исә, бер романтик шагыйрьгә әйләнә: сөйгән кызының «капысына килеп утырып еглый» башлый, хәтта аның үлеме дә шул бер сөйгән кызының дивар өстеннән ыргыткан ташыннан була.

[1] Касрның – сарайның.
[2] Пәнҗәрәсе – тәрәзәсе.
[3] Назар әйләде – карады.
[4] Сим – көмеш.
[5] Зәррә – алтын.
[6] Мөстәгъръкъ улмыш – күмелеп утыра.
[7] Бең-бең – меңәрләгән.
[8] Сәргәрдан – аптыраштан.
[9] Һәман сәгать – тиз арада.
[10] Бәкри – яшь кыз.
[11] Кяр әйләмеш – тәэсир итте, йогынты ясады.
[12] Мөттасил – туктаусыз.

«Мәнакыйб»тә Баттал ифрат галим бер кеше итеп тасвир ителә. Ул әллә никадәр телләр һәм дүрт китапны[1] белә. Инҗил аятьләрен укып вәгазь әйткәндә, бөтен нәсрани руханилары елыйлар... Сәид – шагыйрь дә. Ул, хәлифә алдына килгәндә, нәзым белән генә сөйли. Ләкин аның нәзымы Хуҗа Насретдиннекеннән күп югары түгел. Сәид Баттал яшерен гыйлемнәрдән дә күбесен белә: ул үзен ихфайә чикеп[2], кеше күзенә күренмәс була ала. Ул – кәрамәт сахибе дә: авыруларны терелтә. Үлекләрне кабереннән чыгара[3]. Ул – табиб та: бик оста итеп кешеләрне дәва итә.

**V**

Һәрбер каһарманнар дастаны никадәр хорафи булмасын, анда чын тарихи вакыйгалар мөнгакис[4] булмый калмыйлар. Хәтта аларның кайсысы тарих ягыннан шулкадәр мөһим була ки, бер халыкның тарихын шул дастаннар буенча торгызырга мөмкин була. Әгәр «Илиада» вә «Одиссея» булмаса иде, каблəттарих[5] юнаннарның тарихын археология васитасы[6] белән генә торгызып булмас та иде. Менә бу Сәид Баттал хикәясе дә безнең госманлы төркләренең борынгы хәятын, бигрәк тә аларның беренче тарихи дәверләрендәге сугышчы сыйныфының хәятын торгызу өчен зур мәнбәгъ[7] була ала.

Бу әсәрнең төп мәүзугысы гарәп хорафатыннан алынган булса да, әсәр төркләрдә туган. Төп мәүзуг[8] гарәп тормышыннан алынган булуга карамый, аның каһарманнары – чын госманлы

[1] Биредә Аллаһ тарафыннан кешеләргә иңдерелгән дүрт дини китап күз уңында тотыла: Тәүрат, Зәбур, Инҗил, Коръән.

[2] Ихфайә чикеб – кеше күзенә күренми торган халәткә кереп.

[3] Халык та Сәид Батталны изге дип йөри. 1534 елда Сөләйман Кануни Багдад сәфәрендә аңар зиярәт иткән иде. Хәзер дә аның кабере Ходавәндигяр вилаятендә бер зиярәтгяһ, имеш. Халык арасында әле дә аның кабере хакында әллә нинди харикылгадә вакыйгалар сөйлиләр, имеш. *(Авт. иск.)*

[4] Мөнгакис – кире кайтарылган.

[5] Кәблаттарих – борынгы.

[6] Васитасы – арадашлыгы.

[7] Мәнбәгъ – чыганак.

[8] Мәүзуг – тема; сюжет.

төркләре рухлы кешеләр. Әгәр анда сәлҗук вә госманлы солтаннары урынына Габбас хәлифәләре куелган икән, Флейшер әйтмешли, ул – бары төрк дастанчыларының романтизмнарыдыр. Борынгы ислам дөньясының тагы да тантаналы дәверен күрәселәре килгәннән генә килгән. Шуның өчен ул хилафәт дәверенең тарихи фактлары безнең «Мәнакыйб»не язучыларга ят. Алар аны бары ганганә (традиция)[1] белән генә беләләр. Шуның өчен дә без монда хронологиянең чалмаштырып бетерелгәнен вә андагы күп каһарманнарның тарихи түгеллеген күрәбез. Шуның өчен дә Асатур, Тәкфур, Катус аталган кайсарларның исемнәре – тарихка мәгълүм түгел исемнәр. Шулай ук хәлифәләрдән Тумин (Тубил) ибн Мәгад, Мөслим, Бәхтияр исемнәре дә шулай. Әгәр әсәрдә Мәэмүн (бәгъзы нөсхәләрдә Мөэмин, Һеракл (Гераклий)[2] исемнәре зикер кылына икән, алар Шәрыкта бик мәгълүмлекләреннән, гарәп рыцарь романнарындагы Карл шикелле генә истигъмаль кылынганнар[3].

Ләкин тарихи фактлар монда турыдан-туры бирелмәгән. Алар күбрәк мөселманнарның, бигрәк тә төркләрнең (сәлҗук вә госманлылар морад) Рум кайсарлыгы белән булган сугышларын тасвир формасында мөнгакис[4] булган, шулай ук, шиксез, әсәргә әһле салиб[5] сугышлары хакындагы халык арасында йөргән легендалар да тәэсир иткәннәр. Бер урында бөтен кяфер вә мөселман галәменең бер-берсенә каршы сугышлары тасвир ителә, кайсар җитмеш ике милләтне җыеп, мөселманнар өстенә җибәрә, хәлифә шушы мөселман җирләренә намәләр пәракәндә кылып[6], гаскәр җыя: «Хиҗазә, Йәмәнә, таифә Төркестанә, Чин, Мачинә[7], Бохара, Көрҗестанә, Гыйракә вә Исфаһанә вә Тусә, вә хәдде Каравунә вә Хорасанә». Кайсар да шушы кяфер илләренә

[1] Кирилл хәрефләре белән язылган.
[2] Кирилл хәрефләре белән язылган.
[3] Истигъмаль кылынганнар – кулланылганнар.
[4] Мөнгакис – кире кайтарылган.
[5] Әхле салиб – христианнар.
[6] Намәләр пәракәндә кылып – язулар таратып.
[7] Чин, Мачин – Кытай, Һиндстан.

намәләр пәракәндә кылды: «Ул Франкстанә вә Румә вә Ханаанә вә Хунә вә Сәмәркандә (?) вә Черкисә (?) вә Мавәраэннәһерә (?) вә Сәрһәнкә вә Җәмшидийәйә вә һәр вилаятегә кяферстан иде». Бу мөселман вә гайре мөселман булган илләрне саташтырып санаудан шул мәгълүм була ки, «мәнакыйбчеләр» каршында ике галәм бар. Берсе – хәлифә, икенчесе – кайсар галәме. Бу сугышларны тасвирларда, бер дә шиксез, халыкның хәтерендә бабадан атага, атадан балага сөйләнеп килгән әһле салиб сугышларының яңгыравын ишетәбез...

Тарихи вакыйгаларны күрсәтә торган янә бер урыны булса, ул да Якын Шәрыкта төркләрнең сәяси рольләренең башлануын күрсәтүдер. Менә Малатья газиләре тәмам гаҗиз булган чакта, иганәткә хәлифә килә. Шуның гаскәре эчендә иң куәтле гонсыр[1] – ялан кылычлы, ук белән коралланган Харәзем егетләре була. Моннан морад, бер дә шиксез, Төркестаннан аз-аз хәлифәләрдә пәррә торйан – голям (углан) булып хезмәт иткән, соңра Якын Шәрыкта хакимиятне үз кулларына алган төркләрдер.

Әсәрдә чын бер тарихи вакыйга бар: ул да – хәлифәтнең тарихында шактый мөһим урын тоткан Бабәк вакыйгасыдыр. Дөрес, монда да вакыйга чын булган рәвештә тасвир кылынмый. Шулай да вакыйганың чын тарихи бер факт икәнен күрәбез. Һарун әр-Рәшид заманында ук бер мәзһәб бар иде. Аны «хөррәми» диләр иде. Бу мәзһәб ияләре, Август Миллер[2] фикеренчә, коммунистлар иде[3]. Мәэмүн заманында, 715–716 миладидан башлап[4], аларның башында Бабәк исемле бер кеше торган вә хөррәмиләргә зур көч вә мәгънәви энергия биргән иде. Ул борынгы Базз яисә Буд өлкәсенең хөкемдары Җаванданның (Djawenden) җаны миңа күчте дип ышанадыр иде. Икенче яктан Бабәк батыйниләр мәзһәбеннән иде. Аларның игътикадынча[5],

[1] Гонсыр – өлеш, элемент.
[2] Фридрих Август Мюллер (1848–1892) – немец шәрыкшинасы.
[3] История Ислама, II, 196. *(Авт. иск.)*
[4] Басмада хата киткән. Дөресе: 815–816 еллардан башлап.
[5] Игътикадынча – ышануларына күрә.

Коръәннең һәммә сүзен киная тарикынча (allegorish) аңларга кирәк вә алар бөтен әхкяме шәргыягә[1] каршы иделәр. Мөәррих Вейльнең[2] әйтүенчә, ул иң сул шига (Ultrasehied), ләкин шигалыгы борынгы Иран дине булган зәрдөштлек белән катышкан иде. Аларның сәяси максатлары да габбасиларны төшерү иде[3].

Бабәк хакында безнең «Мәнакыйб» шулай сөйли: «Шимди бер кеше пәйда улды, пәйгамбәрлек дәгъвасын идәр, ук бармас вә кылыч кисмәс вә атәш[4] якмас. Шәрабә хәләл дию вә адәмиләрен атларын белүр вә анасы адын белүр, сөйләр вә йирдән мал чыкарыр вә һәр нә дирсә улыр. Кызы атайә вә карендәше карендәшә хәләлдер дир. Ике дәфга[5] Шами орды вә харап әйләде вә җөмләсе аңа йөз тотды. Кемсә аңа мокабил[6] улмаз, чук вилаятьләр харап әйләде вә Гаҗәме[7] тотды», ди. Янә бераздан дәвам итеп: «Андан бер кач[8] дәүләтсез булыр, анлар илә хөррәмилек идәрләр вә һәр кандә[9] бер хөррәсез варса, фетнә беpeгүр вә бер көн дәхи утырур ки бер пир шәкелендә, якында бер кемсә килүр. Андан Бабәк сорар: «Сән нә кесисең[10]», – дир. Ул дәхи: «Бән Җәбраилем, сән пәйгамбәр, сәңа кәлдем ки, әгәр сүзем тотарсән, тәмам каму дөньяни тотарсин». Менә монда әллә никадәр хыяләт эчендә халыкның күңелендә сакланып калган хакыйкать бар. Гаиләне танымау, ярлылар дәүләтсезләр белән берләшү күк борынгы Шәрык коммунизмына даир галәмәтләр бар... «Гаҗәме тотты» дигән сүзе дә – бер хакыйкать. Бабәкнең хакимияте шул Мидия, Армения, Азәрбайҗан вә Хорасанда иде. 826 елда ул инде Һәмәданны да узган иде[11]. Шулай ук әсәрдә

[1] Әхкяме шәргыягә – шәригать хөкемнәренә.
[2] Густав Вейль (1808–1889) – немец шәрыкшинасы. *(Авт. иск.)*
[3] Weil. Geschielite der Chalifen, Ed. II, s. 235 236.
[4] Атәш – ут.
[5] Дәфга – тапкыр.
[6] Мокабил – каршы.
[7] Гаҗәм – Иран.
[8] Кач – берничә.
[9] Кандә – кайда.
[10] Кесисең – кешесең.
[11] Мюллер II, 237.

аның Рум белән бергә хилафәткә[1] каршы хәрәкәте хакында сүз бар. Бу да бер хакыйкать. Ул Мәэмүн хәлифә заманасында Бизанес[2] белән берләшеп хәрәкәт кылган иде. Бабәк 837 елда әсир төшеп игъдам кылынды[3].

## Кыйсса китаплары

Татар халкы вакытын сугыш китаплары уку белән генә уздырмады. Аның укый торган китаплары җөмләсенә госманлылар аркылы гомумшәрыкның сөеп укый торган кыйсса китаплары да керде. Ул китаплар башта язма килеш укылсалар да, соңра նаширләр кайсысын – госманлыча килеш үк, кайсысын тәрҗемә кылам дигән булып, бозып табигъ иттерделәр[4]. Бу китаплар – хикәя яисә кыйсса китапларыдыр. Аларның саны шактый күп. «Тутыйнамә», «Кырык вәзир», «Хатәм Тай», «Әбү Гали Сина» кыйссалары – шулар җөмләсеннән. Бу әсәрләр, укырга кызык булулары белән бергә, Шәрык галәменең идеал вә фикерләрен укучының күз алдына китереп бастыралар.

Шәрык галәме Яурупаның озын романнары тибындагы әсәрләрне белми. Кызу кояштан саклаучы, ялкаулык китерүче күләгәлек урыннарда шәрыкларның кызу канлы угланнары гыйшык хакында җырларга, нечкә кыллы йөрәкләрне тиз тибрәтә торган сазлары белән үзләренең кояш шикелле кызу лирика әсәрләрен укырга, икенче яктан, күләгә төшкәч, чирәм өстенә чыгып, наргиләләрен чигеп[5], каһвәләрен эчеп, кәеф-сафа кылып, гаять хыялый хикәятләр, чәчләрне үрә торгызучы куркыныч кыйссалар сөйләшергә яисә шуларны укырга яраталар.

Шәрык әдәбияты ул – мораль-әхлакның да чын-чын оясы. Шәрык халкы кыйссадан хисса алырга бик сөя. Шуның өчен Шәрык әдәбиятында әхлакый әсәрләр бик күп. Бу кыйссалар,

[1] Хилафәткә – хәлифәлеккә. Биредә габбасилар хәлифәлеге күз уңында тотыла.
[2] Бизанес – Византия.
[3] Игъдам кылынды – юкка чыгарылды; үтерелде.
[4] Табигъ иттерделәр – бастырдылар.
[5] Наргиләрен чигеп – хурхур, кальян тартып.

белмим, Бәхре мохит һинди[1] буйларындамы, белмим, Һинд вә Ганг елгалары кырыйларындамы, әллә Дәҗлә вә Фырат[2] буйларындамы, әллә хыял белән тулган карт Нил буйларында әһрамнар[3] салынган чакларда укмы зоһур иткәннәр[4] – һәммәсе дә шул «Әлфе ләйлә» тарызында[5] тәртип ителгәннәр.

Бу кыйссаларның күбесенең калыплары яисә ясалулары, гомумән, бертөсле: һәммәсендә дә бер кеше икенчесенә хикәяләр сөйли яки төрле кешеләр бер-берсенә сөйләшәләр; бәгъзан хикәя эченә хикәя кертелеп бирелгән була, менә шул хикәяләр, барысы бергә җыелып, бер мәҗмуга тәшкил итәләр. Хикәяләр һәркайсы аерым-аерым мәүзугларда булсалар да, алар һәммәсе бер җепкә тезелеп, бер гомуми мәүзуг белән бер-берсенә бәйләнгән булалар. Бу тип хикәя мәҗмугаларын Гареб-Яурупа галәменең дә искерәк әдәбиятында очратып була. Аларның иң мәшһүрләреннән берсе – Боккачоның «Декамерон»ыдыр.

### *1. «Тутыйнамә»*

Элек без «Тутыйнамә» хикәяләре хакында сөйлибез. Бу хикәяләрнең мәүзугы – бөтен Шәрыкны гизгән Йосыф вә Зөләйхадан да искерәк мәүзуглардандыр. Серле хыял белән тулган мәңгелек хикәяләр ватаны Һиндстан – «Тутыйнамә»нең дә туган иледер. Бик борынгы заманнан бирле Һиндстанда санскрит телендә «Тутый» кыйссасы бар иде. Һиндстанда телдән телгә, гасырдан гасырга күчерелеп йөри торгач, бу мәүзуглар Иран туфрагына да барып керделәр. 1330 елда Нәхшәби[6] атлы Иран шагыйре бу әсәрне фарсычага тәрҗемә кылып, бәгъзы яңа хикәяләр дә арттырып язып чыгарды. Аның бу әсәре дә халыктан

[1] Бәхре мохит Һинди – Һинд океаны.
[2] Дәҗлә вә Фырат – Тигр һәм Ефврат елгалары.
[3] Әһрамнар – пирамидалар.
[4] Зоһур иткәннәр – барлыкка килгәннәр.
[5] Тарызында – рәвешендә, үрнәгендә.
[6] Зыя әд-Дин Нәхшәби (?–1350) – Һиндстанда яшәгән, чыгышы белән фарсы шагыйре, табиб, фәлсәфә һәм медицина трактатлары авторы.

халыкка, каләмнән каләмгә күчеп, арттырылып, киметелеп йөрде. Шуны ук 1661 елда вафат булган госманлы мөхәррире Сары Габдулла Әфәнде[1] төрекчәгә тәрҗемә итте. Моның тәрҗемәсе тулы булып, яңа хикәяләр дә арттырылган иде. Менә 1851 елдан башлап безнең татар арасында бераз гына татарчалаштырып нәшер ителеп килгәне шушы кешенеке булырга кирәк дип уйлана. Әсәрнең мөкаддимәсендә «Сәрир солтан мәнд араи бәрикяһ Госмани хәзрәтләре китаб мәзкүре гыйбарә мәрбут, кәлимат мәзбут илә тәхрир улынмасыны бу габде кәмтәрләренә фәрман боердыкларында»[2] дип, әсәрнең ахырында «Бу китаб мөстәтабың мөтәрҗим гаҗизенә»[3] дип дога үтенүе, бу әсәрнең шул Сары Габдулла тәрҗемәсе булуы ихтималын күрсәтәдер; ләкин бу хакта катгый бер фикер әйтергә мөмкин түгел; бәлки, аны бәгъзы урыннарын арттырып вә киметеп, бер-бер татар мөхәррире язып чыгаргандыр[4].

Аннан соң «Тутыйнамә китабы», 1887 елда Габделгаллəм Фәезханов тарафыннан саф татарчага тәрҗемә кылынып, 1891 елда нәшер ителде. Фәезханов бу тәрҗемәсен моңар кадәр Казанда басылган нөсхәдәнме, әллә юкта турыдан-туры Истанбул басмасыннанмы кылган – китапның мөкаддимәсендәге сүзләреннән бу ачык аңлашылмый. Анда ул әйтә: «Мин фәкыйрь сәрапа тәкъсыйр[5] Габделгаллəм Фәезхан углы, Казан вилаятемездәге кулланыла торган «Тутыйнамә» китабын

[1] Сары Габдулла Әфәнде (1584–1660) – төрек язучысы, каллиграф. Гарәп, фарсы телләреннән тәрҗемәләре, шул исәптән мәшһүр суфи шагыйрь Җәлаледдин Руминың «Мәснәви» әсәрен төрек теленә тәрҗемә итүе белән билгеле.

[2] Тәхет һәм фикер иясе, Госманлы солтаны әлеге китапны өстәлгән гыйбарәләре, сакланган сүзләре белән күчереп язуны бу кимчелекле колына боерды.

[3] Бу китаб мөстәтабың мөтәрҗим гаҗизенә – бу яхшы китапның гаҗиз тәрҗемә итүчесенә.

[4] «Тутыйнамә»ләрне тикшерүче Пертч (Pertsch) бу мәсьәләне хәл итә алмаган. Шулай да бу кеше Казанның 1850 ел басмасы белән Сары Әфәнденеке бер әсәр түгел микән дигән фикерне әйтеп китә. Бу мәкаләнең исеме шулай: Ueber Nachschebi Papageienbuc (Z.D. Dent. Morg. Geselschaft, Bd. 21, s. 508. *(Авт. иск.)*

[5] Сәрапа тәкъсыйр – баштанаяк гаепле.

госманлы төркләре телендә күреп вә ул телне безнең халкымызга аңлавы мөшкел булганлыктан, һәммә дәрд әһеле укып файдалансыннар өчен мәзкүр госманлы төркләре теленнән үз татар телемезгә тәрҗемә кылдым». Алай да аның Истанбул басмасыннан тәрҗемә иткән булуын тәхмин кылырга[1] мөмкин.

Безнең госманлыча «Тутыйнамә» белән Нәхшәбинең «Җәһел тутый»сы бераз аерылалар[2]. Нәхшәбинең шулай башлана: Һиндстан йортында Әхмәд исемле бер шаһ булган. Аның углы булып, Мәэмүн атлы кушканнар. Үскәч аны Хаҗәстә исемле кызга өйләндергәннәр. Яшьләр бер-берсен бик яратканнар. Мәэмүн бик шәп сөйләшә торган бер тутый сатып алып, аның үзенә генә күңелсез булмасын дип, аңа иптәш итеп, Шәрик атлы бер ана тутый да алган. Көннәрдән бер көнне шаһзадә ил гизәр өчен диңгез сәфәренә чыгып китә. Хаҗәстә үзе генә калып ямансулый башлый. Тәсадефән[3] аны бер чит ил шаһзадәсе күреп гашыйк була. Хатын аның белән кич күрешергә вәгъдә бирә. Элек ана тутый белән мәслихәт итә. Ләкин ул иренә хыянәт итмәскә куша. Шуның өчен Хаҗәстә аны үтерә, әмма ата тутый, хәким зат булганга, аңар төрле хикмәтле хикәя вә мәсәлләр сөйләп, бу эштән дүндерергә тырыша. Һәр кичне Хаҗәстә аның янына моң вә зарын сөйләргә һәм гыйшкын аңлатырга керә. Әмма тутый аңар хикәятләр сөйләп вакытын уздыра да, таң атып иртә була. Шулай итеп, шаһзадә кайтканчы, Хаҗәстә белән теге чит ил шаһзадәсе күрешә алмый калалар.

Безнең төркчәдә эш бераз башкачарак. Суф тарафында бер олуг шәһәрдә Сәгыйд исемле бай сәүдәгәр тора. Ул, баласы булмаганлыктан, бик кайгыра. Аллага гыйбадәт кылып, сәдакалар бирә. Ахырысында аның хатыны бер ир баласы китерә. Атын Сәгыйд куялар. Ул үсеп буйга җиткәч, Маһишәкәр исемле бер матур кызга өйләндерәләр. Кыз белән егет шулкадәр

[1] Тәхмин кылырга – чамаларга.

[2] Бу әсәр Яурупа телләренә бөтен килеш тәрҗемә кылынмаган. Бәгъзы кисәкләре шәрык факультеты өчен Петербурда басылган. Янә русчага начар гына бер тәрҗемәсе бар: Болский и Сухотин. «Тути намэ». *(Авт. иск.)*

[3] Тәсадефән – кинәт.

бер-берсен яраталар ки, Сәгыйд бөтен эшен ташлый. Мөттасил[1] бикәче янында кәеф кыла. Атасы аңар нәсыйхәт йөзеннән бер хикәя сөйли. Соңра аңар мең алтын биреп, базарга сәүдәгә чыгара. Анда мең алтынга бер тутый саталар. Аны бик хәким вә зөфнүн[2] дип мактыйлар. Сәгыйд алырга курка. Тутыйның тәкъдиме буенча Сәгыйд аны хуҗасыннан алып тора. Шул ук базарда тутыйның мәслихәте буенча бертөрле малны җыя да, мал күтәрелеп китеп, Сәгыйд биш мең алтын файда итә. Шулай итеп, тутый аркасында аның эше рәтләнә. Тутый аңар диңгез сәүдәсенә барырга мәслихәт итә. Шул тутыйның сүзен тотып, Маһишәкәрнең елаганына карамыйча китә. Берничә көннән соң Маһишәкәрне бер Бикзадә күреп гашыйк була. Арада бер мәккярә[3] карчык йөри башлый. Маһишәкәр күрешергә разый була. Ләкин элек тутый белән киңәшә. Калганы Нәхшәбинеке төсле. Хатын тутый хикәяләре аркасында хыянәттән котыла. Тутыйны азат итәләр. Сәгыйд – хатыны белән рәхәт-рәхәт көн кичерәләр.

Әсәрдә 56 данә вак һәм эре хикәя бар. Болар һәммәсе дә – әхлакый кыйсса вә мәсәлләр. Бу хикәяләрдәге каһарманнар да – күбрәк хайваннардыр. Бу әсәрдә һәрвакыт мактала торган бер әйбер булса, ул да һәрбер эшнең «уртасы»дыр. Һәрбер ифрат[4] вә тәфрыйт[5] эшләр бу әсәрдә яманлана. Башка Шәрык әсәрләрендәге күк суфилык тәэсире монда аз. Дөньяны сөю, аңар якты караш белән карау – «Тутыйнамә»нең эчендә балкып тора.

Әсәрнең жанры күбрәк Госманлы иле хәятына ияртелгән Рум вә госманлы тормышы, аның каһвәсе, кәефе – һәрберсе анда җәелеп ята. Ләкин, томан аркылы гына булса да, әсәрнең үзенең төп ватаны булган Һиндстан да балкып киткәли: мәҗүс потханәсен тасвирда вә Галатха исемле бер брахманның хикәятендә, шиксез, Һинд күренә.

[1] Мөттасил – өзлексез.
[2] Зөфнүн – гыйлемле.
[3] Мәккярә – мәкерле, хәйләкәр.
[4] Ифрат – чамадан тыш.
[5] Тәфрыйт – эшнең очына чыкмау.

Әсәрдә дин фанатизмы бер дә юк. Шәраб эчү, саз уйнауларны, кәеф вә сафаны бик яратып тасвир итүләр, рәсем ясау – нәккашлек хакында күп кенә хикәяләрнең очравы – болар һәммәсе дә рәсми ортодокс исламнан ерак нәрсәләр. Төрек мөхәррире бу әсәргә никадәр дин рухы үрергә азапланып, бераз пәйгамбәр вә изгеләр хакында кыйссалар тыгып карамасын, анда һаман да иске мәҗүс рухы, һинд пантеизмы калган.

## *2. «Дастане Хатәм Тай»*

Шул ук госманлы теленнән безнең телебезгә, нәмәгълүм[1] шәхес тарафыннан татарчалатам дигән булып бозылып, басылып таралып, хәзергә кадәр укыла торган, халык арасына юмарт кешеләр хакында әйтелә торган зарбе мәсәл[2] булып киткән Хатәм Тай хакындагы кыйсса китабы да кергән.

Хатәм Тай, дөресрәге Хатәм Тайи – тарихи бер шәхестер. Бу кеше Әбү Гади бине Габдулла бине Сәгыйд исемле булып, гарәп арасында үзенең ифрат юмартлыгы белән мәшһүр бер шагыйрь булган. Ул пәйгабәрнең яшь чакларында әле сәламәт булган, имеш. Соңра бу кеше хакында гарәпләрдә легенда вә кыйссалар ясалган хакта бу ганганә[3] «Әлфе ләйлә вә ләйлә» һәм Шәйх Сәгъдинең[4] бәгъзы әсәрләренә дә кергән иде. «Әлфе ләйлә» аның юмартлыгының үлгәч тә дәвам кылганлыгын белдереп, аның кабере яныннан үтеп баручы ач юлаучылар аннан мәдәд[5] эстәгәч, аларга Хатәм Тай гаибдән бер дөя йөге ашамак-эчмәк нәрсәсе биргәнен сөйли[6]. Бәгъзы гарәп мәнбәгъләре[7] Хатәм

[1] Нәмәгълүм – билгесез.

[2] Зарбе мәсәл – күп очракта мисал итеп китерергә яраган сүз.

[3] Ганганә – телдән телгә күчереп сөйләнгән хәбәр.

[4] Сәгъди (Әбү Мөхәммәд Габдулла Сәгъди Ширази, 1203–1210 – 1292) – фарсы шагыйре, фарсы һәм таҗик әдәбиятлары классигы.

[5] Мәдәд – ярдәм, булышлык.

[6] Шушы ук хикәя Иран шагыйре Низаминың әсәреннән икътибас ителеп язылган чыгтайча «Мәхзән әл-әсрар» китабында да бар. *(Авт. иск.)*

[7] Мәнбәгъләре – чыганаклары.

Тайның мәнакыйбен[1] сөйләп, үзенең күршеләренә вә чүлдәге фәкыйрь гарәпләрне туйдырыр өчен, бер вакытта кырык дөясен суйганын сөйлиләр[2].

Безнең тикшерә торган «Дастане Хатәм Тай»ның госманлычага кайдан кергәнлеге хакында бер сүз дә әйтеп булмый[3]. Әсәрдә мөхәрриренең исеме юк. Ләкин хикәяләренең өслүбе, анда булган вакыйгаларның җәгърафи урыннары башта бу әсәр Иран мөхәррирләренең каләменнән чыкмадымы икән яисә «Тутыйнамә» күк фарсы әдәбиятыннан алынып үзгәртелмәдеме икән дигән фикергә китерә.

Бу әсәрнең хыялга байлыгы, матур манзаралары, укырга рәгъбәтлелеге[4], укучының рухын күтәрердәй күңеллелеге әсәрнең кыйммәт әдәбиясен[5] югарыга менгерә. Шуның өстенә әсәрнең эпикуризмга бирелгән булуы[6], шәраб, саз, гыйшык, гыйшрәт[7] тасвирларының байлыгы бу әсәрнең оста вә бай хыяллы кешенең каләменнән туганлыгын күрсәтәләр. Эчендә Фөзулинең[8] халык арасында бик мәшһүр:

> «Мәхәббәт бер бәладер, кем грифтар[9] улмаян белмәз,
> Җәфаны чикмәян гашыйк сафаның кадерене белмәз», –

дигән шигырьнең булуы, һәрхәлдә, «Дастан»ның Фөзулидән соң туганлыгын белдерәләр.

---

[1] Мәнакыйбен – мактаулы эшләрен.

[2] De Herbelot, Orientaliselie Bibliothek, Bd. II, s. 689. *(Авт. иск.)*

[3] Яурупа галимнәренең бу хактагы әсәрләре безгә мәгълүм булмады. *(Авт. иск.)*

[4] Рәгъбәтлелеге – кызыксындыруы.

[5] Кыйммәт әдәбия – әдәби, сәнгати кыйммәтен.

[6] Эпикур – борынгы Юнан хакиме. Дөньяда кәеф-сафага бирелеп, рәхәт яшәүне үзенә идеал иткән. *(Авт. иск.)*

[7] Гыйшрәт – күңел ачу.

[8] Мөхәммәт бине Сөләйман Фөзүли – XVI гасырда иҗат иткән күренекле шагыйрь, фикер иясе. Төрле чыганакларда төрек, азәрбайҗан, госманлы шагыйре дип йөртелә. Азәрбайҗан шигъриятенең классигы санала. Төрек һәм азәрбайҗан шигърияте үсешенә зур йогынты ясый.

[9] Грифтар – дучар.

Әсәр, шул ук «Тутыйнамә», «Кырык вәзир», «Әлфе ләйлә» вә башкалар күк, хикәя эченә хикәя тыгылып ясалган. Әсәрдә зур хикәяләр эчендә мәсәлләр дә очрыйлар. Мәсәлән, анда без бөтен дөнья әдәбиятында мәгълүм булган «Балыкчы вә балык» мәсәлен очратабыз. Шулай ук бәгъзы хикәяләрнең язылу рәвешләре дә «Әлфе ләйлә», «Әбү Гали Сина» кыйссаларына охшыйлар. Мәсәлән, тылсымлы хавызга[1] чумып, шунда каһарманның башыннан әллә никадәр маҗаралар үтүе, зур кошның аягына тотынып очулар – һәммәсе дә шул җөмләдәндер. Шулай ук бөтен дастаннарда, сугыш китапларында очрый торган тылсымлы урыннар, зәнкиләр, аждаһалар монда да зур урын тоталар. Ләкин безнең бу дастанда сугыш китапларында булган артык мантыйксызлыклар, коточкыч вә туйдырырлык озын сугыш, көрәш вә мөбарәзәләр[2] юк. Андый нәрсәләр урынын монда гыйшык вә аның маҗаралары тоталар.

Әсәрнең кыскача гына мөндәриҗәсе шуннан гыбарәт: Бәсра шәһәрендә Хатәм Тай исемендә бик юмарт бер патша була. Аның дөньяда үзеннән юмартрак кешенең булганлыгын ишеткәне юк. Бервакыт аңар бер вәзире Рей шәһәрендә бер кыз патша бар, һәрбер сораучыга мең алтын бирә, дип сөйли. Хатәм моңар бик кәефсезләнә, көнләшә: вәзирне зинданга салып, үзе тәбдиле кыяфәт[3] кылып, Рей шәһәренә таба сәфәр кыла. Күп мәшәкатьләрдән соң анда барып җитә. Чынлап та, кыз патша ифрат юмарт булып чыга, Хатәм, имтихан өчен ярлы кеше киемнәре киеп, берничә мәртәбә алтын алып кайта. Ниһаять, ул кыздан кайдан бу кадәр байлык килде сиңа, дип сорый. Кыз аңар: «Моннан өч айлык җирдә Кандалусиядә бер сәүдәгәр егет бар, ул көн саен бер-ике җәүһәрне базарга чыгарып бәһаләтә дә, мең алтынга җиткәч, җәүһәрне ташка куеп, чүкеч белән бәреп көл итә; әнә шуның ни өчен шулай иткәнен белеп, миңа хәбәр китерсәң, синең соравыңа мин җавап бирермен», – ди. Хатәм,

[1] Хавыз – күл.
[2] Мөбарәзәләр – бергә-бер чыгып сугышу.
[3] Кыяфәт алмаштырып, инкогнито. *(Авт. иск.)*

меӊ мәшәкать күреп, Кандалусиягә бара. Егетне күрә. Ул исә аӊар шулай дип әйтә: «Табарстанда бер каһвәханәдә бер сукыр гарәп бар. Көн саен иӊсәсенә бер йомырык ора: әгәр син шуныӊ сәбәбен белеп килсәӊ, сиӊа җавап биремен», – ди. Хатәм янә өч айлык юлга китә. Гарәпне күрә. Ул да тик кенә җавап бирми: «Бабилдә бер сугыш коралы ясаучы көн саен бер манарага менә дә төшә; әнә шуныӊ сәбәбен белеп килсәӊ, синеӊ сөалеӊә җавап бирермен», – ди. Хатәм Бабилгә китә. Теге останы күрә. Ул да җавап бирер өчен шундый шарт куя: «Бәдәхшанда бер кеше бар, гяһ[1] елый, гяһ кычкырып көлә. Шуныӊ сәбәбен белеп килсәӊ, җавап бирермен», – ди. Менә Хатәм Бәдәхшанга китә. Теге кешене күрә. Ул да бер шарт куя: «Моннан ерак түгел каршы юлны тотып кит. Каршыӊда бер сәхра булыр, анда «дивана сыйфат» бер егет булыр, адәм углыннан чиркәнеп, һаман кыр киекләре, кыр хайваннары белән тереклек итә; шуныӊ сәбәбен белеп кил – сөйләрмен», – ди. Ул газләттәге[2] кеше исә: «Хорасанда шәех бар, шуннан барып минем хәлемне сора, җавап бирер», – ди. Хатәм, меӊ мәшәкатьләр чигеп, шәехне күрә. Карт: «Бер кич кунак бул, иртәгә сөйләрмен», – дип, аны калдыра. Ул сөйли башлый да, хикәяләр шуннан сүтелә башлыйлар. Хатәм һаман кайта, юлда очраган кешеләр һәркайсы озын-озын серле, гаять кызык хикәяләр сөйлиләр. Ниһаять, Хатәм кыз-патша янына кайтып җитә, хикәяне сөйли. Хатәм аны хатынлыкка алып, иленә кайта. Вәзирне дә хибестән[3] котылдыра. Шуныӊ белән хикәя тәмам була.

### *3. «Әбү Гали Сина китабы»*

Татар укучысыныӊ сөеп укый торган кыйсса китаплары арасында «Әбү Гали Сина хикәяте» дип мәшһүр бер әсәр бар. Бу әсәр дә, башка кыйсса китаплары шикелле үк, госманлы

[1] Гяһ – әле.
[2] Газләттәге – ялгыз.
[3] Хибестән – тоткынлыктан.

төркисенчә булып, бездә ул шул төркчә килеш язма хәлендә укылып килгән. Безнең кулыбызда шундый бер кулъязма бар. Шулай ук ул госманлыча басылып та укылган. Госманлыча килеш ул Казанда беренче мәртәбә 1864 елда басылган. 1872 елда Каюм Насыйри аны татарчага тәрҗемә кылып, беренче тапкыр 1881 елда «Рәис әл-хөкәмаи Әбү Гали Сина кыйссасы димәклә мәшһүр тәхәйеләтнең[1] тәрҗемәсе» дигән озын исем белән бастырган. 1900 елга чаклы Насыйриның тәрҗемәсе барысы биш мәртәбә тәкрар табигъ ителгән[2]. 1900 елда ул мулла Шиһаб Габделгазиз углы Рәхмәтуллин[3] тарафыннан бер кат тәрҗемә кылынып, 1902 елда «Әбү Гали Сина китабы» исемендә басылган. Шулкадәр аз вакыт эчендә шулкадәр күп мәртәбә басылуы – бу әсәрнең безнең халык арасында никадәр таралганын күрсәтә торган ачык бер дәлилдер.

Мәгълүм ки, бу кыйсса китабы – Әбү Гали Сина яисә Ибн Сина (Әбү Гали әл-Хөсәен ибн Сина эш-шәех әр-Раш) исемле, XX гасырның ахырында туып, XI гасырда вафат булган, ислам галәменең философ вә мәшһүр табибы тирәсендә ясалган легенда вә хорафат үзәренә төзелгән бер романдыр[4]. Бу хәкимнең мәшһүр Иран мөәррихе[5] Хандамир[6] тарафыннан язылган тәрҗемәи хәлендә дә шактый хорафат сөйләнгән. Бу хорафат буенча, аның тууы аның аталарына йолдызларның аерым бер рәвештә йөрүләре белән хәбәр бирелгән, имеш. Ул биш яшендә фәннәр укырга тотынган. Унынчы яшендә үзенең белеме

[1] Тәхәйеләт – хыялый хикәя.

[2] Табигъ ителгән – басылган.

[3] Рәхмәтуллин Шиһаб Габделгазиз углы – XIX йөзнең икенче яртысы – XX йөз башында яшәгән татар мәгърифәтчесе, тәрҗемәче һәм нашир. Гарәп, фарсы, төрек телләреннән иҗади эшкәртеп, татар теленә күпсанлы хикәятләр тәрҗемә итә. 1890–1900 елларда еллык өстәл календаре бастырып чыгара.

[4] Ибне Сина асыл иранлы булып, әсәрләрен күбрәк гарәп телендә язган. Аның төрк нәселеннән булуы – Йосыф Акчура тарафыннан куертылган хата бер фикердер. *(Авт. иск.)*

[5] Мөәррихе – тарихчысы.

[6] Гыясс әд-Дин ибн Хумам әд-Дин әл-Хөсәйни Хвандамир (1475–1535) – фарсы тарихчысы.

белән кешеләрне гаҗәпкә калдырган. Әмма унҗиденче яшендә пәри-җеннәрне мөсәххәр иткән[1] ки, алар аның әмерләрен, хезмәтчеләр күк, җиренә җиткереп торганнар[2]. Ләкин бу кеше Бохара күк төрк халыклары белән күрше булган җирдә тугангa, аның чабы[3] төрк халыкларына да кереп, соңра ул легендалар зурайганнан-зурайганнар. Ниһаять, намәгълүм язучылар, халык арасыннан җыеп, госманлы дастанчылары авызыннан ишетеп, үзләреннән дә шактый хыял арттырып, бер кыйсса китабы язып чыгарганнар. Безнең язма нөсхәнең башында «Галә әл-кадри әл-имкян[4] яздыкымыз вә күреп ишетдекемез үзрә, инша Аллаһ әр-рахман, тәкърир вә тәхрир идәем» дигән сүзләре, әсәрнең эчендә бик күп шигырьләр булуы, шулай ук анда бәгъзы мәнбәгъләрнең дә күрсәтелүе[5] вә «Тәварихе могтәбәрә» хакында сүзләрнең булуы – һәммәсе дә моның бер мөхәррир тарафыннан бу хактагы төрле легендаларны җыеп язылганлыгын күрсәтәләр.

Әбү Гали Сина кыйссасы да башка кыйсса китаплары тибындарак эшләнгән. Монда да, бербөтен хикәя булу белән бергә, ул бөтен хикәянең эченә эпизодически[6] генә ваграк хикәяләр дә кергәннәр. Безнең кулдагы өч төрле вариантның өчесе дә бер-берсеннән аз-маз аерылсалар да, хикәянең төп кыйссасы (рамкасы) шуннан гыйбарәт: Әбү Гали Сина белән Әбелхарис – ике борадәр[7] – гыйлем тәхсил иткән[8] соңында, мәгъриб

---

[1] Мөсәххәр иткән – сихерләгән, буйсындырган.

[2] Философский лексикон, т. 1, с. 28. *(Авт. иск.)*

[3] Чабы – даны.

[4] Галә әл-кадри әл-имкян – көч һәм мөмкинлек җиткәнчә.

[5] Язма нөсхәдә «Ике баб үзәрә тәртип әйләдек әүвәлге бабны кәндем татбигъ идеб, зикер улынан китаплардан ихраҗ әйләдекем... Ул китаплар бонлардыр ки, исеме тәгърир улынды Канун диба Кабуснамә, Нәтаиҗ әл-фөнүн, Тәварих Гали» диелгән. *(Авт. иск.)*

[6] Кирилл хәрефләре белән язылган.

[7] Борадәр – бертуган.

[8] Гыйлем тәхсил иткән – гыйлем алган.

диярендә[1] бер шәһәргә[2] барып, анда тылсымлы бер мәгарәгә кереп, бер ел риязәт[3] чигеп, кимия вә симия[4] гыйлеменә һәм ихфага[5] өйрәнәләр. Бер елдан алар ифрат килешсез хәлдә, чәч вә тырнаклары җитеп, пәри төсле булып чыгалар. Шуның өчен аларны сахирләр[6] дип хөкемгә тартып үтерергә торганда, алар икесе дә гыйльме симия куәте белән качалар да, Әбү Гали Сина – Мисырга, Әбелхарис Багдадка барып төшәләр. Әбелхарис үзенең әфсен укып ясаган мунчасы аркасында мәшһүр булып, Багдад патшасының вәзире итеп тәгъйин кылына[7]. Әсәрнең төп каһарманы Әбү Гали Сина була. Мисыр урамнарында Гали исемле бер хәлвә сатучы (хәлвәфруш) егетне күреп, шәрык ысулынча аның җәмалына[8] гашыйк була. Шул гыйшкы аны хәлвәфрушка кол итә. Шуның өчен ул Мисыр патшасы белән мөсадәмәгә[9] башлый. Хәлвәфруш патшаның кызына гашыйк була. Әбү Гали Сина аны симия куәте белән сарайдан хәлвәче дөкяненә[10] китертеп, егет белән гыйш-гыйшрәт кылдырта. Бу эштән гаҗиз булган патша, Әбү Гали Сина белән тартышыр өчен, Багдадтан Әбелхарисны китертә. Ләкин Әбелхарис башта бу эшләрне кылучы, патша кызын рисвай итүче – агасы икәнен белмичә көрәш башлый. Ләкин Әбү Галине җиңә алмый. Ниһаять, Әбү Гали патшаның акылын алырлык һөнәрләр күрсәтә. Ләкин патшага бу гыйбрәтләр аз, ул әле кызын хәлвәчегә бирергә һич разый булмый. Әбү Гали Сина, патшаны агулыйм дип, яңлышлык белән борадәрен сихерли. Ахырдан туй итәләр: патша кызын хәлвәфрушка бирергә разый була. Әбү Гали Сина исә ватаны Бохарага кайта, анда гаҗәеп эшләр эшли...

---

[1] Диярендә – җирендә.
[2] Насыйри тәрҗемәсендә Мисырга. *(Авт. иск.)*
[3] Риязәт – теләкләрне тыеп, ашау һәм эчүдә чикләнүчелек.
[4] Симия – алхимиклар идеясе нигезендә туган фантастик бер «гыйлем».
[5] Ихфага – кеше күзенә күренмәскә.
[6] Сахирләр – сихерчеләр.
[7] Тәгъйин кылына – билгеләнә.
[8] Җәмалына – чибәрлегенә.
[9] Мөсадәмә – бәрелешү, каршылык.
[10] Дөкяненә – кибетенә.

---

Әбү Гали Сина хикәяте – безнең кыйсса, хәтта сугыш китаплары эчендә хыялга бик бай вә идеал җәһәтеннән иң оптимизмга бирелгән бер әсәр. Монда без матди көчләр өстеннән гыйлем вә адәм акылының галәбәсен[1] күрәбез. Монда без адәмнең гыйлеменең шулкадәр зур триумфын күрәбез ки, хәким хәтта үлем белән дә көрәшә. Ул мәңге торырга гыйлаҗ[2] таба. Аның шәкерте, Әбү Гали Сина үзе үлгәч кылырга кушкан эшләрне эшләп, мәгъҗүннәрне[3] остазының тәненең калдыгына сибә. Ләкин актык шешәсен салмый: көнләшеп вата да. Ул яткан мунчаны да ихфага чигеп (күздән яшереп) китә. Ләкин ярым терелгән, хәтта эндәшә башлаган хәким «тагы, тагы!» дип кычкырып ята. Ихфага чигелгән мунчадан шушы көнгә кадәр шул тавыш чыгып тора, имеш.

Төрк әдәбиятында без икенче мәртәбә шушы мәңгелек гомер өчен көрәшне – мәшһүр шагыйрь Гётенең «Фауст» трагедиясендә тасвир иткәнне, мәңгелек бөтен инсаният галәменә гам[4] булган мәүзугны очратабыз: «Китабе Коркыд»та Деле Дөмрел үлем белән көрәшеп, фәрештәсе Аллага якынлык белән җиңсә, монда Әбү Гали Сина һичбер Алланың катышыннан башка, үз акылы, көче белән үлемне җиңә!

Хыялга байлык җәһәтеннән бу кыйсса мөһим. Анда Әбү Галинең әфсен куәте белән эшләгән эшләре дошманнарын шундый кызык вә көлке, бәгъзы вакытта мөдһиш[5] халәтләргә калдыра ки, укыганда әле кычкырып көләсең, әле азрак булды, тагын беразга бу кызыклар дәвам кылса яхшы булган булыр иде, дисең. Ләкин шуның белән бергә бу ифрат дәрәҗәдә оятсызлык – порнографиягә бирелгән бер әсәр. Анда без бик күп фахиш, шакшы вә оятсыз манзаралар очратабыз. Моның сәбәбен дә әсәрнең нинди даирә укучылар өчен язылган булуын-

---

[1] Галәбәсен – җиңүен.
[2] Гыйлаҗ – әмәл, чара, дару.
[3] Мәгъҗүннәрне – даруларны.
[4] Гам – гомуми, уртак.
[5] Мөдһиш – куркыныч.

нан эзләргә кирәк. Бу төрле әсәрләрне госманлыларда мәдәни кыйсем әһеле укымый. Бакый[1], Рәвани[2] күк нечкә зәвыклы шагыйрьләрне укучылар андый каба хикәяләрне укымыйлар. Аларны укый торган сыйныф – икътисади изелгән, гомерен сугышларда үткәреп, шуннан каба тәрбия алган Анатулы крестьяны, «өскелә»ләрдә йөк ташучы, иҗтимагый тигезсезлек аркасында каба булып калган хәммальләрдер[3]...

Ләкин, шуның белән бергә, мәүзугы ифрат дөньяви булуга карамый, модага ияреп булса кирәк, әсәргә:

«Итмә дәрвиш габа пүшә хәкарәтле назар[4],
У да хәленчә бәка мөлкенең шаһы кичәр», –

күк суфилык аңкып тора торган шигырьләр дә кергәнлеген күзгә алып узарга кирәк.

### *4. «Кырык вәзир»*

Кыйсса китаплары арасында халык тарафыннан бик сөелеп укыла торган «Кырык вәзир кыйссасы» дигән янә бер әсәр бар. Бу әсәр дә шул Шәрыкта бик модада булган «Әлфе ләйлә вә ләйлә», «Әлфе нәһар вә нәһар», «Тутыйнамә», «Җаһил тутый» тибында язылган. Профессор Крымскийның[5] әйтүенчә, бу әсәр гарәп телендәге XIV гасыр әсәрләреннән булган намәгълүм бер мөхәррирнең «Кырык иртә вә кырык кич» исемендәге хикәяләреннән икътибас ителеп[6], халык арасында сөйләнеп йөри торган кыйссаларны да өстәп, солтан Морад II нең (1421–[14]51) кушуы буенча Шәехзадә (Әхмәд Мисыри) исемле

---

[1] Бакый (Мәхмүд Габделбакый, 1526–1600) – XVI йөзнең күренекле төрек шагыйре. Лирик әсәрләр язу остасы буларак танылу алган.

[2] Харәзми Равани – XIV йөздә иҗат иткән күренекле төрки шагыйрь. «Мәхәббәтнамә» дип аталган поэмасы (1353) билгеле.

[3] Хәммаль – йөк ташучы.

[4] Әй, дәрвиш, суфичылык киеменә кимчелекле караш ташлама.

[5] Крымский Агафангел Ефимович (1871–1942) – тарихчы, рус шәрыкшинасы, тюрколог.

[6] Икътибас ителеп – үрнәк итеп.

мөхәррир тарафыннан язылган. Ләкин бу хикәяләрнең дә асыл ватаны Һиндстан икәнен тикшерүчеләр дәгъва итәләр. Безнең татар телендә бары Каюм Насыйри тәрҗемә кылып бастырганы гына мәгълүм. Монда исә әсәрнең мөхәрриренең кем икәне мәгълүм түгел. Шулай ук әсәрнең мөкаддимәсендә солтан Мостафа кушуы буенча язылганы сөйләнә. Төркия тарихында өч Мостафа бар. Кайсы икәне мәгълүм түгел. «Кырык вәзир»нең татар арасына кайчан килеп керүе билгеле түгел. Татар арасында аның кульязмалары яки Истанбул басмалары безгә очраганы юк. Аны Каюм Насыйри, госманлычадан тәрҗемә кылып, 1868 елда бастырган. XX башына кадәр Насыйриның тәрҗемәсе сигез мәртәбә тәкрар табигъ кылынган. Бу исә аның безнең халык арасында сөелеп укыла торган бер китап булып китүен күрсәтәдер.

«Кырык вәзир» хикәясенең кыйссасы шуннан гыйбарәт: Гаҗәм йортында бер патшаның матур бер углы вөҗүдкә[1] килә. Ләкин аның анасы үлеп китә дә, патша яшь хатын ала. Бала үсеп җитә башлагач, хатын аны сөя башлый. Картны үтереп, баланы тәхеткә менгереп, рәхәт торырга димли. Бала мондый әхлаксыз эшкә разый булмый – үги ананың авызына сугып каната. Хатын патшага углы өстеннән: «Минем намусымны тәхкыйрь итте[2], мин разый булмагач, кыйнады», – дип төһмәт итә[3]. Патша да, хатын сүзенә ышанып, углын игъдам итәргә[4] куша. Ләкин патшаның кырык акыллы вәзире була. Көн саен алар бер гыйбрәтле хикәя яисә бер мәсәл сөйләп, баланы үлем җәзасыннан хәляс итәләр[5]. Ләкин иртәгесен хатын бер хикәя сөйләп, патшаны котырта. Патша иртә белән баланы үтертергә торганда, яңадан бер вәзир хикәя сөйли. Шундый хикәяләрнең саны Әхмәд Мисыри әсәрендә йөз унике булганы мәгълүм булса да, безнең татарча

[1] Вөҗүдкә – дөньяга.
[2] Тәхкыйрь итте – хурлады.
[3] Төһмәт итә – яла яга.
[4] Игъдам итәргә – юкка чыгарырга.
[5] Хәляс итәләр – коткаралар.

тәрҗемәсендә исә сиксәннән артык түгел. Ниһаять, баланың гөнаһсызлыгы мәгълүм була. Хатынны җәза кылалар.

Бу хикәяләрнең табигатендә без шундый хосусият күрәбез: ислам әхлагының бик куәтлелеге, хатыннарга каршы нык каты агитация. Вәзирләрнең бөтен хикәятләре хатыннарны гаепләү белән тулган, Төркиянең югарыгы сыйныфларындагы хатыннарның әсирлеккә төшкән мәүкыйгларын[1] хәтерләсәк, бу бер дә гаҗәеп тоелмас. Монда без сыйнфый бер хосусият күрәбез: солтан кушып яздырган нәрсә, табигый, югарыгы сыйныфлар өчен язылган була. Әмма бу сыйныфта хатыннарның мәүкыйглары шулай түбән иде. Шуның өстенә дә без монда борынгы Төркиядә җәелгән Лут пәйгамбәр кавеме гөнаһының гади эш шикелле сөйләнгәнен күрәбез. Мәсәлән, бер әүлия шәехнең вилданнар[2] күк матур балалар белән гайре мәшруг[3] мөнәсәбәттә булуын мөхәррир күзен дә йоммыйча, ачыктан-ачык сөйли. Тарих күрсәтә ки, Төркиянең гали[4] сыйныфлары арасында бер заманны бу гадәт бик фаш[5] вә гади нәрсә булып киткән иде.

Сөнгате нәфисә[6] ноктаи нәзарыннан «Кырык вәзир» башка кыйсса китапларыннан түбәнрәк тора. Мондагы тозсыз Тәүрат морале туйдыра. Хыялый, куркыта яисә сөендерә торган тойгыларны кузгатучы тасвир вә манзаралар бик аз: коры әхлакчылык вә нәсыйхәт аһәңендәге хикәяләр укучыны ялыктыралар.

## «Ләтаифе Хуҗа Насретдин»

Госманлычадан безнең арага күп таралган мөһим әсәрләрдән берсе – «Ләтаифе Хуҗа Насретдин әфәнде»дер. Бу әсәр бездә беренче мәртәбә 1845 елда басылган. Моңар кадәр кулъязмаларында халык арасында укылып йөргән булырга кирәк.

[1] Мәүкыйгларын – урыннарын.
[2] Вилданнар – җәннәт хезмәтчеләре.
[3] Гайре мәшруг – шәригатькә ярашмаган.
[4] Гали – югары.
[5] Фаш – мәйданга чыккан.
[6] Сөнгате нәфисә – нәфис сәнгать.

Госманлы халык әдәбиятыннан кергән лятыйфәләр[1] арасында Хуҗа Насретдин лятыйфәләре беренче урынны тоталар. Бу әсәрне французчага тәрҗемә кылучы Декурдеманш[2] аның башка шундый тип әсәрләр арасында чагыштырылмаслык рәвештә мөһим икәнен әйтеп китә.

«Хуҗа Насретдин» Истанбулда да бик иртә (1837–1838 миладида) нәшер ителгән[3]. Хуҗаның лятыйфәләре һәммә төрек басмаларында бер төсле түгел. Аларның кайсы озын, кайсы кыска. Госманлы халкы үзенең кырык анекдотларын шул лятыйфәләргә кертеп бетергән. Тюрколог Куносның[4] (Künos) әйтүенчә, әле дә Кечек Азиядә, Хуҗа исеме белән баглап, бик күп лятыйфәләр сөйли: шунда торучы госманлы зыялысы Йосыф Сами бу мөстәшрикъка 126 лятыйфәне халык арасыннан язып алып биргән[5].

Бу кеше хакындагы лятыйфәләр безнең халык арасына бик иртә таралганнар. Хәтта ул татарлар аркылы бөтен Идел буе гайре руслары[6] арасында да мәшһүр булып киткән. Аларның бәгъзылары каршында бу кеше мөкаддәс зат булып хисаплана, имеш. Бу, ихтимал, безнең татарның Хуҗаны изге дип хисап-

[1] Лятыйфә – күңелле кыска хикәя, мәзәк, анекдот.

[2] Decordemanche, Les plaisantieres de Nasreddin Hodja, p. 5. *(Авт. иск.)*

[3] Ул башка телләргә дә тәрҗемә кылынып басылып тора, гарәпчә 1864 елда Муса Кастәли тарафыннан «Һәза нәвадир Хуҗа Насретдин әфәнде Хәҗа әр-Руми» исемендә (Хәҗа – гарәп лятыйфәчеләреннән берсе), соңра әрмән, юнан, рум, немец, француз, инглиз телләренә дә тәрҗемә кылынган. Аның хакында зур тәфтишат та чыккан. Бу хактагы әдәбият: Андерсон [В.] Император и аббат. [История одного народного анекдота. Ученые записки Императорского Казанского университета. 1915, Т. 8] с. 406. *(Авт. иск.)*

[4] Кунош Игнац (1860–1945) – венгр тюркологы, фольклорчы. 1915–1916 елларда Эгер, Эстергом (Венгрия) шәһәрләре тирәсендә урнашкан лагерьлардагы татар хәрби әсирләреннән фольклор материаллары язып ала. «Татар әсирләре лагерьда. Мөселман хәрби әсирләре лагерьларында башкарылган эш турында доклад» («Tatar foglyok taboraban: Jelentes a Mohamedan fogolytaborokban Vegzett tanulmanyokral») «Будапешт күзәтчесе» («Budapesti szemle», Bdpst., 1916) дип исемләнгән еллык басмада дөнья күрә.

[5] Ueber die Volkspoesie der Osmanischen Türken, s. XIX; и «Образцы народной литературы турецких племен», ч. VII. *(Авт. иск.)*

[6] Гайре руслар – рус булмаган халыклар.

лавы тәэсирендә килеп чыккандыр, чөнки безнең татар халкы һәрбер җүләр вә дивананы бераз изге дип игътикад кылганы[1] шикелле, Хуҗаны да әүлиялек белән сыйфатлый.

Әсәрнең кайчан җыелуы мәгълүм түгел. Аның Яурупа көтепханәләрендә XVIII гасырга гаид[2] кульъязмалары булып, шуннан да борынгы булганнары юк.

Әсәрнең басма вә кульъязма халәтендә булганнарында ике тарихи шәхеснең исеме һәрвакытта Хуҗа Насретдин белән бергә бәйләнеп йөртелә. Алар исә – Тимерләң һәм иске сәлҗук калдыгы Карамания солтаны Галәэтдиндер. Кечек Азиядәге калалардан Акшәһәр, Киршәһәр, Конья ләтыйфәләрдә бик күп очрыйлар. Киршәһәрдә исә Хуҗаның көлкелеге белән мәгълүм төрбәсе бар. Безнең татар арасында таралган легенда буенча, аның төрбәсе бер тау кырыенда булып, тауга түбән кыйшайган, ләкин аны аскы яктан түгел, өске яктан түбәнгә таба терәтеп куйганнар, аның яныннан беркем дә көлми үтәргә ярамый. Көлми үтсә, авызы чалыш булып кала, имеш. Бу шәһәр исә 1402 елда мәшһүр Әнкара сугышында Тимерләң тарафыннан алынган. Әмма Галәэтдин исә – шушы вакыйгадан элегрәк Баязид тарафыннан куылган вә җиңелгән бер хөкемдардыр. Димәк, моны хәтергә алганда, Хуҗа Насретдин XIV гасырның ахырларында, XV гасырның башларында торган кеше булырга кирәк. Тикшерүчеләр, Хуҗаның булган тарихи бер шәхес икәнен игътираф иткәннәре[3] хәлдә, аның хакында булган ләтыйфәләрнең күбесенең соңыннан чыкканлыгын икърар итәләр. Госманлы халкы үзе Хуҗаның бер тарихи шәхес икәнен дәгъва кыла. Югарыда сөйләнгән Йосыф Сами тарафыннан Куноска бирелгән ләтыйфәләр төркемендә шулай әйтелә: «Хуҗа киршәһәрле бер госманлы улыб, пик[4] белгеч бер адәм улдыгы госманлылыр арасында сөйләнер. Һанги елда дугдыгы пик билле дәгелсә дә, әлдә[5] булынан

[1] Игътикад кылганы – ышанганы.
[2] Гаид – караган.
[3] Игътираф иткәннәре – әйткәннәре.
[4] Пик – бик.
[5] Әлдә – кулда.

китапларда язылы улдыгына күрә, Хуҗа илә Тимерләң арасында улмыш эшләр вардыр ки, Тимерләң көнендә Хуҗаның саг улдыгы беленер вә боңа күрә Хуҗаның биң[1] дүрт йөз ике миладиадәмләрендин улдыгы билелүдер[2], чөнки Тупал Тимур биң дүрт йөз ике миладида Анадулың бераз җирләренә әл итмешләр. Бу сүземезне исбат итмәк өчен шу хикәя сөйләнер»[3].

Хуҗа Насретдин ләтыйфәләренең мөндәриҗәләрен монда сөйләп торырга хаҗәт юк. Чөнки алар шулкадәр мәгълүмдер ки, балалар да аны беләләр. Хуҗаның маҗаралары һәрвакытта шушы затлар арасында була: балалар, патша, бәк, казыйлар, халык, үзенең хатыны, ишәге һәм үгезе.

Ләтыйфәләрне татар нашире дә бозмыйча бастырган. Бары тик бик читен сүзләрне генә татарчалаштырган[4].

«Хуҗа Насретдин» – госманлы вә гомумән төрк халыкларының һөҗү[5] вә мәзахчылыгының[6] мөҗәссәм[7] һәйкәледер. Ул һәрьяктан халык белән бер дәрәҗәдә тора. Анда төрек авылының бик шаян, бик уңган, әмма үзе шагыйрь табигатьле картының рухында булган һәр нәрсә бар. Ләкин безнең татарның тапкыр карты Хуҗадан бераз аерыла: шимальдә, Идел-Чулман тирәсендә торып, суык һавада яшәргә мәхкүм булып, үзенең тормышы һәм фикерләре өчен көрәшергә өйрәнгән татар карты Хуҗадан практиклык, хәйлә, сәүдәгәрлек, һәрнәрсәдә мәнфәгате шәхсия[8] эзләргә ярату белән аерыла. Хуҗа ул үзенең һөҗүе белән кешене тәмам хур итеп ташламый: аның көлүе – җиңел генә юмор, әмма безнең татар «Хуҗа»сында сарказм куәтлерәк

[1] Биң – мең.

[2] Билелүдер – билгеледер.

[3] Образцы народной литературы турецких племен, VII, 408. *(Авт. иск.)*

[4] Хәтта бер басмасының артына «Казан Хуҗасы» исемендә бер чын Казан анекдоты да арттырылган. Соңгы елларда «Хуҗа Насретдин»нең татарча рәсемлесе дә чыкты. Бу Истанбулның «Икъбаль» көтепханәсе бастырган нөсхәнең тәрҗемәсе булырга кирәк. *(Авт. иск.)*

[5] Һөҗү – сатира.

[6] Мәзах – көлке, юмор.

[7] Мөҗәссәм – гәүдәләнгән.

[8] Мәнфәгате шәхсия – шәхси мәнфәгать.

була. Шуның өчен практик татарга Хуҗа бер дивана күк тыела: әмма Шәрыкның мәрхәмәтле җылысы, сәрви агачлары астында, карлы таулардан агып төшкән салкын чишмәләр буенда гомер сөрә торган Анатулы төрегенә бу табигать бер дә гаҗәеп түгел. Андый кешеләрне Шәрыкта «дивана» диләр. Диваналарны без татарлар җүләрләр, ахмаклар белән бергә буташтырып йөртәбез, әмма җәнүб халкы, ислам шәркы аларны җүләрләрдән аера. Дивана – галим. Үткен фикерле, һөҗүче. Әмма бөтен дөнья хәятыннан, мәнфәгатеннән баш тарткан бер дәрвиш булса, ахмаклар үзләрен акыллы дип йөрүче аңгыралар булсалар, җүләрләр исә миләрендә бер яисә берничә «винт»лары җитмәгән кешеләр булалар. Менә безнең Хуҗа ахмак та, җүләр дә түгел, бәлки диванадыр. Ул бары өстән караганда гына акылсыз булып күренә яисә бездәге төсле рәсми акыллылыкка, Аристу мантыйгына аның акылы бөтенләй буйсынып бетми. Бәлки, аның күңелендә яшеренеп ята торган үз аксиомалары бар. Ул үзе ифрат тикшерүне ярата: аның һәрнәрсәне беләсе килә; шуның өчен ул Мөнкир вә Нәкирне[1] сынар өчен кабергә дә кереп ятып карый. Аның җаваплары да бик тапкыр, үткен булалар. Солтан Галәэтдин янына килгән монахларның сөальләренә бөтен галимнәр җавап таба алмагач, аны китерәләр. Җирнең уртасы кайда, йолдызларның саны ничә, дигән күк мөшкел сөальләргә ул җавап табып бирә. Вәгазь әйткәндә, авторитеттан элек нәрсәләр көтеп, үз башларын файдага калдырып, кеше башы белән файдаланырга теләүче халыкка аның: «Әгәр Кодурины[2] укымаган булсагыз, укып килегез; әгәр берегез белеп, берегез белми килсәгез, белмәгәнегезне өйрәтегез, әгәр белсәгез, өйрәтергә дә хаҗәт юк», – мәалендә[3] биргән классик җавабы белән ул садәләр галәменнән

[1] Мөнкир вә Нәкир – каберләрдә үлеләрдән сорау ала һәм җәзалый торган фәрештәләр.

[2] Әбү әл-Хөсәен Әхмәд бине Мөхәммәд бине Әхмәд бине Җәгъфәр бине Хандан әл-Кодури әл-Багдади (973–1037) – күренекле дин галиме, фәкыйһ. Хәнәфи мәзһәбенең нигез тәгълиматлары хакында «әт-Тәҗрид», «Шәрх Мохтасар әл-Кархи», «Мохтасар әл-Кодури» һ.б. хезмәтләренең авторы.

[3] Мәалендә – мәгънәсендә.

көлә. Аны халык та тапкырлыкта бик югары куя. Тимер бер шәһәрне мөхасарә[1] иткәндә, оста вә акыллы җаваплар белән шәһәрне котылдыру өчен, халык аны әмир Тимергә илче итеп күндерә.

Акыл белән бергә, Хуҗаның тойгысы да бик куәтле. Ул рухан шагыйрь кеше: матурлык сөя, хәтта йорт өстенә килеп кунган ләкләкнең дә аяклары вә борыны ифрат озын булганга яратмый, борынын, аякларын кисә. Аның кайчакта шигъри илһамы да була. Төнлә белән хатынын уятып, кәгазь-каләм сорап, язарга тотына. Ләкин шигырь яхшы чыкмый. Кара тавык яшел үлән арасына кереп китте... булып кына чыга; чөнки Хуҗа нәзымчы, профессиональ шагыйрь түгел.

Әхлакый яктан да Хуҗа бик югары түгел. Аның күңеле адәмгә яхшылык тойгысы белән тулган: карак кергәч, ул аны кумый, урлаган нәрсәне кирәк булганга күрә алгандыр, ди. Анда, гомумән, милек (собственность) тойгысы юк. Ул, кеше бакчаларына кереп, җимеш урлый, чит кеше бакчасына баскыч куеп, койма аркылы төшә... Ул олыларны, байларны да яратмый, чөнки ул – төрк крестьян сыйныфының каһарманы. Яхшы кием киеп килгән кешеләрне хөрмәтләгәнне күргәч, үзе дә яхшы кием киеп килеп, тунының җиңен «аша, аша» диеп кыстап утыра.

Шулай да психология җәһәтеннән Хуҗа – бөтенләй нормальный кеше түгел. Ул, алда әйткәнчә, дивана. Анда бер төрле дә хәяткә, практик тормышка истигъдад[2] юк. Ул балалар белән мунча керә, алар белән әтәч булып кыткылдап йомырка салып уйный; үрдәкләр йөзгән күлгә икмәк манып ашап, халыкка үрдәк шулпасы ашыйм, ди. Хуҗаның кешене җавапсыз калдыра торган тапкыр сүзләре вә кыланышлары арасында без анда бәгъзан шундый коры җүләрлек яки башын җүләрлеккә салуларны да күрәбез.

---

[1] Мөхасарә – камап алу.

[2] Истигъдад – сәләтлелек.

## Госманлыча дини вә фәнни китаплар

Татар халкы үзенең әдәбияты тарихында беренче дәверендә буш вакытларын сугыш вә кыйсса китаплары уку белән генә уздырмады. Болар аның хыялын, нәфасәт тойгысын тәэмин итәргә ярасалар да, аның акылын кәнагатьләндерергә бер төрле әсәрләр кирәк иде. Мәдрәсәләрдә голәма вә шәкертләр үзләренең акылларына материалны схоластика фәлсәфәсендә, мантыйк, каләм, ысулы фикъһләрдә тапсалар, халык – голәма вә шәкертләрдән укымышы түбәнрәк булган сыйныф яисә иске мәдрәсәдә укып-укып та моталәгасе[1] чыга алмый калган кешеләр – акылларына материалны, бер яктан, чыгтай әдәбиятыннан кергән тәсаувыфи, тарихи вә фикъһкә даир әсәрләрдә тапсалар, икенче яктан, аларга шул ук бабтагы госманлы китап репертуары да ризык бирде.

Болар нинди әсәрләр иде? Билгеле, дини әсәрләр иде, чөнки дин бөтен хәяты фикриягә хуҗа булып торган бер заманда, табигый, чын фәнни нәрсәләр арага күп керә алмадылар. Затән[2], шул заман татары өчен фәннең әһәмияте дә юк иде: бөтен нәрсә Алладан, бөтен нәрсә Коръәндә, бөтен белемнәр инде хәл кылынганнар; эзләп заляләткә[3] төшеп, әллә нинди китаплар укып йөрергә кирәк түгел. Шуның өчен дә гарәпчә моталәгасе[4] чыкмый калган бер төркем халыкның фәлсәфи, тарихи, димәк, гакыли хәятын тутыру өчен госманлылардан дин китаплары керде. «Тарикате Мөхәммәдия» тәрҗемәсе, «Пиргули китабы» шул җөмләдән иделәр. Халыкның тарих бабында беләсе килгән нәрсәләренә җавап өчен «Алты бармак» китабы керде.

«Пиргули» яисә «Пиргули васыяте» яисә «Биргули китабы» исемендәге безнең арада иң элек басылып таралган китаплардан берсе булган. Бу әсәр хакында бераз мөфассалрак[5] сөйләргә

[1] Моталәга – уку, өйрәнү.
[2] Затән – нигездә.
[3] Заляләткә – ялгыш юлга.
[4] Моталәгасе – укуы.
[5] Мөфассал – тулы, җентекле.

туры килә. Ул халык арасында элек кульязмаларда йөреп, соңра бездә китап басыла башлаганның икенче елына, ягъни 1802 елда беренче мәртәбә басылып, соңыннан да безнең676 наширләр тарафыннан тәкрар бастырылып килде.

Мөхәммәд Пиргули – асыл госманлы. Ул 1535 елда туып, 1573 елда вафат булган. Бу зат – госманлы хәяты фикриясендә шактый роль уйнаган кеше. Мөхәммәд Пиргули – XVI гасыр голәмаи госманиясеннән[1] мәшһүр Кәмаль пашазадә Әбүссәгуд исемле фәкыйһ вә мөфәссирнең[2] ят вә нәү иҗат[3] фикерләренә каршы ортодокс (правоверный) ислам ноктаи нәзарыннан торып мөназара кылучы бер адәм иде. Ул бик күп нәрсәләрен гарәп вә фарсы телендә язган[4]. Аның күп әсәрләре фикъһ вә гакаидка даир әсәрләрдер. Без тикшерә торган әсәр дә дини. Ул нәзым белән, гарәп вә фарсы сүзләрен аз катыштырып язылган. Өслүбе садә, теле госманлының чын халык теленә якын диярлек. Ул үзе мөхәррире тарафыннан дәреслек итеп тәртип ителгән. Бу китапның теленең яхшылыгы Яурупа мөстәшрикъларының да дикъкатен җәлеп кылган. Шуның өчен бу әсәр тел ягыннан шактый тикшерелгән. Беренче мәртәбә французчага да тәрҗемә кылынган[5].

«Пиргули китабы»ның мөндәриҗәсе шуннан гыйбарәт: «Мөкаддимә, фи бәяне сыйфат әс-сәлбия, фи бәяне сыйфат әс-сөбутия, сыйфате Сәмигъ, Басыйр, ирадәт, кодрәт, Каләм, тәквин мәляик, тәфсыйле хәзрәте Җәбраил, Газраил. Китабе Аллаһы Тәгалә, Рәсүлуллаһ Тәгалә хәзрәте Мөхәммәд галәйһиссәлам, могҗәзатән-нәби, мигъраҗ ән-нәби, Коръән Газыйм әш-Шан, әзваҗе ән-нәби, фи вакт мәҗи әл-вәхи, фи кәрамәт әл-әүлия, хәзрәте Әбү Бәкер, Гомәр, Госман, Гали. Газабе кобрә,

[1] Голәмаи госманиясеннән – госманлы галимнәреннән.

[2] Мөфәссир – аңлатып бирүче.

[3] Нәү иҗат – яңа.

[4] Brockelmann, Geschichte der Arabischen Litteratur, Bd. II, s. 440–442. *(Авт. иск.)*

[5] Бу тәрҗемәләр хакында карагыз: Крымский, История Турции и ее литературы. т. I, с. 38. *(Авт. иск.)*

фи галәмәт әл-Кыямәт, әхвәле Кыямәт, хәшер әл-әҗсадә гата әл-китап, Сөаль, Мизан, Сыйрат, Хәвыз, Җәннәт, Җәһәннәм, Каза вә Кадер, фи бәяне әл-әгъян илх[1]». Аннан соң, «Тарикате Мөхәммәдия»дәге шикелле үк, монда да ислам әхлакы хакында мәгълүмат бирелеп, шунда әгъзаларның афәтләре дә белдерелә. Соңра нәсер белән иман яңарту формуласы китерелә. Ата-ана, солтан, кардәш-ыру, күрше-күлән хаклары, гадәтләр, төрле намазлар, догалар, тәүбә рәвешләре, фарызларны үтәү вә аларны калдыру, үлек күмү рәвешләре, тәһарәт алу, госел вә башкалар хакында сөйләнә. Әлхәсыйль, «Пиргули китабы» чын мөселманга аның бөтен дөнья вә ахирәте өчен кирәк булган мәгълүматның барысын да бирә. Игътикад, фикъһ, вәгазь, ислам әхлагы вә башка нәрсәләр – барчасы монда кергән. Шулай итеп, ул, татарның шул замандагы бөтен фикере-теләкләренә җавап биргәнгә күрә дә, халык арасында бик күп таралды, укылды. Мәктәпләрдә дәрес китабы булып истигъмаль ителде. Бу әсәр безнең әдәбиятыбызда иң фанатизм вә тәгассыбка[2] бирелгән бер китап булганга күрә, ул XIX гасырда чыккан консерватизм вә яңалыкка хилаф агымның, Кара Ишми[3] мулланың әсәрләренең алдан килүчесе (предшественник)[4] вә аларның мәгънәви атасыдыр. Аның фанатизм, чи фәкыйһлек идеясе белән язылганлыгын күрү өчен, шушы берничә мисрагны[5] уку җитсә кирәк:

[1] Илх – илә ахриһи – һәм башкалар.

[2] Тәгассыбка – фанатизмга.

[3] Ишмөхәммәт Динмөхәммәтов (Ишми ишан) (1842–1919) – дин эшлеклесе, кадимчелек вәкиле. 1880 еллар уртасыннан Г. Курсави, Ш. Мәрҗани һәм җәдитчелекнең башка вәкилләре карашларына кискен каршы рухани, фикер иясе булып танылa. Ул аларның эшчәнлеген шәригать нормаларыннан читкә тайпылу дип исәпли. И. Динмөхәммәтов татар милләтен саклап калуның бердәнбер юлы – традицион мөселман белеме һәм башка дин тотучылардан аерым тулы автономия дигән фикердә тора.

[4] Кирилл хәрефләре белән язылган.

[5] Мисраг – шигырь юлы.

Фи афәт әл-әзен[1]

«Сакыйнә дәкелмийә сазлә сүз,
Дәхи мизмар[2] вә канун[3] чиштә капу,
Дәхи танбур[4], дәхи чәнг[5] вә җәганә[6]
Колакә тотмайә һәм аның уйланә[7].
Ишетмийә дәхи фәхеш илә гайбәт,
Тәганнидән[8] качә һәр дәм бигаять[9].
Кирәк Коръән, кирәк әзкяр[10] вә әшгар[11]
Тәганнисез[12], ләхенсез[13] улә, зинһар».

Бу фикерләр ни өчен бу кадәр коры? Ни өчен Пиргули, бу кадәр арттырып җибәреп, хәтта Коръәнне дә көй белән укырга кушмый? Моның төп сәбәбе башта әйтелгән ортодокслыкта, «чи фәкыйһлек»тәдер. Суфилар күк музыка вә әшгар мөхибе[14] булган мөхәррирләр, билгеле, болай язмыйлар. Алар һәрбер тар фикердән ерак. Аларның фикерләре үзләре сизмичә тәлкыйн итә[15] торган пантеизм мәсләге күк киң була. Әмма чын фәкыйһләр булса, алар инквизиторлар булалар. Аларның фикерләре көтебе мөкаддәсәнең[16] катып калган аятьләре күк зынҗырлар белән багланган. Шулар шикелле үк, ул фикерләр хәрәкәтсез. Алар атларга истигъдадсыз[17], күгәргән булалар. Әгәр суфилар

[1] Фи афәт әл-әзен – колак афәте турында. Биредә музыка тыңлау, Коръәнне көйләп укуның һәм тыңлауның зыяны турында сүз бара.
[2] Мизмар – флейта.
[3] Канун – лира, арфа.
[4] Танбур – гитара, мандолина.
[5] Чәнг – арфа; кыллы уен коралы.
[6] Төрле уен кораллары. *(Авт. иск.)*
[7] Уйланә – уйнама.
[8] Көйләүдән. (*Авт. иск*.).
[9] Бигаять – чиктән тыш.
[10] Әзкяр – дини зикерләр.
[11] Әшгар – шигырьләр.
[12] Тәганнисез – көйләмичә.
[13] Ләхенсез – көйсез.
[14] Мөхибе – сөюче.
[15] Тәлкыйн итә – аңлата.
[16] Көтебе мөкаддәснең – изге китапларның.
[17] Атларга истигъдадсыз – атлап барырга комачау итә торган.

табигатьнең бөтен зоһурат вә матурлыкларына табынучы кешеләр булсалар, «чи фәкыйһләр» шул искергән текстларның тузган фикерләренә, хәтта формулаларына тәре итеп табынучы булалар.

Менә мөтәсаувиф[1] «чи фәкыйһлек»тән тышта торган Исмәгыйль Хаккыйның «Мәгърифәтнамә»се бөтенләй башка аһәң белән суарылган. Бу әсәр бездә 1895 елда күп кыскартылып басылып таралды.

«Мәгърифәтнамә» иясе Исмәгыйль Хаккый – XVII гасыр миладида Эрзерум санҗагында[2] Хәсән кальгасында туган, 1186 һиҗридә вафат булган Төркиянең галим вә мөтәсаувифы. Аның тарикатькә даир бер шигырь диваны да бар.

«Мәгърифәтнамә» – урынына карап нәсер яки нәзым белән язылган калын бер китап. Аның теле вә өслүбе авыр. Гарәп вә фарсы сүзләре белән тулган. Хәтта җөмлә тәртипләре дә кайсы җирдә фарсыча. Бу эш – билгеле, замана бәласе: бу чакта госманлыларның телләре бозылган, әдәби телләре ясалып җиткән заман иде.

«Мәгърифәтнамә» үзенең рухында тәгассыбның[3] юклыгы белән аерылып тора. Ул – XVII гасыр ислам галәменең гыйлемнәр энциклопедиясе, аның мөндәриҗәсе бик киң. Ул бер мөкаддимә, өч фән, бер хатимә үзәренә[4] язылган. Мөкаддимәдә ислам галимнәре, көтебе мөкәддәсә, бигрәк тә суфилар тәсаувыр иткәнчә[5], күк вә хыяләт галәме булган Гареш, Көрси, Җәннәт, Җәһәннәм шикелле урыннар тасвир ителә. Мөәллиф үзе аны «һәйәте ислам» дип атый. Беренче фән – «Маһият җәваһир вә әгъраз вә һәйәт гонасыйры[6] – өч баб илә белдерер». Монда Алла, галәм, аның ясалышы хакында сөйләнә, димәк, бу үзенә

[1] Мөтәсаувиф – суфи.
[2] Санҗагында – өлкәсендә.
[3] Тәгассыбның – фанатизмның.
[4] Үзәренә – бәйлелектә, нигезләнеп.
[5] Тәсаувыр иткәнчә – гәүдәләндергәнчә.
[6] Галәмнең, җир һәм күкләрнең яратылышы.

күрә космология, физика һәм астрономия. Соңгысын мөхәррир икегә бүлеп сөйли: «һәйәте кадимә»[1], «һәйәте җәдидә»[2]. Соң ничек ул ике төрле бер-беренә каршы хакыйкатьне бергә оештыра ала? Исмәгыйль Хаккыйның фикеренчә, ул һәйәте кадимәне ислам фәлсәфә вә хикмәтен тасвир кылырга кирәк булганлыгы өчен яза, ләкин аның төп ихласы һәйәте җәдидә ягында. Ул, аңар каршы булган бәгъзы фикерләр вә игътиразларны[3] сөйләп, соңра аларга бик матур җаваплар биреп китә. Ләкин мәсьәләнең башка ягы бар. Бит бөтен ислам гыйлеме, ислам галәмендә мәшһүр булып, дини игътикад[4] шикелле булып киткән Бталомеусның (Птоломей)[5] «әл-Мохит»ендәге җирнең түгәрәк булуы, аның бөтен галәмнең мәркәзе булулары белән нишләргә? Һәйәте җәдидәне кабул кылу соң дингә каршы кыям[6] булачак түгелме? Ләкин мөәллиф аннан курыкмый; ул андый сөальләргә, безнең XIX гасыр галиме Мәрҗани күк, шундый матур җавап бирә: «Анчак гафләт улынмасын ки, әхвәле мәркумәйә игътимад вә игътикад итмәк өмуре диния вә ләвазим бакыядән дәгелдер. Зира ки, төп галәм һәр нә шәкел вә һәйәт улыб улсын, вә әҗрам вә әҗсамың тәркибе һәр нә кыяфәттә булынырса булынсын, бу чәрех фәләк һәр нә тәкъриб илә дүнерсә дүнсен, һәман галәмең хөдүсене инкярә мәҗал улынмадыгына вә мәүһиа көллү бәдигъ әл-әшкял бер санигъ мөтәгали Җәнабе Зөлҗәлалең сонгый бер кәмале булындыгыннан гайре хыял әмер мәхаль улдыгына игъ-

[1] Һәйәте кадимә – борынгы астрономия.
[2] Һәйәте җәдидә – яңа астрономия.
[3] Игътиразларны – каршы фикерләр.
[4] Игътикад – ышану, инану.
[5] Клавдий Птолемей (87–165) – борынгы юнан астрономы, астролог, математик. Птолемейның төп әсәре «Математик система» дип атала. «Математик система» 13 китаптан тора һәм безнең көннәргә гарәп тәрҗәмәсе аша «Әлмагест» яки «әл-Мәҗис» исеме белән килеп җитә. Бу китапта антик чор астрономнарының белемнәре системага кертелә һәм гомумиләштерелә. Птолемей кешегә күренә торган Кояш, Ай һәм Кояш системасының тагын биш планетасының хәрәкәтен тасвирлаган математик система кора.
[6] Кыям – баш күтәрү.

тимад вә игътикад итмәк ләвазим диния вә өмуре йакыйниядәндер»[1], – ди.

Шул ук беренче фәндә мөәллиф риязияттән[2] хисап вә аның гакыйдәләрен, һәндәсәнең[3] төп шәкелләре хакында мәгълүмат биреп узганнан соң, голүме табигыядән мәгадин, нәбатат вә хайванатка күчә[4]. Икенче фәндә булса, гыйльме тәшрихка[5] керешә, адәмнең төрле әгъзалары вә аларның функцияләрен заманына күрә тулы һәм озын итеп сөйли. Фи салис[6] булса, инде анысы – игътикад вә тәсаувыфның нәзариясе вә практикасы. Монда ул, җанга күчеп, үзе әйткәнчә, кальбен тәхлил итәргә[7] тотына. Хатимә исә әхлакы исламиягә багышланган. Монда инде яңа нәрсә юк. Шул ук «Пиргули китабы»ндагы принциплар – Насыйриның «Фәвакиһелҗөләса» вә «Кырык бакча»сының мәнбәгы[8] булган «Мөстәтраф»тагы әсәслардыр[9].

Татар укучысы госманлылардан дини-тарихи бер әсәр дә алды. Ул исә «Алты бармак» китабы исеме белән мәгълүм. «Дәляиле нөбүвәт Мөхәммәди вә шәмаиле фөтүвәт Әхмәди»дер[10].

---

[1] Гафләт булмасын ки, (галәм турында) язылганнарга ышану һәм таянып эш итү дини эшләрдән һәм бакыйлык өчен кирәк булган гамәлләрдән түгелдер. Чөнки галәмнең асылы ни шәкелдә ясалган булса булсын, күк җисемнәре һәм йолдызларның төзелеше ни рәвешле булса, шулай булсын, күк йөзе ничек хәрәкәт иткән, шулай хәрәкәт итсен, әмма шул ук вакытта галәмнең барлыкка килүен инкяр итәрлек, тиңе булмаган бу җисемнәрнең Аллаһы Тәгалә тарафыннан барлыкка китерелгән камил бер система икәнлеген кире кагарлык көч юк. Менә шуларга инану һәм таянып эш итү – дини эшләрдән һәм ахирәт гамәлләреннәндер.

[2] Риязият – математика.

[3] Һәндәсәнең – геометриянең.

[4] Голүме табигыядән мәгадин, нәбатат вә хайванатка күчә – табигать белеменнән казылма байлыклар, үсемлекләр һәм хайваннарга күчә.

[5] Гыйльме тәшрих – анатомия.

[6] Салис – өченче.

[7] Тәхлил итәргә – аерырга.

[8] Мәнбагы – чыганагы.

[9] Әсаслардыр – төп төшенчәләрдер.

[10] «Дәляиле нөбүвәт Мөхәммәди вә шәмаиле фөтүвәт Әхмәди» – «Мөхәммәднең пәйгамбәрлегенә вә Әхмәднең затлы сыйфатларына дәлилләр».

Бу әсәрнең мөхәррире – Мөхәммәд ибн Мөхәммәд әфәнде Чокрыкчызадә[1] дигән кеше. Үзе Эскуб шәһәрендә туган вә шунда вафат булган.

Бу кеше «Мөхәммәдия» иясе шикелле могтәдил[2] тәсаувыф тарикатьләреннән Бәйрәми тарикатенә мәнсуб кеше булып, 1623 миладида вафат иткән. Бу кеше заманасының мәшһүр мөдәррис вә вәгыйзьләреннән булган. Бер вакытта Истанбулда вә Каһирәдә мөдәррис һәм вәгыйзь булып торган.

«Алты бармак» китабы – чыгтай әдәбиятындагы «Кыйссас әл-әнбия Робгузи» шикелле, пәйгамбәрләр, бигрәк тә Мөхәммәд пәйгамбәрнең тәрҗемәи хәленә даир язылган әсәрдер. Монда да «Мөхәммәдия»дәге күк Мөхәммәд пәйгамбәр мәркәз итеп алына да, шуның сәире[3] өчен кирәкле башка вакыйгалар да языла. Бу әсәр Казанда берничә мәртәбә 1861 елда басылды. Басылганчы, язма килеш халык арасында укылып йөргәнме – анысы мәгълүм түгел, безгә аның кульязмалары очраганы юк.

Әсәр шактый авыр госманлы шивәсендә язылган. Бик күп хәдис вә аять тыгып, мөхәррир әсәрне укырга читенләштерә, анда шигърият бик аз. Тасвирлар бик садә, матур урыннар бик сирәк очрыйлар. Әсәрнең рухында тойгыга караганда акыл күбрәк роль уйный. Ләкин ул акыл да нәү[4] иҗат түгел – суфилык белән чын фәкыйһлекне бергә җыю өченрәк язылганы әсәрнең аһәңеннән сизелеп тора.

Тәмам.

---

[1] Мөхәммәд ибне Мөхәммәд Чыкрыкчызадә (1623 елда вафат булган) – төрек галиме. Китапның исеме авторның кушаматы – Алты Бармак белән бәйле. Шул исем белән әсәр киң таралыш алган, автор биргән исем әкренләп онытылган.

Китап фарсы галиме Мөхәммәд әл-Фәрәхинең (Муин-Мискиннең) «Мөгариҗ ән-нөбуа» («Пәйгамбәрлек баскычлары») исемле трактаты нигезендә язылган. Пәйгамбәрләр тормышыннан вакыйгалардан, сахабәләрнең һәм авторга замандаш галимнәрнең Мөхәммәд пәйгамбәр турында фикерләреннән тыш, китап тарих, педагогика һ.б. фән тармакларыннан да күп кенә мәгълүматларны үз эченә ала.

[2] Могтәдил – уртача.

[3] Сәир (сирә) – тормыш юлы, яшәү рәвеше.

[4] Нәү – яңа.

# ӨЧЕНЧЕ БҮЛЕК

## XVII, XVIII ҺӘМ XIX ГАСЫРЛАРДА ИСКЕ ӘДӘБИЯТ

### Мөкаддимә урынына[1]

Татар әдәбиятының тарихын тикшерү юлында бер тәҗрибә булган бу әсәребезнең беренче җилде[2], ягъни бездә Яурупа тәэсире башланганчы туган тәмамән Шәрык тәэсирендәге борынгы кыйсеме хәзер язылып тәмам булды.

Бу әсәр дәреслек булу йөзеннән тәртип ителмәгән. Эчендәге материалның гомуми бер бәйләнеше булса да, ул җепкә тезелеп язылмаган, бәлки аерым-аерым (мөстәкыйль) мәкаләләрдән тора. Бу мәкалә-фикъраләрнең[3] бер-берсенә галякасы[4], әлбәттә, бар. Алар, билгеле бер әсаста[5] бер-бер артлы тезелеп, һәммәсе бергә бер көллият[6] тәшкил итәләр. Бөтен җилднең гомуми мөкаддимәсендә бу хакта мөфассал[7] тукталынды.

Бу җилд өч бүлеккә бүленә:

1 нче бүлек. «Борынгы төрк әдәбиятларына бер караш».

Мөндәриҗәсе[8]: Мөкаддимә (Г. Газиз, Г. Рәхим). Мәдхәл (Г. Рәхим). Орхон язулары (Г. Рәхим). Уйгур әдәбияты (Г. Рәхим). Суфилык вә аның төрк-татар әдәбиятына тәэсире (Г. Газиз, Г. Рәхим). Чыгтай әдәбияты (Г. Рәхим). Госманлы төркләрнең әдәбияты (Г. Газиз).

---

[1] Өч бүлекне бергә төпләткән вакытта бу мөкаддимә ертылып алыныр. *(Авт. иск.)*

[2] Җилде – томы.

[3] Фикъраләрнең – бүлекләрнең.

[4] Галякасы – бәйләнеше.

[5] Әсаста – нигездә.

[6] Көллият – бөтенлек.

[7] Мөфассал – тулы, җентекле.

[8] Мөндәриҗәсе – эчтәлеге.

2 нче бүлек. «Идел буендагы иң борынгы тел ядкәрләре һәм татар арасына чыгтай вә госманлы әдәбиятларыннан кергән әсәрләр».

Мөндәриҗәсе: Идел буе төркләренең әдәбияты [тарихи-иҗтимагый мөкаддимә] (Г. Газиз). «Коман мәҗмугасы» (Г. Газиз). Болгар кабер ташлары (Г. Газиз). Ярлыклар (Г. Газиз). Идел буенда чыгтай әсәрләре: Робгузи (Г. Рәхим). Сөләйман Бакыргани вә аның әсәрләре (Г. Рәхим). «Рәүнәкъ әл-ислам» (Г. Рәхим). «Мәхзән әл-әсрар» (Г. Рәхим). «Кыйссаи Сәйфелмөлек» (Г. Рәхим). «Сөбат әл-гаҗизин» (Г. Рәхим). «Кисекбаш китабы» (Г. Рәхим). «Йосыф вә Зөләйха» (Г. Газиз). Идел буенда госманлы әсәрләре: «Мөхәммәдия» (Г. Газиз). Сугыш катаплары (Г. Газиз). Сәид Баттал китабы (Г. Газиз). Кыйсса китаплары (Г. Газиз). «Ләтаифе Хуҗа Насреддин» (Г. Газиз). Госманлыча дини вә фәнни китаплар (Г. Газиз).

Өченче бүлек (ошбу китап) – «XVII, XVIII һәм XIX гасырларда иске әдәбият».

Мөндәриҗәсе: «Тәварихе Болгария» (Г. Рәхим). «Җәмигъ әт-тәварих» тәрҗемәсе (Г. Рәхим). «Галикәй Аталык васыятьнамәсе» (Г. Рәхим). «Әхвәле Чыңгыз хан вә Аксак Тимер» (Г. Рәхим). Вәкаигънамәләр (Г. Газиз). Исмәгыйль сәяхәтнамәсе (Г. Газиз). «Бәдәвам китабы» (Г. Рәхим). Догалык, фалнамә, йолдызнамә вә төш тәгъбирләре (Г. Газиз). «Иман шарты» (Г. Газиз). «Рисаләи Газизә» (Г. Рәхим). «Фәзаил әш-шөһүр» (Г. Рәхим). Хикәят китаплары, «Таһир илә Зөһрә» һәм «Бүз егет» кыйссалары (Г. Рәхим). «Кыйссаи Нәбрүз» (Г. Рәхим). Иске шагыйрьләр (Г. Рәхим). 1. Габдерәхим Утыз Имәни (Г. Рәхим). 2. Әбелмәних Хаҗи (Г. Рәхим). 3. Габделкаһир Сөләйман углы (Г. Рәхим). 4. Шәмседдин Суфи Зәки (Г. Рәхим). 5. Һибәтулла Ишан (Г. Рәхим). 6. Мәхмүд Ширвани (Г. Рәхим). Габделҗәббар Кандалый (Г. Рәхим). Бәетләр (Г. Рәхим).

Беренче бүлектәге мәкаләләр турыдан-туры татар әдәбияты тарихына гаид булмаса да[1], татар әдәбиятының борынгы

[1] Гаид булмаса да – карамаса да.

дәверен өйрәнү өчен чыгтай вә госманлы әдәбиятларының гомуми барышын белү лязим[1] булганга, аларга аерым мәкаләләр багышланды. Уйгур әдәбияты исә, чыгтай әдәбиятына тәэсире булганга күрә, Орхон язулары да иң борынгы төркчә язу нәмунәләреннән[2] булу йөзеннән, гомумән картинаны тулыландыру өчен кертелделәр. Икенче бүлеккә, турыдан-туры татар әдәбиятына катнашлары булмаса да, хәзерге татар халкын ясауда гонсырлык хезмәтен иткән[3], борынгы заманда Идел буенда яшәгән төрк халыкларыннан сакланып калган тел ядкәрләре кертелде. Бу бүлекнең иң зур кыйсемен безнең татар арасына чыгтай вә госманлы әдәбиятларыннан кереп тә, үзгәртелмичә укылып килгән һәм, тәмамән үзләшеп, татар халкының үз әдәби малы хөкемендә булып киткән әсәрләр тәшкил итә. Өченче бүлек исә баштанаяк соңгы өч үткән гасыр эчендә Идел буенда татарларның үз язучылары тарафыннан язылган (оригиналь) әсәрләрдән гыйбарәт.

Шуңар күрә, бу җилднең иң әһәмиятле кыйсеме – өченче бүлегедер. Моңар кадәр ни мәктәпләр, ни укучы халык өчен бу бабта һичбер төрле әсәрнең мәйданда булмавын игътибарга алып, бу өченче бүлек алдан нәшер ителә торды. Калган бүлекләре дә Дәүләт нәшрияты кулында булып, басылырга хәзерләнгән. Һәм техника ягыннан имкян[4] булу белән, тиз көннән басылып чыксалар кирәк.

Бу китап өчен вакыты белән аерым нәмунәлек (хрестоматия) чыгарылачак. Шуңар күрә мисаллар күп алынмады.

Мөәллифләр[5]

[1] Лязим – тиеш, кирәк.
[2] Нәмунәләреннән – үрнәкләреннән.
[3] Гонсырлык хезмәтен иткән – катнашкан.
[4] Имкян – мөмкинлек.
[5] Мөәллифләр – авторлар.

**«Тәварихе Болгария»**

Идел буенда язылып та, безгә мәгълүм булган китапларның иң искеләреннән берсе – «Рисаләи Тәварихе Болгария вә зикре мәүлānә хәзрәте Аксак Тимер вә хәрабе шәһре Болгар» аталган китап. Бу – басмада урта кул кырык битле, нәсер белән язылган бер рисалә.

«Тәварихе Болгария»нең язучысы – китапның үзендә әйтелгәнчә, Ташбилге авылының[1] Хисамеддин бине Шәрәфетдин әл-Мөслими атлы кеше. Ул китапның башында шушы сүзләрне яза:

«Бу китап тәмам улынды Ташбилге карьясендә шәһре Болгарның җуарендә[2] тарихе һиҗрәтнең тукыз йөз илле сикездә голәма[3] Тәфтазани заманында ирде аның мәдрәсәсендән укып кайтдыкым заманда; тәвабигъ Болгарның мәшаихләре[4] төрки теле берлә мәкамәт табигыйндән вә гарәиб галәминдән[5] бер рисалә язмага боердылар, анларның илтимасларына имтисалән[6] бу нөсхәнең тәсвиденә[7] шөругъ идәлем[8]».

Китапның ахырында без түбәндәге сүзләрне укыйбыз: «Бу рисаләгә “Тәварихе Болгария” дию исем бирдек, фәкыйрь Хисаметдин бине Шәрәфетдинне догаи хәерегездән фәрамуш[9] боермаясызлар тарихе һиҗрәтнең тукыз йөз туксан икенче елында Ташбилге авылында маһи мөхәррәмнең 15 нче көнендә, җәүзаның[10] һәм унынчы көнендә сычкан елында бу рисалә тәмам улынды».

[1] Спас кантонында. *(Авт. иск.)*
[2] Җиварендә – тирәсендә, янында.
[3] Голәма – галим.
[4] Тәвабигъ Болгарның мәшаихләре – Болгар өлкәсенең шәехләре.
[5] Мәкамәт табигыйндән вә гарәиб галәминдән – изгеләр тормышыннан һәм таң калырлык вакыйгалар дөньясыннан.
[6] Илтимасларына имтисалән – үтенечләрен кәнагатьләндереп.
[7] Тәсвиденә – караламасына.
[8] Шөругъ идәлем – керешәмен.
[9] Фәрамуш – оныту.
[10] Җәүзаның – май аеның.

Менә бу сүзләргә караганда, Мөслими бу китапны милади 1551 елда яза башлап, 1572 елда тәмам иткән. Димәк, бу кеше – XVI гасыр кешесе. Ул бу әсәрне, Казан алынудан бер ел элек яза башлап, Казан алынганнан 31 еллар соң тәмам иткән. Үзенең «Мөстәфад әл-әхбар»ендә «Тәварихе Болгария»гә рәхимсез тәнкыйть язган Шиһаб Мәрҗани аның хакында: «Һай-һай, никадәр күп заман шөгыль берлә тәхкыйкләнгән[1]», – дип истиһза кылып[2] китә. Аннан соң аның үзен Тәфтазанинең шәкерте дип атап, аннан дәрес алып кайтуын сөйләве – һич асылсыз бер сүз. Чөнки Тәфтазани милади 1389–[13]90 елларда, ягъни Мөслиминең аннан «дәрес алып кайтып килгәндә» дип язган елыннан 160 еллар элек вафат булган. Шуннан күренә ки, бу кешенең язуларында фактлар коры наданлык белән генә түгел, бәлки кассасдан[3] буташтырыла, аның сүзләрендә ачыктан-ачык ялганнар бар. Менә шуның өчен дә аның үзе хакында сөйләнгән сүзләренә, китергән тарихларына шөбһә белән карамый мөмкин түгел. Кайбер тикшерүчеләр Мөслими хакында соңрак заманда яшәгән бер кеше булырга кирәк дигән фикергә килгәннәр. Чынлап та, китапның теле дә, мөндәриҗәсе дә бу фикерне куәтли. «Тәварих»нең теле бик яңа, бик татарча: бер дә моннан 250 еллар әүвәл язылган бер китапның теле булырга охшамый. Мөндәриҗәсенә килгәндә, Казан алынганнан бераз гына соң язылган бер әсәрдә Казан алыну шикелле зур бер тарихи фактның һичбер төрле ингыйкяс итмәве[4], мөәллифнең бу хакта бер авыз сүз сөйләмәве – гаҗәпсенерлек бер эш. Аннан соң ул үзенең китабында әллә никадәр мәшаих вә әүлияләрне санаса да, Казан шәһәрендә булган галим вә изгеләрне телгә алмый, һич булмаганда, Кол Шәриф мулла шикелле, Казанның соңгы вакытындагы атаклы руханиларыннан булып, Казан руслар тарафыннан алынган чакта зур фидакярлекләр күрсәтеп шәһит

[1] Тәхкыйкләнгән – тикшергән.
[2] Истиһза кылып – мыскыл итеп.
[3] Кассасдан – сөйләүченең үзеннән.
[4] Ингыйкяс итмәве – чагылмавы.

булган бер зат хакында бер сүз әйтми. Вә халәнки[1], Казан алынуы аның күз алдында булган бер эш булырга тиеш иде, халыкның хәтере дә борынгы хан заманындагы Казан белән байтак изгеләрне, газиләрне бәйләп йөртә, әмма Казан изгеләре хакында Мөслимидә бер дә тәфсил юк. Аннан соң Мөслими руслар һәм рус тормышы белән шактый таныш булганга охшый. Бер урында ул русларның Покрау бәйрәмнәре хакында сөйли. Аның телендә дә «Волга»[2], «Рим»[3] шикелле русча тәгъбирләр очрый, вә халәнки, Казан алынганчы Төркестанда укыган, үзенең әсәрен Казан алынгач утыз еллардан соң гына язып бетергән бер татарның руслар белән ул дәрәҗәдә таныш булуын ихтимал тотып булмый. Шул ук вакытта Мөслими Аксак Тимер заманында «Мәскәүдә хан рус Иван Вачилий углы иде», ди. Әсәрдә ул Казан алыну дәверендәге кеше булса иде, үз заманындагы рус падишасының исемен белер иде, аны Тимер заманасындагы кенәз белән саташтырып йөртмәс иде. Шушы сүз үзе аның Мөдһиш[4] Иван заманасыннан күп соң килгән кеше икәнлеген күрсәтә. Чынлап та, Казан татарларының башына Казан ханлыгының җәберан, каһәран бетерелүе шикелле бер фәлякәт[5] килеп торган чагында, бөтен татар халкының тормышы үзенең тупсасыннан сөрелеп, һәркем башының исән калуы хакында гына уйлаган бер заманда китап язу өчен зәмин[6] булмагандыр дип уйланыла. Һәрхәлдә, бу китап XVIII гасырдан да соң язылмаган. Соңрак заманда халык хәтереннән тәмам югалган бәгъзы бер хатирәләрнең, заманның узуы белән тәләф булган[7] бик күп иске каберләрнең аңар мәгълүм булуына карап, Мөслиминең шактый иске заман кешесе булуын чамаларга мөмкин.

---

[1] Халәнки – чынлыкта.
[2] Кирилл хәрефләре белән язылган.
[3] Кирилл хәрефләре белән язылган.
[4] Мөдһиш – явыз.
[5] Фәлякәт – бәла.
[6] Зәмин – җирлек.
[7] Тәләф булган – юкка чыккан.

«Тәварихе Болгария» татарлар арасында бик таралган, халык тарафыннан бик яратып укыла торган бер китап булган. Рус мөстәшрикъларының кулында, пайтәхет көтепханәләрендә аның байтак кулъязмалары булган һәм бар. Хәзерге көндә дә халык арасында аның язма нөсхәләрен табарга мөмкин. 1832 елда язылган бер нөсхәсеннән алып, бу китап 1887 елда Казанда бастырылган. Элеккеге заманда милли тарихыбыз булу йөзеннән халык арасында ошатылып укылып йөргән хорафи әсәрләрдән берсе һәм дә иң мәкъбүл булганы[1] – шушы. Шиһаб хәзрәт аның бәгъзы талибә вә хәвас[2] каршында да мәкъбүл булганын әйтеп уза.

Бу китап никадәрле «Тәварихе Болгария» аталып йөртелсә дә, анда Болгар хакында мәгълүмат бит аз. Язучы үзенең әсәрен ике бүлеккә бүлеп йөртә. Беренче бүлеген «Әл-мәкаләт әл-әүвәли фи гаҗәиб әл-мәхлукат»[3] дип, икенчесен «Әл-мәкаләт әс-сани фи мәкамәт әт-табигыйн вә-т-тәбигать»[4] дип атый. Китапны тәэлифдән[5] максудын мөәллиф башта шушы сүзләр белән бәян кыла:

«Әмма бәгъд. Бу фәкыйрь әл-хәкыйрь калил әл-бизагать вә кәсир әл-биталәт Хисамеддин бине Шәрәфеддин әл-Болгари әйдер ки, хадисәт шөһүр румиянең бәянлары вә хәвадис җәүрләре "Китабе Мәлхәмә"дән бәян улынды. Шимди шөһүр гарәбиянең исемнәрене вә вәҗһе тәсмияләрен вә сәгыд вә нәхесләрен мөстәкыйлән бәян әйләмәк лязим улды вә дәхи кәвакиб сәбганең сәгыд вә нәхесләрене бәян әйләмәк мөһим улды вә дәхи бу китабә язмак лязим улынды безнең шәһре Болгарның мөселман улдыкы заманында сахабәи кәрам ризван Аллаһы Тәгалә галәйһим әҗмәгыйннән тәгълим вә тәхсил идән табигыйн вә табигатьләрне бәян итмәк вә анлардан соңра әүлия гыйзам вә

[1] Мәкъбүл булганы – яхшы табылганы.
[2] Талибә вә хәвас – шәкертләр һәм зыялылар.
[3] «Гаҗәеп җан ияләре турында беренче бүлек».
[4] «Изге ир-атлар һәм изге ханымнар тормышы турында икенче бүлек».
[5] Тәэлифдән – төзүдән.

мәшаихе кәрам бу диярдә кемләрдер анларны бәян әйләмәк әмер газыйм улынды вә анлар кайу илләрдә мәдфүн улдылар»[1].

Китапның мөндәриҗәсе нидән гыйбарәт булганлыгы, мөәррихнең аңар нинди ноктаи нәзардән торып караганлыгы шул мөкаддимәдән ачык күренсә кирәк. Китап берничә фасылга бүленә.

Беренче фасылда атнадагы көннәрнең хасиятләре вә аларның ислам тарихы мөкаддәсенә мөнәсәбәтләре сөйләнә. Кайсы көннәрдә тырнак кисүнең ярап-ярамавы Мөслими өчен бик әһәмиятле. Икенче фасылда сәнәи камәрия[2] айларының хасиятләре һәм аларның тарихы мөкаддәскә мөнәсәбәтләре сөйләнә: гарәби айларның ни өчен ул исемнәр белән аталулары хакында хикәяләр китерелә, бу айларның юнанча, сүрияле телдә исемнәре шулай дип, һич дөньяда булмаган исемнәр атала. Әлхасыйль[3], китапның бу кыйсеме – календарь сымак бер нәрсә, ләкин анда китерелгән тарихи мәгълүматның да күбесенең ялган вә асылсыз риваятьләр булуын Мәрҗани үзенең тәнкыйтендә әйтеп уза.

Шуннан соң «килдек үземезнең икълим[4] бәянына» дип, Мөслими җәгърафи[5] мәгълүмат бирергә керешә. Бу – үзенә күрә Болгар иленең җәгърафиясе. Бу кыйсемдә ул Болгар өлкәсе керә торган җиденче икълим, аның чикләре, мәшһүр агымсулары хакында сөйли. Мөслиминең бирә торган җәгърафи

[1] Түбән дәрәҗәле фәкыйрь, белеме аз, эшсезлеге күп Хисаметдин бине Шәрәфетдин әл-Болгари әйтер: «Милади ай исемнәре, алар белән бәйле вакыйгалар “Мәлхәмә” китабыннан бәян ителде. Гарәп айларының исемнәре һәм аталышлары, аларның уңыш яки бәла-каза китерә дип уйланылганнарын мөстәкыйль рәвештә билгеләргә һәм бу китапка язарга туры килде. Безнең Шәһре Болгарның мөселманлыкны кабул иткән заманында изге сахабәләрдән (Аллаһы Тәгалә аларның барсыннан да разый булсын) белем алган, укыган табигыйннәр һәм табигыйн ханымнар турында бәян итү, алардан соң бөек әүлияләр һәм изге шәехләр, аларның кайда җирләнгән булулары һәм Болгар илендә яшәгәннәр турында бәян итү үтенеп соралды».

[2] Сәнәи камәрия – ай яңаруы буенча хисапланган ел.

[3] Әлхасыйль – кыскасы.

[4] Икълим – климат.

[5] Җәгърафи – географик.

мәгълүматы, әлбәттә, хәзерге фәнни җәгърафиядән бик ерак тора. Мөәллиф үзе бу мәгълүматны Бталомеус хәким (Бталамеус – Птоломей[1])ның «Атлас» исемле әсәреннән (әлбәттә, аның гарәпчәсеннән) алып тәрҗемә иткәнлеген яза. Димәк, аның җәгърафиясе – Бталамеус җәгърафиясе, ягъни моннан ике мең ел элек бер юнанлы галим тарафыннан шул заманның сабый фәне ноктаи нәзареннән карап төзелгән җәгърафия. Ислам галәме, мәдәнияткә аяк баскан вакытта, юнанлыларны үзләренә мөгаллим иттихаз итеп[2], аларда булган дөньяви гыйлемнәргә гаид әсәрләрне тикшерүсез хакыйкатькә хисаплап алганнар. Шулай итеп, борынгы юнан фәне ислам галәмендә дөньяви гыйлемнең бердәнбер ышанычлы нигезе булган. Борынгы җәгърафия җир йөзен дүрт өлешкә бүлеп, аның өч өлешен уттан (эсселектән), судан һәм салкынлыктан «хәраб»[3] дип исәпләп, бары гарәпләр тарафыннан «робгы мәскүн» аталган дүртенче өлешен генә инсан торыр өчен сәләхиятле[4] санаган. Шул «робгы мәскүн» җиде икълим, ягъни климатка бүленгән, бу җиде икълим эченә, әлбәттә, шул борынгы галәмгә мәгълүм булган җирләр генә кергәннәр. «Тәварихе Болгария» мөәллифе җәгърафия гыйлеме белән шөгыльләнгән булырга кирәк, чөнки ул китапның бер урынында «безләрнең үз ки йортлар бәянында улган вә һәм әкалимләр[5] бәянында улган икенче тәфсыйлән[6] язган рисаләмез вардыр», – ди. Ләкин аның бу китабы хәзергә кадәрле табылганы юк. «Тәварихе»ндә исә ул, җәгърафиягә читтән генә кагылып, бары тик Болгар иленең җәгърафи халәтен тасвир өчен генә туктала. Шуның өчен ул җиденче икълим, ягъни шәркый Яурупа вә Гарби Яурупаның бер кыйсеме хакында гына сөйли. Алтынчы икълимгә, ягъни Урал тауларыннан шәрыкка таба, Кытайга хәтле булган җирләргә ул бары

[1] Кирилл хәрефләре белән язылган.
[2] Иттихаз итеп – кабул итеп.
[3] Хәраб – бозылган; харап ителгән.
[4] Сәләхиятле – сәләтле.
[5] Әкалимләр – климатлар.
[6] Тәфсыйлән – җентекләп.

җиденче икълимгә мөнәсәбәте булганга күрә генә кагыла һәм, ни өчендер, «икълим» мәгънәсендә бәгъзан «Урал» дигән сүзне куллана. Ләкин аның икълимләр хакында белеме чуалчык, мәсәлән, ул алтынчы икълим белән җиденчене болгатып, чуалтып йөртә, аның күбрәк әһәмият биргән нәрсәләре – нәһерләр[1], анда да Идел хаузасындагы[2] Болгар илендәге нәһерләргә мөфассалрак[3] туктала. Миас, Ай, Өфе, Чирмешән, Нократ, Мишә, Зөя, Казанка шикелле вак-төяк елгаларны шул мәшһүр нәһерләр рәтеннән саный, тәфсилләп, аларның кайсысының кайсысына койганнарын сөйли. Ләкин «Ока иделе[4] Агыйделгә коя» дигән шикелле тупас ялгышлары бар. Җиденче икълимнең башка елгалары хакында ул: «Мәшһүр елгалар чукдыр, барыны язмак мөмкин дәгелдер», – дип кенә уза. Шул ук вакытта әллә кайдагы әллә нинди «Риҗаль әл-гаиб» чишмәсе аның өчен бик әһәмиятле.

Китапның икенче кыйсемендә болгарларның ислам кабул итүләре һәм Болгарда вә Болгарстанда булган табигыйн вә изгеләр хакында сөйләнә. Болгарларның ислам кабул итүләре хакындагы мәгълүмат һәммәсе тарихи дөреслектән ерак булган хорафаттан гыйбарәт. Мөхәммәд пәйгамбәр, Болгар ханы Айдар ханны дингә дәгъвәт кылу өчен, өч сахабәне махсус Болгарга җибәрә. Ханның кызы Туйбикә фалиҗ[5] зәхмәтенә мөбталя[6] булган була, табиблар аны терелтүдән гаҗиз калалар. Сахабәләр, үзләрен табиблар итеп күрсәтеп, халыкны дәвалап йөриләр. Ахырда аларның осталыгы ханга ишетелә. Хан, аларны чакыртып, кызын дәваларга куша. Кызны терелтер өчен яшь каен себеркесе кирәк була. Вакыт кыш көне булганга, себерке табылмый. Әгәр кызын терелтсәләр, хан аларның диннәрен кабул

[1] Нәһерләр – елгалар.
[2] Хаузасындагы – буендагы, бассейнындагы.
[3] Мөфассалрак – җентеклерәк.
[4] Иделе – елгасы.
[5] Фалиҗ – паралич.
[6] Мөбталя – дучар.

итәргә вәгъдә бирә. Сахабәләр кәрамәт[1] белән каен агачы үстереп, шуның себеркесе белән кыз чабынгач, терелеп, мунчадан үз аягы белән йөгереп кайта. Бу кәрамәтне күреп, Айдар хан бөтен вәзирләре һәм шәһәр халкы белән мөселман булалар. Хан кызы Туйбикәне сахабәләрдән Зөбәер бине Җәгъдәгә никахлап биреп, ул, Болгарда калып, шунда вафат була. Башка сахабәләр мәчет бина кылып, халыкка дин өйрәткәннән соң кайтып китәләр. Менә бу – Болгарның мөселман булуы хакында безнең татар арасында бик таралган легенданың вариантларыннан берсе. Бу легенда бик борынгы заманнарда, ихтимал, Болгарның үзендә үк ясалган булырга кирәк. Һәрхәлдә, бу риваятьләрнең төрле вариантлары – язылганнары һәм халык телендәгеләре җыелып, чагыштырылып тикшерелергә тиеш иде.

Мөслими, шушы хикәяне сөйләгәннән соң, Болгар илендәге изгеләрне вә аларның дин тарату юлында кылган хезмәтләрен тәфсыйлән сатарга керешә. Мөәллифнең асыл максаты да Болгар иленең тарихын сөйләү булмаенча, шул изгеләргә хассыр кылына[2]. Китапның бу кыйсеме биш фасылга бүленә: 1) Болгарның үзендә булган табигыйн[3]. 2) Болгарның тирәсендә булганнар. 3) Болгардагы тәбгы табигыйн. 4) Болгардагы табигать (табигаләр). 5) Болгардагы мәшаихләр вә әүлияләр.

Менә бу кешеләрне Мөслими мәгълүм кешеләр шикелле итеп сөйли, аларның кай җирлек, кай авыллык булуларын, каберләре кайда икәнлеген бәян кыла, аларны исемнәре һәм аталары исеме белән атый, аларның мишәрләр вә башкортлар арасында ислам динен тарату юлында кылган хезмәтләрен саный. Шәһри Болгарга сахабәләрнең килүе коры бер мифтан гыйбарәт булганга, бу кешеләрнең табигыйннән була алмаулары хакында, әлбәттә, сүз дә булырга мөмкин түгел, әмма аларның исемнәре

---

[1] Кәрамәт – могҗиза.

[2] Хассыр кылына – багышлана.

[3] Табигыйн (табигънең җәмгысе) – сахабәләр белән утырдаш булган кешеләр. Табигать – хатыннар. Тәбәгъ табигыйн (тәбгы табигыйн) – табигыйн белән утырдаш булган кешеләр. *(Авт. иск.)*

вә эшләре безнең Мөслимигә кайдан мәгълүм булган – бу хакта тәгаенләп бер сүз дә әйтер хәл юк. Ихтимал, ул бу мәгълүматны төрле авылларда халык авызында йөргән риваятьләрдән чүпләп җыйгандыр, төрле изгеләрнең каберләрендәге мөҗавирләрдән[1] ишеткәннәрен язып ала баргандыр. Бу риваятьләрнең күбесе әле аның заманында халыкның хәтерендә булып, соңыннан, заман үтүе белән, онытылып беткәннәрдер. Ихтимал, ул вакытта әле аларның күбесенең кабер ташлары да исән һәм укырлык булганнардыр. Мөслими санаган кешеләрдән каберләре хәзерге көндә дә сәламәт булган һәм халык аңында тарихлары Болгар белән галякале[2] әүлияләр юк түгел. Җөмләдән берсе – Казан артында Әйшә авылындагы казан татарларының бик сөекле зиярәтгяһләре[3] булган Гайшәбикә һәм Мулла Хаҗи каберләрен күрсәтергә мөмкин. Шуңар күрә дә уйлана ки, «Тәварихе Болгария»дә саналган кешеләр – ихтимал, һәммәсе тарихи затлардыр[4]. Аларның исемнәренең дә, күбесенчә, бик борынгы төркчә-татарча исемнәр булуы бу фикерне куәтли. Бу китапта хәзерге тормышта гына түгел, хәтта якынрак заманнарда да очрату мөмкин булган гаҗәп төрле иске татарча исемнәр бар, андый исемнәрне бары тик «Мөстәфад әл-әхбар» вә «Асар»да гына очратып була. Ризаэтдин хәзрәт «Асар»ында Мөслими хакында: «Занымызга күрә[5] бер мәҗзүб[6] адәм булып, гомерләрене зиярәтләрдә йөреп, һәрбер нәзер вә сәдака ашаучылар тарафыннан эшләнеп чыккан хәбәрләргә ышанып язып йөргән улса кирәк», – ди. Риза хәзрәт тә бу кешенең соңрак заман кешесе булуын дәгъва итә.

Китапның бер җирендә шушы сүзләр бар: «Без нәкыль[7] идүке (итдүке?) мәкамат табигыйндә улан китапларда күрелмәде, әмма

---

[1] Мөҗавир – кабер сакчысы.

[2] Галякале – бәйләнешле.

[3] Зиярәтгяһ – зиярәт кыла торган урын.

[4] Мөслими төрле мәшаехләр арасында ниндидер «шагыйрь Синаи»не зикер итә: «кабере Иделгә койган Чушма елгасының тамагында» ди. *(Авт. иск.)*

[5] Занымызга күрә – уйлавыбызча.

[6] Мәҗзүб – мавыккан.

[7] Нәкыль – күчерү.

сахибе әйде (айде – әйтде?) бу ике нәһердә улан табигыйннәр гадәде[1] беленмәде». Бу җөмләнең мәгънәсе яхшы ук караңгы. Табигыйн хакында язылган ниндидер китаплар булып, Мөслими үзенең язганнарын шулардан күчергән дип аңларга мөмкин. Әмма «сахибе әйтде» дигән сүзне ничек аңларга кирәк? Китапта әйтелгәнне әйтәме, әллә ул, китапның мөәллифе Мөслимигә гасырдаш кеше булып, аңар үз теленнән әйткәнме? Китапның бик озын гына (15 битлек) хатимәсе[2] Аксак Тимернең сугышларына багышланган. Монда Тимернең Чыңгыз хан белән, Надиршаһ белән сугышуы, Истанбулны алуы, Болгарны харап итүе хакында сөйләнә. Күренә ки, болар һәммәсе – тарихи дөрес вакыйгалар булмаенча, хакыйкатьтән бик ерак нәрсәләр, Мөслиминең тарих бабындагы наданлыгы җәгърафия бабындагы наданлыгыннан артыграк, ул үз заманасындагы тарих китапларының һичберсе белән таныш булмаска кирәк. Тарихи вакыйгаларны сөйләгәндә, ул шундый фахиш хаталар ясый ки, Мәрҗани үзенең тәнкыйтендә бу хәттән ашкан ялганлауга ачуы килеп, чыдый алмыйча, аны «кәззаб»[3], «җаһил», «ахмак», «сәфиһ»[4] дип атый, әгәр аның бөтен ялгышларын берән-берән санап тәнкыйть итә башласаң, җилдләрчә китап язарга кирәк булыр иде, ди. Чынлап та, аның бөтен тарихи хәбәрләре тоташ бер хатадан гыйбарәт. Мәсәлән, аныңча, Тимер Кытай падишасы (?) Чыңгыз ханны дингә өнди. Кабул итмәгәч, аны үтерә: шулай итеп, Мөслимичә, Чыңгыз үзенең вафатыннан 110 ел соң дөньяга килгән Тимер белән гасырдаш булып чыга. Аннан соң төшендә Хозыр килеп, аңар Бохара шәһәрен «кызылбашлыкдан хәляс әйләргә[5]», Надиршаһны үтерергә Алладан әмер китерә. Тимер, Надиршаһны «әһле сөннәт» итәр өчен, бик озак сугыша. Ахырда җиңеп, башын кисә. Надиршаһ исә XVIII гасыр кешесе булып, вафаты 1747 елда. (Менә моңар караганда, Мөслими XVIII гасыр

[1] Гадәде – саны.
[2] Хатимәсе – йомгак өлеше.
[3] Кәззаб – алдакчы.
[4] Сәфиһ – ахмак, юләр.
[5] Хәляс әйләргә – азат итәргә.

ахырыннан да иртә булган кеше булмаска кирәк), шуннан соң яңадан Хозыр пәйгамбәр килеп, аңа, Истанбулга барып, төрек солтаны Мәһди белән сугышырга куша. Сугыш игълан кылуның сәбәбе – төрек солтанының Истанбул голәмасының һәм халкының бәччәбазлык, каһвә эчү, челем тартуга мөбталя булулары[1], җәмәгать намазыннан калулары, намазга ат белән барулары, кәҗә тәкәләре сөзештереп уйнаулары. Менә төрекләрне шул бозыклыклардан тыю өчен, Алла Тимерне Истанбул өстенә мөсәлләт кыла[2]. Тимер Истанбулны җиде ел мөхасарә[3] кылганнан соң, ахырда хәйлә белән ала. Солтанны әнваг[4] газап белән үтерә. Галимнәрне астыра. Тимер вакыйгаларында иң озын вә мөфассал сөйләнгәне – шушы Истанбул вакыйгасы. Тимернең Йылдырым Баязид белән Анатулыда сугышуын, аны җиңеп әсир алуын Мөслими колагының бер чите белән генә ишеткән яки үз китабы шикелле үк хорафи бер китаптан истифадә итеп[5] язган булырга кирәк. Мәһди исемле төрек солтаны Төркия тарихында булганы юк, Аксак Тимернең дә Истанбулны мөхасарә итүе һәм алуы булган бер эш түгел. Гомумән, Мөслиминең бу тарихи мәгълүматны нинди мәнбәгъләрдән[6] алуы – бик кызыклы һәм тикшерелергә тиеш мәсьәләләрдән.

Истанбулдан соң Тимер һәртөрле бидгатьләрне бетерү өчен Ширванга, аннан Дагстан йортына, аннан Чистай кальгасына, аннан Андрей кальгасына бара. Аннан соң Тимер шәһри Болгарга таба юнәлә. Болгар халкы, мөяссәр[7] юк дип, җомга укымыйлар, биш вакыт намаздан соңгы әүрадләрне[8] калдыралар икән, галимнәре рибаның һәм буза вә максама[9] эчүнең хәләл-

[1] Мөбталя булулары – дучар булулары.
[2] Мөсаллат кыла – башлык итә.
[3] Мөхасарә – камау.
[4] Әнваг – төрле.
[5] Истифадә итеп – файдаланып.
[6] Мәнбәгъләрдән – чыганаклардан.
[7] Мөяссәр – җайлы, җайлылык.
[8] Әүрәдләрне– Коръән аятьләрен укуны.
[9] Буза һәм максама – исерткеч исемлекләр.

легенә фәтва биргәннәр икән. Менә шул гөнаһлары өчен Алла алар өстенә Тимерне җибәрә. Ул вакытта Болгар ханы Бикчура исемле булган.

Мир-Тимер белән Болгар галимнәре арасында төрле шәригать мәсьәләләре хакында озын моназара башлана. Ахырында Тимер гаскәрләренә Болгарга һөҗүм итәргә әмер бирә: «Укларыңызны вә тупларыңызны атыңызлар, биллаһи галиел-газыйм, бу Болгар шәһәренең урыны начиз вә набуд идәрмен[1]», – дип ант эчә.

Таш кальгаларны туп белән ваттырып, Волга төбенә салдыра. Унике вәзире белән Бикчура ханның башларын кистерә, лөәлөә әмсал[2] кызларын вә хатыннарын кол итеп, гаскәрләренең рәисләренә бирә, утыз алты голәманы таганга астыра. Калган халыкка бер җомганың эчендә читкә китәргә әмер итә. Шуннан соң Болгар халкы әтрафка[3] таралалар, Болгар шәһәре исә бетә. Халыкның таралып утыруын Мөслими бу рәвешчә тасвир итә: «Җанбакты карты ыругы илә чыкды. Җанбакты авылы үлде, вә янә безнең Мөслим бабамыз ыруы берлә Ташбилге елгасына төште – Ташбилге авылы булды. Татыш (Тәтеш) карты ыругы берлә Ак Идел (?) ярына төште – Татыш авылы булды, бәгъзылары Казан суының тамагында яңа Казанга күчеп киттеләр, бәгъзылары Уралның җәнүб шәркыйсенә Сарайчыкка күчтеләр, бәгъзылары кыргыз халкына керделәр ля илә ниһая[4] әтраф галәмә таралдылар». Бу риваятьләрне Мөслими халык авызыннан ишеткән булырга кирәк. Һәрхәлдә, алар Казан татарларының үз ганганәләрен[5] борынгы Болгарга ничек илтеп терәгәнлекләрен күрсәтәләр. Тимернең Болгарны харап итүе – безнең татар арасында бик таралган ялгыш фикер, тарихи галәт[6]. Мөслими үзенең китабында халык телендәге шул риваятьне генә алып язган. Дөреслектә, Аксак Тимер, Туктамыш белән сугышыр өчен Идел

[1] Начиз вә набуд идәрмен – юкка чыгарырмын.
[2] Лөәлөә әмсал – энҗе кебек.
[3] Әтрафка – читкә.
[4] Ля илә ниһая – чиксез.
[5] Ганганәләрен – телдән-телгә сөйләнеп килгән хәбәрләрен; тарихларын.
[6] Галәт – хата.

буена килгәндә, Болгарга якын килсә дә, аңар барып җитмәгән, мохасар итмәгән[1] һәм җимермәгән. Сарай ханнарыннан Пулат Тимер исемле кешенең, чынлап та, Болгарны харап иткәне мәгълүм. Менә шул Пулат Тимерне халыкның хәтере Аксак Тимер белән саташтырып, Болгарның харабын Тимерләрнең арада мәшһүррәк булганына нисбәт биргәндер. Чынлыкта, Пулат Тимер һәлак иткәннән соң да, Болгар шәһәре тәмамән юкка чыкмаган, бәлки әһәмиятсез бер кала хәлендә XV гасыр ахырларына кадәр барып, зәгыйфьләнә-зәгыйфьләнә, табигый үлем белән үлгәндер дип тарихчылар тәхмин итәләр[2], чөнки һичбер вакыт калалар дәфгатән[3] югалып китмиләр, никадәр яман туздырылса да, халык бер өйрәнгән урынына кире кайтып утыручан була. Шәһәрләр бетсәләр дә, акрынлап икътисади әһәмиятенең үзләреннән китүе аркасында эреп бетәләр. Болгар да шул ук хәлгә тарыган, икътисади мәркәз Казанга күчкәч, ул, зәгыйфьләнеп, ахырда тәмам юкка чыккан.

Тимер, Болгар вә Кашанны туздырганнан соң, Мәскәү өстенә сәфәр итә. Ләкин Владимир кальгасына җиткәч, тагын Хозыр пәйгамбәр төшендә күренеп, аңар: «Сиңа Мәскәү йортын дингә дәгъвәт итәргә Алла Тәгаләдән әмер юк, кайт, фәкыйһ Әбүләис (Әбү әл-Ләйс) Сәмәрканди кабере эчендә сиңа мөштак булып[4] ята», – ди. Тимернең гаскәрендә булган голәмаи Тәфтазани да аңар кайтырга киңәш бирә. Шулай итеп, Тимер кире борылып кайтып китә. Ләкин китәр алдыннан ул хыялый хикәяләрдәге баһадирларга гына килешә торган бер батырлык күрсәтеп китә: ул көнне русларның Покрау бәйрәмнәре улып, халык «теләү»гә чиркәүгә кергән икән. Тимер чиркәү күршесендәге бер русның кара байталын, ике арт ботыннан тотып, чиркәүгә ыргыта. Чиркәүнең манарасы ава, байтал икенче якка барып төшеп, сөякләре көл була. Байтал төшкән урында бер күл пәйда булып, Тимернең

[1] Мохасар итмәгән – камамаган.
[2] Тәхмин итәләр – фаразлыйлар.
[3] Дәфгатән – кинәт, көтмәгәндә.
[4] Мөштак булып – күрергә теләп.

гаскәре шул күлдә тәһарәт алалар. Ул күл хәзердә дә бар, имеш, ул чиркәүгә дә кермиләр, имеш. Менә Тимернең, Мәскәү өстенә бара башлап та, яз җитүдән куркып, кире борылып кайтуы шикелле тарихи бер вакыйга халык легендаларында шул рәвешчә гакес иткән[1]. Кайтышлый Тимер Казан шәһәренә туктый. Казан ханы Илһам исемле була. Ул Казан тирәсендәге Курса, Кәче, Салавыч шикелле авыллардагы изгеләрнең каберләрен зиярәт кыла, юлда тагын әллә никадәр калаларны харап итә, әллә никадәр халыкларны дингә дәгъвәт кыла[2].

Гомумән, Аксак Тимер, Мөслими буенча, дөньядагы халыкларны туры юлга күндерү өчен Алла тарафыннан җибәрелгән пәйгамбәр шикелле бер кеше булып чыга. Бер халыкка каршы сугыш ача икән, ул аны ислам диненә дәгъвәт кылыр өчен яки шигаләрне сөнни ясар өчен, һич булмаганда гөнаһка, фисыкфәсадка[3] баткан илләрне җәза кылу өчен эшли.

Мөслиминең Тимергә каршы ихтирамы бик зур. Ул аңар тәмамән Урта Азия ноктаи нәзареннән торып карый, «хәзрәте Аксак Тимер» дип кенә атап йөртә. Хәтта аның шәһри Болгарны харап итүе дә үзен «Болгари» дип йөртә торган Мөслиминең тамчы кадәр дә милли хөббе нәфесенә[4] тими, ул бу вакыйганы үзенчә тәэвил кылырга[5] тырыша. Бу – әлбәттә, Урта Азия мәдәниятенең безгә никадәр зур тәэсир ясаганын күрсәтә торган фактлардандыр.

«Тәварихе Болгария»нең теленә килгәндә, ул борынгы заманда язылган башка татар китапларына караганда күп җиңел тел белән язылган. Аның теле сөйләшү теленә бик якын. Алтын Урда ярлыкларының теленнән ул бик ерак, уйгур һәм монгол тәэсире анда юк. Без анда борынгы әдәби татар теле өчен характерный булган чыгтай вә госманлы тәэсирен күрәбез. Ләкин бу

[1] Гакес иткән – чагылыш тапкан.

[2] Җөмләдән берсе «Алабуга» яки «Сәдум» каласын һәлак итә, «Алабуга», аныңча, рум телендә «балык» мәгънәсендә икән. *(Авт. иск.)*

[3] Фисык-фәсадка – бозыклыкка.

[4] Хөббе нәфесенә – мин-минлегенә.

[5] Тәэвил кылырга – аңлатырга.

китапта чыгтай теленең тәэсире госманлы теленекенә караганда азрак. «Козуг, ачигланмагыл, кылаен, ирди, түрт» шикелле чыгтайчалыкларны без анда сирәгрәк очратабыз. Киресенчә, «япды (ясады), әйләде, килеркен, димәклә, ула, улдыкы, зинданә, исемләрене, соңра, вар, дәгел, чук» шикелле госманлы сүз вә формалары бик еш истигъмаль кылына[1]. «Торур» урынына һәрвакыт «дыр» языла, «илә» белән «берлә», «булды» белән «улды» каракатыш йөртелә, «улган» шикелле борынгы әдәби телебезгә махсус госманлычалаштырылган формалар да очрый.

Өслүбдә «Сәид Баттал» тибындагы госманлылардан кергән хикәя китапларының тәэсире күзгә бәреләә, мәсәлән, «әлкыйсса», «әзин җаныбп» дип башлап китү, Хозырның Тимергә «чәкер гүшем» дип хитап кылуы[2] шикелле – өслүбдә булсын, имляда булсын – гомумән, бертөрлелек, утырып җиткәнлек мөшаһәдә ителми[3].

## «Җәмигъ әт-тәварих» тәрҗемәсе

Идел буенда язылган китапларның иң борынгыларыннан берсе – мәшһүр иранлы төрк тарихчыларыннан Рәшид әд-Динең «Җәмигъ әт-тәварих» исемле әсәрнең тәрҗемәседер. Иң борынгы дәвернең татар китаплары арасында кайчан язылуы тәгаен мәгълүм булган бердәнбер әсәр шушы.

Бу китап безнең халык арасында таралган вә укылган китаплардан түгел. Аның моңар кадәр мәгълүм булган бердәнбер нөсхәсен XIX гасыр башында яшәгән татар галиме (Казан дарелфөнүнендә татар теле мөгаллиме) Ибраһим Хәлфин университет көтепханәсенә алып биргән. Бу кулъязма 157 кәгазьдән гыйбарәт. Башыннан бер кәгазе һәм ахырыннанрак берничәсе төшкән. Бу нөсхәнең күчерелү тарихы 1641 ел.

[1] Истигъмаль кылына – кулланыла.
[2] Хитап кылуы – эндәшүе.
[3] Мөшаһәдә ителми – күрелми.

Ул артык матур булмаган ярым шикәстә, ярым тәгълик[1] язуы белән язылган.

Бу нөсхә мөстәшрикъ[2] Березин тарафыннан 1851 елда «Библиотека восточных историков»[3] мәҗмугасының II җилдендә хәрфиян бастырылды.

Бу китапның икенче нөсхәсе шушы 1922 елда гына Казандагы мәркәз шәрык көтепханәсенә вакыф ителгән Галимҗан Баруди көтепханәсендә заһир булды. Бу кулъязма урта кулда 70 кәгазьдән (140 бит) гыйбарәт; шулай ук артык чиста булмаган ярым шикәстә язуы белән. Баб сәрләүхәләре[4] һәм кайбер әһәмиятлерәк сүз вә исемнәр кызыл кара белән язылган. Кулъязманың ахырына шул ук кешенең кулы белән язылган «Дәфтәре Җыңкызнамә» сәрләүхәсе астында 20 битле бер хикәя теркәлгән. Бу хикәя – Казанда басылган «Әхвәле Чынгызхан вә Аксак Тимер» дигән китапның бер кыйсеменең бераз гына үзгәртелгәне, шулай итеп бөтен кулъязма 160 биттән гыйбарәт.

Бу әсәрнең Галимҗан Баруди көтепханәсенә ничек килеп кергәне мәгълүм түгел, ләкин Барудиның соңгы хатыны – Шакуловлар кызы Гайшә ханым белән бергә Касыймнан Казанга килгән язма китаплар арасында булган булуы якын ихтималлардан. Чөнки «Җәмигъ әт-тәварих» тәрҗемәсенең асылы Касыймда язылып, Казан татарлары арасында таралган китап булмаган. Тәәссеф ки[5], Хәлфин нөсхәсенең кайдан табылганлыгы мәгълүм булмады. Ул да, ихтимал, Касыймнан китерелгәндер. Аның күчерелү тарихы 1735 ел, димәк, дарелфөнүн нөсхәсеннән алты еллар элек.

Дарелфөнүн нөсхәсе белән Баруди көтепханәсендәге нөсхә текст ягыннан бер-берсенә бик якын булсалар да, алар арасында беркадәр аермалар юк түгел. Бу аермалар – китапның эчендәге

[1] Шикәстә, тәгълик – гарәп хәрефе белән языла торган язу төрләре исемнәре.

[2] Мөстәшрикъ – Көнчыгышны өйрәнүче.

[3] Кирилл хәрефләре белән язылган.

[4] Сәрләүхәләре – исемнәре.

[5] Тәәссеф ки – үкенеч ки.

кайбер кисәкләрнең бер нөсхәдә булып та, икенчесендә булмавында. Дарелфөнүн нөсхәсенең югалган беренче кәгазендә мөтәрҗим[1] тарафыннан язылган мөкаддимә[2] булып, аның ахыргы юллары гына сакланган. Аннан соң «Фасыл әл-әүвәл»[3] сәрләүхәсе астында Борис Годуновка багышланган, басмада биш битле бер фикъренең[4] дәреҗ ителгән. Баруди нөсхәсендә бу кисәкләр юк. Китапның ахырындарак «Дастане Булгайыр хан бине Тулушикъ улан» сәрләүхәле баб Баруди нөсхәсендә бөтен түгел: актыгыннан яртыдан артыграгы (бит ярымнар чамасы) төшерелеп калдырылган.

«Дастан Идегә би разыйа Аллаһу галәйһи» сәрләүхәле бабның башыннан һәм ахырыннан бер кадәресе һәм «Дастане Йадкяр хан бине Әйби Гарәб улан» сәрләүхәле бер генә битле бөтен бер баб дарелфөнүн нөсхәсендә юк. Алар югалган кәгазьләрдә булганнардыр.

Әмма Баруди нөсхәсендәге төшеп калган урыннар касдән[5] калдырылганга ошый, чөнки китапның баш кәгазе сәламәт (китапның исемен язу урынына, шәрык гадәтенчә, беренче бит калдырылган); китапның эчендә вә ахырында да төшкән кәгазьләр юк. Тел һәм текст ягыннан ике нөсхә арасында аерма юк дияргә ярый. Имля вә гади язу хәттыларында[6] аз гына башкалыклар күзгә чалына. Хасыйль, бу ике нөсхә бик уңайлы рәвештә бер-берсен төгәллиләр.

Бу китап XVI гасыр белән XVII гасыр арасында, Русия тәхетенә Борис Годунов хөкүмәт сөргән вакытта, Касыйм – Ханкирмән шәһәрендә мәйданга килгән. Бу шәһәр – Рязань губернасының шималендә, Ока иделенең сул ярына салынган бик борынгы бер мишәр каласы. Электә аның исеме Кирмән

[1] Мөтәрҗим – тәрҗемәче.
[2] Мөкаддимә – сүз башы, кереш сүз.
[3] Фасыл әл-әүвәл – беренче бүлем.
[4] Фикъре – аерым бүлек, параграф, кечкенә өзек.
[5] Касдән – белә торып, үзе теләп.
[6] Хәтты (хатты, хат) – язу-сызу, почерк.

булган. Кирмән борынгы монгол-төрк телендә кальга – крипыч[1] мәгънәсендә[2]. Хәзердә дә бу шәһәрнең халкы аны «Кирмән» яки «Ханкирмән» дип атыйлар. Казан татарлары «Кәчем» диләр; бу – «Касыйм»нан бозылган сүз. Бу шәһәр 1471 елда Мәскәү князе тарафыннан Казан ханзадәсе Касыймга бүләк итеп бирелгән. Шуннан соң аның рәсми исеме «Город Касимов»[3] булып киткән. Касыйм ханнары бер нәселдән генә килмичә, күбесенчә бер-берсенә һич кардәшлекләре булмаган шәхесләр аның тәхетенә утыра торган булганнар.

Рус вәкаигънамәләре буенча, 1598 елда[4] Борис Годунов Кирмән тәхетенә кыргыз ханзадәсе Уразмөхәммәдне утырта. Уразмөхәммәд – 1565 елда Русиягә табигъ[5] булган кыргыз ханы Тәвәккәлнең туганнан туганы. Ул, рус вәкаигънамәләренең хәбәренә күрә, үзенең дусты – Себер ханы Сәидтәк белән бергә рус гаскәре тарафыннан әсир алынган. Шуннан соң Мәскәү патшасы Федор Ивановичның сараенда торып, шул вакытта хөкүмәт башында торган чукынчык татар Борис Годуновның тәлинкәсен ялаучылардан булган. Шуның аркасында ул 1595 елда, Борис патша булгач, Касыйм тәхетенә утырырга муаффәкъ була[6]. Безнең мөәррих[7] Уразмөхәммәдне Сәидтәкнең дусты дип түгел, бәлки тоткыны иде дип күрсәтә, бәгъзы рус вәкаигънамәләре дә бу риваятьне куәтлиләр.

«Җәмигъ әт-тәварих»ны төркичәгә тәрҗемә кылучы – шул Уразмөхәммәднең якын кешеләреннән Тарак тамгалы җәлаир ыругыннан Кадыйргали би исемле кеше. Ул Уразмөхәммәд хозурында зур дәрәҗәле, игътибарлы вә тәэсирле адәм булган

---

[1] Крипыч – крепость.

[2] Татарстанда Спас кантонында «Ташкирмән» атлы керәшен авылы бар. *(Авт. иск.)*

[3] Кирилл хәрефләре белән язылган.

[4] Кульязмаларда «Тарихның меңдә...» дип, һиҗри мең дә ничәнче ел икәне язып бетерелмичә, буш урын калдырылган. *(Авт. иск.)*

[5] Табигъ – буйсынучы.

[6] Муаффәкъ була – ирешә.

[7] Мөәррих – тарих язучы, тарихчы.

булырга кирәк. Уразмөхәммәдне халыкка күтәрү мәрасимендә иштиракь иткән[1] дүрт иң зур дәрәҗәле кешедән берсе шушы Кадыйргали би булган. Хасыйль, ул Уразмөхәммәд ханның ата-бабаларына ук хезмәт итеп килгән. Җәлаир ыругы соңыннан төркләшкән мәшһүр аксөяк монгол ыругларыннан булып, төрк-татар тарихында зур роль уйнаган. Кадыйргали би дә, Уразмөхәммәдкә ияреп, Азиядән килгән булган. Ул үзенең нәселе хакында китапның ахырында түбәндәге сүзләрне яза:[2]

«(Әл-хакыйрь[3], әл-фәкыйрь бәндәи нәвайи[4]) Кадыйргали би[5] (битеде): «Бән Хушум би бине Тәмҗик (һәрду[6]) бәһадур[7] бине Әдимшәекъ мирза [бине] агасы Караҗ би. (Аның нәселе Шәех Суфи би ирүр), бине Кобай, бине Канбәр Мирза, бине Итаули би, Итбага би ирүр [бине]. Җәдде Чыңгыз хан заманыда Сартак ноян[8] ирүр. Аның углы (һәрду әмир[9]) Җәлаир Саба ирүр. Аның нәселе җәлаир Тәбирә би ирүр, аның нәселе Итаули би ирүр, мәгъруф, мәшһүр торур. Урус ханның нәселе дә олуг өмәраи бозорг[10] ирүр вә Урус ханның мәймәнә мәйсәрә бу торур. Бу йирдә йад кылынды, йәгъни мәймәнә уң кул, мәйсәрә сул кул ирүр.

---

[1] Иштиракь иткән – катнашкан.
[2] (...) эченә Баруди нөсхәсендә генә, [...] эченә дарелфөнүн нөсхәсендә генә булган сүзләр куелды. *(Авт. иск.)*
[3] Хакыйрь – мескен.
[4] Бәндәи нәвайи – елаучы бәндә.
[5] Дарелфөнүн нөсхәсендә һәр җирдә «би» урнына «бик» язылган. *(Авт. иск.)*
[6] Һәрду – икесе дә.
[7] Һәрду бәһадур – икесе дә бәһадур титулы белән.
[8] Ноян – титул.
[9] Һәрду әмир – икесе дә әмир титулы белән.
[10] Өмәраи бозорг – бөек әмирләр.

| | |
|---|---|
| Мәймәнә[1]: | Мәйсәрә[2]: |
| әкъваме[3] каум Катагыйн[4] | әкъваме кауме Алаҗ Миңи |
| ирүр, ике сан нәфәр[5] | ирүр, өч сан нәфәр |

Каум Катагыйн үз араларында бу заманга дигәч олуглары (үз араларында) мәгълүм ирүр. Әмма Алаҗ Миңи арасында олугы Тарак тамгалы Җәлаир булгай. [Та] Чыңгыз хан заманыдин бирү вә мәртәбә-мәртәбә била[н] Тәбирә бикә тикде[6]. Андин Шәех Суфи бикә (тикде), андин Итаули бикә тикде, андин Итбага бикә тикде, андин Караҗ бикә тикде, андин Тутка бикә тикди. Бу Алаҗ Миңинең агасы бола килгән(ләр), болар торур. Үзбикийа арасында мәгълүм, мәшһүр торур».

Бу китап Уразмөхәммәднең вәли нигъмәте Борис патшага багышланып, ихтимал, аңар тәкъдим ителергә дә уйлангандыр, чөнки аның башында мөәллиф[7] Борисны чын шәрык ысулында күкләргә күтәреп мактый. Бу мөкаддимәдә без Борис Годунов исеменә шушы мәдехләрне укыйбыз: «Җөмләтел крәстиан[8] патша хәзрәтләре Борис Федорович, олуг бик, ак хан...

Айналасы[9] алты хан, түкрагы[10] түрт хан, дөнйаның түрт бөреҗен[11] билкан[12] хан. Хәляикын[13] гаделлек билан сөргән[14] хан, йәтимләргә рәхим кылыйб, чигайларны[15] туйдырган хан. Кыш вә йаз, ай вә йыл хәзинәдә бар малын Хак йулында

[1] Мәймәнә – уң як.
[2] Мәйсәрә – сул як.
[3] Әкъваме – кавемнәр.
[4] Дарелфөнүн нөсхәсендә «кангани». *(Авт. иск.)*
[5] Нәфәр – кеше (нумератив).
[6] Тикде – тиде.
[7] Мөәллиф – автор.
[8] Барча христианнарның. *(Авт. иск.)*
[9] Әйләнәсе. *(Авт. иск.)*
[10] Түгәрәге, ягъни дүрт ягында. *(Авт. иск.)*
[11] Гарәпчә «бөрҗ» – кальга манарасы. Монда «дүрт почмагы» мәгънәсендә. *(Авт. иск.)*
[12] Биләгән, ишгаль иткән. *(Авт. иск.)*
[13] Хәляикъ – халыклар.
[14] Көткән. *(Авт. иск.)*
[15] Ярлы, фәкыйрь. *(Авт. иск.)*

ихсан кыйлган хан... Тәхтең синең тагга охшар, халкың синең сайа’и дәүләткә[1] охшар. Затың синең мисалы айга охшар, гаделлегең синең болытка охшар. Фигылең синең шәфәгатькә[2] охшар, хәйрең синең тингизка[3] охшар. Ил ашасун, йөз йашасын[4], аты йахшы Борис хан... Тәңре әзәлдин[5] синка бөйле[6] берде[7], тәхте Сөләйманны синка рузи[8] кылды. Гадел килде, золым күтәрелде. Кем сине күрә алмас, тәнедә башы вә ни җаны бар. Кем сиңа коллык кылыб хезмәт кылса, гыйззәте артыр. Кем күп биликне белеб куңелендә тотса, дәүләте артыр. Сәгадәт аңа йар булса, михнәтне ким тартар... Ак урданың[9] күктәге болыт кеби күп гаскәрең бар. Ай кеби, көн кеби халыкка яруклыгың[10] бар. Барча урус вә татар вә нимеч[11] вә липканың[12] Борис атлих[13] ханы бар... Җиһан эчендә дөньяның бөрежин[14] гиздим мән. Күп китаплар да укып һәм билдим мән. Гадел вә инсаф хәбәрин һәм күрдем мән. Бу камәт сахавәт[15] падишаһ һич күрмәмешем. Көн дә синең хәйрең иксәмәс[16]. Хәзинәңдә һич малың түкәнмәс. Түрт тарафка биреб, һич кимемәс. Кем синең шәфәгатеңә очраса, үлсә[17], үкенмәс[18]».

Китапның ахырында язучы «сәбәбе тәэлиф» хакында түбәндәге сүзләрне сөйли:

---

[1] Дәүләт күләгәсенә. *(Авт. иск.)*
[2] Шәфкать. *(Авт. иск.)*
[3] Диңгез. *(Авт. иск.)*
[4] Ханнарны мактап әйтә торган сүз.
[5] Тәкъдирдән. *(Авт. иск.)*
[6] Бөйле – шундый.
[7] Бирде. *(Авт. иск.)*
[8] Рузи – ризык, язмыш, өлеш.
[9] Чату, киез өй. *(Авт. иск.)*
[10] Пакьлек. *(Авт. иск.)*
[11] Нимеч. *(Авт. иск.)*
[12] Поляк, лях. *(Авт. иск.)*
[13] Атлы, исемле. *(Авт. иск.)*
[14] Тарафын. *(Авт. иск.)*
[15] Бу кадәр юмарт. *(Авт. иск.)*
[16] Кимемәс. *(Авт. иск.)*
[17] Үлсә дә. *(Авт. иск.)*
[18] Бу мактау бик озын; монда урыны белән сайлап алынды. *(Авт. иск.)*

«...сәбәп ул торыр: кем бу тәварихка Уразмөхәммәд хан хәзрәтләренең ата-анасыдин коллык кыйла килгән җәлаир тарак тамгалы ирди, “Чыңгызнамә” китабыдин бу нөсхәне фарсы телендин төрки телегә укурды[1]. Кайусын соң заманда булганларны үз истинбатыйндин[2] Аллаһы Тәгалә тәүфикъ биреп тасниф кыйлды. Падишаһ Борис Федоровичның тоз-үтмәк[3] гадле хакы өчен бителде[4] вә тәкый[5] Уразмөхәммәд хан хәзрәтләренең нижук[6] падишаһ хәзрәтләре гыйззәт икрам билән ханлыкка ултыргызганын, хәзрәте Нух галәйһиссәламдин бер Угызга дигәч, Угыздан Һиҗрәткә дигәч, Һиҗрәтдин Чыңгызга дигәч, Чыңгыздин бу заманга дигәч нә җаклы[7] падишаһлар, ханнар үтеб ирде – тәмамысы бетелде[8]».

Кадыйргали бинең тәрҗемәи хәленнән без артык бернәрсә дә белә алмыйбыз. Ихтимал, ул заманасына вә мохитенә күрә чибәр генә галим кеше булгандыр. Ләкин гарәп сүзләрен бәгъзан бик ялгыш язуы аның гыйльми дәрәҗәсе хакында бераз шөбһәгә төшерә.

Китапның язылу тарихы милади 1602 елга туры килә. Баруди көтепханәсендәге нөсхәнең иң ахырында шушы сүзләр язылган: «Кәтәбәһү галә йәди әз-зәгыйфь[9] Кадыйр Гали бик бине Хусум би тарихның мең дә унберендә куян йылы, мөбарәк мөхәррәм аеның ахырында шинбә көне бу тарихны тәмам кылды. Ошбу тарих әүвәл ошбу китапның нөсхәсенең тарихыдур». Соңгы җөмлә, әлбәттә, күчерүче тарафыннан арттырылган: ягъни монда китерелгән тарих – китапның асыл нөсхәсендәге тарих

[1] Тәрҗемә кылды. *(Авт. иск.)*
[2] Үзлегеннән. *(Авт. иск.)*
[3] Икмәк. *(Авт. иск.)*
[4] Язылды. *(Авт. иск.)*
[5] Тәкый – диндар, бозыклыктан саклаучы.
[6] Ничек. *(Авт. иск.)*
[7] Ничаклы. *(Авт. иск.)*
[8] Баруди нөсхәсендә «Үтеп ирди әлхакир әлфакир бәндә нуаи Кадыйргали би битде». *(Авт. иск.)*
[9] Кәтәбәһү галә йәди әз-зәгыйфь – ...зәгыйфь бәндә куллары белән язылган.

икәнен ул укучыларга аңлатып китәргә теләгән. Әсәрнең кайчан язылуын аерымачык белдерә торган бу кәтга[1] дарелфөнүндәге нөсхәдә бөтенләй юк. Анда аның урынына «1051 сәнә тарих тәмам шәд» дип кенә язылган. Бу исә 1841 гә туры килә торган күчерү тарихы.

Бу китапны мөәллиф нининдидер фарсыча «Чыңгызнамә»дән тәрҗемә кылдым дисә дә, аның мәшһүр Урта Азия мөәррихе[2] Рәшид әд-Диннең «Җәмигъ әт-тәварих»ыннан бераз кыскартып тәрҗемә кылынганлыгы аерымачык күренеп тора.

Рәшид әд-Дин бине Гыймад әд-Дәүлә Әбелхәер – Чыңгыз нәселеннән килгән һәм XIII–XIV гасырларда Иранда хөкем сөргән «Илхани»лар сөляләсе[3] хозурында вәзирлек хезмәтендә булган кеше. Нәсел ягыннан ул – таҗик. Монгол ханнары да, Шәрык хөкемдарларының гадәтләренә ияреп, үзләренең яннарында шагыйрьләр, галимнәр вә мөәррихләр асрый торган булганнар. Рәшид әд-Дин иң элек Абака хан (1282–1295) хезмәтенә кергән. Ул үлгәч, Газан хан (1295–1304) хозурында торган. Бу хан аңар җирле Иран әһалисе аңларлык фарсы телендә монгол-татарларның тарихын язарга тапшырган. Бу тарихны язу өчен Рәшид әд-Дин монголларның мөкаддәс китабы булган «Алтын дәфтәр»дән һәм монгол тарихын күңелдән белүчеләрнең сүзләреннән файдаланып язган булырга кирәк, дип уйлыйлар. Газан хан үлгәндә, Рәшид әд-Диннең тарихы тәмам булмый калган. Газан ханның хәләфе[4] Үлҗәйтү хан (1304–1316) аңа бу әсәрен, киңәйтеп, бер гомуми тарихка әверелдерергә боерган. «Җәмигъ әт-тәварих» исемле бу зур әсәр 1310–[13]11 елларда тәмам булып, башта өч җилддән гыйбарәт булган: 1) Монголлар тарихы, 2) Тарихе гомуми һәм Үлҗәйтү ханның хөкүмәт сөрүе, 3) Җәгърафиядән мәгълүмат. Ләкин бу әсәрнең беренче бүлегеннән башкасы югалган. Ислам голәмасы Рәшид әд-Дингә каршы

[1] Кәтга (кыйтга) – кисәк, өлеш,бүлек.
[2] Мөәррих – тарих язучы, тарихчы.
[3] Сөляләсе – династиясе.
[4] Хәләфе – варисы.

кубып, аны хыянәттә гаепләгәннәр. Ул 1318 елда Әбүсәид ханның әмере белән үтертелгән. Ихтимал, «Җәмигъ әт-тәварих»ның ике җилде[1] шул вакытта юк ителгәндер. Бу китап төрк вә монгол тарихын өйрәнү өчен иң ышанычлы вә дөрес мәнбәгъләрдән[2] хисаплана.

Төркчә тәрҗемәсенә килсәк, аның мөндәриҗәсе[3] гомумтөрк халыкларының, хосусан монголларның тормыш вә тарихларына гаид булып, күбрәк урыны Чыңгыз ханга багышланган. Ләкин мөтәрҗим китапның ахырына, үз тарафыннан бераз арттырып, Рәшид әд-Диндә булмаган соңгы әхвәл хакында сөйли; иң ахырда Ханкирмәндә Уразмөхәммәд ханның тәхеткә утыруын тасвир белән тәмам итә.

Мөәллиф Уразмөхәммәднең нәселен, кайдан чыгуын, Борис хозурында кабул ителүен, аның Борис тарафыннан тәгаен ителгән алпавыт (боярин)[4] белән бергә Кирмәнгә килүен, мәчеттә тәхеткә утыру мәрасимнәрен, мәрасимдән соң булган зыяфәтләрне тәфсилләп сөйли. Аның бу тасвирлары шул заманның гадәтләрен күрсәтә торган ачык бер тарихи картина бирәләр. Тәхет туенда хисапсыз бал һәм аракы эчелә, елкылар, сарыклар суеп, халыкны сыйлыйлар. Бер ай буенча тоташтан кичә-көндез гыйш-гыйшрәт[5] кылалар. Муллаларга, хафизларга, ятимнәргә, толларга хәер-ихсаннар[6] кылына. Коллар азат ителә.

Китапдан бу заманда Касыймда югары даирәләрдә исерткеч эчүнең бик мәшруг[7] бер эш булганлыгы күренә. Бу хакта мөәррих бер дә тартынмыйча сөйли, бик кызык кына итеп, диндарлык, мөселманчылык белән аракы эчүне бергә җыя; Уразмөхәммәд хакында ул «падишаһ Борис Федоровичның теләген теләде

[1] Җилде – томы.
[2] Мәнбәгъләрдән – чыганаклардан.
[3] Мөндәриҗәсе – эчтәлеге.
[4] Кирилл хәрефләре белән язылган.
[5] Гыйш-гыйшрәт – вакытны ашап-эчеп, типтереп уздыру.
[6] Ихсан – ярдәм, булышлык.
[7] Мәшруг – шәригать каршында дөрес булган эш, легаль.

даим. Кичә-көндез бер касә мәй[1] эчсә, аны йад кылмай эчмәс ирде, вә тәкый үзе Аллаһы Тәгаләнең коллыгында хазир ирде. Сәрвәре[2] әнбийа Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең рухларына даим дога вә тәзаррог[3] билән нийазлар[4] кыйлыр ирде», – ди. Ихтимал, бу рәсми эчке мәҗлесләрендә шул ук муллалар, хафизлар, хәтта руханилар башлыгы Бүләк сәид үзе дә хәзер булганнардыр. Һәрхәлдә, бу эшләр Кирмән аксөяк сыйныфы арасында гадәтләрнең бик руслашкан булуын күрсәтәләр. Уразмөхәммәд ханның бөтен яктан Мәскәү тәэсирендә булуы, аның ханлыкка утыруы Годунов тарафыннан ясалган бер курчак уеныннан гына гыйбарәт булуы бик ачык күренеп тора. Мөәллиф үзенең хикәясен шушы сүзләр белән тәмам итә: «Уң кулы да шәригать белән гамәл кылыр ирде. Сул кулы белән угры-каракчыны, йаманларны патша Борис Федорович хан хөкеме-ярлыгы белән сәясәт камчысыны яманларга күтәк[5] (?) орар ирде. Ул сәбәбдин Кирмән шәһәре Борис Федорович хан дәүләтендә әманлык[6] ирде. Бу сәбәбдин көндин-көнгә падишаһе ислам Насыйр әд-Дин Әбелфәтех Уразмөхәммәд[7] ханга дәүләте икъбаль[8] илән ил ашап, йөз яшәп та әбәдел-әбәдкәчә[9] дәүләт аңа йар булсын, инша Аллаһы Тәгалә, амин, йа Раббилгаләмин».

Китапның теленә килгәндә, ул чыгтайча диярлек. Язучының Урта Азия әдәби теле белән яхшы таныш булуы ачык күренә. Ләкин аның телендә бераз гына госманлыча һәм татарча тәэсире дә юк түгел. Бу – китапның телен беркадәр борынгы татар әдәби теленә якынлаштыра. Татарча тәэсире хосусан ахырда, соңгы вакыйгалар сөйләнгән урыннарда күп. Монда чыгтайча «куллу-

[1] Исерткеч, аракы. *(Авт. иск.)*
[2] Сәрвәр – башлык, җитәкче.
[3] Тәзаррог – түбәнчелек, ялыну, ялвару.
[4] Нийаз – бүләк, ялвару.
[5] Күтәк – сугу, ору.
[6] Әманлык – иминлек.
[7] Ханның титулы. *(Авт. иск.)*
[8] Икъбаль – уңыш, бәхет.
[9] Әбәдел-әбәд – мәңге.

гига», «өстика» урынына «коллыгына», «өстенә» шикелле тәркибләр[1], «бирлә» урынына «билән» (белән); татарча сүзләрдән «урам», «күренеш», «янәшә» күк сүзләр, «Шәехгали ханның салдырган таш мәсҗеде» дигән күк татарча гыйбарәләр очрый. Китапны язучының, Идел буе татары булмавына карамый, телендә татарчалыкларның булуы мохит тәэсиреннән килгәндер дип уйланырга тиеш. Госманлы тәэсире бик аз: «әл» кеби, «күрмәмешем» шикелле сүзләр булса да, сирәк очрыйлар.

Фарсычадан тәрҗемә кылынган урыннарда әсәрнең өслүбе шактый авыр. Җөмлә төзелешләре турыдан-туры фарсычадан алынып ясалганга, кайбер урыннары чыгышсыз[2], хәтта аңларга читен. Казан, Кырым, Касыйм тарихлары хакында мөәллифнең үзе тарафыннан арттырылган кыйсемендә[3] теле бераз ачыграк, ләкин һаман да кытыршылыклардан хали[4] түгел. Башта Алтын Урда канцелярияләрендә эшләп чыгып, татар ханнарының ярлыклары языла торган рәсми өслүб белән дә таныш булган булырга кирәк, бигрәк тә Борис ханны мәдехләгән мөкаддимәдә бу өслүбнең[5] тәме сизелә. Китапның әдәби яктан бик матур, иң фәсыйх[6]-бәлигъ[7] язылган урыны – шушы мөкаддимә. Нәрсә белән язылган булса да, бу – чын шәрык тарызында[8] тәртип ителгән бер мәдхия. Борисны мактау юлында анда һичбер төрле мөбаләгалар[9] кызганмаган. Шуның белән бергә аның өслүбе – чын-чын төрек рухында булган бизәкле өслүб. Аның һәрбер җөмләсеннән чит телләр тәэсиренә бирелмәгән саф төрекчәлек аңкып тора.

[1] Тәркиб – сүз тезмәсе, кушымта.
[2] Чыгышсыз (диал.) – ятышсыз.
[3] Кыйсм – өлеш.
[4] Хали – буш.
[5] Өслүб – стиль, ысул.
[6] Фәсыйх – матур һәм килешле итеп сөйләнгән сүз, фәсахәтле сүз, әдәби.
[7] Бәлигъ – матур, төзек.
[8] Тарыз – рәвеш, сурәт, тәртип, ысул, тип.
[9] Мөбаләга – арттыру, күпертү.

**«Галикәй аталык васыятьнамәсе»**

Тел ягыннан әһәмияте булганга күрә, без татарның борынгы әдәбияты рәтеннән иске заманнан сакланып калган бер васыятьнамә хакында бер-ике сүз әйтеп узарга тиешле күрәбез. Бу документ XVII гасырда Ханкирмән шәһәрендә язылып, шунда сакланган. «Касыйм патшалары вә шаһзадәләре хакында тәфтиш» исемле мәшһүр тарихи әсәрне язган Вельяминов-Зернов[1] аны табып, шул китабында нәшер иткән. Аның хакында ул: «Бу борынгы заманда Русиядә татар телендә язылган бердәнбер документлардан», – ди.

Бу васыять 1639 елда Касыймдагы аксөякләр сыйныфыннан булган Галикәй аталык[2] дигән берәү тарафыннан Акмөхәммәд сәид илән Дустмөхәммәд мирза атына яздырылган. Акмөхәммәд сәид – мәшһүр сәид Шакуловлар фамилиясеннән булып, Уразмөхәммәд ханны Касыйм тәхетенә утыртканда аның тәхет хөтбәсен укыган рәисе рухани Бүләк сәиднең углы. Васыятьнамәдә телгә алына торган Фатыйма солтан бигем – шул вакытта Касыймда хан булган, бу шәһәрнең актыккы ханы Борһан солтанның анасы һәм шул Акмөхәммәд сәиднең кызы. Бу бо-

[1] «Касыйм патшалары вә шаһзадәләре хакында тәфтиш» исемле мәшһүр тарихи әсәрне язган Вельяминов-Зернов – тарихчы Владимир Владимирович Вельяминов-Зерновның (1830–1904) «Исследование о касимовских царях и царевичах» дигән хезмәте.

[2] Борынгы татар ханлыкларында (Казанда, Касыймда) задәкян (дворянин. – *ред.*) сыйныфы (аксөякләр), төрле дәрәҗәләргә бүленеп, төрле исемнәр белән аталып йөртелгән. Мәсәлән, карачылар, мирзалар, бикләр, тарханнар, сәидләр, данишмәндәләр (гыйлем ияләре. – *ред.*), хафизлар (абыз), аталыклар, имилдәшләр булган. Болар хакында Вельяминов-Зерновтан байтак мәгълүмат алырга мөмкин. Аларның бәгъзылары – дөньяви, бәгъзылары (мәсәлән, сәид, мулла, данишмәнд, хафиз) – рухани дәрәҗәләр. Сәидләр үзләрен пәйгамбәрләр нәселеннән киләбез, дип дәгъва кылганнар. Сәид нәселеннән килгән кешеләр, рухани булмасалар да, «сәид» ләкабен (кушаматын. – *ред.*) ташыганнар. Аталыклар башта хан балаларының тәрбиячеләре, имилдәшләр хан балаларының имчәктәшләре, ягъни сөт кардәшләре булган. Соңыннан бу ләкабләр төп мәгънәләреннән катгый нәзар, коры бер дәрәҗәне аңлата торган сүзләр булып калганнар. Ханкирмәндә хәзердә дә «сәид»ләрнең токымнары бар, мәсәлән, Сәид Шакуловлар фамилиясе. *(Авт. иск.)*

рынгы документның шул замандагы Касыйм татарларының югары сыйныфларының икътисади хәлләрен тасвир ягыннан да әһәмияте юк түгел.

Васыять чыгтайчага маил[1] татар телендә язылган. Анда бик күп истигъмальдән[2] чыккан татарча сүзләр, хәзер мәгънәләре караңгы булган истыйляхлар[3] очрый. Имлясы бик ялгыш; хосусан, гарәп сүзләре бик фахиш хаталар белән (ишетелгәнчә) язылганнар. Аны язучы кятиб[4] бик надан кеше булып, аңар имля кылып яздырганнар булса кирәк. Һәрхәлдә, хан сарае даирәсендәге кешеләрнең васыятьләрен язар өчен дә бер дөрес яза белүченең табылмавы XVII гасырдагы Касыйм татарларының мәдәни дәрәҗәләрен бик ачык күрсәтәдер.

### «Әхвәле Чыңгыз хан вә Аксак Тимер»

Бу әсәр дә «Җәмигъ әт-тәварих» һәм «Тәварихе Болгария»ләр рәтеннән, Идел буенда борынгырак заманда язылган китаплардан дип тәхмин итәргә[5] мөмкин. Бу китап 1819 елда, Казанда татар галиме Ибраһим Хәлфин тарафыннан, дарелфөнүндә студентларга татар теле укытканда бер әдәбият вә тел нәмунәсе итеп куллану өчен бастырылган. Китапның тышында без шушы сүзләрне укыйбыз: «Әхвәле Чыңгыз хан вә Аксак Тимер вә тәварихләрә махсус бәгъзы кыйсем-кыйтгалар, замим[6] вә тилмизләрә[7] сәһләт[8] өчен җәмигъ лөгатьләрене хоруфы һиҗа[9] үзрә тәртип әйләп, императорның Казан университеты димәклә мәгъруф баш мәдрәсәсе нәфегы чөн[10] мәзкүр университетның

[1] Маил – тартым.
[2] Истигмальдән – кулланыштан.
[3] Истыйляхлар – атама, терминнар.
[4] Кятиб – язучы.
[5] Тәхмин итәргә – чамаларга.
[6] Замим – өстәмә.
[7] Тилмизләрә – укучыларга.
[8] Сәһләт – җиңеллек.
[9] Һоруфы һиҗа – әлифба.
[10] Нәфегы чөн – файдасы өчен.

лекторы титулованный советник Ибраһим бине Исхак Хәлфин иҗад вә тәкърир әйләмешем»[1].

Ибраһим Хәлфин үзенең язган мөкаддимәсендә әйтүенчә, бу китап Казан татарлары арасында яхшы ук каралган һәм укылган булырга кирәк. Чөнки Хәлфин кулында берничә нөсхәсе булган. Ул, шөбһәле вә аңлашылмый торган урыннарны төрле кульязмаларны чагыштырып тикшереп, үзе дөрес булырга кирәк дип уйлаганын алган. Әмма үзе тарафыннан китапка һичбер төрле үзгәреш кертмәгән. Аңлашылмастай булган сүзләрне, сызык астына төшереп, русчага тәрҗемә иткән, шулай ук китапның ахырына шундый сүзләрнең әлифба тәртибе белән төзелгән лөгатен шәрех иткән. Әлхасыйль[2], бу кадерле борынгы китапны бастырган вакытта, Хәлфин Яурупа галимнәре тота торган бер юлны тоткан.

Бу әсәрнең кем тарафыннан, кайда вә кай вакытта язылуы хакында аның үзендә турыдан-туры мәгълүмат юк. Хәлфин дә бу хакта бернәрсә белә алмаган. Ул бары китапның «таснифы[3] кадим вә тәләффызлары[4] себер татарынча кеби» дип әйтү белән канәгатьләнә. Ләкин китапта сурәтләре булган тамга вә галәмәтләрнең бәгъзы җир астыннан чыккан иске акчалардагы галәмәтләргә охшавына бина кылып, Казан татарлары арасында үзләренең тарихларына гаид борынгы заманнан бирле языла килгән вәкаигънамәләре булуын, бу китапның да асылы шуннан алынып язылуын тәхмин итә, тик бу китапка нигез булган шул иске тарих китаплары руслар белән татарлар арасында булган сугышларда тәләф булып[5] беткәндер, дип уйлый һәм Казаннан

---

[1] Шушы ук китап, башка бер кульязмадан алынып булса кирәк, Казанда 1882 елда Җиһаншин дигән кешенең хәраҗәте белән «Һәза китап фазыл дастан нәселе Чыңгыз хан вә һәм Тимер нәселеннән бәян идәр тарих йиде йөз елда» исеме астында бастырылган. Тәәссефкә каршы, бу нөсхәне кулыбызга төшерергә муәффәкъ булмаганга, аларның мөндәриҗә вә телләрен чагыштырырга мөмкин булмады. *(Авт. иск.)*

[2] Әлхасыйль – нәтиҗәдә.

[3] Таснифы – язуы.

[4] Тәләффызлары – әйтелеше.

[5] Тәләф булып – һәлак булып.

ераграк торучы татарлар арасында табылуларын ихтимал тота. Бәлки, Хәлфин бу сүзләрне шушы китапның ахырына тагылган Казан тарихына гаид вәкаигънамә калдыкларына иснадән иткәндер[1]. Димәк, китапның нә эченнән, нә тышыннан аның кем тарафыннан кайда вә кайчан язылуы хакында тарихи мәгълүмат алып булмый. Бу хакта бер-бер фикергә килер өчен башка юллар эзләргә хаҗәт булып төшә.

Моның өчен әсәрнең теленә карарга гына кала. Хәлфин бу хакта ни өчен «себер татарлары кеби» дигәндер – без моны белә алмыйбыз, ләкин, фикеребезчә, бу китапны язучы яки, һич булмаганда, үзенчә эшләп чыгаручы кеше Казан татарларыннан булса кирәк. Чөнки аның теленең төбе татарчага бик охшаган. Борынгы «әдәби тел» катлавы бу әсәрнең теле өстенә никадәр калын булып утырган булса да, аның асыл төзелеше (структурасы) татарча булуы дикъкать белән моталәга итүчегә[2] ачык күренә. Борынгы төрк сүзләре, чыгтай вә госманлы сарфи формалары астында китапның бөтен буе белән чын казан татарынча җөмләләр, үтә татарча гыйбарәләр вә тәгъбирләр күзгә бәрелеп тора.

Хасыйле, без монда шул ук татарның борынгы әдәби телен, шул ук катышкан (корама) телне күрәбез. Шул ук чыгтайча вә госманлыча тәэсирен мөшаһәдә итәбез[3]. «Тышкару – ташкару, үзигә, хатынига, андаг, бондаг, файдалиг, сакаллиг, корытылгу, кылгыйл, күркүзгел, бинаян, күрәрсен, ултырың, булгалы, булгай, ирсә, ирмеш» шикелле чыгтай формалары һәм шулай ук байтак кына аерым чыгтайча сүзләр (йа – җәя, ягыр, таңла, агыр (кыйммәтле) һәрвакыт истигъмаль ителә[4]. Күп сүзләр татарча, госманлыча һәм чыгтайча формада кара-каршы йөртелә: мәсәлән, «тау-таг, җау-йау-йаг, туру-тугры, дәхи-тәкый, кимам-киман, итде-иде, диде-тиде, иде-ирде, дер-торур, улды-

[1] Иснадән иткәндер – бәйләгәндер.
[2] Моталәга итүчегә – өйрәнүчегә.
[3] Мөшаһәдә итәбез – күрәбез.
[4] Истигъмаль ителә – кулланыла.

булды, илә-берлә, вар-бар, дип-тип, дин-дән» шикелле, госманлычадан без анда «улмакла, улырды, куймайуб, килгәнмези, кемәйә» шикелле формаларны, «бер кач, өйлә, кеби, кәнди, дәгел, соңра, зирә, гүзәл хатын алмак, йиймәк, оемак» шикелле сүзләрне бик еш очратабыз. Мисаллардан күрелгәнчә, татарча сүзләр бәгъзан госманлы сарфи формаларына ияртелә: мәсәлән, «килдекемез» түгел, «килгәнмези», «кемийә» түгел, «кемәйә» язылган. Озын сүзнең кыскасы, язучы үзенең татарчасын азаплап, имгәтеп, кысрыклап, телен «әдәбиләштерергә», ягъни чыгтайча вә госманлычалыклар кертергә, чит телләр калыбына сугарга тырыша. Менә китапның теленә тәнкыйть күзе белән карап, моталәга кылган кешегә шушы хәл бик ачык күренә[1].

Дөрес, бу мәсьәлә хакында башка төрле уйларга да мөмкин: ихтимал, бу китапны язучы татар булмагандыр. Башта ул татар телендә язылмагандыр. Татарча тәэсире исә аңар соңыннан, татар күчерүчеләре аркылы гына кергәндер. Дөрес, бу – була торган эш: әдәбиятта без мондый хәлне еш очратабыз. Мәсәлән, «Бакырган», «Ахырзаман», «Йосыф китабы» шикелле читтән кергән, татарлар тарафыннан язылмаулары шөбһәсез булган китапларга кергән татарчалыкларны без бары китап күчерүчеләр тәэсире белән генә изах итә[2] алабыз. Ләкин бу китап турысында бу фикерне әйтергә туры килми, чөнки югарыда бер кат әйтелеп узылганча, аның теленең асыл төзелеше татарча, анда чын татарча гыйбарә вә тәгъбирләр бик күп очрыйлар. Күчерүчеләр кулында гына телнең ул кадәр үзгәрүе мөмкин түгел. Хосусан, безнең татарның һәрбер китапка бер мөкаддәс нәрсәгә караган шикелле каравын игътибарга алсак, алар тарафыннан китаплар ул дәрәҗәдә үк үзгәртелмәгән булырга тиеш. Булган

[1] Китапның имласында чуалчык хөкем сөрә. Асыл имла иске заманда бездә кулланылган чыгтай имласы улса да, утырып җиткәнлек күрелми: «с» س – ص, «т» ت – ط (каты) хәрефләре бер үк сүзләрдә әле берсе, әле берсе истигъмаль ителә. Бер үк сүзләр бик төрлечә язылa: «дип, тип, тиеп, дию», «җыелып, җиелып, йыйылып, йыгылып» кебек. *(Авт. иск.)*

[2] Изах итә – аңлата.

үзгәрешләрне алар тарафыннан касдан[1] түгел, бәлки үзләре дә сизмәстән кертелгәндер, дип уйлана. Югарыда зикер ителгән китаплар шикелле, башка халыклардан кереп, татар арасында күп укылып йөргән нәрсәләрдә дә без шундый гына үзгәрешләр күрәбез. Татар язучысы исә никадәр әдәби тел белән язарга теләсә дә, татарчалык анда бик ачык күренеп тора торган була (Мәрҗанинең «Мөстәфад»ендә дә без шул ук хәлне күрәбез). Менә шуңар күрә без тикшерә торган әсәрнең язучысы яки татарчалаштыручысы Идел буе татары булырга кирәк, дип әйтергә җөрьәт итәбез.

Китапта Чыңгыз һәм Тимер хакында сөйләнә торган хорафи хикәяләр, шөбһәсез, аны язучының үз башыннан чыкмаганнар, ул аларны каян булса да алган. Ихтимал, ул бу риваятьләрне колактан ишетмеш буенча, ихтимал ки, башка китаплардан алып язгандыр. Ике ихтималның соңгысы дөреслеккә якынрак дип уйлана. Бәлки, бу әсәрен язганда, безнең мөхәрриренең күз алдында Урта Азиядә язылган бер-бер китап булгандыр. Китапта байтак кына бик борынгы төрк сүзләренең очравын шул юл белән генә аңларга мөмкин[2].

Шулай итеп, без бу китапның язучысы һәм кайда язылуы хакында артык бернәрсә дә белә алмыйбыз. Бары тик мөәллифе татар булып, әсәр Идел буенда язылган булырга кирәк, дип уйлыйбыз. Шуның өчен дә без аны Идел буе әдәбиятыннан санап яздык.

[1] Касдан – белә торып.

[2] Зәки Вәлиди «Шура»да Хәлфиннәр хакында язган мәкаләсендә бу китапның Урта Азиядә «Чыңгызнамә» исемендә йөри торган китап белән бер булуын сүз арасында гына әйтеп китә. Ләкин бу исемдәге китап безнең кулыбызга төшкәне юк. Мәшһүр Урта Азия мөәррихе Әбелгази Баһадур хан үзенең «Шәҗәрәи-төркия»сен язганда, аның күз алдында «Чыңгызнамә» аталган китабының бер-берсенә башка булган 17 төрле нөсхәсе булганлыгы мәгълүм. Һәрхәлдә, бу турыда, тикшерми торып, ачык бер фикер бәян итәргә мөмкин түгел. Без тикшерә торган китап («Әхвәле Чыңгыз хан») – мөстәшрикъләр тарафыннан хәзергә кадәр тикшерелмәгән бер әсәр. Димәк, бер китап хакында язганда файдалану өчен һичбер төрле материал табу мөмкин түгел. Шуңар күрә монда язылган фикерләр – безнең үз фикерләребез генә. *(Авт. иск.)*

Кайвакытта язылу мәсьәләсенә килгәндә, бу турыда да шулай ук кармаланып кына эзләргә кирәк була. Хәлфин үзенең мөкаддимәсендә[1] татар арасында укылып йөргән бу китапның башка китаплар шикелле тәләф булып, бөтенләй юкка чыгып китүеннән куркып бастырып калырга карар биргәнлеген сөйли. Димәк, ул Хәлфингә кадәр, ягъни XVIII гасыр эчендә татарлар кулында йөргән бер китап булган.

Бу әсәрнең кайчан язылуын тәхкыйкләр[2] өчен, аның эчендәге асыл хикәяләрдән башка башына вә ахырына теркәлгән кечерәк кыйсемнәренә игътибар итәргә кирәк. Казан вә Русия тарихына тәгаллекъле[3] вәкаигънамәне карап карыйк. Еллар тәртибе белән язылган бу вәкаигънамә XVIII гасырның беренче яртысындагы вакыйгалар белән тәмам була. Китапның һәммә кыйсемнәре, гомумән, бер төрлерәк тел вә өслүб белән язылган. Әгәр дә без бу вәкаигънамә кыйсемен «Әхвәле...»нең мөәллифе үзе язмаса да, китапның ахырына үз теле, үз өслүбе белән үзгәртеп теркәгәндер дип уйласак, асыл китап XVIII гасырның урталарына таба язылмадымы икән, дип фараз кылырга мөмкин.

Ләкин вәкаигънамә кыйсеменнән алда кечкенә генә бер генә битле «Фи бәяне мәсакин вә мәкян» аталган бишенче кыйсем бар. Бу кыйсемдә кайсы «йорт» кайсы ханныкы булуы бәян ителә. Менә шул кыйсемнең ахырында «Казан Шигали ханның йорты торыр» дип әйтелгән. Әгәр дә бу кыйсемне дә китапның башка кыйсемнәрен язган кешенеке дип карар бирсәк, әсәрнең язылу тарихын Казанда Шаһгали хан хөкем сөргән дәвергә, ягъни XVI гасырның беренче яртысына туры китерергә тиеш була[4].

Өченче яктан, китапның «Фи шәҗәрәи Чыңгыз хан» аталган иң баштагы беренче кыйсемендә, Чыңгызның нәсәбен сөйләгәндә, балаларының нәселе Ханкирмәннең актыккы ханы Борһан

---

[1] Мөкаддимәсендә – сүз башында.

[2] Тәхкыйкләр – дөреслеген тикшерер.

[3] Тәгаллекъле – мөнәсәбәтле.

[4] Тарихта «Шаһгали» һәм «Шәехгали» дип ике исем белән аталып йөртелә торган Казан ханын халык, үзенчә үзгәртеп, «Шәгали» – «Шигали» дип атаган. Казан артында Шәгали авылы хәзер дә дә бар. *(Авт. иск.)*

солтанга китереп терәлә. Бу бүлекнең ахыргы сүзләре шушы: «Күчем хан, аның углы Арыслан хан, аның углы Борһан солтан, әмма Борһан солтан рус кулында хәбес улынып мөрд булды[1]».

Монда саналган ханнар – тарихи шәхесләр. Борһан солтан – Касыйм шәһәренең ахыргы ханы, XVII гасырның урталарында Мәскәүдә Алексей Михайлыч падишаһлык сөргән заманда булган кеше. Аның христианлык кабул итүе дә – тарихи факт. Бу эш 1653 ел белән 1655 ел арасында булган. Безнең тикшерә торган әсәр дә шушы вакыйгадан аз гына соң оештырылган булырга кирәк (чөнки тарихи вакыйгалар халык хәтереннән бик тиз югалалар).

«Оештырылган», дидек, «язылган», димәдек, чөнки шушы 1922 елда гына Галимҗан Баруди көтепханәсендә, «Җәмигъ әт-тәварих» нөсхәсенең артына теркәлеп бергә төпләнгән хәлдә, «Әхвәле Чыңгыз хан...» китабының иң зур кыйсемен тәшкил иткән Чыңгыз хан хакындагы хикәянең яңа нөсхәсе табылды. Хикәянең сәрләүхәсе – «Дәфтәре Чыңгызнамә». Монда без шул ук «Әхвәле»дәге хикәяне күрәбез, тел-өслүб, мөндәриҗә – һәммәсе бер, бары тик текст һәм мөндәриҗәдә бәгъзы бер әһәмиятсез аермалар гына бар. Бу хикәя шул ук «Җәмигъ әт-тәварих»ны күчерүченең кулы белән күчерелгән. Ул, үзенең исемен атамаса да, күчерүенең тарихын китапның ахырында бик тәфсилләп яза. Анда без шушы сүзләрне укыйбыз: «Тарих туңыз йылы 144 сәнә булганда маһи рамазан аеның бишеңесе сишәнбе көн төш вакытында ошбу китапның язып тәмам булды, иртәнге намаз укып ултурдым та өйлә намазынча та зоһур намазын кылып ултырдым, намаз дикеренчә бу хатны яздым, кыш ирде, каләмем камыш ирде, хатымыз килмешде гаеп әйләмәңезләр муллалар.

Моны яздым ядкәр улмак өчен, укыйанлар бер дога кылмак өчен.

Әл-хакыйрь, әл-фәкыйрь  
Моны яздым хат бетердем ядкәр  
Мән үлсәм, хатым калсын ядкәр».

---

[1] Мөрд булды – вафат булды.

Бу язуда бер шөбһәгә төшерә торган нокта булса, ул да елның рәкыме[1] чуалчык язылуыдыр. Аны һиҗри 1144 ел дип тә укырга мөмкин, чөнки елны рәкым белән язганда, меңне төшереп калдырып, йөзләрдән башлап кына язу гадәте юк түгел. Ул вакытта безнең нөсхә милади 1732 елның февралендә язылган булып чыга. Ләкин бу ел дуңгыз елына туры килми, тычкан елына туры килә. Әгәр дә без уртада нокта (ноль) төшеп калган яки юри кырыйга куелган дип фараз кылып, һиҗри 1044 дип укысаң – нөсхәнең язылу тарихы 1235 елның февралендә булырга тиеш. Бу ел, чынлап та, дуңгыз елына туры килә. Ләкин дуңгыз елы белән тычкан елы күрше булып, төрк еллары беренче хәмәлдән (11 нче мартта) башланганга, бу ике елның күчерүче тарафыннан саташтырылган булуы мөмкин. Хасыйле, шөбһәне тәмам бетерү өчен, китапның кәгазен тикшерергә кирәк булып чыга. Бу кәгазьдә без яктыга тотып караганда аермачык күренә торган галәмәтләр күрәбез, кәгазьгә шушы төрле галәмәт (водяной знак)[2] төшерелгән: багана, багана өстендә рус таҗына охшаган тәреле таҗ, багананың ике ягында аягүрә баскан ике арыслан. Менә бу – мөтәхабисләрнең бәянына күрә, Голландиядә, Амстердам шәһәрендә эшләнгән кәгазь. Русиядә бу кәгазьгә язылган XVI гасырның ахырына гаид документлар табылган, димәк, шул ук төрле кәгазьнең XVII гасыр башларында Русиядә, димәк татарлар арасында да (бигрәк тә һәр эштә Мәскәү белән мөнәсәбәтле булган Касыймда) истигъмаль ителгән булуына һичбер төрле истихалә[3] юк. Әмма XVIII гасырда инде бу кәгазьнең истигъмале бик ерак ихтималлардан, чөнки бу гасырда Беренче Пётр, Русиядә кәгазь фабриклары ачып, чит мәмләкәтләрдән кәгазь кертергә чик куйган. Менә шул дәлилләргә истинадән[4], без бу китапның 1635 елда күчерелгән булуы белән хөкем итәбез. Димәк, бу факт безгә «Әхвәле Чыңгыз хан...» ки-

[1] Рәкыме – саны.
[2] Кирилл хәрефләре белән язылган.
[3] Истихалә – мөмкин булмау.
[4] Истинадән – таянып.

табындагы хикәяләрнең нөсхәләре татар арасында XVII гасырның башында ук булганлыгын исбат итә.

Ләкин монда башка бер сөаль килә: соң алай булгач, вәкаигънамәнең беренче һәм бишенче кыйсемнәрнең ахырындагы сүзләрне ничек аңларга? Моны аңлар өчен, бу әсәргә баштанаяк бер генә кеше тарафыннан бер вакытта язылган китап түгел, бәлки, төрле кешеләр тарафыннан язылган кисәкләрдән күчерүчеләр кулы белән оештырылган бер мәҗмуга дип карарга тиеш була. Мондый мәҗмугалар – борынгы татар китаплары арасында бик күп очрый торган гади (типичный) бер әйбер. Безнең китап күчерүчеләр һәрвакыт төрле җирдә таралып йөри торган, күбесенчә бер-берсенә бер дә мөнәсәбәте булмаган китап вә рисаләләрне, шулай ук аерым кәгазь парчаларындагы язуларны бер китапка теркәп яза торган булганнар. Бу әсәрнең дә шундый мәҗмугалар җөмләсеннән булуында шөбһә юк. Без аның хакында аерым бер китап шикелле итеп сөйлибез икән, тик аның иң күп урынын ишгаль иткән[1] һәм төп мөндәриҗәсен тәшкил иткән Чыңгыз хан белән Аксак Тимер хакындагы хикәяләрне эченә алган икенче һәм өченче кыйсемнәре турысында сөйлибез. Вәкаигънамә кыйсеменә килгәндә, аның без тикшерә торган китаптан бөтенләй аерым икенче бер гарәпчә китапның ахырына теркәлгән хәлдә табылуы, теленең дә бераз башка булуы бөтенләй үзенә башка, аерым әсәрләр булуын исбат итә[2]. «Әхвәле...»гә теркәлгән нөсхәсенең теле асыл китапның теле белән бертөсле булуын исә соңгы күчерүчеләр тәэсирендә булгандыр дип (ягъни күчерүчеләр ахырдан теркәлгән кисәкнең телен китапның теленә ияртүкәннәрдер дип) уйларга кирәк. Шулай ук Шаһгали Казанда хан булган заманда язылган бишенче кыйсем хакында да соңыннан теркәлгән кыйтга дип хөкем итәргә туры килә, чөнки аның асыл китап белән турыдан-туры һич мөнәсәбәте юк.

[1] Ишгаль иткән – алган.

[2] Бу вәкаигънамә борынгы әдәбиятыбызда аеруча әһәмиятле бернәрсә булганга, аның хакында аерым мәкалә язылды. *(Авт. иск.)*

Китапның мөндәриҗәсенә килгәндә, ул алты кыйсемгә бүленә. Бу кыйсемнәрнең зурлыклары бик төрлечә. Беренче кыйсем «Фи шәҗәрәи Чыңгыз хан» аталып, монда Нух пәйгамбәрдән Борһан солтанга чаклы Чыңгызның нәселе – шәҗәрәсе күрсәтелә. Бу кыйсемнең зурлыгы – урта кулдан бераз кечерәк басма бите белән өч бит. Икенче кыйсем «Кыйссаи Чыңгыз хан» аталып, монда Чыңгызның ата-бабалары, харикылгадә[1] рәвештә дөньяга килүе, яшьлеге, ханлыкка утыруы турысында хыялый бер хикәя сөйләнә. Бу кыйсемнең зурлыгы 59 бит. Өченче кыйсем «Кыйссаи Аксак Тимер» аталып, Тимернең дөньяга килүе, үсүе, хан булуы, сугышлары хакында шулай ук хыялый хикәяләр риваять кылына, зурлыгы 22 бит. Дүртенче кыйсем «Фи бәяне шәҗәрәи Идегә би» атала. Монда Идегә би исемле ниндидер изге хан турысында сөйләнеп, аның нәселе Әбүбәкер хәлифәгә илтеп тоташтырыла. Зурлыгы өч бит[2]. Бишенче кыйсем «Фи бәяне мәсакин вә мәкян» аталып, кайсы илнең кайсы ханныкы булуы бәян кылына. Зурлыгы бер бит. Монда саналган ханнар тарихка мәгълүм кешеләр түгел: аларның күбесе шул заманда (Казан алыныр алдыннан) татар илләрендә утырган феодаллар булырга кирәк. Алтынчы вәкаигънамә кыйсеме «Фи бәяне тарих» атала. Зурлыгы биш бит.

Әсәрне язучы үзе анда язылган хикәяләргә ышанып, тарихи вакыйгаларга караган күк карап язган булырга ошый. Без, әлбәттә, бу китаптагы хорафат вә легендаларга тарих ноктаи нәзарыннан карый алмыйбыз һәм аларда тарихи дуслык эзләмибез дә. Безнең өчен бу кыйссаларның әһәмияте бары тик аларның Чыңгыз һәм Тимер шикелле төрк-татар тарихының ике зур шәхесе хакында халык хыялында туган легенда булулары ягыннан гына. Шулай итеп, без бу әсәргә мәхыз[3] әдәби яктан гына карыйбыз. Юкса, алардагы хыяләт вә тарихи ялгышлар шул дәрәҗә-

[1] Харикылгадә – гадәттән тыш.

[2] Бу Идегә би хакында Кадыйргалинең «Җәмигъ әт-тәварих»ында да бар. Аңар анда өч битле бер баб багышланган. *(Авт. иск.)*

[3] Мәхыз – саф.

гә бара ки, Чыңгызның әнисе Ак диңгез уртасындагы Мальта атавының ханы Алтын ханның кызы булып чыга. Алтын хан үзенең кызы Гыйләмәлек күрекләне көнгә күрсәтмичә яшерен үстерә. Үсеп җиткәч, ул көннәрдән бер көнне тәрәзәне ачып, беренче тапкыр кояшка күренүгә, кояш нурыннан йөкле була. Ояттан куркып, аталары аны, кырык хезмәтче кызы, кырык күк күгәрчене, алтын кузысы, тутый кошы, сүнмәс чырагы белән бергә алтын көймәгә салып, бер насыйплыга юлыгыр дип, Торатаудан Төн диңгезенә агызып җибәрәләр.Ниндидер Торымтай чәчәннең углы Томавыл мәргән, атасы белән ачылышлы булып, ил тышына чыгып киткән икән. Диңгез буенда йөргәндә, шунда Гыйләмәлек күрекләнең алтын көймәсе килеп чыга да, Томавыл мәргән кызны үзенә хатынлыкка ала. Гыйләмәлекнең кояштан яралган баласы туа. Аны Дөен Баян атлы кушалар. Менә шул кеше Чыңгызның атасы була[1].

Бу китапта «алыс, өтрәк» шикелле казакъча сүзләр очраштыргалый. Аның бәгъзы бер урыннары казакъның әдәби гадәтенчә сиҗгылы[2] нәсер белән язылган. Гомумән, хикәяләрдә баштанаяк дала рухы аңкып, күчмәле төрк халыкларының тормышы вә хосусиятләре күренеп тора. Шуңа караганда, Чыңгыз хакындагы бу хикәя, монголлардан күчеп, кыргыз-казакъ арасында эшләнеп чыкмадымы икән, дип уйларга мөмкин, һәрхәлдә, бу хикәяләр һәр икесе – тәфтиш өчен кызыклы материал. Алар, бер яктан, тел, икенче яктан, мәүзуг җәһәтеннән тәфсилле тикшерүгә тукталып калалар. Хосусан, Чыңгыз вә Тимер хакында төрле төрк халыкларының халык әдәбиятында булган риваятьләр бу китаптагы хикәяләр белән чагыштырылып каралса, бу борынгы әсәрнең тарихы, шөбһәсез, актырыр иде.

Хикәя буенча атасы Дөен Баянның да Чыңгызны тудыруы табигый рәвештә түгел. Атасы үлгәндә, Чыңгыз әле яралмый

[1] Бу исемнәр тарихи исемнәр (Дөен Баян, Мәргән) булса да, безнең хикәядә аларның Чыңгызга мөнәсәбәт вә якынлыклары бөтенләй ялгыш күрсәтелгән. (*Авт. иск.)*

[2] Сиҗгы – рифмалаштырылган чәчмә сүз.

калган була. Ул, үзе үлгәннән соң, хатыны янына күктән ут булып иңә. Елкы яллы күк бүре булып китә. Китеп барышлый, бу бүре, артына әйләнеп, «җыңыз, җыңыз!» дип аваз бирә. Шуңар күрә туган баланы Җыңыз (Чыңыз, Чынгыз) атлы кушалар. Бу баланы мөәллиф түбәндәгечә тасвир итә: «Алтын изарлык[1], йәфрендә[2] мөһерле, вә мөһерендә Җәбраил фәрештә аты бар ирде, вә үзе бүре йәферле, Җәбраил күрекле, йөзен күргән артыннан «улайын»[3] дип иде, вә кашында ултырганлар, май дик эреп, тәкый атым төнем сәнең булсын ирде». Чыңгыз үсә, олыгая, халыкка туры хөкем кылып, файдалы була. Халык углы[4], аны яратып, аңар иярә башлыйлар, «яхшы хан», «ханның хакыйкый баласы» дип мактыйлар. Чыңгызның Бүденҗар, Каганҗар һәм Сәлҗут атлы өч бертуган абзасы була. Алар, баштан ук энеләреннән көнләшеп, аның уйнаштан туганлыгын исбат итәргә тырышалар. Ахырысында, төһмәт[5] белән генә халык күзеннән төшерә алмагач, аны үтерергә киңәш итәләр. Моны сизеп, Чыңгыз «казакъ чыгып китә», ягъни далага кача. Ул киткәч, агалары халыкка җәберзолым итә башлыйлар. Халык чыдый алмый, алты ыруглан кешеләр сайлап, аны эзләргә җибәрәләр. Чыңгызны тапкач, бу алты кеше, шатлыкларыннан, атланган атларын ирекке җибәрәләр. Инде аны ничек итеп олуглап алып кайтырга дигән мәсьәлә куба. Ахырда араларыннан Калдар би атлысы, үзеннән чыгарып, беренче мәртәбә арба ясый. Чыңгызны шул арбага утыртып, үзләре тартып алып кайталар. Шуннан Калдар би «арба пире» (пире – башлап чыгаручысы) булып кала. Менә бу арба пире хакындагы легендада казакъ-кыргыз тәэсире бик ачык күренә. Казакълар һәрбер тормыш өчен кирәкле булган әйбернең ихтирагын[6] берәр кешенең исеме белән бәйлиләр дә шул кешене шул әйбернең пире дип атыйлар. «Пир» фарсыча «пир» (шәех, карт)тан алынган бу-

[1] Биләүле. *(Авт. иск.)*
[2] Аркасында. *(Авт. иск.)*
[3] Улайн – улым. *(Авт. иск.)*
[4] Китапта халык «халык углы» дип йөртелә. *(Авт. иск.)*
[5] Төһмәт – яла.
[6] Ихтираг – уйлап чыгару.

лырга кирәк. Безнең татарда да «пир» дигән сүзләр бар: бер-бер кеше бер-бер әйбер белән артык чуалса, бер-бер эшнең мөтәхассыйсе[1] булса, аны «шуның пире инде ул», диләр.

Чыңгыз, иленә кайткач, үзенең агаларын бөтен нәселләре һәм иярченнәре белән үтертеп, кырдырып бетерә дә үзе хан булып утыра. Бүртә Кучин исемле бер хатынга өйләнеп, аннан Йужи, Җөдәй, Кәрәй[2], Түләй атлы дүрт углы була. Хикәядә Чыңгызның хан булганнан соңгы тормышы бер-ике сүз белән генә сөйләнә. Ул яхшы, туры хөкем итә, күп ханнарны вә урдаларны үзенә бактыра. Аты-чабы дөньяга җәелә. Ул үзен чакыра барган бикләргә һәм башка бикләрнең һәркайсына урыннар тәгъйин кылып[3], ил-көн сөйүргаб[4] бирә. Һәрберсенә берәр кош, берәр агач, берәр тамга һәм әүран[5] билгеләп бирә. Борынгы төрк вә монголларда кеше, үзен яки ыругын берәр кошка, җанварга яки агачка нисбәт биреп, шуның исеме белән атала торган гадәт булган, шулай ук һәрбер ыругның тамгасы булган. Китапта бу тамгаларның рәсемнәре дә төшерелгән.

Хикәянең ахырында Чыңгызның ау аулаулары, угылларына мәмләкәтен ничек бүлеп бирүе хакында кыскача сөйләнә дә, шушы сүзләр белән китапның икенче кыйсеме тәмам була: «Янә белгәй сезкем Җыңыз хан тарихе һиҗрәтдин биш йөз тукызынчы елда вә туңыз елы ирде зөлхиҗҗә аенда анадин тугды вә йитмеш ике ел гомер сөреп вә унөч яшендә ханлыкка ултырды, илле тукыз ел ханлык сөреп вә йитмеш ике яшендин соң туңыз елында вә мөбарәк рамазан аеның ундүртенче көне тарих алты йөз екерме түртдә дөньядан үтде, әмма Җыңыз ханның туган шәһәре вә торган йорты Кытай ирде. Тәммәт[6]».

Хәлфин бастырган нөсхә белән Баруди көтепханәсендә табылган нөсхәнең ахырларында аерма бар. Баруди нөсхәсендәге

[1] Мөтәхассыйсе – белгече.
[2] Гәрәй булса кирәк. *(Авт. иск.)*
[3] Тәгъйин кылып – билгеләп.
[4] Багышлап, ихсан итеп – бик борынгы сүз. *(Авт. иск.)*
[5] Биредә әураз (байрак) дип язылырга тиеш булса кирәк.
[6] Тәммәт – тәмам.

хикәя Чыңгызның, арбага утырып, иленә кайтуы белән тәмам булып, өзелеп кала. Аннан соңгы өч биттә асыл хикәягә тәгаллекы[1] аз булган әйберләр хакында сөйләнә, мәсәлән, Чыңгызның углы Йүҗи (Җүҗи)нең нәселе һәм аларның тарихыннан кайбер вакыйгалар шикелле «дастан» дип башланган аерым бабта Чыңгыздан башлап төрле ханнарның көбәләренең (тимер кием) исемнәре санала һәм «үз йортыбызны җую» хакында бик матур сүзләр белән тәәссеф[2] бәян ителә. «Дастан мөддәт» аталган бабта «имде ханнарның йортларындин кәф уралың» дип, кайсы йорт кайсы ханныкы булуы хакында сөйләнә. Бу баб Хәлфин нөсхәсендәге бишенче кыйсемгә мокабилдер[3]. Баруди нөсхәсендә Чыңгызның ханлыкка утыруы, аннан соңгы эшләре, бикләренә тамгалар вә башка билгеләр өләшүе хакында бернәрсә юк. Ике нөсхә арасында кеше исемнәренең язылуында да беркадәр башкалык бар: мәсәлән, Хәлфиннекендә – Җыңиз, Барудиныкында – Чыңгыз: Чыңгызның угыллары Хәлфиннекендә – Йүҗи, Җөдай, Кәрәй, Түләй, Барудиныкында – Йүчи, Чөдай, Күкдай, Түләй, арба пире беренчесендә – Калдар би, икенчесендә – Балын углы Кыйвалдар.

Тимер хакында Баруди нөсхәсенең ахырында «Миртимер хан нәселләре болардыр» сәрләүхәсе астында биш кенә юл язылган: «Төхми Барлас дигән халык торыр хасыйле, ханга җыелан угланнары ирде хан нәселе торур мәшһүр бабасы Улукчы, аның углы Ярукчы, аның углы Дәрагай, аның углы Миртимер торыр барча мәшһүр булган кырык кеше берлә йорт алган, тәрәзәсе ярау[4] булган, дип әйтерләр валлаһи әгъләм бис-савап».

«Әүвале Чыңгыз хан...» китабындагы Аксак Тимер хакындагы хикәядә булган тарихи хаталар, «Тәварихе Болгария» китабындагыдан артык булмаса, ким түгел. Һиндстан шәһәренең падишасы Чыңгыз углы Җөдай хан көннәрдән бер көнне

---

[1] Тәгаллекы – мөнәсәбәте.
[2] Тәәссеф – үкенү.
[3] Мокабил – кара-каршы.
[4] Тәрәзәсе ярау – тәрәзәсенә карындык тарттырылган.

куркынычлы төш күреп уяна. Багучылар һәм фалкярләр аның төшен юрап әйтәләр: «Алмалык дигән авылда Торагай атлы бер кеше бар[1]. Аның хатыны йөкле, синең үлемең шул хатынның корсагындагы баладан булачак», – диләр. Шуннан соң хан, Торагайны эзләтеп таптырып, хатынын алдырып, анасын үтермәстән генә, эчендәге баласын үтерергә куша. Хатынның эчен таптыйлар: аның һушы китә, хан да бала үлгән дип белеп тынычлана. Ләкин бала үлми кала, тик ул аксак булып туа, чөнки анасының эчен таптаган чакта, аның аягы имгәнгән була. «Шушындый имгәктән үлми котылып калдың, җаның тимер икән», – дип, атын Аксак Тимер кушалар. Тиздән анасы үлеп, Тимер ятим кала. Бер ялгызы «казакъ чыгып китә». Йөри-йөри Шимакый (Шимаха?) шәһәренә барып чыга. Анда башка малайлар белән бергә бозау көтүчесе булып яллана. Уен уйнаганда ук, аның баш булырга яратканлыгы, хакимияткә маиле сизелә. Малайларга башлык булып, урлап бозау суеп ашау шикелле һәртөрле башбаштаклыклар эшли. Бер аксак кырмысканың ифрат зур гайрәт вә сәбат[2] белән агач башына менәргә тырышуын күреп, шуннан гыйбрәт алып, хан булу уена төшә. Бераз зурайгач, үзенә иптәшләр җыеп, юлбасарлык кылырга, кәрваннарны таларга тотына. Җөдай хан алардан гаҗиз булып, гаскәр белән аңар каршы бара. Ләкин алар, хәйлә белән сәүдәгәрләр булып киенеп, араларына кереп, гаскәрне кыралар. Тимер үз кулы белән Җөдай ханның башын кисә. Аннан соң Һиндстан шәһәренә барып, аның урынына хан була. Менә бу вакыйгалар – берсе дә дөрес булмасалар да, Тимернең яшьлегендә кичергән вакыйгалары. Аның чын тәрҗемәи хәле хикәядә чалыш көзгедә күренгән төсле күренеп торалар. Халык хыялы аларны үзенчә үзгәртеп эшләп чыгарган. Ахырда Тимернең кайбер сугышлары, шул җөмләдән Истанбулны алуы һәм Болгарны һәлак итүе сөйләнә. Менә хикәянең бу кыйсеме «Тәварихе Болгария»нең

[1] Кыймырның атасы Тургай исемле әмир булган. *(Авт. иск.)*
[2] Сәбат – чыдамлылык.

Тимер хакында сөйләгән урыннары белән бик бер төсле. Төрле вакыйгаларда ике китап арасында байтак кына охшашлар (параллельләр) китерергә мөмкин. Мәсәлән, анда да, монда да Тимер, төрек солтаны белән сугышып, Истанбулны ала. Ләкин солтанның исеме «Тәварихе Болгария»дәге шикелле Мәһди түгел, бәлки Шаһсолтан дип кенә йөртелә. Һәр ике китапта да Тимер Истанбулны хәйлә белән ала. Мөслими нинди хәйлә белән алуын тәфсыйлән сөйләми, әмма Тимернең Истанбул өстенә йөрүенең сәбәпләрен бәян кыла. «Әхвәле...»дә Тимернең солтан белән сугышы хакында кыскарак сөйләнә. Ләкин монда Тимернең хәйләсенә зур урын бирелә. Аныңча, Тимер Истанбулны биш ел камаса да, ала алмый, чөнки бу шәһәр сигез кат койма белән әйләндерелгән була. Китапта бу койманың планы дәреҗ ителгән[1]. Бу план буенча, шәһәргә керер өчен, шул сигез кат койма арасыннан бик озын чуалчык юл (лабиринт) аркылы узарга кирәк. Робгузиның «Кыйссас әл-әнбия»сендә дә Истанбул (Константина)ның шундый ук лабиринт планы бар, ләкин Робгузида аның формасы дүрт почмаклы, «Әхвәле...»дә – түгәрәк. Шулай ук Тимернең Болгарны харап итүе хакында «Тәварихе Болгария»дә дә, «Әхвәле Чыңгыз хан...»да да сөйләнә. Ләкин «Әхвәле...»дә Тимернең Болгарга һөҗүменең сәбәпләре күрсәтелми. Болгар ханының да исеме башка төрле: Мөслимидә – Бикчура, ә монда – Габдулла. «Әхвәле...» буенча Тимер Болгарны җиде ел камаганнан соң гына ала: Мөслими буенча исә өч көн эчендә харап итә. Өченче параллель Тимернең рус белән ни өчен сугышмавы мәсьәләсендә: һәр ике китапта Тимер, Владимир кальгасына җиткәч, кире кайтып китә. «Әхвәле...»дә Тимергә өнендә Хозыр пәйгамбәр килеп: «Сиңа рус белән сугышырга вәгъдә ирешми», – дип әйтә. Мөслимидә Хозыр аңар, төшендә күренеп: «Сиңа Алладан Мәскәү йортын дингә дәгъвәт итәргә әмер юк», – ди. «Әхвәле...»дә рус падишасының исеме – Михайло, Мөслимидә – Иван Вачилий углы. Бу параллельләрдән күренә ки, бу ике китапның бер-берсенә турыдан-туры тәэсире булмаган, аларның

[1] Дәрҗ ителгән – теркәлгән.

мөәллифләре бер үк легендаларның төрле вариантларын халык авызыннан ишетмеш буенча язганнар булырга кирәк. Тимернең Болгар вә руслар белән булган маҗараларының сөйләнүе – үзе бу китапның Идел буенда язылган булуына ачык бер дәлилдер.

«Әхвәле Чыңгыз хан...» китабы зарарсыз гына өслүб белән язылган. Урыны-урыны белән ул куштырнаклардан һәм чыгышсызлыклардан хали булмаса да, бик матур, фәсахәтле язылган җирләре дә юк түгел. Бәгъзан өслүб сиҗгылы, аһәңле нәрсәгә әверелеп китә. Бәгъзан бик матур халык мәкальләре бер-бер артлы тезелеп килеп, өслүбене җанландыралар. Һәрхәлдә, бу китап борынгы дәвернең бармак белән генә санарлык нәфис әдәби әсәрләребез арасында әһәмиятле бер урын тотарга тиеш.

**Вәкаигънамәләр**

Әдәбият галәмендә һәрбер мәдәни халыкта очрый торган бер төркем әсәрләр бар, аларны «вәкаигънамә», русча «летопись»[1], Яурупада исә «хроника» яисә латинча «annaies» дип йөриләр. Мондый тип әсәрләр ислам галәмендә дә булып, мәшһүр Ибн әл-Әсирнең «Тарих»ы[2] шул җөмләдәндер. Бу вәкаигънамәләр безнең Идел буе төркләрендә дә бар иде. Аларның күбесе югалганнар: Мәрҗанинең «Мөстәфад әл-әхбар»ендә зикер кылына торган төрле мәҗмугалар шул җөмләдән иде. Гомумән, мондый тарихи вакыйгаларны җыйган мәҗмугалар ясау татарларда бик борынгыдан калма гадәт иде. Матбагада басылган китаплар булмаган, китапларны кул белән күчереп укыган заманнарда китапның кырыена һәм ахырына ишеткән һәм күргән вакыйгаларны язып кую бер йола иде. Боларны уку, җыю, күчереп бастыру вә тарихыбызның тәрәккыенә зур хезмәт булачактыр. Киләчәк буын мөхәррир вә мөаррихләр, билгеле, бу эшне эшләячәкләрдер.

[1] Кирилл хәрефләре белән язылган.

2 Биредә күренекле тарихчы Ибн Әсир (тулы исеме: Гыйзеддин Әбелхәсән Гали бине Мөхәммәд әл-Җәзәри, 1160–1233) тарафыннан язылган «Әл-камил фи-т-тарих» хезмәте турында сүз бара.

Хәзергә мәгълүм булганнары бары бер генә. Бу вәкаигънамә «Әхвәле Чыңгыз хан вә Аксак Тимер» исемле бер хорафи-тарихи мәҗмуганың ахырына гыйлавә[1] кылынып йөртелгән. Бу вәкаигънамә Идел буе татарларының тарихларына даир мәгълүматны тәнкыйтьсез, ил игътибары белән санап чыга. Бу әсәрнең берничә кульязмалары Петербург халык көтепханәсендә бар икән.

Бу әсәрнең төрле кульязмаларын тикшергәнебез юк, без, нәшер ителгән берничә вариантын алып, шуларга карап сүз сөйләячәкбез.

Шуларның берсе – Ибраһим Хәлфин тарафыннан 1822 елда Казан дарелфөнүненең шәрык шөгъбәсендәге студентларга файдалану өчен «Әхвәле Чыңгыз хан вә Аксак Тимер вә тәварихләрә махсус бәгъзы кыйсем кыйтгалар тилмизләрә[2] сәһләт[3] җәмигъ лөгатьләрен хоруфы һиҗа[4] үзрә тәртип әйләйүб...» дип озын исем белән бастырган мәҗмуганың ахырында, икенчесе – 1902 елда профессор Катановка бер галимнең кыргыз арасыннан табып җибәргән кульязмасы, ул мәҗмуганың сәрләүхәсе[5] «Фи бәяне шәҗәрәи Чыңгыз хан» булып, кульязманың ахырына «Чыңгызнамә» дип куелган. Бу әсәр алман ягына күчеп киткән татарлар тарафыннан Казан вә этрафыннан таралган нөсхәдән күчерелеп алып кителгән булырга кирәк. Өченче кульязмасы – Гайнетдин Әхмәревнең[6], Буа өязендәге Әлки (Алкиево)[7] исемле авылдан табып, Катановка җибәргән нөсхәсе, бусы башка гарәби вә төрки дини нәрсәләр белән бергә төпләнгән. Ләкин вәкаигънамәнең ахыры юк. Тәмам түгел. Шул ук әсәр 1882 елда Коковин матбагасында Җиһаншин хәраҗаты[8] белән басылган.

[1] Гыйлавә – өстәмә.

[2] Тилмизләрә – укучыларга.

[3] Сәһләт – җиңеллек.

[4] Хоруфы хиҗа – әлифба.

[5] Сәрләүхә – мәкалә исеме.

[6] Әхмәрев Гайнетдин Нәҗметдин улы (1864–1911) – тарихчы, этнограф, педагог, татар халкы тарихына караган этнография һәм археология мирасын туплаучы, тел белеменә мөнәсәбәтле хезмәтләр авторы.

[7] Кирилл хәрефләре белән язылган.

[8] Хәраҗаты – акчасы.

Аның сәрләүхәсе – «Һәза китап фазыл дастане Чыңгыз хан вә һәм Тимер нәселеннән бәян идәр тарих йиде йөз елда», әсәрнең кем тарафыннан язылганы мәгълүм түгел, вакыйганың соңгысына караганда, XVIII гасырдан да иртә язылмаган.

Гайнетдин Әхмәревнең алып кайткан нөсхәсендә шундый сүз бар: «Мин мулла Сәйфулла Сәгыйть углы бу рисаләне тәмам иттем чәһаршәнбе көн 1784 елда». Ләкин башка нөсхәләрдә бу сүз күренми, бу зат әсәрнең мөхәррире түгел, бәлки күчереп язучысы гына булырга кирәк. Китап күчерүчеләр, әсәрнең мөхәррире шикелле, китапның ахырына үз исемнәрен куярга яраталар. Ул башка халыкларда да шулай. Мәсәлән, беренче мәртәбә табылган рус летописенең иң борынгы кулъязмасының ахырына «Нестор»[1] дип куйганга, күп заманнар бу вәкаигънамәне «Летопись Нестора»[2] дип йөргәннәр. Бу мәсьәләдә шулай ук мулла Сәйфулла, әсәрнең мөхәррире булмыйча, бәлки күчерүче генәдер, әмма әсәр үзе бер вакыта гына язылмыйча, һәр вакыйганы арттырып, төрле вакытта төрле кеше тарафыннан язылган булуы бик ихтимал. Бәгъзы нөсхәләрнең тәмам булмавы да, бәлки, шуңарга дәлил була алыр.

Әсәрнең теле – чыгтай шивәсенең сарфи формалары белән бераз катыш Казан татарларының иске әдәби теле. Әхмәрев тапкан нөсхәдә тел хәзерге татарның сөйләшә торган теленә тагы да якын, әмма 1882 елда басылганы исә тагы да татарчарак. Моның сәбәбе исә нашир вә хәреф җыючыларның татарлаштыруы булгандыр дип уйлана.

Мөндәриҗә җәһәтеннән бәгъзы гыйбарәләрнең башкачалыгына карамасаң, казакъ арасыннан килгән, Гайнетдин Әхмәрев алып кайткан вә Ибраһим Хәлфин нәшер иткән нөсхәләр бер төсле, әмма 1882 елда нәшер ителгәнендә исә бәгъзы вакыйгалар күбрәк, бәгъзылары исә кимрәк.

[1] Кирилл хәрефләре белән язылган.
[2] Кирилл хәрефләре белән язылган.

Борынгы татар тарихы әдәбиятында да, халык ганганәсендә[1] дә бик шаигъ[2] булган Аксак Тимернең Болгарга һөҗүме белән башланган бу әсәр (без монда озынрак нөсхәсен алабыз) Пётр Великий заманасында, 1722 елда, иранилар кулыннан Каспий буендагы бәгъзы шәһәрләрне алуны тасвир белән бетә.

Вәкаигънамә бәгъзы елларда, бигрәк тә борынгырак вакыйгаларны сөйләгәндә, бераз ялгыша, шулай да күбрәк вакыйганы дөрес яза. Бу хаталар – күбрәк, елларны һиҗри белән хисаплаудан килгән бер чуалчыклык кына. Мәсәлән, «тарих бең йөз дә алтынчы ирде рус Азауны[1] алды, унсигез елдан соң кайта мөселманнар алдылар», диелә. Бу исәптән бу вакыйга милади белән 1694–[16]95 еллар эчендә булырга тиеш, әмма дөресендә Петр 1695 елда Азовка һөҗүм иткән, 1691 елда ул руслар тарафыннан алынган, 1711 елда Прут мәгълүбияте[4] соңында төрекләргә кире кайтарылып бирелгән иде. Димәк, 18 елдан соң мөселманнарга кире кайтарылды дигән сүз – хата. Бу хаталарны вә тексттагы бәгъзы аңлашылмаган сүзләргә шәрехләрне әсәребезнең хрестоматия кыйсеменә калдырабыз да шулкадәр мәгълүмат белән кифаяләнәбез[5].

## Исмәгыйль ага сәяхәтнамәсе

Борынгы заманнарда ук шәркый Яурупаның сәйях халыкларының иң мәшһүрләре безнең бабаларыбыз булганнар иде. Болар Будапешттан Хәзәр диңгезенә эт җигеп йөри торган караңгы шималь илләреннән алып, хөрмә бакчалары белән зиннәтләнгән Шәрыкның кызу өлкәсендәге Багдад базарларына кадәр баралар, ләкин бу сәяхәт һәвәсе[6] Болгар иленең Алтын Урдага кушылганы соңында бераз кимегән иде. Бу чакта Шәркый Яу-

[1] Ганганәсендә – авыз иҗатында.
[2] Шаигъ – билгеле, киң таралган.
[1] Азау – Азов.
[4] Мәгълүбияте – җиңелүе.
[5] Кифаяләнәбез – чикләнәбез.
[6] Һәвәсе – теләге, омтылышы.

рупа төркләре суканы – кылычка, солыхны сугышка алмаштырганнар иде инде, ләкин Казан алынып, сугышчан татар үзенең ярым күчмә тормышын утраклыкка алмаштыруы аркасында сәүдәгәргә әйләнгәч, алар яңадан сәйях булганнар иде. Ләкин татар каләм белән коралланмаганга, мәдәният дәрәҗәсендә шактый түбән булганга, ул сәйяхләр үзләренең юл хатирәләрен язып, безнең заманыбызга калдырмаганнар. Ләкин шулай да безнең тәхминебезгә[1] күрә, 1780 елда язылган бер сәяхәтнамә очратабыз, ул исә – Исмәгыйль хаҗи Бикмөхәммәд углының юл хатирәләредер.

Исмәгыйль абзыйның сәяхәте 1751 елда башланган. Аның язып калдырган хатирәләре дә элек кулъязмаларында йөреп[2], соңра 1862 елда Казанда «Ике хаҗиның рихләтнамәләре бере хаҗи Исмәгыйль Бикмөхәммәд углындан, бере хаҗи Мөхәммәд бине Гомәр углындин риваять улынган» сәрләүхәсе[3] астында нәшер ителгән иде. Соңра «рихләт»ләр мөхибе[4], тарихыбызның мөҗидләреннән[5] Риза хәзрәт тә 1903 елда «Исмәгыйль сәяхәте» исемендә бу китапны бик мөһим шәрехләр белән нәшер итте. Бездәге кулъязмасына караганда Риза хәзрәт нәшере тулырак.

«Исмәгыйль сәяхәте» – татар әдәбиятындагы әсәрләрнең XVIII гасырда язылып та, язучысы безгә мәгълүм булмаганнарының беренчеседер. Бу заманда татар халкы авыр бер хәләте иҗтимагыйа вә сәясийәне кичерә, рус милләтчесе ролен үтәргә азаплануччы императрица Елизаветаның безне буарга тырышкан заманы иде.

Сәяхәтнамә, мәктүб шәкелендә язылып, Истанбулдан туганнарына җибәрелгән. Шуның өчен дә ахырында «дәүләтле солтаным әфәнде саг уласыз» дигән сүз белән тәмам була. Сәяхәтнең ни өчен ясалуы хакында катгый мәгълүмат булмаса

[1] Тәхминебезгә күрә – чамалавыбызча.
[2] Безнең кулыбызда да бер кулъязмасы бар. *(Авт. иск.)*
[3] Сәрләүхәсе – исеме.
[4] Мөхибе – яратучы.
[5] Мөҗидләреннән – тудыручыларыннан; язучыларыннан.

да, сәяхәтне ижра итүчеләр[1] мулла Надир, Ягъкуб, Габдрахман исемле өч кеше булып, болар хөкүмәт тарафыннанниндидер бер эшкә Һиндстанга күндерелгәнлекләре мәгълүм. Аларның акчаларының бик күп булуы һәм әсәрнең башында «Бохари шәһәрендә тордыгымызда падишаһымызның әмере варды илче улып, Һиндстанга варымга» дигән сүзләре шуны күрсәтәдер. Хөкүмәт татарларны кысса да, аларны икътисади һәм мәгънәви яктан буса да (башкаларга караганда күп салым алу, чукынучылар өчен дә мөселманнардан гаскәр һәм салым алу күк), үзенең эшләренә кирәк булгач, Шәрык белән мөнәсбәттә алар белән файдаланадыр иде. Мондый файдалануларның – Шәрыкка Идел буе татарларын илче итеп җибәрүләрнең башкалары мәгълүм булса да, бу 1751 ел сәфарәте хакында без мәнбәгъләрдә[2] бер төрле дә мәгълүмат таба алмадык. Мәсәлән, 1785 елдагы Бохарага Русия тарафыннан күндерелгән илче һәйәте[3] арасында Миңдияр Бикчурин дигән бер татар чиновнигы (коллежский регистратор)[4] шактый эш күреп, анда күргән вә белгән нәрсәләре хакында русча бер доклад язып алып кайткан иде[5]. Соңра, 1818 елда, Сөбханкулов, Оренбург губернаторы тарафыннан илче булып Хивага барып, ул вакыттагы хивалыларның кисүеннән бары мөселман булганлыгы өчен генә котылып калган иде[6]. Менә без сөйли торган сәфарәт тә шундый бер һәйәт итеп Һиндка күндерелгән булырга кирәк.

Исмәгыйль агай, сәяхәтен башлаган чагында, артык мәгълүматлы кеше булмаган булса кирәк – аның, Истанбулга барып җиткәч, дүрт ел укуы шуны күрсәтәдер. Ләкин дүрт ел укыгач та, аның мәгълүматы күп артмаган. Шуның өчен дә ул төрле ишеткән хорафатны чын булган эш күк итеп сөйли, Һиндстанда халык хорафаты белән ясалган төрле пәйгамбәрләр хакындагы кыйссаларга, аларның каберләренең Һиндстанда булуына ыша-

[1] Ижра итүчеләр – оештыручылар.
[2] Мәнбәгъләрдә – чыганакларда.
[3] Һәйәте – төркеме.
[4] Кирилл хәрефләре белән язылган.
[5] Жуковский. «Сношения России с Бухарой и Хивой», с. 90. *(Авт. иск.)*
[6] Жуковский, с. 97. *(Авт. иск.)*

нулары вә, гомумән, һәрбер хәбәрне тәнкыйтьсез кабул итүләре шуны күрсәтәдер.

Исмәгыйль агай галим кеше булмаса, аның икенче бер хасияте бар. Ул – рухан[1] практик кеше. Ул – чын-чын сәүдәгәр, Сәгыйд Бистәсе (Каргалы) кешесе. Мәгълүм ки, бу бистәне төзүдән максуд та, шунда татарларны утыр[ты]п, Шәрык белән Русия сәүдәсенә васитачылык[2] хәзерләү иде. Шуның өчен дә Исмәгыйль агай икътисади нәрсәләргә зур әһәмият бирә, үзенең мәнсүб[3] булган сәүдәгәр сыйныфының рухы анда бик көчле.

Сәяхәттә аны иң күп мәшгуль иткән нәрсә – төрле шәһәрләрнең икътисади хәлләре: мал бәһасе, ул шәһәр вә җирләрдә чыга торган маллар вә мәгъмулат[4]. Ул бу мәсьәләләрне аерым бер рәхәт белән яза: «Әүвәлге Бендер дигән шәһәргә дахил улдык... ефәк вә мамыкның әгъля[5] вә гаять дә чук йиредер яхшы асыл ефәк зә тарик пакизәләре бихисап бонда чыгар. Шәкәр, дөге үзләрендә йитәр, шәкәр камышы вә шәкәр гаять дә чукдыр, очуздыр». Икенче бер җирдә, Максудабад шәһәрен тасвир иткәндә: «Кытайга һәм казакъга сатылына торган елан башы бонда улыр сиксән башы бер тиен», – ди. Бигрәк тә икътисади хәлнең озын тасвирын без Һиндстанның мөкаддәс һәм сәүдә шәһәре булган Бәнаресны[6] тасвир кылганда күрәбез.

Исмәгыйль агайны сәяхәт кылган җирләренең этнографиясе дә шактый ишгаль кыла[7]. Күп шәһәрләрне сөйләгәндә, ул өлкәнең әһалисе[8] хакында да мәгълүмат биреп үтә. Шуның белән бергә безнең сәйяхебез җирнең табигатенә, хайван вә үсемлекләренә дә шактый әһәмият бирә: күлләрендәге баглар, урманнарындагы маймыллар, кош-кортлар, филләр хакында ул шактый озын сүзләр яза. Халыкларның диннәре, мәзһәбләре дә

[1] Рухан – рухи яктан.
[2] Васитачылык – арадашлык.
[3] Мәнсүб – караган.
[4] Мәгъмулат – эшләп җитештерелгән нәрсәләр.
[5] Әгъля – сыйфатлы.
[6] Бенарес.
[7] Ишгаль кыла – кызыксындыра.
[8] Әһалисе – халкы.

Исмәгыйль агайның дикъкатен җәлеп кылалар. Белүш шәһәре янындагы Зәкәрия исемле бәдмәзһәбләр һәм Һиндстанда сыерга табынучылар хакында ул шактый мәгълүмат бирә. Шулай ук ул төрле өлкәләрдә халык арасында йөргән хорафат вә мифология хакында да сөйләп китә.

Исмәгыйль агай белән бергә барган һәйәт, элек Оренбург шәһәреннән Үргәнечкә барып, аннан Бохарага бара. Анда бер кыш торган соңында, Һиндстанга таба йөз тотып, юлларында дәвам кылалар. Җиде көннән соң Андхой шәһәренә җитәләр, аннан үтеп, Мәргуҗан аркылы Һират шәһәренә китәләр. Соңра Кандаһарга (язма нөсхәдә «Кандуган» язылган). Аннан тугры тугыз көндә Кәлатка җитәләр. Аннан Белүс (язмада «Белүш»), соңра Кәбех каласыннан узып, бер гарәп шәһәренә ирешәләр. Анда сәйяхләр ике ай калсалар да, ул шәһәрнең тасвиры юк, анда бары хәлифә тарафыннан куелган хакимнәр барлыгы гына әйтелә. Соңра Һиндстан диңгезендә көймәгә утырып, Бендер-Сурат дигән шәһәр янына җитеп, якорь салалар. Шул шәһәрнең йортында торганда, боларга диңгез караклары һөҗүм итәләр. Туп вә мылтык белән сугыш була, мулла Кадыйрның башына бер туп җәдрәсе тиеп, башын өзеп китә, Габдрахманның карыны ярыла, көймә иясенең боты өзелә, Исмәгыйль агайның да авыз-борыныннан кан китә. Бары тик, бәхетләренә каршы, бер франк көймәсе килеп чыгып, бу караклардан сәйяхләрне хәляс итә[1]. Аннан Үрнәкабад шәһәренә җитәләр, аннан Хәйдәрабадка баралар. Аннан Мичле[2] шәһәренә юлланалар. Юлда урманнарны үтәләр, зур-зур маймыллар күрәләр, һәм, бер арыслан очрап, сәйяхләрне хәвефкә төшерә. Мичлегә барып җитеп, анда ике ай торалар. Монда Исмәгыйльнең дикъкатен җәлеп кылган нәрсә – шундый бер вакыйгадыр: «Бонда тордыгымыз әүкә[3] каберстаннары якын иде, бер көн каберстан-

[1] Хәляс итә – коткара.

[2] Бу сүз бәгъзы нөсхәләрдә «Мәчле» вә бәгъзыларында «Миңлә» исемендә язылмышдыр. Хариталарда һичбере табылмады. Риза хәзрәт, б. 11. *(Авт. иск.)*

[3] Әүкә – өйгә.

нан кидәр улдыгымызда мәетләрең йөзләре тарафына күләгәсе дөшмеш күрдек, и Ягъкуб ага, көнешең күләгәсе безнең ардымызда улмак кирәк иде, бу нә хәлдер, дидем, андагы халыкдан боның сәбәбе сорадык. Анлар исә: «Сезләр көнешдин кичәсез», – дия җавап вирделәр, дөньяның ярымындан үтә көлебмез дия гаҗәбән калдык». Мичле шәһәреннән көймәгә утырып, Челихра шәһәренә киләләр. (Бу шәһәрне Риза хәзрәт Калькутта шәһәре түгел микән дип уйлый). Бу шәһәрне ул шактый озын тасвир кыла: андагы сыерга табынучыларның аның тизәген бойлә изге нәрсә хисап итүләренә даир тәфсилле мәгълүмат биреп үтә. Бу шәһәрдән узып, тагы кабык белән әүвәлге Бендер дигән шәһәргә юнәләләр. Аннан Максудабадка китәләр. Мондагы филләрнең күплеге безнең сәйяхне гаҗәпләндерә. Соңра Әзингабадка, аннан Йитүк шәһәренә баралар[1]. Тугыз ай анда калган соңында, арба белән Бәнареска килеп, аннан Шаһ җәнаит шәһәренә китәләр, бу вакытта бу калага әфганлылар һөҗүм иткән булалар: кире кайтырга уйласалар да, юлны әфганлылар ишгаль кылганга, кайта алмыйлар. Соңра тагын Бендер-Суратка килеп, Хиҗазга (Мәккәгә) барырга ниятләп, диңгез корабына утыралар. Диңгездә ачлык, сусызлык вә башка күп фаҗигале вакыйгаларны кичергән соңында, Сәрәндиб (Сәйлүн) атавына килеп, ниһаять Җиддәгә җитәләр. Аннан Мәдинәгә килеп, зиярәт иткән соңында Шамга баралар. Бер елдан соң Нәдес шәһәренә китәләр. Юлда гаҗәеп көчле зилзиләгә очрыйлар. Аннан янә Шамга кайталар. Анда яман формада ваба (холера) башлана: Исмәгыйльнең бөтен юлдашлары вафат булалар. Безнең сәйях бик фәкыйрьлеккә төшә. Хаҗиларга ияреп, Истанбулга килә. Шамда вабадан үлгән бер юлдашының малын алу өчен, үлгән кешенең бер варисын алып, янә Шамга килә. Ләкин бу эш муәффәкыятьсез чыга. Тагы да Истанбулга кайта. Анда дүрт ел фәкыйрьлектә горбәттә гомер кичергән соңында, бер магазинга приказчик булып кереп, 25 ел шул урында Истанбулда тора.

[1] Бу шәһәрнең нинди вә кайда икәне мәгълүм улмады. Риза хәзрәт тә белми. *(Авт. иск.)*

Сәяхәтнамәнең ахырында: «Ватанымызга кайтырга кулымда хариҗемез[1] улмады, мохтаҗлыкдан тугъма[2] янына килә алмадык, гарип булып[3], чук-чук[4] зарлык кылдык», – ди. Соңра бу кеше кайда киткән: ватанына кайта алганмы, һәйәт, хөкүмәт кушкан эшне башкарганмы – әсәрнең үзеннән бернәрсә мәгълүм түгел. Әмма бу әсәр яисә сәйяхләр хакында башка мәнбәгъләр таба алмадык.

Рихләтнең теле, бәгъзы бер госманлы җөмлә төзелешләрен һәм сүзләрен истисна кылганда[5], саф татарча. Аның теле, нәкъ шул Риза хәзрәтләр һәм вакыт язучылары теле күк булып, соңрак бер дәверебезнең әдәби теленә охшый. Ләкин Мәрҗани өслүбе шикелле гарәп вә фарсы сүзләре белән чуарланмаган. Шуның өчен тел бабында Исмәгыйль агайны безнең әдәби телебезне ясаучылардан иң искесе дияргә туры килә. Аның теле Ибраһим Хәлфиннекенә дә охшый төшә. Шуның өстенә Исмәгыйль агай борынгы төрк сүзләрен дә шактый истигъмаль кыла[6]. «Язмак» урынына «бетмәк», «якшы» вә «рәхәт» урынына «яругъ», «мылтык кору» урынына «ярагламак» сүзләрен куллана. Билгеле, Исмәгыйль агайга бу турыда чыгтай әдәбияты тәэсир иткән дип әйтеп булмый. Чөнки аның гыйльми-мәдәни дәрәҗәсе алай тәэсирләргә бирелерлек түгел. Бу сүзләр безнең XVIII гасырыбызда сөйләшү телендә истигъмаль кылынган булырга кирәк. Шуның өчен дә бу сәяхәтнамә безнең ике гасыр мөкаддәм булган сөйләшү телебезне өйрәнү өчен дә, ихтимал, мәнбәгъ була алыр.

Әдәби яктан рихләт бер школага ияреп яисә бер нәрсәгә тәкълидән язылган әсәр түгел. Ул – бары бер мәктүб. Ләкин шулай булса да, бу кешедә әдәби зәвык булган булырга кирәк. Аның оста вә матур тасвирлар белән бик табигый рәвештә йөр-

[1] Хариҗемез – картабыз.
[2] Тугъма – туганнар.
[3] Гариб булып – туган җирдән аерылып.
[4] Чук-чук – бик күп.
[5] Истисна кылганда – аерып алганда.
[6] Истигъмаль кыла – куллана.

гән каләме бу мөхәррирнең заманасы өчен шактый бер мөһим язучы булуын күрсәтә һәм аның сәяхәтнамәсен XVIII гасырдан безгә кадәр сакланып калган бик аз гына әдәби әсәрләр рәтенә тезәргә хак бирәдер.

**«Бәдәвам китабы»**

«Бәдәвам китабы» татар арасында иң таралган китаплардан берсе иде. Аны әле хәзердә дә һәрбер авылда, һәрбер йортның шүрлегендә «Һәфтияк» вә «Иман шарты» белән бергә очратып була. Ул әллә кай заманнардан бирле мәдрәсәләрдә укылып килгән. Һәрбер мәктәп баласы, язу таный башлагач та, иң элек уку китабы итеп шуны кулланган.

«Бәдәвам» – кечкенә кулда 16 битле, бәхре бәсыйт (мөстәфагыйлен фагыйлен) вәзенендә[1] нәзым белән язылган вәгазь китабы. Һәрбер дүртьюллы бәйте «Аллаһ! – дигел бәдәвам» дигән җөмлә белән тәмамланганга, «Бәдәвам китабы» дип аталган. Ул, татар арасында иң мәкъбүл[2] китаплардан булса да, беренче тапкыр бары 1846 елда гына басылган.

«Бәдәвам китабы»ның кем тарафыннан һәм кайчан язылуы турысында без бернәрсә дә белмибез. Тик ул, шактый борынгы китап булып, XVIII гасырдан да соң язылмаган булырга тиеш. Шуңар күрә без аны XIX гасырга кадәр язылган татар китаплары рәтеннән саныйбыз.

«Бәдәвам»ның борынгылыгына аның түбәндәге бәйтләре дәлаләт итәләр:

«Һәркем җенгә табынса,
Йа суга нәрсә салса,
Йа агачка нәрсә чалса,
Аллаһ! – дигел бәдәвам.

Яз нарны багласа,
Йа ул келәү күтәрсә,

[1] Вәзенендә – ритмында.
[2] Мәкъбүл – кабул ителгән.

Хәрәмне хәләл белсә,
Аллаһ! – дигел бәдәвам.

Пәйгамбәр билә, диде,
Кяфердер анлар, диде,
Тәмуглык анлар, диде,
Аллаһ! – дигел бәдәвам».

Менә монда саналган эшләр – җенгә табыну, суга әйбер салу, агачка әйбер чалу (ягъни бәйләү), keләү күтәрү – болар һәммәсе мәҗүс-шаман диненең, ягъни төрк вә фин халыкларының борынгы диннәренең гадәтләре. Җенгә табынудан морад монда мәҗүс тәңреләренә табыну булса кирәк. Мәҗүси булган бер-бер халык арасына яңа гына китаплы бер дин кергән вакытта, аны китерүчеләр, борынгы милли диннең Аллаларын бөтенләй үк халык күңеленнән, халык игътикадыннан[1] чыгарып бетерүдән гаҗиз булганга күрә, һәрвакыт аларны күзгә күренми торган кара көчләр, ягъни пәри-җеннәр дип игълан итеп, яңа дин күз каршында рәсмиләштерергә мәҗбүр булганнар. Шуның аркасында, чынлап та, заманның үтүе белән, халык аңында байтак иске тәңреләр пәри-җенгә әверелеп киткәннәр. Башка халыклардагы шикелле, безнең төркләрдә дә бу, әлбәттә, шулай булган. Халык хыялында гәүдәләнгән һәрбер халыкның үзенә махсус җеннәре булган шикелле, безнең татарның да һәртөрле урман ияләре (шүрәле), су аналары, йорт ияләре, абзар ияләре, албасты вә убырлар – кадим[2] заманда һәммәсе берәр мәгъбүд итеп[3] исәпләнгәннәрдер. Шулай итеп, шүрәле – урман иясе, урман тәңресе, су анасы – су тәңресе, йорт иясе – йорт тәңресе, абзар иясе йорт хайваннарын саклаучы тәңре булгандыр. Ия дип аталулары да аларның мәгъбүд булганнарын күрсәтә. Чөнки «хуҗа» мәгънәсендә булган «ия» борынгы төрк телләрендә (Орхон язмаларында, уйгурчада, чыгтайчада «иде» яки «изе»

[1] Игътикадыннан – ышануыннан.
[2] Кадим – иске.
[3] Мәгъбүд итеп – табынылa торган зат итеп.

формасында тәләффыз ителә[1]; «иде-изе» сүзе уйгурчада һәм борынгы чыгтайчада турыдан-туры Алла мәгънәсендә истигъмаль кылына. Аллага тәгаллекъли[2] «мөкаддәс» мәгънәсендә булган «идук, идгү, изкү» сүзе безнең татарчага «изге» формасында килеп кергән.)

Менә шул мәҗүс тәңреләрдән мәрхәмәт яки ярдәм теләр өчен җыелышып, кырларга, тауларга чыгып, хайван корбан кылуны йә бер-бер әйбер пешереп ашауны бездә «келәү күтәрү» дип атыйлар (келәү – «теләү», «теләк», «дога» мәгънәсендә, келәнче – теләнче). Шулай ук, тәңреләргә атап, аларга корбан йөзеннән пешкән ашлар кую, ырым өчен суга бер-бер әйбер ташлау, мөкаддәс агачларда яши торган тәңреләргә багышлап, агачның ботакларына чүпрәк-фәлән бәйләү шикелле эшләр дә – шаман динендә бар эшләр. Соңгы гадәт әле яңа гына ислам кабул итеп, шаманлык тәэсиреннән котылып җитмәгән кыргыз-казакъларда хәзердә дә бар. Бәгъзы бер далада ялгыз утыра торган агачларның бөтен ботаклары чүпрәк белән тулган була.

Менә шушы мәҗүс гадәтләренә каршы безнең «Бәдәвам китабы» җиһад[3] ача, аны эшләүчеләрне көфер[4] белән куркыта; пәйгамбәр андый кешеләрне кяфер, тәмуглык дип әйткән, ди. Әлбәттә, бу сүзләрне пәйгамбәр әйтмәгән, әмма мәҗүси халыкларны дингә өндәүче мөселман миссионерлары, аларга нисбәтән пәйгамбәр ролен уйнаган галимнәр пәйгамбәр исеменнән әйткәннәр. Менә «Бәдәвам»ның югарыда китерелгән сүзләренә карап, бу китап бик борынгы заманнарда, әле безнең халык яңа гына ислам кабул итеп, дин ныгып җитмәгән чакларда язылган дип уйлау гадәт булып киткән.

Ләкин болгарлар моннан мең ел элек мөселман булганнар, XIII гасыр башында Идел буена килеп, Алтын Урда дәүләтен тәэсис иткән[5] татарлар да озакламый ислам диненә кергәннәр.

[1] Тәләффыз ителә – әйтелә.
[2] Тәгаллекъле – бәйләнешле.
[3] Җиһад – изге сугыш.
[4] Көфер – динсезлек.
[5] Тәэсис иткән – оештырган.

Әгәр дә без «Бәдәвам китабы»н болгарлар вә татарлар арасындагы мәҗүсият калдыклары белән көрәшү дәверендә язылган дип уйласак, аның язылу тарихын бик еракка илтергә туры килер иде. Әмма мөәррихләр[1] татарлар арасында Казан ханлыгы дәверендә дә әле исламиятнең бик үк ныгып җитмәгән булуын гөман итәләр[2]. Татарларда дини хис, Казан алынганнан соң, рус хөкүмәтенең динне кысуы, чукынырга көчләве аркасында бигрәк ныгып, фанатизм дәрәҗәсенә җиткән булырга кирәк, диләр.

Алай булган сурәттә дә, «Бәдәвам»ның язылуына берничә йөз еллар булырга тиеш. Чөнки безнең арада инде шаман гадәтләренең таралган вакыты бик күптән булырга кирәк. Бигрәк тә җенгә табыну, агачка әйбер бәйләү безнең халыкта әллә кайчаннан бирле юк. Келәү күтәрү дә бик сирәк урыннарда гына калган. Абзар яки йорт иясенә атап абзарга, төнлек юлына яки чормага ботка пешереп кую гадәте генә әле безнең авылларда шактый таралган бугай. Әмма чирмеш, ар, мукшы шикелле халыкларда бу гадәтләр әле дә куәтле, бу халыкларның рәсмән христиан саналганнарында да әле алар бик нык хөкем сөрәләр. Элегрәк аларның чукындырылып өлгермәгәннәреннән бик күбесе татарлар тәэсирендә мөселманлык кабул итеп, татарлашып киткәннәр. Идел буендагы бу вак фин кабиләләренең мөселманлыкка чыгуы татар ханлыгы заманнарыннан алып соңгы заманнарга кадәр дәвам иткән. Тик XIX гасырда рус руханилары һәм хөкүмәте бу эшкә игътибар итеп, вак халыкларны бик ныклап христианлаштыра башлагач кына, бу мөселманлыкка күчү туктала төшкән. Менә безнең «Бәдәвам китабы»н язучы, ихтимал, шул яңа мөселман булган, халыклар арасындагы шаман гадәтләре белән көрәшүне күз алдында тоткандыр. Һәрхәлдә, бу әсәрнең моннан берничә йөз еллар элек язылуын дәгъва кылырга мөмкин. Мәрҗани «Мөстәфад»ендә аны үзе болгарлардан калган дип уйлаган әсәрләр рәтеннән саный. Болгарлар

[1] Мөәррихләр – тарихчылар.
[2] Гөман итәләр – белдерәләр.

хакында сөйләгәндә, 15 нче биттә ул әйтә: «Вә ма әсәрләре мисле «Нәһҗел-фәрадис», вә «Башлагали», вә «Йосыф китабы», вә «Нәсыйхәт әс-салихин», вә «Бәдәвам китап»лары кеби төрки китаплар вә Нәүрүз бәйтләре, вә Шәһре Болгар газиләре бәйтләре бар. Бәгъзылары бик җыш бик иске язу икәнзардә өч-дүрт йөз сәнә мөкаддәм[1] язылган. Димәк, мөмкин һәм Болгар шәһәрендә улан олуглар язуларына бик мөшабәһә[2] бу китаплар бу мәмләкәтләрдә басма вә язмалары галиел-кәсрәт[3] табыладыр, гайре мәмләкәтләрдә бер дә күрелгән вә ишетелгәне юк вә бу китаплар лисане госманлы[4] вә чыгтай вә төрекмән вә Казакъстан лисаннарына мөбәйяндыр[5]». Мәрҗани, гәрчә бу китапларга фәнни ноктаи назардан[6] карап, аларның язуларының иске язуга, Болгар ташларының рәсме хаттына[7] охшашлы булуына истинадән[8], борынгы Болгарда язылган булуларын тәхмин кылырга[9] тырышса да, аның бу дәлилләре генә, әлбәттә, иң зәгыйфь һәм бер әйбер дә исбат итмиләр. Хосусан, аның тел хакында әйткән сүзләре бер дә тәнкыйтьне күтәрми. Ләкин, шөбһәсез, Мәрҗанинең кулында бик борынгы рәсме хатт белән язылган кульъязмаларының булуы бу китапларның, шул җөмләдән «Бәдәвам китабы»ның, бик күптәннән бирле халык арасында укылганлыкларын күрсәтәдер.

«Бәдәвам»ның теле саф татарча диярлек; сүзләр һәм сарфи[10] формалар анда, күбесенчә, татарча истигъмаль ителгән[11]. Ләкин арада аз-азлап сибелгән чыгтай вә госманлы сүзләре һәм формалары очрый. Бәгъзы формалар кара-катыш – татарча вә

[1] Мөкаддәм – алда, элек.
[2] Мөшабәһә – охшаган.
[3] Кәсрәт – күп.
[4] Лисане госманлы – госманлы телле.
[5] Мөбәйяндыр – бик ачыктыр.
[6] Ноктаи назардан – караштан.
[7] Рәсме хаттына – язуына, почеркына.
[8] Истинадән – таянып.
[9] Тәхмин кылырга – чамаларга.
[10] Сарфи – морфологик.
[11] Истигъмаль ителгән – кулланылган.

чыгтайча китерелгән; «беленкез – беленең», «белемкән – белмәс», «төбинә – башигә» шикелле. Китапта «дигел, ирмез, урларсын, килгәй, чыгар, ягар (явар)» күк чыгтайчалыклар, «дәгел, вармак, йөрмәк, йимәк, куймак (ташлау), булмак (табу)» күк госманлычалыклар очрыйлар. Чыгтай вә госманлы телләренең безнең әдәби телебезгә тәэсире элек-электән була килсә дә, «Бәдәвам»да бу тәэсир бик зәгыйфь. Идел буенда язылган башка борынгы әсәрләргә караганда бик аз. Язучы, ихтимал, китабын халык гаммәсе[1] өчен язганга, касдан[2] шундый садә[3] тел белән язгандыр. Һәрхәлдә, бу китапны Идел буенда бер татар тарафыннан язылган дип бер дә шикләнми әйтеп була.

«Бәдәвам китабы»ның бер вәгазь китабы булуын югарыда әйткән идек. Аның мөндәриҗәсе менә шуннан гыйбарәт: иман белүнең кирәклеге, имансызларны сүгү, имансызлыкның сәбәпләре, намаз укырга өндәү, намазсызларны сүгү һәм куркыту, зәкят бирергә өндәү, исереклектән тыю, ахырзаманның якын булуы, замананың бозылуы, яман галимнәр, үлем хәлләре, кабер газапларын, ахырзаман әхвәлен тасвир, Җәннәт, Җәһәннәм, вәгазь-нәсыйхәт, фани дөньяны куярга, гыйбадәт кылырга өндәү. Бу әйберләр хакында аерым бабларга бүлеп түгел, бәлки бертоташтан сөйләнә. «Бәдәвам»да тәсаувыф тәэсире дә бераз сизелә. Ул дөньяны куярга, зөһдлеккә[4] чакыра. Китапның ахырында мөәллиф аларга хитап кылып әйтә:

«Максудым сән, сән бәңа,
Матлубым[5] ризаң бәңа,
Мөштәкым[6] дидарыңа,
Аллаһ! – дигел бәдәвам».

---

[1] Гаммәсе – массасы.
[2] Касдан – уйлап, максатчан.
[3] Садә – гади.
[4] Зөһдлеккә – тәкъвалыкка, суфилыкка.
[5] Матлубым – теләнгәнем, соралганым.
[6] Мөштәкым – омтылуым.

Һәрбер бәйтнең бертөрле җөмләгә тәмамлануы да – тәсаувыф әдәбиятына махсус шикелле бер формадыр.

«Бәдәвам китабы» кыска ифадәле[1], көчле өслүб[2] белән язылган. Аның мөхәррире имансызларга, намазсызларга, исерекләргә каршы бик каты тәгъбирләр куллана. Үз фикеренчә, көфергә сәбәп була торган эшләрне эшләүчеләр хакында ул «хатыннары хәрәмдер, бугазлаганы мордардыр», ди. «Иман белмәс хатыннар иргә варса һәм анлар иренә хәрәм анлар», ди; иман белмәгән кеше үлсә, аны юмаска, кәфен сармаска, җеназа укымаска һәм кяфер каберенә күмәргә куша. Кяферлекнең сәбәпләреннән галимне сүгү, остазны хурлау, сабакны сүгү, Коръән таптау шикелле эшләрне саный, исерткечнең «катрәсе[3] кандин яман», ди. Исереккә сәлам бирмәскә, ул бирсә дә алмаска куша. Зәкят бирмәгән кешене дуңгыздан яман, ди, аны карун дип атый; «карун зәкят вирмәде, ахры, аны йир йотты, җәһәннәм төбенә китде», ди, «зәкятсез мал хәрәмдер, дуңыздин һәм ямандыр», ди, «ахырзаман якын булды, дөньяга фетнә тулды, күп галимләр залим булды, күп суфилар шайтан булды», дип уфтана, «йиймәкдер – һиммәтләре, хатындыр – кыйблалары, дирһәмдер һәм диннәре», ди. Туры әйтмәгән, гыйлеме белән гамәл кылмаган, кеше күңелен саклаган галимнәрне «галим дәгел, шайтандыр, наданлардин ямандыр, бел, хайвандин азгындыр», ди; аларны шайтанның дусты, Алланың дошманы, тәмугка юлбашчы дип атый. Һәркем аңларлык, ачык, саф төркичә тел белән язылган булуы, әйтәсе сүзен пычак белән кискән төсле үткен һәм нык әйтүе аркасында бу китап, безнең халык арасында ифрат рәваҗ табып[4], мөселман татар гаммәсе өчен кулдан төшмәс бер китапка әверелеп китеп, халыкка дин юлында бердәнбер юлбашчылык хезмәтен үтәп килгән.

---

[1] Ифадәле – аңлатмалы.
[2] Өслүб – стиль.
[3] Катрәсе – тамчысы.
[4] Ифрат рәваҗ табып – күп таралып.

## Догалык, фалнамә, йолдызнамә вә төш тәгъбирләре

Борынгы Шәрык – хыялятнең куәтле урыны иде. Тарихтан әүвәлге адәмнәрдә үк туган бөтен дини хыялят Шәрыкта бик соңгы заманнарга кадәр калды. Багу, сихер, тылсымнар, нөҗүм[1] гыйльме – астрология, ниһаять, гарәпләрдә бик тәрәккый иткән гыйльми әсәрләре – хоруф – Шәрыкта туган нәрсәләрдер.

Ислам мәдәнияте ясалып, матди вә мәгънәви мәдәният бик яхшы тәрәккый иткән булса да, гарәпләрдә, бигрәк тә хыялят вә серле гыйлемнәрнең ватаны хисапланган Һиндстан күршесе Иранда, бу хыялят бетмәде, куәтләнде. Әгәр Хуҗа Хәлифәнең «Кәшф әл-зөнун»ның сәхифәләрен генә актарып карасаң да, сихер, тылсым кебек асылсыз сөнгатьләргә даир язылган әллә никадәр китап исеме очратасың. Менә безнең татарның укый торган китаплары эчендә дә без шундый хыялый әсәрләр күрәбез. Алар исә – догалыклар, фалнамә вә йолдызнамәләр, ярым хыялый, ярым дөрес тыйб китапларыдыр[2].

Кадим бабил халкының иҗат иткән астрология, ягъни йолдызларның йөрешләреннән кешеләрнең киләчәген, бәхет вә бәхетсезлеген караулар элек җенесдәшләре сүриялеләргә, соңра гарәпләргә вә иранлыларга күчеп, мөселман дөньясында да бу хорафи, ялган гыйлемгә даир күп китаплар язылды. Исламның бөтен яхшы вә яман якларын тәнкыйтьсез алган төрекләргә дә бу әсәрләр керде, кешеләр талигъларын[3] шуның белән карап хәл итә торган булдылар.

Бу йолдызнамәләрнең арага таралуларына төрк-татар кавемнәрендә болай да хәзерлек бар иде. Татарлар әле күптән түгел генә икътисади яктан күчмәлектән чыкканнарына күрә, алар кабләттарихи[4] бер хәленнән ерак тормыйлар, шуның өчен

[1] Нөҗүм – йолдызлар.

[2] Безнең кулыбызда борынгы тыйб китапларыннан берничә кульязмасы бар. Ләкин бу мәсьәлә белән шөгыльләнү өчен шул бабда, бигрәк тә «халык тыйбы»на даир гыйлемдә мөтәхассис булырга кирәк. Шуның өчен бу мәсьәләне тикшерүне әһеленә калдырабыз. *(Авт. иск.)*

[3] Талигъларын – киләчәкләрен.

[4] Кабләттарихи – әүвәлге тарихта.

аларда борынгы шаманлык әсәре әле шактый күп калган, ислам аны куып чыгармаган, бәлки яңа исем генә биргән иде. Мәгълүм ки, шаман динендәге татар вә башка Урал-Алтай кавемнәрендә йолдызларга табынулар вә аларның йөрүләренә зур игътибар итеп, багу-багулар булган. Шуның өчен ислам тәэсире белән килгән бу йолдыз вә фалнамәләр бу әзер мохиткә килеп төшкәннәр иде.

Фалнамәләрдәге алдан хәбәр бирүләр һәрвакыт Җәгъфәр Садыйк исеменнән сөйләнә. Җәгъфәр Садыйк исә шигаләрнең мәшһүр имамларыннандыр (имам – шигаләрдә һәр гасырда бер генә килә торган, пәйгамбәрнең һәм Галинең хәләфе[1] вә каим мәкаме[2]). Бу – фалнамәләрнең, безгә госманлылар аркылы керсә дә, асыл Ираннан чыкканлыгын күрсәтә.

Шул ук шаманизм төш юрау мәсьәләсенә дә шактый әһәмият бирә. Шуның өстенә дә ислам әдәбиятында моңарга даир әдәбиятның булуы аның, ислам рухында булып, китап, ягъни «тәгъбирнамә»ләр рәвешендә керүенә зур мөсагадә[3] бирде. Шулай итеп, элек туп-туры госманлычадан алынып, бәгъзысы яңадан язылып, безнең арада күп төш тәгъбире китаплары йөри торгач, матбугат чыгу белән басылып та таралдылар.

Тәгъбирнамәләрдәге төш тәгъбирләре һәрвакыт Йосыф пәйгамбәргә нисбәт бирелеп йөртелә. Тәгъбирнамәләрнең бездә әллә ничә төрлеләре басылды. Аларның асылы Ираннан чыккан булырга кирәк. Безнең XVIII гасыр язучыларыннан Габдерәхим Утыз Имәнинең фарсычадан бер тәгъбирнамә тәрҗемә иткәнлеге мәгълүм.

Ләкин шаманлыкның безнең арабызда ислам хиркасына төренеп калуы икенче бер әдәбият чиренең җәелүенә сәбәпче булды. Ул исә догалыклардыр. Төрле имамнар кирамәтләр ясаганда, куркулыклар койганда, мәҗүси корбаннары чалганда, яңгыр боткалары пешергәндә, чалпулар салганда әйтелә торган

[1] Хәләфе – варисы, дәвамчысы.
[2] Каим мәкаме – вазифаларын башкаручы.
[3] Мөсагадә – мөмкинлек.

дога вә сүзләр бетеп җитмәде. Иске шаман кяһине[1] – багучы (баксы) күздән төшеп барган чакта, аның урынын тоткан «чалмалы шаман» – ислам рухание, үзенең икътисади тормышын яхшылату өчен, теге догаларны яңадан яңартты, ләкин ул аларны әүвәлге күк татарча түгел, бәлки халыкны яңадан да көчле талауга имкян биргән халыкка аңламаслык гарәп телендә яңартты. Шулай итеп, «догалыклар» мәйданга килде.

Кайдан килде бу догалыклар?

Алар ислам галәмендә дә бар иделәр. Хәтта шул догалар хакында исламның иң җитди дин галимнәре, мөфәссир[2] вә мөхәддисләре әсәрләр яздылар. Имам Нәвавинең «Китап әл-әзкяр»е[3], Җәзәринең «Хәсән әл-Хөсәен»е, Хәсән Сиддыйкның «Назил әл-әбрар»ы[4] шул җөмләдәндер. Менә шундый китаплар вә аларга тәкълидән[5] ясалган башка бик күп рисаләләр элек Урта Азиядә вә госманлы тупрагында язылдылар да, соңра безнең арага килеп кереп, бик тиресле әзер җир таптылар. Ниһаять, басу сәнәгате безнең арага таралгач, бастырыла башладылар. Ләкин алар – бездә иң соң басыла башлаган китаплардандыр. Алар бары 1847 елда басыла башладылар.

Бу безнең матбугатыбыз өстенә үсеп чыккан гөмбә вә чир белән шактый көрәшергә кирәк булачактыр. Шуның өчен бу хакта бераз озынрак туктарга мәҗбүр булабыз.

1847 елда «Әсмаи-хөсни», «Догаи Сәйфи» һәм «Догаи гаҗаиб әл-истигъфар»[6] басылды. Соңгысы исә бер елда ике мәртәбә табигъ кылынды. 1848 елда исә «Догаи җәннәт әл-әсма»[7], «Догаи гаҗаиб әл-истигъфар» яңадан берәр мәртәбә, «Догаи әл-рәнг әл-вәҗа» исә ике мәртәбә басылды. Моннан күреләә ки, бу ике ел татар галәменә әллә никадәр шарлатанлык ыргытты.

[1] Кяһин – фалчы.
[2] Мөфәссир – аңлатучы.
[3] «Китап әл-әзкяр» – «Зикерләр китабы».
[4] «Назил әл-әбрар» – «Күктән иңгән китап».
[5] Тәкълидән – ияреп.
[6] «Догаи гаҗаиб әл-истигъфар» – «Көчле тәүбә догасы».
[7] «Догаи җәннәт әл-әсма» – «Югары җәннәт догасы».

Моның сәбәбе исә ул елдагы холера яисә башка бер каза булырга кирәк. Ике ел татар матбугаты бу догалыклардан ял итте. Бу әдәбиятка чыккан чир, 1851 елда яңадан көчләнеп, тагы да алдаучырак нәрсәләр бирде. Бу исә – «Догаи исме Әгъзәм», «Догаи гаҗаиб әл-истигъфар». Болар өстенә хәтта бер догага шәрех тә багланды, ул исә «Шәрех дога кырынҗә», ягъни «Кырмыска будыр» сәрләүхәле[1] догалык иде. Шул ук елда ике кәррә «Тылсым шәриф» вә «Мөһер шәриф» басылды.

Диварга элә торган «Мөһер шәриф» басылу белән яңа мода чыгып, 1851 елда «Башка шәриф хасиятләре белән» дигәне табигъ ителде. «Мөһер шәриф» бер елда ике мәртәбә басылды. 1852 елда яңа догалык басылмады. Ләкин искеләре берәр кат янә табигъ ителделәр. Әмма 1853 ел бу бабта яңа нәрсәләр бирде: «Бизгәк өчен догалар», «Догаи өмме-л-сыйбъян»[2], «Догаи иман», «Догаи шәриф» аталганнары чыкты. Шул ук елда догачылар яңа бер нәрсә бирделәр: ул исә «Янга тагу өчен догалар» иде. Димәк, наширләрнең аппетитлары яңадан үсте, алар хәзер халыкның укый-яза белмәгәненә дә яраарлык нәрсәләр бастыра башладылар, шуның өчен бу ел яңадан бер мәртәбә «Мөһер шәриф» ясалды. Шулай итеп, ел саен шул догалар басылып киләләр дә, 1808 елда «Догаи кадәх ән-нур»[3] дигән яңа бер догалык пәйда була. Ниһаять, 1860 елда догаларның энциклопедиясе булган «Мәҗмәгъ әд-дәгъвәт» чыга. Шулай итеп, бу туктаусыз догалыклар нәшер ителеп киләләр.

Шунысы кызык ки, бу догалыкларның кайсысының тиражы һаман (прогрессивно)[4] арта бардылар. Мәсәлән, «Янга тагу өчен догалар» 1852 елда 2400 генә нөсхә нәшер ителгән иде, әмма 1854 елда – 4800 данә, 1856 һәм 1857 елларда 3000 данә басылдылар. «Бизгәк өчен дога» исә 1853 елда – дүрт мең, 1856–1857 елларда өчәр мең данә басылып килделәр дә

[1] Сәрләүхле – исемле.

[2] «Догаи өмме сыйбъян» – «Аналарның балалалары өчен кылган догасы».

[3] «Догаи кадәх ән-нур» – «Нур касәсе догасы». Гөнаһлардан арыну һәм бәла-казалардан имин булыр өчен укыла.

[4] Кирилл хәрефләре белән язылган.

1858 елда 19 200 нәшер ителде. «Догаи исме-Әгъзәм» 1851 вә 1857 елларда 4800 данә басылып килде дә 1858 елда 7800 данә басылды, «Догаи җәннәт әл-әсма» исә 1854 елда – 3000 данә, 1858 елда 5000 данә басылды. 1885 елда догалык эше яңадан бер мәртәбә сикерә, әмма 1858 елдан алып бертөрле генә нәшер ителеп килә. Мәсәлән, «Өмме сыйбъян» – сиксән мең данә, «Исме Әгъзәм» – егерме мең, «Догаи-Сәйфи» – ун мең данә. Билгеле, догалыкларның күпме басылуларына даир бөтен статистиканы бирү безнең максатыбыз түгел. Бары шуны гына әйтеп китәргә кирәк ки, 1886 елда «Догаи әл-әнгам»[1] сигез мең данә басылганы хәлдә, шул ук елда татарча беренче тапкыр Яурупага тәкълидән язылган роман – Муса Акъегетзадәнең «Хисаметдин менла»-сы – бары мең данә нәшер ителде... Бу догалыклар 1887 елларда яңадан күп нәшер ителә башлыйлар. Мәсәлән, «Догаи мәрҗан» күкләре берьюлы егермешәр мең басылалар...

Бу догалыклар безнең әдәбият тарихы өчен бары бер яктан мөһим: ул да булса – һәрбер догалыкның алдындагы «хасиятләре» аталган төркчә хикәя вә доганың әһәмиятен сөйләгән сүзләре.

Һәрбер «хасият», күбесенчә сугыш китаплары шаблонынча, пәйгамбәрнең михрабка аркасын куеп вәгазь әйтеп утырганыннан башлана. Шул чакта пәйгамбәргә Җәбраил фәрештә Алладан бүләк итеп бер мөҗәррәб[2] дога китерә. Шуннан соң доганың хасиятләре сөйләнә башлый.

Бу урында без ике тип догалык алабыз. Аларның берсе – халык арасына бик таралган «Догаи сәйфи», икенчесе – «Догаи риҗаль әл-гаиб».

Беренчесенең кырык төрле хасияте сөйләнә: шуның унысы – теге дөньяда, утызы – бу дөньяда. Шуларны сөйләр алдыннан, язучы: «Зинһар вә зинһар, шик вә гөман итмиясен кем барча савабдан мәрхүм уласын», – дип куя. Кыскача гына әйткәндә, шундый хасиятләр бәян ителә – әгәр кеше шуны укыса, һәр-

[1] «Догаи әл-әнгам» – «Хайваннар догасы».
[2] Мөҗәррәб – сыналган.

бер мөшкелдән хәляс була[1]. Зинданнан котыла, төрле авырулардан терелә, ул тәнасел[2] куәсен көчләндерә, сөйдерә, юлы уңа, дошманнарын җиңә, бу дога усал җанварлардан да хәляс итә. Агуланган кешене терелтә, югалган нәрсәсен таптыра. Баласы булмаса, булдыра. «Догаи сәйфи» булган йортта һич янгын булмый, янында йөрткән кеше суда батмый, адашкан кеше юл таба, бай була, бигрәк тә дию вә пәриләр аңар мөсәххәр[3] булалар. Безнең борынгырак заманыбызда бу дию пәрие мөсәххәр итү[4] мәсьәләсе бик мөһим бер эш хисапланадыр иде. Хәтта Казан вә авылларда, «Догаи сәйфи» укып, бик күп кеше шашадыр иде дә, шуның өчен бу хактагы сүзләрне күчереп үтәбез: «Бер кемсә дию пәри аңа мөссәхәр ула, җомга көн госел идә, вөҗүден җөмләи әндәмдин (җенләрдән) пакь идә, пакь тун кия вә хуб кухулар[5] исләнә вә «Куль йә әййүһе-л-кәфирун» сүрәсен вә мәгузәтен укыя хәлвәт[6] йирә варә, һич боны белмәяләр. Андан соңра «Куль һуа» сүрәсен укыя, зинһар, курыкмая вә гаҗәиб вә гарәиб нәрсәләр заһир улса кирәкдер. Аждаһалар вә еланнар вә гыйфритләр вә һавадан утлар вә ягмурлар вилдеремләр шыкмакы (?) ула вә болар заһир улмак вә дөкемез сыйфатлардан хәляс улмага ул бер булат пычак бер даирә эчендә кәндү үгендә[7] куя. Бу «Догаи сәйфи»не укымага мәшгуль ула курыкмайа, кем Тәңре Тәгаләнең олуг атлары бу «Догаи сәйфи»дә дөрделер вә пәриләр ул даирә эчендә һич кермийә, әмма даирәйә килсәләр, зыян декермийәләр[8] вә бу «Догаи сәйфи»не бер ләхза[9] тәрк итмийүб[10] укыйа такым диюләр мәсхәр улып, зәбун[11] улалар, андан соң диюләр чагырып идәләр, ябни адәм әмрадының

[1] Хәляс була – коткарыла.
[2] Тәнасел – нәсел арту.
[3] Мөсәххәр – буйсындырылган.
[4] Мөсәххәр итү – сихерләү.
[5] Хуб кухулар – хушбуй.
[6] Хәлвәт – аулак.
[7] Үгендә – өендә.
[8] Декермийәләр – китермиләр.
[9] Ләхза – күз ачып йомганчы.
[10] Тәрк итмийүб – ташламыйча, читкә куймыйча.
[11] Зәбун – зәгыйфь.

вә максудының вардыр бойурырына куялым»... «Догаи риҗаль әл-гаиб» ислам мифологиясендәге бер кыйсса үзәренә әйтелгән. Мәгълүм ки, халык телендә 360 «Риҗаль әл-гаиб» яисә «гаиб ирәнләре» бар икән, диләр. Болар кешеләргә төрле уңайсызлыкларда иганәт итәргә куелганнар. Бу кешеләр бер дә шул бер саннан кимеп тормыйлар. Әгәр берсе үлсә, хәзер үзләренә иптәш итеп берәр кешене урлыйлар, шуның өчен дә тик торганда бәгъзы адәмнәр юкка чыгалар, имеш. Менә бу догалар – гаиб ирәнләреннән иганәт сорар өчен бер васита[1]. Бу ирәнләр дөньяның «җәһат әрбәга» (дүрт ягы)ның төрле урыннарда булалар, шуның өчен доганы укый белеп укырга кирәк. Бу доганы нәшер итүче кеше, аның мөҗәррәблеген[2] исбат итү өчен, матур гына хикәяләр дә китерә. Шуларның берсенең мөндәриҗәсе шулай. Кыйссаның әсасенә мәшһүр әдәби мәүзуг булган «Ләйлә вә Мәҗнүн» төймәсе салына. Һәрмәз исемле бер падишаһның Ләйли (Ләйлә) исемле бер кызы була: кыз үзе ифрат бай, хәзинәсе «хисапка сыгмаз», әмма төскә ифрат ямьсез: «чытык чырайлы холыксыз ирде», кырык яшенә җитсә дә, аны беркем дә кияүгә сорамаган. Падишаһ, күп акча сарыф итеп, төрле догалар кылдырган, ләкин берсе дә файда бирмәгән.

Ниһаять, кызның «сачләре агарды, тешләре дөшде, йөзләре бөрешде». Бара торгач, бер шәехкә мөрәҗәгать кылганнар, ул шушы доганы яздырган, тагып йөрергә һәм укырга кушкан. Шуннан соңра кыз, шәехнең мәслихәте буенча, доганы укырга тотынган. Бер көнне Мәҗнүн исемле бер егет, сарай янынннан узып киткәндә, кызны күреп, гашыйк була: «Аты өстеннән аһ идеп, Мәҗнүн әвәрәи җиһан[3] булды...». Бу Мәҗнүн гади кеше түгел, патша углы икән. Аның өчен ата-аналары Чин-Мачин падишаһы кызларын кырык ел карап йөргәннәр – һичбер патша кызларын яратмаган һәм алмаган. Аңарга кыз таба алмыйча гаҗиз калганнар. Мәҗнүн, гомумән, өйләнмәм, дип ант иткән. Менә шушы

[1] Васита – әмәл, чара.
[2] Мөҗәррәблеген – сыналганлыгын.
[3] Әвәрәи җиһан – җиһаннан ваз кичү.

Мәҗнүн, кызның ямьсезлегенә, аталарының ризасызлыкларына карамый, Ләйләне хатынлыкка ала. Төскә ямьсез һәм кияүгә бара алмый утырган кызларга бу кызыкмаслык бер эшмени?

Бу догаларның хасиятләрендәге төрки текстларның күбесенең теле татарча. Ләкин чыгтай вә госманлы телендә булганнары да бар. Аларның безгә кульязма халәтендә Истанбул һәм Урта Азиядән килгән булулары бик ихтимал.

## «Иман шарты» яисә «Шәраит әл-иман»

Татар арасында иң күп таралган, халык арасына җәелеп, бер мөкаддәс китап, хәтта бер фәтиш[1] дәрәҗәсенә менгән, ысулы кадимә вә җәдидә низагысы чакларында караларга бер терәк, бер авторитет булып хезмәт иткән бер китап була. Ул да «Иман шарты» яисә «Шәраит әл-иман»дыр. Бу рисалә безнең арада китап басыла башлауның икенче елыннан (1802) алып басыла башлаган. Китапның теленең борынгылыгы, чыгтай сүзләренең күплеге, кайсы җөмлә вә сүзләренең сигезенче гасыр һиҗри Болгар кабер ташларының тел вә өслүбен искә төшерүен хәтергә алсак (билгеле, саф татарча булганнарын), бу әсәрнең бездә бик борынгы заманнардан бирле укылып килгән булуын күрәбез. Ләкин аның кайчан вә кем тарафыннан язылуы хакында китапның эчендә бертөрле дә мәгълүмат юк. Тел вә өслүбенең һәр җирендә бертөсле булуы әсәрнең коллектив иҗаты түгел, бәлки бер мәгълүм зат тарафыннан язылган булганын күрсәтә. Галимҗан Баруди бу хакта «әд-Дин вә әл-әдәп»нең 1906 ел номерларында (10–11 нче саннарындагы «Иман шарты» дигән мәкаләсендә) бу әсәрнең мөхәррире хакында шул сүзләрне яза:

«Мәзкүр китапның кайу заманда тасниф кылынганы[2] вә кем тасниф иткәне бик ачык мәгълүм түгел. Мәгәр минем остазым мулла Сәлахетдин ибне мулла Исхак: «Мәшһүр мулла Мортаза хафиз әсәре дәгелме икән», – диядер иде. Мулла Мортаза

[1] Фәтиш – фетиш.
[2] Тасниф кылынганы – язылганы.

хафизның шундый әсәрләр берлә халык файдасына тырыштыгыны вә иман, игътикад китабында күп дәхеле[1] булмаган силсиләләр бәян итеп, үз мәсләкенчә хуҗа Әхмәт Ясәви силсиләсеннән дию җавап үгрәтдекене каринә[2] идәр иде вә каринәләр, дәлил булмасалар да, тәхминән өчен бер юл була алыр». Янә шул ук Баруди мәкаләсенең искәрмәсендә бу мулла Мортаза хафизның Бохара вә Төркестаннан укып кайтып, уникенче һиҗри башларында, димәк, Анна[3] вә Елизаветаның[4], татарларны кыскан Лука Канашевичларның куәтле хөкем сөргән чакларында дәрес әйтү белән мәшгуль булганлыгын бәгъзы әсәрләрдә язганлыгын сөйли; Мәрҗанинең сүзенә карап, бу кешенең 1136 һиҗридә исән булганлыгын белдерә. Ләкин бу сүзләр – һаман да бер дәгъва гына. Сәлах мулланың нигә иснадән[5] әйткәнлеге Барудиның бу мәкаләсеннән аңлашылмый. Язма нөсхәләрен табып, башка бер каринәләр булганчы, мәсьәлә һаман да ачык кала.

«Иман шарты»ның безнең әдәбиятыбызда тоткан урыны зур түгел. Ул, үзенең халык арасына күп таралуы аркасында, үзенең телен, өслүбен тәгъмим кылды[6], халык шул «Иман шарты»ндагы чыгтайчага маил[7] татарча телне намаз ниятләгәндә дә, корбан чалганда да истигъмаль кылды[8], һәркем андагы кырык фарызны бикләде, «Гакыйд-е мәнзумә»не[9] ятлады. Шулай итеп, «китапча» дип мәшһүр булган бу тел бездә күп еллар, уяну дәверебезгә кадәр әдәби тел рәсми дини тел урынын тотты.

---

[1] Дәхеле – катнашы.

[2] Каринә – галәмәт хәл.

[3] Анна Иоанновна (1693–1740) – 1730–1740 елларда Романовлар династиясеннән Россия императоры.

[4] Елизавета Петровна (1709–1761) – 1741–1761 елларда Романовлар династиясеннән Россия императоры.

[5] Иснадән – башкага аудару.

[6] Тәгъмим кылды – таратты.

[7] Маил – тартым.

[8] Истигъмаль кылды – кулланды.

[9] «Гакыйд-е мәнзумә» – «Иманлылык шигырьләре».

«Иман шарты» безның ысулы җәдидәгә кадәрле булган дәверебездә татарның иң кирәкле бер китабы иде. Шуның өчен, мөстәшрикъ дәверенең хисабына күрә[1], бу рисалә 1802 елда ук 11000 нөсхә, 1806 елда 19000 нөсхә, 1855 ел белән 1864 ел арасында дарелфөнүн матбагасында гына 147600 нөсхә басылды. Татар баласы моның белән дәрес башлый, әлифба укый, шуның аркылы дин өйрәнә. Татар арасында ислам аркасында хөкем сөргән фикъһ (гарәп хокукы) белән бераз таныша иде. Ниһаять, ул татарга үлгәч тә кирәк. Ул шундагы сүзләр белән «Мөнкир-Нәкир»гә җавап бирәчәкмен, дип ышана. Шуның өчен, кеше үлгәч тә, аны мәетнең күкрәгенә куеп күмгәлиләр. Мулла да, күмгәч, шуның буенча иман тәлкыйн итәргә[2] кала иде.

## «Рисаләи Газизә»

«Рисаләи Газизә» – Суфи Аллаһиярның «Сөбат әл-гаҗизин»енә шәрех[3] итеп язылган бер китап. Ул безнең татарның бик яратып укый торган китапларыннан берсе; ысулы кадим мәктәпләрендә дәреслек итеп тә кулланылган. «Рисаләи Газизә» басмада урта кулдан зуррак 254 битле, нәсер белән язылган. Беренче мәртәбә Казанда 1847 елда басылган.

Бу китап 1807 елда Таҗеддин Ялчыгол углы дигән бер башкорт мулласы тарафыннан тасниф ителгән[4]. Мәрҗани «Мөстәфад»ендә бу кеше хакында: «Асылы бәлдә әҗнәбидән[5] улыб, бу бәлдә вә руд вә башкорд исемендә диваннарында мәктүб», – дип әйтә. Мәрҗанинең «бәлдә әҗнәбия»сеннән кай җир морадтыр – бу аңлашылмый. Әмма Риза хәзрәт «Асар»да аның чит җирлек булуын сөйләми, атасының исеме чын башкорт исеме

[1] «Chronoloische Verzeichniss der seil demi hare 1801 bis 1866 im Kazan gedrusklen arab., turk., persisch, tatarischen Werke» исемле мәкаләсе.

[2] Тәлкыйн итәргә – үлекне күмеп, озатучылар киткәч, руханиның, үлекнең исенә төшерү өчен, иман укуы.

[3] Шәрех – аңлатма.

[4] Тасниф ителгән – язылган.

[5] Бәлдә әҗнәбидән – чит шәһәрдән.

булуына, үзенең дә «Башгори» дип кул куюына караганда, ул башкорт булырга кирәк. Мәрҗани дә, Риза казый да бу затның кайсы авылда мулла булганлыгы хакында сөйләмиләр. Китапта ул үз-үзен «аз азыклык, күп языклык Көди халкының галиме» дип тәгъбир итә. Көди – ихтимал, аның мулла булган авылының исемедер. Тәрҗемәи хәлен язучыларның әйтүенә күрә, Таҗеддин мулла гомерендә күп нәрсә язган һәм күп сәяхәт кылган. Йөргән вакытында һәрвакыт җәяү йөри икән. Бер сәяхәте әснасында[1] Имәнле исемле авылда, дусларыннан берәүнең йортына кереп, эчәргә сораган. Йорт хуҗасы бал китереп, бу шуны эчкәч, кинәт вафат булган. Вафат тарихы милади 1837 елга туры килә. 1807 елда «Рисаләи Газизә»не тәмам итеп, шул вакытта аның зур кызы булганлыгын хәтергә алсак, ул шактый картаеп вафат булган булырга кирәк. Мәрҗани бу кеше хакында «күп китаплар тасниф итте, ләкин мосаннәфаты[2] фахиш[3] илә галәттер[4]», – ди. Аның тагы «Әл-касыйдәт әл-кафия», «Тәгаллем әс-саләәат» вә «Шорут әс-саләәт» китапларына язган шәрехләре бар икән. Ләкин бу шәрехләрнең төркичәме, гарәпчәме булуы әйтелмәгән.

«Рисаләи Газизә»нең язылуы хакында мөәллиф китапның мөкаддимәсендә түбәндәге мәгълүматны бирә. Имеш, халык аннан «Сөбат әл-гаҗизин» китабын төрки теленә тәрҗемә итәргә үтенгән: «Бу китапта аңлашылмый торган сүзләр күп, шуларны үз телебез белән аңлатсаң иде; борыныбызга синнән бераз фән исе килә», – дигәннәр. Ләкин ул, һәзме нәфес итепме, аларның сүзен кабул итмәгән. Аннан соң үзенең бик сөекле Газизә исемле кызы атасына шул ук үтенечне гарыз иткән[5]: «Халыкның үтенечен кабул итсәң иде, без дә аннан файдаланыр идек», – дигән. Ләкин атасы кызының да сүзенә колак салмагач, Газизә

[1] Әснасында – вакытында.
[2] Мосаннәфаты – язылган китаплары, әсәрләре.
[3] Фахиш – начарлык.
[4] Галәт – ялган.
[5] Гарыз иткән – сораган.

тәкрар[1] үтенеп: «Мине аталык мәрхәмәтеңнән ташлама, сүземне тыңла», – дип ялварган. Таҗеддин мулла, ахры, кызын бик яраткандыр, китабында ул аны «күзем нуры, бәгърем парәсе» дип кенә атый. Кызы шулкадәр үтенгәч, «Биззарур[2] ул күз нурымның илтимасыны[3] кабул әйләйүб, «Сөбат әл-гаҗизин» китабыны шәрех әйләмәкә касд әйләдем[4]», – ди. Бу китапны ул, кызы Газизәгә нисбәт биреп, «Рисаләи Газизә» дип атаган.

Мөәллиф үзенең китабын гомум мөселман шәрехчеләре һәм тәфсирчеләре ысулы белән тәртип иткән. Элек ул мәтен[5] итеп, «Сөбат әл-гаҗизин»ның бер бәйтен китерә дә, артыннан шул бәйтнең мәгънәсен изах кылып[6], берничә юл шәрех баглый. Бәгъзан, бәйттә чыккан бер-бер сүз яки исем мөнәсәбәте белән озын-озын мөляхәзәләргә[7] керешә яки, җае туры килгәндә, берәр кыйсса сөйләп китә. Шулай итеп, кайбер бәйтләрнең шәрехләре берничә биткә җәелгәли. Бу мәгълүматны шарих[8] төрле китаплардан чүпләп җыйган булырга кирәк. Анда, пәйгамбәрләр, изгеләр тормышыннан алынган хикәяләр булганлыгы шикелле, табигать вә мәхлукат[9] хакында шәрык ысулында хорафи мәгълүмат очратып була; мәсәлән, еланнар хакындагы мәгълүмат шул җөмләдән. Монда еланнарның йөз яшәгәч аждаһага, мең яшәгәч, юхага әверелүләре хакында сөйләнә. Гомумән, халкыбыз арасына һәртөрле хорафат тарату юлында бу китап зур роль уйнаган. Аның мөәллифе хакында Мәрҗани: «Үзе «Сөбат әл-гаҗизин»не бер дә белмәгән, гыйлләт[10] бәян иткән», – ди.

---

[1] Тәкрар – кабат.
[2] Биззарур – чарасыздан.
[3] Илтимасыны – үтенечен.
[4] Касд әйләдем – ният иттем.
[5] Мәтен – китапның, әсәрнең төп тексты.
[6] Изах кылып – аңлатып.
[7] Мөляхәзәләргә – фикер йөртүләргә.
[8] Шарих – аңлатма язучы.
[9] Мәхлукат – җан ияләре.
[10] Гыйлләт – ялгыш.

«Сөбат әл-гаҗизин» шикелле тәсаувыфи бер китапка шәрех баглау факты үзебезнең язучының тәсаувыфка малик[1] кеше булуын күрсәтә. Ихтимал, аның һәрвакыт җәяү йөрүе дә бер нәүгъ[2] дәрвишлегеннән булгандыр. Китапның башында ул Суфи Аллаһиярның һәм аның шәехе Хәбибулланың тәрҗемәи хәлләрен сөйли, ахырдарак Хуҗа Баһаведдиннең мәнакыйбенә[3] берничә бит багышлый.

«Рисаләи Газизә»нең теле – әлбәттә, саф татарча ук түгел, бәлки чыгтайча вә госманлыча тәэсире белән ясалган борынгы әдәби тел. Язучының максаты китабын халыкка аңлаешлы ясау булганга, ул чит сүзләрне мөмкин кадәр аз катыштырырга тырышкан. Шуңар күрә аның теле җиңел вә һәрбер татар өчен асат аңлашыла.

Таҗеддин Ялчыгол углы нәзым белән язуда да үзенең көчен сынап караган: китапның мөкаддимәсендә аның берничә бәйтләре бар. Ләкин бу бәйтләр назыймның[4] шигырьдә артык осталыгы булмаганлыгына шәһадәт бирәләр[5]. Мәсәлән:

«Бу Таҗеддин илаһи бинәвадыр[6],
Тәрхим кыйл[7], илаһи, бинәвадыр».
.........................................................
«Сөбат әл-гаҗизин кем бер бәдигъдер[8]
Миләл әрбабына гайре хәфидер[9].
Тарикатьдә улан һәрбер гакыйдә
Улур нәзымда[10] бер миһре фәридә[11].

---

[1] Малик – ия.
[2] Нәүгъ – төр.
[3] Мәнакыйбенә – мактавына.
[4] Назыймның – тезмә әсәр язучының, шагыйрьнең.
[5] Шәһадәт бирәләр – күрсәтәләр.
[6] Бинәвадыр – бәхетсез.
[7] Тәрхим кыйл – хәленә кер.
[8] Бәдигъдер – охшаш, үрнәге булмаган, искиткеч гүзәл.
[9] Миләл әрбабына гайре хәфидер – милләт әһеленә яшерен түгелдер.
[10] Нәзымда – шигырьдә.
[11] Миһре фәридә – тиңдәшсез дус.

Хəлявəтдə бəңзəр канд Мисрə[1],
Рəваҗе булына та рузе хəшрə[2]».
..................................................
«Бу нəзымдəн Аллаяр мoрады[3]
Бəян əһле сөннəт игътикады[4]».

**«Фəзаил əш-шөһүр» китабы**

«Фəзаил əш-шөһүр» – татар арасында иң күп таралган китаплардан берсе. Бу китап ысулы кадим мəктəплəрендə «Иман шарты»ннан соң балаларга беренче дəрес китабы итеп укытыладыр иде. Безнең миллионарча ир вə хатыннарыбыз ничə буыннан бирле шушы китап өстендə тəрбиялəнгəннəр; меңнəрчə авыл остабикəлəренə, авыл хатыннарына вəгазь сөйлəр өчен ул кимемəс мəнбəгъ[5] булып хезмəт итеп килгəн һəм хəзер дə хезмəт итмəктə. Бу китап борынгы татар тормышы белəн шулкадəр үзлəшкəн иде ки, безнең җəдитчелəр, кадимлектəн көлəргə телəсəлəр, иске укыту вə иске тормышның тимсале[6], мөҗəссəме[7] итеп аны телгə алалар иде. Аның хисапсыз күп мəртəбə басылуы да никадəр татар арасында рəваҗлы[8] əсəр булганлыгын күрсəтəдер. Риза хəзрəт, бик хаклы буларак, аның мөхəррирен «Русия мөселманнарының гомуми остазы» дип атый.

Китапның үзендə мөəллифнең исеме һəм язылу тарихы күрсəтелмəгəн булуы аның хакында һəртөрле ялгыш фикерлəрнең тууына сəбəп булган. Мəсəлəн, аны нигə иснадəндер[9] Əлмəт авылының Габделҗəббар муллага нисбəт биргəннəр. Риза хəзрəт

[1] Хəлявəтдə бəңзəр канд Мисрə – Татлылыкта охшар Мисыр шикəренə.
[2] Рəваҗе булына та рузе хəшрə – Кыямəт көненə кадəр җəмəгать əйлəнешендə булсын.
[3] Морады – максаты, телəге.
[4] Бəян əһле сөннəт игътикады – сөннилəргə инануларны бəян итү.
[5] Мəнбəгъ – чыганак.
[6] Тимсале – образы.
[7] Мөҗəссəме – гəүдəлəнеше.
[8] Рəваҗлы – таралган.
[9] Нигə иснадəндер – нигəдер.

1898 елда чыккан «Рихләте әл-Мәрҗани» исемле китабында аның хакында «Болгар голәмасының[1] әсәрләреннән булырга кирәк», дигән бер фикер бәян иткән иде. Аның хакыйкый язучысын кәшеф итү дә[2] шул ук Риза хәзрәткә насыйп булды. Ун ел соң 1908 чыккан 15 нче җөзьә «Асар»да ул аның тәрҗемәи хәлен яза. «Рихләт»тә язылган хата фикерен күргәннән соң, «Фәзаил әш-шөһүр»нең язучысын белгән кешеләр аңар хакыйкать хәлне аңлатканнар. Бу китапның мөәллифе Казан губернасы Мамадыш өязе Шәдче[3] дигән авылның имамы Җәмаледдин бине Бикташи исемле бер мулла булган. Ул, Малмыж өязе Мәмәшир авылында туып, элек Көек авылының мәдрәсәсендә, аннан соң Мәчкәрәдә, аннан соң Чистайда укып, Шәдчегә мулла итеп тәгаен кылынган.

Җәмаледдин мулланың углы «Фәзаил әш-шөһүр»нең язылуы хакында түбәндәге мәгълүматны бирә: «Мәктәпләрдә балаларга укытырга төрки телендә җиңел китап булмаганга, Җәмаледдин хәзрәт, бер дәрес китабы язу фикеренә килеп, күптөрле вәгазь китапларыннан интихаб кылып[4], бер китап тәэлиф итеп[5], үз мәдрәсәсендә укыта башлаган. Бу китап мәдрәсәдә бик мәкъбүл булып китеп[6], шәкертләр аны үзләре өчен күчереп ала торган булганнар. Ихтимал ки, ул читкә, башка авылларга да язма нөсхәләрдә таралган булгандыр. Әлхасыйль[7], көннәрдән беркөнне әсәр Казан наширләреннән берсенең кулына төшеп, ул аны 1854 елда урта кул 64 битле, мөхәррире намәгълүм[8] бер китап шәкелендә[9] бастырып мәйданга куя. Китапның мөхәррире бу хакта бернәрсә дә белми кала. Басылган нөсхәсе кулына кергәч, ул китапның кыскартылып, яртысыннан күбрәге тө-

[1] Голәмасының – галимнәренең.
[2] Кәшеф итү дә – ачу да, билгеләү дә.
[3] Чыганакта: Шәтче.
[4] Интихаб кылып – сайлап.
[5] Тәэлиф итеп – төзеп.
[6] Мәкъбүл булып китеп – яхшы кабул ителеп.
[7] Әлхасыйль – нәтиҗәдә.
[8] Намәгълүм – билгесез.
[9] Шәкелендә – формасында.

шерелеп калдырып бастырылганлыгын күрә. Ләкин аны тулы итеп бастыру хакында һичбер тәшәббескә керелмәгәнгә[1], тәкрар[2] басмаларында да китап һаман шул кыскартылган килеш басыла бирә». Казан наширләре, аның кем тарафыннан язылганлыгын да белмичә, бер-бер иске китап дип уйлаганнар булырга кирәк. Җәмаледдин хәзрәтнең углы кулында булган кульязма исә басма «Фәзаил әш-шөһүр»гә караганда күп зур икән. Бу китапның мөәллифе хакында мәгълүмат бирүче икенче бер кеше аның яхшы гына гыйлем сахибы[3] булганлыгын һәм әсәрен имам Зәндусти тәэлифе[4] булган «Раузат әл-гыйльман» исемле китаптан алып язганлыгын сөйли. Ләкин Риза хәзрәт аның бу китаптан гына түгел, бәлки, углы әйткәнчә, берничә китаптан истифадә иткәнлеген[5] куәтли. Җәмаледдин хәзрәт 1873 елда вафат булган.

«Фәзаил әш-шөһүр» – дини вә әхлакый рухта язылган бер китап. Исеме «Айларның фазыйләтләре» мәгънәсендә булса да, аның мөндәриҗәсе моңар гына хассыр кылынмаган[6]. Ләкин мөндәриҗәнең җыелуында һәм тәртибендә һичбер төрле система юк. Ул берничә бабларга бүленә. Бабларның мөндәриҗәләре шушы: «Бисмилла»ның, «Лә иләһә илләллаһ» кәлимәсенең, биш вакыт намазның хасиятләре, юмартлыкның, сәдаканың, тәсбихның хасиятләре, төрле айларда нәфел уразасы тотуының савaплары, бәйрәм кичләрнең фазыйләтләре, сүз йөртү, гайбәт сөйләү, ир хакы, ата-ана хакы, изге баланың нинди булуы. Шуның арасына тагы кавын ашауның хасиятләре вә савaплары күк вактөяк мәсьәләләр дә катышып китә. Хасыйл[7], бу – типичный бер вәгазь китабы. Анда китерелгән әхлакый кагыйдәләр (мәсәлән,

[1] Тәшәббескә керелмәгәнгә – эшкә керешмәгәнгә.
[2] Тәкрар – кабат басылган.
[3] Сахибы – иясе.
[4] Тәэлифе – төзүчесе.
[5] Истифадә иткәнлеген – файдалануын, куллануын.
[6] Хассыр кылынмаган – карамаган, багышланмаган.
[7] Хасыйл – нәтиҗәдә.

хатыннарның ирләренә каршы булган вазифалары) безнең халыкның дөньяга карашына бик зур тәэсир ясаганнар.

«Фәзаил әш-шөһүр»дә асыл вәгазь-нәсыйхәт күп урын алмый, ул күбрәк төрле мөнәсәбәт белән китерелгән хикәяләр белән тулган. Алар – гадәттә, шундый китапларда була торганча, пәйгамбәрләр, сахабәләр[1], әүлияләр тормышыннан алынган кыска-кыска кыйссалар. Мөхәммәд пәйгамбәр сәйрәтеннән дә[2] анда байтак нәрсә бар; Гайсә пәйгамбәр дә күп хикәяләрдә роль уйный; Шәмсун (Самсон[3]) кыйссасы шикелле Тәүраттан[4] күчеп үзгәргән хикәяләр дә очрый.

Бу китап, гомумән, башыннан ахырына хәтле һәртөрле дини хорафат белән тулы. Татар арасында ислам динен, башын – түбән, аягын югары куеп, әһәмиятсез мәсьәләләргә зур әһәмият биреп, үзенчә, татарча аңлауны мәйданга китерүче гамилләрдән[5] берсе, шиксез, шушы китап булгандыр. Андагы мөбаләгаләр[6] искиткеч дәрәҗәдә. Бу китап буенча, юк кына эш (мәсәлән, мәгълүм бер көндә нәфел уразасы тоткан) өчен кешегә шундый зур саваплар багышлана ки, хәтта ул бәндәгә, гомере буенча бер дә башка гыйбадәт кылмыйча, гөнаһ кына эшләп торса да, җәннәтнең иң түренә кереп утырырга мөмкин булачак. Мәсәлән, Гарәфә көн ураза тоткан кешегә 240 000 ел бертоташтан ураза тоткан кадәр савап була; берәү шәгъбан аеның башында, уртасында һәм ахырында өчәр көн ураза тотса, аның гамәл дәфтәренә җитмеш пәйгамбәрнең савабын язалар, ул кеше җитмеш ел гыйбадәт кылгандай була, үлсә, шәһитләрдән китә. Гомумән, мөбаләгаләр бу китапта чын-чын шәрык ысулында; мисал өчен Гарешнең[7] тасвирын китерергә мөмкин: «Риваять кылынды Аллаһы Тә-

[1] Сахабәләр – Мөхәммәд пәйгамбәрнең замандашы булып, аны күргән кешеләр.

[2] Сәйрәтеннән дә – сәяхәт итүеннән дә.

[3] Кирилл хәрефләре белән язылган.

[4] Тәүраттан – яһүдиләрдә Муса пәйгамбәр китабы.

[5] Гамилләрдән – эшчеләрдән.

[6] Мөбаләгаләр – арттырулар.

[7] Гареш – күкнең иң югары катлавы, дин буенча, Алла тәхете урнашкан иң югары тугызынчы кат күк.

галә Гаршене яратды, яшел җәүһәрдин ул Гаршенең мең мең дә алты йөз мең (1 600 000) башы вардыр, һәрбер башында мең мең дә алты йөз мең йөзе вардыр, һәрбер йөзе дөнья кадәре мең мең дә алты йөз мең кадәрдер, һәр йөзендә мең мең дә алты йөз мең агызы вардыр, һәрбер агызда мең мең дә алты йөз мең теле вардыр һәрбер теле берлә мең мең дә алты йөз мең лөгать илә тәсбих әйдер». Димәк, Гарешнең бөтен телләре белән берьюлы әйтә торган тәсбихләренең санын язар өчен 32 галәмәттән гыйбарәт булган бер рәкым[1] кирәк булыр иде!

«Фәзаил әш-шөһүр» саф татарча диярлек җиңел тел белән язылган. Гарәп-фарсы сүзләре, чыгтай вә госманлы тәэсире анда бик аз. Хәтта, аның кайвакытта нинди мохиттә язылуын игътибарга алганда, теленең шулкадәр асат булуына гаҗәпләнергә туры килә. Өслүбе[2] дә зарарсыз гына төзек. Һәрхәлдә, Җәмаледдин мулла халык өчен язылган китапларның халыкның үз телендә булуы тарафында булган булырга кирәк. Аның әсәренең тиз арада бөтен татар арасына таралып, иң мөстәгъмәл[3] китаплардан булып китүенең сәбәбе дә – шөбһәсез, теленең җиңеллегедер.

## Хикәят китаплары

Әдәбиятыбызның борынгылык дәверендә халык кулында йөргән бер такым[4] китаплар бар – аларны, «Тутыйнамә», «Кырык вәзир» тибындагы мөрәккәб[5] җыентык хикәяләрдән аеру өчен, «хикәят китаплары» дигән исеме гам[6] астына җыярга мөмкин. Тегеләрен без шулай ук ихтыяри рәвештә интихаб ителгән[7] «кыйсса китаплары» дигән исем астына алып тикшергән идек.

[1] Рәкым – цифр, сан.
[2] Өслүбе – стиле.
[3] Мөстәгъмәл – кулланылган.
[4] Такым – төркем.
[5] Мөрәккәб – җыелган.
[6] Исеме гам – гомуми исем.
[7] Интихаб ителгән – сайлап алынган.

Болар – Борынгы Шәрык хикәяләре тибында нәсер белән язылган кыска-кыска хикәяләр, зурлыклары кечкенә кулда 16 бит белән 64 бит арасында. Шуның өчен аларны «кечкенә хикәяләр» яки «вак хикәяләр» дип тә атарга мөмкин булыр иде, ләкин югарыдагы тәгъбир безгә уңайлырак тоелды. Бу төрле хикәяләр бездә, күбесенчә, кечкенә кулда басылганнар.

Гадәттә, бу хикәятләрнең мөхәррирләре вә кайдан алганлыклары аларның үзләреннән мәгълүм булмый. Аларны язучылар вә күчерүчеләр үзләренең эшләгән эшләрен шундый әһәмиятсез нәрсә дип уйлаганнар ки, китапның башында булсын, ахырында булсын, бу турыда берәр сүз язарга кирәксенмәгәннәр дә, алар бары тик «Равиләр[1] андаг риваять вә мондаг хикәят идәрләр кем...» дип башлап китү белән канәгатьләнгәннәр. Хикәят китаплары әдәбиятның безнең арада соңрак таралган формаларыннан булырга кирәк. Аларның иң беренчесе – мәшһүр «Мәликә китабы» – 1846 елда басыла. Исеме «Бер залим гаярь вә галим казый...» дип башлана торган хикәя – 1857, «Дөхтәре солтане Кәшемир» 1871 елда басыла. 90 нчы елларда хикәят китаплары күбрәк чыга башлый. Соңгы заманнарга якынлашкан саен алар өслүб вә мөндәриҗә[2] ягыннан бозыла баралар, турыдантуры «Әлфе ләйлә» дән алынып бастырылган хикәяләр, төркичәдән тәрҗемә кылынып, өстенә мөтәрҗимнең[3] исеме куелганнары да очрый башлый. Мәсәлән, XIX һәм XX гасырның чигендә шундый хикәяләрне мәйданга кую белән шөгыльләнүче Шиһабетдин Рәхмәтуллин исемле бер язучы да килеп чыга. Бу кеше госманлы әдәбиятында саннары бик күп булган шул тип хикәяләрне татарчага тәрҗемә итә. Аның тәрҗемәләреннән «Тиярзадә» («Тыярзадә») – 1900 елда, «Колуфе бәләдиләрә гашыйкларның хикәяте» – 1901 дә, «Каләф белә Турандык хикәяте» 1903 тә басыла. Бу зат үзенең татар әдәбиятында тоткан урыны белән Каюм Насыйри, Фатих Халиди тибындагы

[1] Равиләр – хикәятчеләр.
[2] Мөндәриҗә – эчтәлек.
[3] Мөтәрҗим – тәрҗемәче.

язучылар рәтенә тезелергә тиеш. Ул да – алар шикелле, бер ягы белән Борынгы Шәрык рухындагы әдәбиятка тоташса, икенче ягы белән уяну дәверенә тоташкан язучылардан.

Шулай итеп, 1905 елларга, яңа әдәбиятыбызның куәт алган дәверенә кадәр, мондый борынгы типтагы Шәрык хикәяләре чыгуда дәвам итәләр. Яңа әдәбиятның көчәюе, нашир вә язучыларның, шулай ук укучыларның да Яурупа тарызындагы[1] тормыштан алынган әдәбиятка бирелеп китүләре белән аларның модасы бетә: бәгъзылары тәкрар басылуда дәвам итсәләр дә, «Мәликә китабы» шикелле электән бирле халык арасында таралганнары гына яңадан басылалар.

Мөндәриҗә ягына килгәндә, бу хикәятләр Шәрыкта махсус үзенә бер төрле әдәби жанр тәшкил итәләр. Алар, күбесенчә, Шәрык гадәтенчә, һәр төрле гаҗаиб гарәиб эшләр белән тулган булып, «Әлфе ләйлә вә ләйлә» хикәяләренә охшыйлар. Бәгъзылары, мәсәлән, 1893 елда басылган «Әбелкасыйм хикәясе» нәкъ «Әлфе ләйлә» хикәяләреннән берсе төсле. Аның каһарманнары – Һарун әр-Рәшид, Җәгъфәр Бәрмәки һәм бик бай вә юмарт Бәсра сәүдәгәре Әбелкасыйм. Шулай ук турыдан-туры госманлыча «Әлфе ләйлә»дән татарчага тәрҗемә ителеп, аерым хикәят итеп бастырылганнары да юк түгел. Мәсәлән, «Җәүдәр», «Шаһмаран» вә «Кызлар хикәяте» шикелле.

Безнең хикәят китапларында, күбесенчә, укучыны гайрәтләндерү яисә бер-бер нәрсәгә өндәү төп максат итеп куелган булмый, «кыйссадан хисса» чыгарылып, хикәят бер-бер әхлакый кагыйдәне исбат итәргә керешми, әлхасыйль, аларны язучылар халис[2] әдәби максатларны күз алдында тотып (укучының күңелен ачар өчен яки күздән яшь китерер өчен генә) язганнар. Шәрык өчен бик характерлы булган гыйбрәтле хикәяләр белән беррәттән, Шәрык әдәбиятларында бу төрле хикәяләр дә күп очрый, аларга классик мисал итеп шул ук «Мең дә бер кичә»дә җыелган хикәяләрне китерергә мөмкин. Бездә нәшер

[1] Тарызындагы – рәвешендәге.
[2] Халис – чын, чиста.

ителгән хикәятләр арасында гыйбрәт өчен язылганнары күп түгел. Андыйларның иң игътибар итәрлекләре – 1857 елда басылган «Бер залим, гаярь вә галим казыйны Хак Тәгалә бер галим угрының кулына гөрифтар кылып, күп дәлилләр берлә казыйны рисвай җиһан кылган кыйсса торыр» дигән хикәя белән «Егет кешегә йитмеш төрле һөнәр аз дигән сүз раст сүз» аталган хикәядер. Гомумән, хикәят китаплары арасында шундый ифрат озын исемлеләре очраштыргалый.

Бу хикәяләрнең беренчесенең мөндәриҗәсе исеменнән үк күренеп тора. Анда, ялгыз ишәккә атланып бара торган бер казыйга бер карак очрап, аны таларга хаклы булуы хакында казый белән моназарага керешә. Һәр ике як аять вә хәдисләрдән дәлилләр китерәләр. Ахырысында карак казыйны мөлзәм кылып[1], җаваптан гаҗиз итеп, баштанаяк чишендереп, ишәген дә алып, җәяү һәм ялангач килеш өенә кайтарып җибәрә. Карак шул дәрәҗә оятсызлыкка барып җитә – икенче көнне үзе казыйның йортына барып, аның хатынының да үзенә тиеш булуын дәгъва кыла башлый. Гаҗиз булган казый, бөтен малын биреп тә, каракның тәсәллытеннән[2] котыла алмый. Ахырысында (бу карак изгеләрдән икән) казыйның бөтен малын үзенә кайтарып биреп, моннан соң дөрес хөкем итәргә, ришвәт алмаска, риба һәм ятимнәр малын ашамаска кушып, үгетләп, үз юлына китә.

Икенче хикәяттә Габдулла исемле Бохара сәүдәгәренең Әмин исемле углы атасының үзенә сату итәргә сумма башы итеп биргән акчасын, төрле шәһәрләргә барып, төрле һөнәрләр өйрәнүгә сарыф итә. Бу һөнәрләр: скрипка уйнау, мәшкый[3] язу һәм шәтранҗ[4] уены. Менә шушы һөнәрләрне елына меңәр сум биреп, патша уллары гына өйрәнәләр икән. Әмин бай шуларны өйрәнү һәвәсенә кереп, сәүдә итүдән ваз кичеп, шул юлда атасының бөтен төп суммасын бетерә. Аталары, әлбәттә, улла-

[1] Мөлзәм кылып – бәхәсләшеп җиңеп.

[2] Тәсәллыт – берәүне үз биләвенә алып, аның өстеннән үзе теләгәнчә хөкем итү.

[3] Мәшкый – каллиграфик.

[4] Шәтранҗ – шахмат.

рының болай булып чыгуына бик кайгыралар. Аның өйрәнгән һөнәрләре бу Шәрык мещаннарына бер тиенлек файда китерми торган эшлексез кешеләргә генә махсус булган һөнәрләр булып күренәләр. Дәрвакыйг[1], Әмин башта бу һөнәрләре белән үзенә киченерлек акча таба алмый. Ахырысында алар тәмам фәкыйрьлеккә төшәләр. Менә бер заманны, иттифакы туры килеп, Әминнең өйрәнгән һөнәрләре эшкә ярап куя. Кәрван белән барганда, иптәшләре аны бер ташландык коега ташлап китәләр. Кое төбендә яшәүче диюгә скрипка уйнавы аркасында ул коедан котыла; үзен үтертергә язылган хатны, язуга osталыгы аркасында, яңадан үзгәртеп язуы белән ул икенче тапкыр үзен үлемнән коткара; ахырда, шәтранҗ уйнарда мәһарәте[2] аркасында бер мәмләкәтнең патшасының кызын алып, үзе патша була. Хикәятнең ахырында түбәндәге сүзләр язылган: «И укучылар, яшь егетләр, яшь вакытыгызны бушка үткәрмәгез, ничек булса да һөнәр өйрәнегез, һич булмаса да лом, икнә[3] берлән кодык казыңыз, суы чыксын, эш – коралында түгел, болында кодыкдан су чыкса, лом берлән казыган суны эчмәймез, димәсләр һәм ни берлән казыдың, дип сорамаслар, суы яхшы булсын, әйтерләр суы яхшы, дип».

Төп идеаллары гыйбрәт булмаган хикәят китапларын, башлыча, ике төрле типка бүләргә мөмкин. Беренче тип хикәятләрдә, гадәттә, бер патшаның бик билгеле кызы була. Үзен кияүгә сораучы егетләргә ул табышмак шикелле җавап бирүе авыр булган сөальләр тәкъдим итә, җавап бирә алмаганнарның башын кистерә. Бик күп кешеләр – шаһзадәләр, галимнәр, хәкимнәр – кызны алырга теләп имтиханга керсәләр дә, сөальләргә җавап бирә алмый башлары киселә тора. Ахырда хикәянең каһарманы дөрес җавап биреп, мәгърур кызны алырга муаффәкъ була[4]. Бу мәүзуг Шәрык дөньясында бик борынгы заманнарда ук ясалган

[1] Дәрвакыйг – чыннан да.
[2] Мәһарәте – осталыгы.
[3] Икнә – энә.
[4] Муаффәкъ була – ирешә, лаек була.

булырга кирәк, чөнки легендаларда Саба мәликәсе Бәлкыйснең дә Сөләйман патшага шундый читен сөальләр биреп, Сөләйман аларга җавап биреп, Бәлкыйстән бик күп мал вә хәзинә отып алганлыгы сөйләнә. Югарыда сөйләнгән типтагы хикәяләрдән мәшһүр «Каләф белән Турандык» хикәясе дә – Шәрыкта бик таралган мәүзуг[1]. Мондый хикәятләрдән безнең татар арасына кереп иң таралганы – «Мәликә китабы». Ул – бездә иң элек басылган хикәят китапларыннан. Кирәк өслүб, кирәк мөндәриҗә ягыннан 16 битле бу кечкенә рисаләнең һичбер төрле әдәби кыйммәте юк. Аның мөндәриҗәсе бик садә: Рум шәһәрендә Малик дигән бер патшаның Мәликә исемле бик галимә кызы була. Ул үзен хатынлыкка алырга теләгән кешеләргә йөз сөаль тәкъдим итүне шарт итеп куя, җавап бирә алмаганнар шарт буенча асылалар. Шул арада Төркестаннан килгән Хәлим исемле бер фәкыйһ, һәммә сөальләргә дөрест җавап биреп, кызны ала. Кызның биргән сөальләре күбрәк дини мәүзугта, схоластикага гаид мәсьәләләр хакында. Мәсәлән: «Кыз сорды: «Комугдин борын ни шәйне яратты?» Фәкыйһ әйде: «Кяф илә нунны яратты». Кыз әйде: «Кяф илә нун нә кылгучы торыр?» Фәкыйһ әйде: «Күн фәякүн кылгучы торыр». Кыз сорды: «Җефетләрдә кайу җефетне яратты?» Фәкыйһ әйде: «Тәблит-Җәблит атлыг кем ирсәне яратты, беренең койрыкы елан дик вә янә беренең койрыкы җыян дик, икесен җефет кылды». Кыз сорды: «Шайтанның ата-анасы кайу торыр? Фәкыйһ әйде: Тәблит-Җәблит торыр». Кыз сорды: «Кайу намаз торыр күкдин иңде, йиргә тимәде?». Фәкыйһ әйде: «Ул җеназа намазы торыр». Кыз сорды: «Дәрьяларның асылы нә торыр?» Фәкыйһ әйде: «Нух туфаны торыр...». Гомумән, бу сөальләр Робгузиның «Кыйссас»ында төрле җирдә чәчелгән сөаль вә җавапларны хәтергә төшерәләр. Хәтта бер үк сөальләр тегендә дә, монда да очрыйлар. Менә шуңар карaганда, шулай ук теленең чыгтайчага тартымлыгын, аннан соң хикәянең каһарманының Төркестан галиме булуын искә алганда, «Мәликә китабы»ның асылы Мәвараэннәһердән килмәдеме

[1] Шиллер бу мәүзугны пьеса хәлендә эшләп чыгарган. *(Авт. иск.)*

икән дип уйларга мөмкин. Ул мөндәриҗә ягыннан да Төркестан халкы кулында йөри торган һәртөрле «рисалә»ләргә беркадәр охшый. «Мәликә китабы»ның кем тарафыннан һәм кайчан язылуы китапның үзендә әйтелмәгән. Ул – татар арасында йөри торган хикәятләрнең иң борынгы тел белән язылганнарыннан, бу – безнең халыкта бик мәкъбуль бер китап, хосусан, хатын-кыз аны укучан.

Андагы бәгъзы хорафат халык гаммәсенең аңына да кереп өлгергән. Мәсәлән, төрле хайваннарның төрле гөнаһлы кешеләрдән азган булулары хакындагы халык арасында бик таралган игътикад[1] шушы китап тәэсирендә мәйданга килгән. Бу китап буенча, 23 төрле хайван элек кеше булганнар, гөнаһлары өчен Алла аларны хайван сурәтенә куйган: «Төя бер кеше ирде – пәйгамбәрдин гизләнде[2], аю бер кеше ирде – бәни Исраил кавемендә хәрамилык кылыр ирде, мәймүн бер кеше ирде – Гайсә галәйһиссәламгә ышанмады, дуңгыз бер кеше ирде – хәрәмхур[3] ирде, төлке бер кеше ирде – угрылык кылыр ирде, үрмәкүч бер кеше ирде – мәккярә,[4] канәгатьсез хатын ирде, качыр бер кеше ирде – артык алып, ким бирер ирде. Ташбака бер кеше ирде – артык үлчәп алыр ирде, ким үлчәп бирер ирде, тутый бер кеше ирде – вөҗүден халыкга күрсәтер иде, сычкан бер кеше ирде – күп сүзләр ирде, фил бер кеше ирде – надан бай ирде...»

Икенче төрле тип хикәятләрнең төп мәүзугысы болай була: бер патшаның бер дә баласы булмый, Ходайдан күп тели торгач, яки бер-бер изге, я хәким тарафыннан өйрәтелгән чараларына керешкәч, картайган көнендә аның бер кызы, я углы дөньяга килә. Үсеп җиткәч, бу кыз яки егет берәүгә гашыйк булалар. Бөтен хикәя менә шушы гыйшык өстенә нигезләнә. Ике гашыйкка тыныч кына кавышырга тәкъдир язмаганга күрә,

[1] Игътикад – ышану.
[2] Гизләнде – качты.
[3] Хәрәмхур – хәрәм ашаучы.
[4] Мәккярә – хәйләкәр.

аларның башларыннан бик күп мажаралар, бик күп читенлекләр вә бәлаләр уза, үз-үзләре сөймәгән башка кешеләр аларны гыйшыклары белән җөдәтәләр. Күп вакыт алар үлемнең чигендә генә калалар, хәтта, үлгәнгә саналып, каберләргә күмеләләр. Бәгъзан, бу җәфалар кызның башына тәкәбберлеге, үзенә тиң белмәве аркасында киләләр («Җәүһәр таҗ», «Дөхтәре солтане Кәшемир»). Ләкин ничек кенә булмасын, ахырда һәммә бәлаләр яхшыга әверелеп, хикәят дошманнарның һәлакәте, гашыйк белән мәгъшукның кавышуы, аларның туйлары, бәхет-сәгадәткә ирешүләре белән тәмам була.

1871 елда басылган «Хикәяте дөхтәре Кәшемир» исемле 24 битле китап мондый мәүзугтагы хикәятләр өчен мисал булырлык. Ул югарыда сөйләнгән гомуми калыпка тәмамән туры килгәнгә, мөндәриҗәсе хакында аерым сөйләп торырга да хаҗәт юк. Аның өслүбе матур һәм тасвири, теле яхшы ук, борынгы татарча тәэсире ул кадәр зур түгел, бу хикәятнең асылы Төркиядән килгән булырга кирәк, чөнки гомумән, бу төрле хикәяләрнең чын оясы – госманлы иле, аның телендә дә госманлы тәэсире көчле булуы шуңар дәляләт[1] итә. Хикәят китаплары арасында иң бозылмый саклангany – шушы китаптыр.

Әмма аларның яңа заман тәэсире белән бозылганнарына мисал итеп намәгълүм[2] бер мөәллифнең 1890 елда басылган «Хикәяте мәгъриб зәминдә[3] Бәскяр шәһәренең ишан шәех Насретдин әфәнде» исемле хикәясен китерергә мөмкин. Бу хикәят үзе Борынгы Шәрык хикәяләре формасында язылса да, анда Шәрык белән Яурупа бик кызык рәвештә буташтырылган. «Кадим заманда мәгъриб тарафында Бәскяр дигән шәһәрдә бер патша бар ирде. Исмия Габделмәлик дирләр ирде...» дип башлана торган бу хикәяттә, мәсәлән, Париж шәһәрендә тора торган француз короле һәм аның улы Бернард мәйданга чыгалар. Корольнең кызы исә Мәликәи Әбризә атлы була (бу исем,

[1] Дәляләт – дәлиллек.
[2] Намәгълүм – билгесез.
[3] Мәгъриб зәминдә – көнбатыш җирлегендә.

шөбһәсез, «Әлфе ләйлә»дән урланган). Хикәяттә туплар атып сугышалар, пароходларда сәяхәт итәләр. Хәтта телеграмм белән хәбәрләшәләр. Аннан соң бу китапта яңа әдәбиятыбызның әүвәлге елларына хас булган мораль сату, әхлактан дәрес бирү дә юк түгел.

Тәмәке тарту, хәмер эчү шикелле «ислам тыйган» эшләрнең зарарлары хакында китерелгән гаклый дәлилләр – нәкъ шул безнең исламиятне мәдәният вә фәнгә татбикъ кылучы[1] мөтәфәлсифләребез өслүбендәге әйберләр. Бу хикәянең мөәррихе, төрек китаплары укып, шулар тәэсирендә язган булырга кирәк. Һәрхәлдә, бу китап – иске әдәбиятның, яңа заман җилләре тәэсире астында бозылып, үз эченнән үзе чери башлаганын күрсәтә торган бик ачык бер мисалдыр.

Хикәят китапларының тел вә өслүбләре бер генә төрле түгел. Гомумән алганда, аларның теле татарча: ләкин 9 нчы елларга кадәр басылганнарында чыгтай һәм госманлы телләренең тәэсире күбрәк, әмма бу тәэсир асыл телнең татарча булып калуына зыян итәрлек дәрәҗәдә түгел. Һәрхәлдә, аларның теле безнең борынгы гарәп, фарсы, чыгтай, госманлы вә татар телләренең катышуыннан хасил булган классик әдәби телебезгә караганда шактый садә вә татарчарак. Гомумән, борынгы әдәби телебездә булганча, чыгтай вә госманлы тәэсире кара-катыш булса да, кайбер китапларда – чыгтай, кайберсендә госманлы теле куәтлерәк хөкем сөрә[2]. Бу – кайсы китапның асылы кайсы телдән алынганлыгына дәлаләт итә торган бер факт дип уйлыйбыз, чөнки, шиксез, бу хикәяләр – татар багыннан уйланып чыгарылган әйберләр түгел, бәлки тәрҗемә ителгән яки, һич булмаса, мәүзуглары алынып үзгәртелгән әсәрләрдер.

Соңгы заманнарга якынлашкан саен, хикәят китапларының теле җиңеләя, татарчалаша, чит телләр тәэсиреннән чыга бара: шулай итеп, борынгы сүзләр, иске формалар, чыгтай

[1] Татбикъ кылучы – яраклаштыручы.

[2] Мәсәлән, «Мәликә» китабында – чыгтай, «Дәхтәре солтан Кәшемир»дә госманлы тәэсире күбрәк. *(Авт. иск.)*

вә госманлычалыклар, бөтенләй үк бетмәсә дә, юк диярлек дәрәҗәдә азаялар. Борынгы гадәт буенча, чыгтай белән госманлы имласы арасындагы бер имла белән, нокта вә галәмәтсез язылган бу әсәрләрнең татарчасы – тел вә лөгать ягыннан саф татарча булса да, грамматика ягыннан караганда, әле ул эшләнмәгән, бәлки, эшләнү дәверендә булган тел. Аларның өслүбе әле безнең XX гасырда туган яңа әдәбиятыбыз өслүбенә бөтенләй башка: ул әле ямьсез, чыгышсыз. Безнең борынгы язучыларыбыз, «тупас тел, урам теле» дип, татарча язудан юкка качмаганнар бит! Чынлап та, әле ул чакларда татар теле «урам теле», ягъни сөйләшү теле генә булган, әдәби тел дәрәҗәсенә ирешмәгән. Мәгълүм ки, сөйләшкәндә, халык игътибарсыз сөйләшеп, һәрвакытта грамматика ягыннан хаталар ясый: хосусан, бу нәхү ягыннан караганда шулай. Сөйләшкәндә, кеше җөмләләрне тәмамән нәхү кагыйдәләренә туры китереп сөйләми. Шуңар күрә һәрбер халыкның сөйләшү теле, шул ук халыкның язу өчен махсус булган кагыйдәләргә туры китереп тәртипкә куелган, «эшләнгән» әдәби теленә караганда, һәркайчан азмы-күпме аермалы була.

XIX гасырның ахырларына кадәр безнең татар теле бары сөйләшү теле генә булган, ул телдә язсалар да, ничек теләсәләр – шулай. Ничек туры килде – шулай, ягъни сөйләшкәнчә яза биргәннәр. Бу яктан аларга бары тик чыгтай вә госманлы әдәби традицияләре генә киртә булып килгән. Фәнни яктан карап, татар теленең кагыйдәләрен, грамматикасын тикшерүче, аны бер тәртипкә китерүче булмаган. Кайбер мөстәшрикъ яки миссионерлар яисә хәлифәләр шикелле үз арабыздан чыккан бәгъзы бер затлар бу юлда эшләсәләр дә, аларның хезмәтләренең җимешләре, руслар өчен генә булып, руслар арасында гына калганга, үз әдәбиятыбызга тәэсир ясый алмаганнар.

Кыскасы гына, татар телен әдәби тел хәленә кертер өчен, аны акрын-акрын «эшләр» өчен, бу телдә яза башларга кирәк булган. Җәдиди язучыларның, чын мөсаннифларның[1] истихфафлы[2] күз

[1] Мөсаннифларның – китап төзүчеләрнең.
[2] Истихфафлы – мыскыллы.

карашлары, мыек астыннан елмаюлары астында, җөрьәт итеп, халык өчен халык телендә хикәят китаплары язарга керешкән исемсез, намәгълүм вак-төяк язучылар – менә шулар безнең хәзерге әдәби телебезнең чын фидакярләре.

Шулай да Мәрҗани шикелле зур мөсанниф, үзенең авторитетына таянып, «Мөстәфад әл-әхбар» күк җитди бер китабын татарча язып (яки язарга тырышып), безнең арада үз телебезнең рәсми әдәби телләр рәтенә керүенә ярдәм итмәсә, Насыйри шикелле тырыш бер язучы гомере буе татарча язып, татар теленең грамматика вә лөгатьләрен тәртипкә салмаган булса иде, кем белә, ихтимал, хәзерге әдәби татар теленең мәйданга килүе тагын бераз вакытка кичеккән булыр иде.

Дәрвакыйг[1], XIX гасырда безнең татар теле әле чын мәгънәсе белән «урам теле» иде. Ул телдә җитди бер нәрсәне язып аңлату, тирән фикерләр бәян итү мөмкин түгел, чөнки кирәк кагыйдә, кирәк өслүб ягыннан булсын, ул нык бер дисциплина астына алынган иде әле. Шуның өчен дә Мәрҗани, никадәр принцип ягыннан татар телендә язуның тарафдары булса да, «Мөстәфад»ны саф татарча итеп чыгара алмады, бары тик бу китапның тормышка иң якын булган, анекдот характерындагы урыннары гына чын татарча булып чыктылар. Хәтта нәзари яктан татар телен эшләгән, аны нәзек аңлаган Каюм Насыйри да, гамәлияткә күчкәч, шул эшләнмәгәнлекнең бәласен күрде: аның үз өслүбе дә кытыршылыклардан хали булмады. Шуңар күрә дә татар теле башта әдәбиятның хикәяләр, кыйссалар бүлегендә нык оя ясады, чөнки бу төрле әдәбият голәма өчен түгел, бәлки гавам өчен, киң халык массасына уку материалы итеп языла һәм нәшер ителә. Шунлыктан аның халык теленә иң якын булган бер телдә булуы һәм матлуб[2], һәм табигый иде. Шулай итеп, хикәят китаплары әдәби татар теленең барлыкка килүе юлында бер күпер, бер баскыч ролен уйнадылар.

[1] Дәрвакыйг – дөрестән дә.
[2] Матлуб – таләп ителгән.

Татарча язылган хикәят китапларында бигрәк тә аларның соңгыракларында без тәмамән бер тел башбаштыклыгы, өслүб вакханалиясе хөкем сөргәнлеген күрәбез. Бер яктан, грамматика ялгышлыгы, төрле дәрәҗәдә булган чыгтай вә госманлы тәэсире булса, икенче яктан, тантаналы шәрык өслүбе белән янәшә үк чикылдаган (вульгарный) татарча җөмләләрнең, Печән базары, Тегәрҗеп урамы һәм Яңа Бистә тәгъбир вә гыйбарәләренең очравы күзгә бәреләә. Шулай ук 90 нчы елларда һәм соңрак язылган хикәятләрдә русча тәэсире дә күреләә башлый. Безнең сөйләшү телебезгә бик күп гарәп-фарсы сүзләре белән бергә, заманның озынлыгы белән, әлбәттә, байтак кына рус сүзләре дә кергән. (Мин, әлбәттә, русча укыган зыялылар сөйләшә торган телне түгел, бәлки халык сөйләшә торган телне әйтәм). Без хәзер яңа әдәбиятта рус теле тәэсиреннән, рус сүзләре истигъмаль итүдән мөмкин булган кадәр билкасд[1] качарга тырышабыз. Борынгы әдәбиятта исә рус сүзләре бөтенләй үк катыштырылмаган, әмма безнең «урам телендә» язучы-кыйссачыларыбыз халык телендә йөргән рус сүзләрен, бер дә тукталып тормыйча, үзләренең китапларына тутыра биргәннәр. Бу русча тәэсирнең ни дәрәҗәдә булуын күрсәтү өчен 90 нчы елдан алып 93 нче елга кадәр чыккан берничә хикәят китабыннан чүпләнгән русча сүзләрне күчерәбез. Король, дворец, карета, кучер, кораб, пароход, кают, капитан, матрос, астроном, адъютант, план, совет, форма, карта, кантор, расход, отель, копеек, богодельня, корпус, подвал, свод[2] вә башкалар. Менә болар – тәсадефи[3] сайланган сүзләр, шундый чеп-чи рус сүзләре – безнең хикәят китапларында «кудук» шикелле иске чыгтай сүзләре белән янәшә үк истигъмаль ителәләр.

---

[1] Билкасд – алдан уйлап.
[2] Кирилл хәрефләре белән язылган.
[3] Тәсадефи – очраклы.

## «Таһир илә Зөһрә» һәм «Бүз егет» кыйссалары

«Кыйссаи Таһир илә Зөһрә» һәм «Кыйссаи Бүз егет» аталган ярым нәзым, ярым нәсер белән язылган гыйшкый поэмалар безнең халыкның тәмам йөрәгенә кергән, канына сеңгән әдәби әсәрләрдән. Бу кыйссаларны бөтен татар авылларында укыйлар, көйле кисәкләрен үзенә махсус көйләргә салып көйлиләр. Һәрбер укый белүче булган авыл өендә бу китапларның берәр нөсхәсен табарга мөмкин. Меңнәрчә абыйстайлар вә әбиләр бу гашыйкларның фаҗигалы язмышлары өстендә күз яшьләрен түккәннәр, меңнәрчә гыйшык тотучы дәртле яшьләр, аларның саф гыйшыкларыннан илһам алып, аларны үзләренә мисал итеп, шулар төсле сөешергә тырышканнар. Аларның сурәтләре безнең халыкның аңына шулкадәр нык кереп урнашкан ки, «җан Таһир»лар, «җан Зөһрә»ләр, «Бүз егет»ләр чын мәгънәсе белән татарның милли гыйшык каһарманнарына әверелгәннәр.

Әгәр дә без «Таһир илә Зөһрә»нең 1879 елда язылуын, «Бүз егет»нең беренче мәртәбә 1876 елда басылуын искә алсак, аларның шулкадәр тиз арада халык арасына таралып, халык белән үзләшеп, бөтен татарның кулыннан төшерми укый торган китапларына әверелеп китүләре искиткеч бер эш төсле тоела. XIX гасыр актыкларында ук татар халкы, татар тормышы белән өзелмәслек булып бәйләнгән бу китаплар хәзер безгә, әйтерсең, халыкның үзе белән бергә дөньяга килгән төсле тоелалар. Һич булмаганда, аларның халык арасында йөрүен йөз еллар белән хисаплыйсы килә. Шуның өчен дә, бу китапларның тарихлары белән танышырга кызыксынып, аларны тикшерү касды[1] белән беренче мәртәбә кулына алган кеше «Таһир илә Зөһрә» китабының ахыргы битендә язылган шушы сүзләрне күреп бераз аптырып кала: «Имди мин фәкыйрь пир тәкъсыйр бу хикәяте гаҗибәне госманлы тәварихларыннан[2] күреп, җиңелрәк телемез нугай вә казакъ лөгатенчә чыгарып, «Бүз егет» нам нөсхәмез кеби мин әүвәлиһи илә ахриһи[3], тасхих вә мокабәлә

[1] Касды – теләге.
[2] Тәварихларыннан – язмаларыннан.
[3] Мин әүвәлиһи илә ахриһи – башыннан алып азагына кадәр.

кылып[1], иҗаз тарикынча[2], бер-ике телгә[3] тасниф кылдым[4]. Фәкыйрь мелла Әхмәд мелла Мөхәммәдзариф углы Уразаев әл-Кызылҗари әл-Кормаши. Максудымыз бәлки үземездәй бүз балалар һәм олуг ага-энеләр укып хушнуд[5] булып, мәзкүр фәкыйрьне догаи хәер илән яд кылмаслармы[6] дип өмид кылганым бу гашыйкларның рухлары өчен бер фатиха өмид илә тасниф кылды фи сәнәи 1879 карьяи Күшәрдә вә әлһәмдүлилләһи раббил-галәмин».

Менә бу ике китапның язылу тарихлары, аларны язучының тәрҗемәи хәле белән танышу өчен безнең кулда булган бердәнбер материал шушы. Димәк, аларны язган кеше – Әхмәд Уразаев исемле бер татар мулласы. Ул, Кормаш авылында туып, Казан өязе Күшәр авылында имам булган булырга кирәк. Һәрхәлдә, «Таһир-Зөһрә» Күшәрдә язылган. Мөәллиф аны госманлыча китаплардан алып татарчалаштырган. Бу коры тәрҗемә генә булмаска кирәк, чөнки ул хатимәсендә[7] бу китапны башыннан ахырына кадәрле тасхих вә мокабәлә кылганлыгы хакында сөйли. Күренә ки, ул берничә госманлыча нөсхәне алып, аларны бер-берсе белән чагыштырып, үзенчә дөресләп язып чыгарган. Татарчасы басылып чыкканчыга кадәр безнең татар арасында Истанбул басмасында «Таһир илә Зөһрә»нең берничә төрле нөсхәсе укылып йөргәне мәгълүм. Мондый нөсхәләрдән берсе безнең кулыбызда бар. Асыл китапны «Гашыйк гариб» хикәясе тәшкил итә. «Таһир илә Зөһрә хикәясе» китапның читенә (хашиясенә) басылган. Бу китап, шул типтагы бик күп госманлы телендәге хикәя китаплары шикелле, сары кәгазьгә ташбасма белән табигъ кылынган[8]. Эчендә («Гашыйк Гариб хикәясе»нә махсус) бик каба[9] ясалган рәсемнәр бар. Бу нөсхәдәге «Таһир-

[1] Тасхих вә мокабәлә кылып – төзәтеп һәм чагыштырып.
[2] Иҗаз тарикынча – кыскартып.
[3] Бер-ике телгә – дөресе: «бу ике телгә» булырга кирәк. *(Авт. иск.)*
[4] Тасниф кылдым – яздым.
[5] Хушнуд – шат, риза, канәгать.
[6] Яд кылмаслармы – искә төшермәсләрме, хәтергә китермәсләрме.
[7] Хатимәсендә – ахырында.
[8] Табигъ кылынган – басылган.
[9] Каба – начар, ямьсез.

Зөһрә» хикәясе бик кыска, 48 битле китапның бит кырыйларына гына басылган. Аннан соң безнең икенче шундый ук типтагы «Таһир-Зөһрә» хакында ишеткәнебез бар. Бу нөсхә ташбасмада, рәсемле, шактый калын икән. Ләкин, мәгаттәәссеф[1], бу нөсхәне кулга төшерә алганыбыз юк.

Әгәр дә без кулыбызда булган госманлыча нөсхә белән Уразаев нөсхәсен чагыштырсак, безнең мөәллифнең берничә нөсхә белән файдаланганы тагы да ачыграк күренә. Уразаев «кыйсса»сы госманлыча «хикәя»гә караганда шактый озын (кечкенә кул 64 бит). Уразаевтагы нәзым белән язылган озын монологлар урынына госманлычада күбесенчә берничә сүз генә әйтелеп узылган. Уразаевның исә бу көйле парчаларны үзеннән уйлап чыгармаганлыгы шөбһәсез. Шулай ук нәсер белән язылган урыннарда да Уразаев бәгъзан госманлыча нөсхәгә караганда озынрак сөйли. Мәсәлән, шушы кыйтгаларны чагыштырыйк:

Госманлычада: «Ул вакыт Зөһрә дәхи хәммамдан чыгып сарая килдекдә һаман кафәсе[2] калдырып гаризе җәмал[3] әйләдекдә Таһирың үлем хәтеренә килмийүб бу өченче бәйте сөйләде».

Татарчада: «Бу тарафтан Зөһрә хәммам сарайдин килмеш иде. Тиз барып, падишаһ алдында Таһир нәзым әйтер дип, Зөһрәгә хәбәр бирделәр. Зөһрә моны ишетеп, җан атып, Таһирның падишаһ алдында нәзым әйткәнен күрәенчә дип, тәрәзәнең канатларын ачып, Таһир гашыйкка җәмалын[4] күрсәтте. Әмма белмәсдер кем Таһирның үлеменә сәбәп булыр. Таһир гашыйк Зөһрә солтанның гөл йөзен күреп, ихтыяры кулыннан китте, үз-үзен, сөйләгән сүзен белмәде, әҗәл касәсе дәхи[5] тулмыш иде. Ул хәлдә өченче нәзымны әйтте».

Менә шушының шикелле тәфсиләтне әгәр Уразаев үзеннән арттырмаган булса, шөбһәсез, башка бер озынрак төрекчә нөсхәдән алынгандыр. Бәгъзы урыннарда чын Анатулы

[1] Мәгаттәәссеф – кызганычка каршы.
[2] Кафәсе – тәрәзәсе.
[3] Гаризе җәмал – йөзе матурлыгы.
[4] Җәмалын – йөзен, матурлыгын.
[5] Дәхи – тагын.

мәддахлары[1] өслүбендәге риваячеләргә махсус иститрадлар[2] очрый ки, аларны инде Уразаевның үзе өстәгән булу ихтималы һич юк. Гомумән, Уразаев әсәрен төрекчә нөсхә белән чагыштырганда, безнең мөәллифнең хикәянең асыл төзелешенә (планына) һәм мөндәриҗәсенә һичбер төрле үзгәреш кертмәгәнлеге күренә. Уразаев китабының күп урыннары төрекчә нөсхәдән турыдан-туры тәрҗемә кылынган төсле тоела.

Төрекчә нөсхә бисмилласыз һәм болай дип башланып китә: «Равиян әхбар вә нәкълән әсәр шу илә риваять идәрләр ки, заман сабикда бер падишаһ Кямран шаһиншаһ вар иде ки, мал вә гаскәре чук иде. Бу кадәр дәүләт вә солтанат илә бер шәйә ихтыяҗы юк. Анчак бер әүлады улмадыкындан кәдәр идәрде». Уразаев хикәяне бисмилладан соң шушы рәвешчә башлый: «Равиян[3] асар вә нәкъләндер нәсер шундаг риваять вә мондаг хикәят кылырлар. Кем заман әүвәлдә бер олуг вә мәшһүр падишаһ бар ирде. Малы вә хәзинәсе вә гаскәре бик күп иде. Бунча солтанлык илә дөньяда һичнәрсәгә ихтыяҗы юк иде. Ләкин дөньяда угыл-кыздан фәрзәнде[4] юк ирде. Шул сәбәптән һәрвакыт күңеленә бераз кайгы вә тарлык килер иде». Арада сибелгән көйле парчаларны да Уразаев госманлыча шигырьләрдән генә тәрҗемә кылган. Шигырьләрнең асыл мәфһүмен[5] үзгәртмәсә дә, ул бу тәрҗемәләрдә үзен бик иркен тотканы күренә. Шигырьләрне татарчалаштырганда, ул, үз теләвенчә, байтак үзгәрешләр керткән. Мисал өчен хикәянең ахырында Таһирның тәкъдирен хәл итүгә сәбәп булган өч бәйтне чагыштырып карыйк:

Госманлычадан:

«Гөл өчүн былбыл аглар,
Дәртле синме даглар.
Мәҗнүн кеби Таһирың
Мәкәне улсун даглар».

---

[1] Мәддахлары – мактап язучылары.
[2] Иститрадлар – читкә китүләр.
[3] Равиян – сөйләүчеләр, башка бер кешедән ишетеп сөйләүчеләр.
[4] Фәрзәнде – нәселе.
[5] Мәфһүмен – эчтәлеген.

«Былбылы хар аглыйдыр,
Гашикый агйар аглыйдыр.
Бән фәл ки нә әйләдем,
Бәне һәр бар аглыйдыр».

«Гашыйк улдым яуруя,
Җан вирдем яурубә.
Каршымда бер ай тугды,
Бикзәр Зөһрә хурия».

Уразаевта:

«Гөл дип былбыл аглайды,
Дәртле синәм даглайды.
Мәҗнүндәен Таһирның
Урыны даглар улгайде».

«Тигәнәк былбыл еглатыр,
Гашыйкны кем еглатыр.
Бер көймәгә менгәнмен,
Мәне һәркөн еглатыр».

«Гашыйк булып җан биргән
Ошбу йөзгә охшайды.
Бер ай туган каршымда,
Зөһрәм хурга охшайди».

Әлхасыйль[1], Уразаев бу әсәргә үз хыялыннан бернәрсә дә арттырмаган. Хәтта беренче караштa татар тарафыннан арттырылган төсле тоела торган

«Ай, татар сез, татар сез,
Бер-береңезгә ук атарсыз,
Базарда ит беткәнме?
Таһир итен сатарсыз».

шигыре дә госманлыча нөсхәдә бар:

«Һай, татарлар, татарлар,
Бер-беренә ук атарлар.

[1] Әлхасыйль – нәтиҗәдә.

Чаршуда эт дөкенмеш,
Таһирың итен сатарлар».

Шулай итеп, Уразаевның «Таһир-Зөһрә»сенең кайдан алынганлыгы аерымачык мәгълүм булса да, аның «Бүз егет»енең мәнбәгъләре[1] тәмамән караңгылык вә томан эченә яшерелгән. Бу китап госманлычадан алынмаган булырга кирәк. Һәрхәлдә, татар арасында аның госманлыча нөсхәсе булганлыгын белмибез. Уразаев үзе дә югарыда китерелгән хатимәсендә аның госманлы теленнән алынганлыгын күрсәтми, бары тик «Таһир илә Зөһрә»не дә, «Бүз егет» шикелле «тасхих вә мокабәлә» кылып, татарчага әвereлдергәнен генә сөйли. Уразаев үзен «Кызылҗари» дип тә атый. Уфа янында Кызылҗар атлы бер авыл бар. Ләкин шуның белән янәшә үк мөәллиф үзен, Кормаш авылына нисбәт биреп, «Кормаши» дип атаганга, сүз Кызылҗар авылы хакында булмаска кирәк. Фикеребезчә, бу Кызылҗар кыргызказакълар тарафыннан шулай атала торган Петропавел шәһәре булырга тиеш. Ничектер гомеренең бер дәверендә Уразаев казакъ арасында Петропавел каласында торганга охшый. Чөнки аның казакъ теле вә әдәбияты белән яхшы таныш булуын һич башка юл белән аңларга мөмкин түгел.

Ул татарларны казакъларча нугай дип атый, үзенең китапларын нугай һәм казакъ телендә тасниф кылдым, ди. Чынлап та, бу ике китапта казакъ-кыргыз тәэсире бик зур. «Бүз егет» исеме үзе дә казакъ сүзенә охшаган. Һәр ике китапның тел вә өслүбендә кыргызлык тәэсире бик ачык күзгә бәрелә. Бу тәэсир «Бүз егет»тә бигрәк тә зур. Текстка кергән аерым казакъ сүзләре, тәгъбирләре вә формаларына башка «Бүз егет»нең шигырьләре нәкъ казакъның халык поэмалары өслүбендә ясалган. Хәтта шигырьләрнең вәзеннәре дә милли казакъ үләңнәренең вәзеннәре белән бер. Гомумән, бөтен хикәядән аның каһарманнары төркләр һәм вакыйганың урыны төрк иле булмауга карамый, күчмәле төрклек хәяты аңкып тора. Анда тасвир ителгән туйлар,

[1] Мәнбәгъләре – чыганаклары.

туйда буза эчүләр, сарайның тышында ук һәммә кешенең атлары хәзер булып торуы – һәммәсе төрк тормышы тәэсире астында мәйданга килгән тасвирлар. Аннан соң Бүз егетнең үлгәнен атасына хәбәр бирергә баручы карт җырчы-шагыйрь (импровизатор) Кари баба – бу да бары төркләргә махсус күчеп йөрүче җырчы (бард[1]) тибы. Менә без, шушы дәлилләргә таянып, Уразаев «Бүз егет»енең асылын казакъчадан алмадымы икән дип уйлый алабыз. Ләкин бу, әлбәттә, бер фараз гына. Казакъ халык әдәбиятында бу исемдәге һәм бу мәүзугтагы[2] әсәрнең булганлыгын белмәгәнлегебез шикелле, басылган казакъча китаплар арасында да без «Бүз егет»нең прототибын очратканыбыз юк.

«Таһир-Зөһрә» белән «Бүз егет»не Уразаев кыйсса дип (госманлылар хикәя дип) атаса да, аларны дастан (поэма) дип атау дөресрәк булыр иде.

Шәрыкта шул типтагы гыйшкый кыйссалар языла торган бер тарызда[3], нәзым белән нәсер кара-катыш язылганнар. Хикәянең мөәллиф авызыннан сөйләнә торган ривая кыйсеме вә әһәмиятсезрәк сөйләшүләр мондый әсәрләрдә, гадәттә, нәсер белән язылып, каһарманнарның озын итеп сөйләгән сүзләре (монологлар) яки бер-берсе белән сөйләшкән сүзләре (диалоглар) көйләп языла. Мондый әсәрләрне без чыгтай әдәбиятында да очратабыз («Йосыф вә Зөләйха»). Бигрәк тә иске госманлы әдәбияты бу төрле әсәрләргә бай («Ләйлә илә Мәҗнүн», «Фәрһад илә Ширин», «Арзу илә Канбәр», «Вәрәка илә Гөлшаһ», «Күр углы Солтан», «Мәликшаһ илә Гөлихан», «Гашыйк Гариб», «Маһруй илә Хөршид», «Разый нәһен илә маһи Фирүзә-солтан», «Мәнакыйби[4] шаһ Исмәгыйль вә Гөлгазар», «Дәрде юк илә зөлфе сәйях» вә башкалар). Болардан кайберләре (мәсәлән, «Разый нәһен илә маһи Фирүзә солтан» хикәясе) бездә дә басылган, кайберләре («Күр углы Солтан») Истанбул басмасында татар

[1] Кирилл хәрефләре белән язылган.
[2] Мәүзугтагы – сюжеттагы.
[3] Тарызда – ысулда, типта.
[4] Мәнакыйби – мактаулы.

арасында таралганнар. Менә безнең «Таһир-Зөһрә» белән «Бүз егет» тә шул тарызда язылган шул типтагы әсәрләрдән.

Бу төрле гыйшкый хикәя-поэмаларның мәүзуглары бөтен галәм әдәбияты өчен уртак булган, бер халыктан бер халыкка күчеп йөри торган «сәйяр мәүзуглар»дан, «күчмәле сюжетлар»-дан. Безнең «Таһир-Зөһрә» белән «Бүз егет»тә төп мәүзуг вә идея ягыннан шул гомуми шаблоннан (калып) читкә чыкмый-лар. Бу әдәби мәүзугның төп кыйссасы шушыннан гыйбарәт: гашыйк белән мәгъшука бер-берсен саф (идеальный) мәхәб-бәт белән сөяләр. Ләкин аларга дөньялыкта кавышырга тәкъ-дир язмаган. Шушы юлда аларның арасына бик күп манигъ-лар, киртәләр куела; күбесенчә кыз белән егетнең ата-аналары аларның никахларына разый булмыйлар. Ыруг дошманлыгы, сыйнфый яктан тиңдәш булмавы да бу турыда зур роль уйный. Гашыйклар бөтен көчләре белән бер-берсенә омтылалар, ка-вышу юлында әллә нинди мәшәкатьләргә очрап, әллә никадәр җәфалар чигәләр. Аларның гыйшыклары харикылгадә[1] рәвеш-тә каты, һич гади тормышта булмый торган көчле вә дәвамлы була. Ләкин шуның белән бергә бу ифрат шагыйранә, саф-пакь, каба[2] хайваниятлән ерак булган бер мәхәббәт. Алар бер-берсенең кочагында булган бик сирәк моментларны да күбрәк мәхәббәтләренең тулылыгыннан күз яшьләре түгеп үткәрәләр. Мәсәлән, «Таһир белән Зөһрә»нең бер урынында әйтелгәнчә, ике гашыйк, бер-берсе белән кочаклашкан хәлдә, күзгә күрен-гән һичбер сәбәп булмастан елыйлар, ник елаганнарын үзләре дә белмиләр. Ләкин явыз язмыш аларны һәрвакыт бер-береннән аера. Алар аерылышу утында яналар. Фирак-һиҗраннан[3] көяләр, саргаялар, ашау-эчүдән калалар, авыруга сабышалар, гакылдан шашып, вәхши хайваннар шикелле, ялангач тауларда, сахраларда яшиләр, еллар буенча зинданнарда утыралар. Шулай итеп, алар шул мәхәббәтләре юлында исәпсез-хисапсыз кайгы-

[1] Харикылгадә – гәдәттән тыш.
[2] Каба – ямьсез.
[3] Фирак-һиҗраннан – аерылышудан.

хәсрәткә дучар булалар. Ләкин аларга исән вакытларында кавышу юк: хикәянең ахырында гашыйк белән мәгъшука икесе дә фаҗигалы үлем белән дөньядан китәләр.

Менә бу – бөтендөнья әдәбиятында табыла торган, шаблонлы бер мәүзуг. Андый хикәяләрне Шәрыкта да, Яурупада да, халык әдәбиятында да, язма әдәбиятта да очратып була. Мәсәлән, Шекспир тарафыннан сәхнә өчен эшләнеп, бер гүзәл фаҗигага әверелдерелгән мәшһүр «Ромео һәм Джульетта» маҗарасы, Яурупадагы мәшһүр урта гасыр легендаларыннан «Тристан һәм Изольда» шул төрле әсәрләрдән. Гаять ялкынлы булуы белән бергә чиктән тыш сентиментальный булган бу гыйшык Җәнүб вә Шәрык халыкларының рухларына ифрат[1] туры килә. Шуңар күрә, бу мәүзугтагы хикәяләр Шәрыкта, бахосус[2] ислам Шәрыгында бик таралган. Бөтен ислам галәмендә, бөтен мөселман шәрыгының әдәбиятларында атлары телдә тәсбих урынында йөртелә торган «Ләйлә вә Мәҗнүн»нәр, «Фәрһад вә Ширин»нәр хакында кемнең ишеткәне юк, нинди генә Шәрык шагыйре боларны үзенә мәүзуг итеп алып көчен сынамаган. Гарәп, Иран, чыгтай, госманлы шагыйрьләре тарафыннан шул сәрләүхәләрдә[3] төрле гасырларда язылган дастаннар бетәсе юк. Лирик шагыйрьләрдә шул «тамгалы» гашыйкларның исемнәрен телләреннән салмыйлар; суфи шагыйрьләр, үзләренең Аллага булган гыйшыкларын аңлату өчен, шуларны мисал итеп алалар. Югарыда әйтелгән ике иң рәваҗлы[4] мәүзугтан «Ләйлә вә Мәҗнүн»нең асылы – бәдәви[5] гарәпләр арасыннан, «Фәрһад вә Ширин» Ираннан чыккан. Безнең Таһир белән Зөһрә дә шундый бөтен ислам Шәрыгы өчен уртак булган парлы гашыйклардан. Бу мәүзугның башлап кайсы халыктан чыкканлыгын тәгаенләп әйтеп булмый. Безнең төрк халыкларына мондый мәүзуглар

[1] Ифрат – бик.
[2] Бахосус – бигрәк тә.
[3] Сәрләүхәләрдә – исемнәрдә.
[4] Рәваҗлы – таралган.
[5] Бәдәви – күчмә тормыш белән яшәүче.

күбесенчә иранлылар аркылы кергәнгә, Иран, гомумән, шул төрле мәүзугларның оясы булганга, аны да Иран аша килгән дип тәхмин итәргә[1] мөмкин. «Бүз егет»нең исә кайдан килеп чыгуы, югарыда әйтелеп узылганча, караңгы. Аның каһарманы – Багдадтагы Габдулла исемле ханның углы. Монда без гомумислам Шәрыгы калыбы, гарәп шәһәрләре, гарәп исемнәре астында шундый ачык күренә торган төрклек рухы табабыз ки, бу хикәяне төрк халыклары (мәсәлән, казакълар) арасында туып та, гомуми калыпка тыгып язылган сахтә[2] классик әсәрләрдән түгел микән дигән фикер башка килә. Шәрык язучылары үзләре дә мондый мәүзуглар арасындагы берлекне игътираф итәләр[3]. Мәсәлән, «Таһир илә Зөһрә» китабының ахырында без түбәндәге сүзләрне укыйбыз: «Таһир илән Зөһрә, Фәрһад илән Ширин, Ләйлә илән Мәҗнүн, Арсу илән Канбәр, Вәрәка илән Гөлшаһ – монлар бер-беренә хакыйкать гашыйклардыр. Илә ахриһи[4] һәркайсы морадларына йитәлмәй китмешләрдер. Бу фани дөньяда гаҗаиб кыйссаларны гыйбрәт өчен вә укучыларга дога кылмак өчен калдырмышлардыр». Шәрык язучылары, алар артыннан халык та, шул фәҗигъ[5] тәкъдирле гашыйкларның хакыйкый дөньяда булган тарихи затлар икәнлегенә ышаналар. Күбесенчә китапның ахырында бичара гашыйкларның рухларына укучыларның дога кылуларын үтенәләр. Безнең Уразаев та, үзенең каһарманнарының үлүләрен сөйләгәннән соң, чынчынлап «иннә лилләһи вә иннә иләйһи раҗигун» укып куя, аларны шәһитләрдән саный (гомумән, шәрыкта гыйшык сәбәпле үлгәннәрне шәһитләрдән хисаплыйлар). Ул, бер яктан, үзе шикелле бүз балалар (!) һәм «агай-эне укып хушнуд булып», язучыны хәер-дога белән яд итәрләр[6] дип өмет итсә, икенче яктан, шул гашыйкларның рухлары өчен укучылардан бер фатиха

[1] Тәхмин итәргә – якынча билгеләргә.
[2] Сахтә – ялган, ясалма.
[3] Игътираф итәләр – таныйлар.
[4] Ила ахирихи – ахырына кадәр.
[5] Фәҗигъ – фаҗигалы, аянычлы.
[6] Яд итәрләр – искә алырлар.

өмет итеп язганлыгын әйтеп китә. Ихтимал, ул бу сүзләрне чын күңелдән, ихтимал ки мулла булганга күрә, голәма үзен шундый сафсата, чүп-чар язган өчен гаеп итмәсеннәр дип, риядән[1] әйтә торгандыр.

«Таһир илә Зөһрә»нең мөндәриҗәсе шушы: ниндидер намәгълүм[2] бер мәмләкәттә бер ханның бер дә баласы булмый. Шулай ук баш вәзирнең дә баласы юк икән. Бер дәрвиш аларга моның чарасын өйрәтә. Ханның бер кызы, вәзирнең углы буласын хәбәр биреп, үскәч, аларны бер-берсенә никахлап бирерсез, ди. Шулай итеп, ханның кызы дөньяга килә, аңар Зөһрә дип исем бирәләр; вәзирнең углын Таһир атлы кушалар. Хикәя менә шундый Шәрыкка махсус шаблон буенча башланып китә. Бу ике бала дәрвишнең кушуы буенча бергә тәрбияләнәләр, бергә үсәләр, кечкенә чакларында ук бер-берсеннән аерылып тора алмыйлар. Унике яшьтән бер-берсенә гашыйк булалар, алар икесе дә шундый матур булганнар – бер күргән кеше тагын бер тапкыр күрсәм иде дип, аһ итә икән. Шул вакытта ханның колларыннан бер кара гарәп аларның арасына төшеп, шымчылап йөри башлый, гыйшыкларын ханга белдерә. Башта хан – кызын Таһирга бирергә уйласа да, хатыны, вәзир углын кызына тиң күрмәгәнгә, бу эшкә каршы була. Кара гарәп аларга котырык биреп, Таһирның гыйшкын кабахәт төстә итеп күрсәтергә тырыша. Ахырысында, сихер белән, ханны да үз якларына аударалар. Шул көннән башлап, ул да Таһирга дошман киселә.

Таһир үзе шагыйрь була. Шигырь әйтүдә ул шулкадәр оста булган – һичбер шагыйрь аңар тиңләшә алмаган. Ул аларның һәммәсен җиңеп, җаваптан гаҗиз[3] итә икән. Менә бу шигырь ярышы, бер-берсен гаҗиз иткәнче кара-каршы шигырь әйтешү гадәте күчмәле төрк халыкларының хосусиятеннән. Мәсәлән, хәзерге казакъ-кыргызларда бу гадәт әле дә бик куәтле хөкем

[1] Риядән – кешегә күрсәтер өчен генә.
[2] Намәгълүм – билгесез.
[3] Җаваптан гаҗиз – җавапсыз.

сөрмәктә. Шунысы шаян[1] игътибар ки, бу тәфсил безнең кулдагы төрекчә нөсхәдә юк. Таһир, Зөһрәдән аерылгач, һаман шигырь язып, язган берсен җиргә ташлап калдырып йөри. Йөрәкләре янган гашыйклар аларны табып алып җыялар. Таһирның шигырьләрен укыган һәрбер кешенең күңелендә гыйшык уты пәйда була. Таһир Зөһрәгә дә шигырьләр язып җибәрә, яшертен аның тәрәзәсе төбенә килеп, бәйтләрен әйтә – серенадалар җырлый. Аларның яшертен күрешеп сөйләшкәннәрен тагын теге гарәп сизеп, ханга хәбәр бирә. Бу кара гарәп – безнең гашыйклар өчен явыз тәкъдир ролен уйнаучы бер шәхес. Хан, Таһирны тотып зинданга яптырыр өчен, гаскәр җибәрә. Таһир, гадәттән тыш көчле, баһадир егет булганга, никадәр гаскәр килмәсен, һәммәсен тар-мар кылып, җиңеп качыра. Ахырда ул бары ханның сүзенә буйсынып кына бирелә. Аны Мәрдин шәһәренең зинданына сала. Таһир шул зинданда җиде ел утырганнан соң, Хозыр пәйгамбәр килеп, аны коткара. Таһир, кире Зөһрә шәһәренә кайтып, яңадан яшертен рәвештә мәгъшукасы белән күрешә башлый. Аны тагын тотып алалар. Хан үтермәкче була, бары тик вәзирләре генә йолып алып калалар. Үтерү урынына Таһирны, сандыкка салып, Шат суына агызырга карар бирелә (бу исем «Шат әл-гарәб»тән бозылган булса кирәк). Аны, суда агып барганда, Гөл патшасының кызлары күреп, тотып алалар. Бу кызлар никадәр матур булсалар да, ничаклы Таһирны кадерләп, үзләренең гүзәллекләрен гарыз кылсалар да, аларның гыйшыклары аңар кяр кылмый[2]. Ул кире Зөһрәсе янына китә. Кайтса, Зөһрәне бер шаһзадәгә бирергә әзерләнәләр. Таһир, хатыннар киеме киенеп, туйга кереп, туй тамашасы арасында Зөһрәне урлап качмакчы була. Ләкин эш барып чыкмый: качып барганда аларны яңадан камап тоталар. Качып котылырга мөмкин булса да, Таһир, тәкъдиргә буйсынып, яңадан тотыла. Зөһрәнең качарга өндәвенә каршы ул шушы мисраглар белән җавап бирә:

[1] Шаян – тиешле дәрәҗәдә.
[2] Кяр кылмый – тәэсир итми.

«Гакыйль хәйлә корсаң да,
Булыр эшләр булыр ул.
Күңлеңне киң тотсаң да,
Булыр эшләр булыр ул».

Менә бу сүзләрдә чын Шәрык фатализмы күренеп тора.

Хан Таһирны тагын үтермәкче була. Вәзирләр тагын аның өчен үтенәләр. Ахырда хан аңар, үзен коткарыр өчен, карап торырга бик асат, ләкин мәкерле бер шарт куя: ул өч бәйт әйтергә тиеш. Әмма аларда Зөһрәнең һәм ханның исемнәре телгә алынмасын. Таһир ике бәйтне әйтә. Өченчесен әйтер алдыннан исә, тәсадефи рәвештә[1], күзенә Зөһрә килеп күренә дә, саташып, шигырендә аның исемен зикер итә[2]. Ләкин җәлладның кылычы Таһирның муенына кагылмый: ул, ике рәкәгать намаз укып, җанын алуын сорап, Ходайга ялвара һәм шул сәгать егылып җан тәслим кыла[3]. Таһир үлгәннән соң, Зөһрә дә, һичкемнең юатуына карамыйча, сөйгәненең гәүдәсен кочаклап җан бирә. Зөһрәнең үлгәнен күргәч, теге кара гарәп тә үз-үзен хәнҗәр белән чәнчеп үтерә. Чөнки ул Таһирга каршы эшләгән явызлыкларын бары тик үзенең Зөһрәгә булган яшертен гыйшкы сәбәпле, көнчелектән эшләгән икән.

«Таһир-Зөһрә кыйссасы» шушы рәвешчә тәмам була: «Падишаһ яхшы йиргә мазар[4] казымага боерып, тәҗһиз кылып[5], икесене янәшә (кыйтар[6]) дәфен кылдылар[7]. Ул мәлгунь гарәпне башлары очына күмделәр. Зөһрәнең кабере өстенә ак гөл үсеп, Таһирның өстенә кызыл гөл үсте, вә ул гарәб мәлгуньнең кабере өстенә кара тигәнәк үсте. Һәркайчан ул ике нәфис гөлләр бер-беренә кавышмак теләсәләр, кара тигәнәк араларына төшеп, кавыштырмас иде. Гашыйклар вә күкрәкләре янган адәмнәр һәр

[1] Тәсадефи рәвештә – көтмәгәндә.
[2] Зикер итә – телгә ала.
[3] Җан тәслим кыла – җан бирә.
[4] Мазар – кабер.
[5] Тәҗһиз кылып – үлекне күмәргә әзерләп.
[6] Кыйтар – саф, рәт.
[7] Дәфен кылдылар – җирләделәр.

елны ул мазарлыкка килеп, зиярәт кылып, ул кара тигәнәкне үткен балталар вә кылычлар илән чавып бетерерләр иде. Янә үсәр иде. Бик зур зиярәтгяһ улгандыр, гашыйклар вә гарибләр һәрвакытны зиярәт кыйлырлар мәшһүрдер».

«Бүз егет»нең мөндәриҗәсе «Таһир-Зөһрә»некенә бик якын. Багдад шәһәренең ханы Габдулланың углы Бүз егет һәм Малатья шәһәренең ханы Таһмасның кызы Һәфүзә бер-берсен төшләрендә күреп гашыйк булалар. Хикәянең бу рәвешчә башланып китүе дә – Шәрык әдәбиятында иң мөстәгъмәл[1] бер әзер калып. Хикәянең башында кыз Һәфүзә аталса да, ни өчендер соңыннан ул Сахибҗәмалга әверелеп китә һәм ахырга кадәр шул исемдә йөртелә. Бүз егет үзенең дусты – Кәмин исемле егет белән кызны эзләргә чыгып китәләр. Бик озын сәяхәттән соң, Багдадка җитеп, ике гашыйк кавышалар. Алар кызның сараенда кәефсафа кылып утырганда, бу хәбәрне ханга барып хәбәр итәләр. Хан, гаскәр җибәреп, Бүз егетне тоттырмакчы була. Ләкин ул, Таһир шикелле үк көчле гайрәтле булганга, гаскәрне тар-мар итеп кача. Шуннан соң ул, яшеренеп, шәһәрнең читендә бер кортканың йортында тора башлый. Яшертен генә мәгъшукасы белән күрешәләр. Хан, Бүз егетне хәйлә белән кулга алмакчы булып, гүя ки кызын аңар бирергә риза булган шикелле туй мәҗлесе кордыра һәм Бүз егеткә хәбәр җибәрә. Бүз егет ышанып туйга килә. Аны эчертеп исертәләр. Ул бернәрсә дә сизми. Исерек хәлендә аны үтермәкче булалар. Ләкин дусты Кәминнең эшне сизүе аркасында гына ул котылып кача. Бу ялган туй манзарасы – хикәянең иң матур урыннарыннан берсе. Ахырысында, теге кортканың алтынга сатылуы аркасында, Бүз егет тотыла. Аның башын кисәргә җәлладка тапшыралар. Ләкин һичбер кылыч Бүз егетнең башын кисми, чөнки ул һәрвакыт «Исме Әгъзам» догасын укый һәм госел коена икән. Бик җаны кыйналгач, ахырда ул әйтә: «Минем олтаным астында алмас хәнҗәрем бар, шуны алып башымны чабыгыз», – ди. Ул әйткәнчә, аның үз хәнҗәре белән башын кисәләр. Үлеме үз кылычыннан булуы-

[1] Мөстәгъмәл – кулланыла торган.

ның сәбәбе – кылычын бөкләп табан астында йөртүе була. Моннан Шәрык халыкларының кылычка, гомумән, сугыш коралына бер мөкаддәс нәрсә итеп караулары күренеп тора. Коралын тәхфиф итеп[1] аяк астында йөрткән өчен, Бүз егет үз кылычыннан әҗәлен татый. Башын кисkәннән соң, ничек итептер, аны дарга да асалар. Бүз егет йөзенә кылдан пәрдә ябып йөри икән. Палач, аның пәрдәсен ертып матурлыгын күргәч, үтергәненә үкенә. (Кара син, нинди «гүзәллек сөюче» җәллад булган икән!) Бүз егетнең үтерелгәнен Сахибҗәмал белми кала. Бу эш мәгълүм булгач, ул бик кайгыра, елый, бәйтләр әйтә, аталарын шелтәли. Бу да хикәянең матур урыннарыннан. Аннан соң ул, мәгъшукы өчен бик матур төрбә эшләтеп, үзе шунда кереп, Бүз егетне кочаклап, үз-үзен үтерә. Шулвакыт төрбәнең ишеге үз-үзеннән ябыла – һичкем аны ача алмый. «Бүз егет хикәясе»нең чишелүе мантыйкый рәвештә баш каһарманнарның һәлакәте белән генә тәмам булмый. Ул тагын байтак кына сузылып, планның бөтенлегенә зарар китерә. Бүз егетнең дусты Кәмин шаһзадәнең үлем хәбәрен әйтергә Малатьяга китә. Ата-анасын кайгылы хәбәрне ишетергә хәзерләү өчен, алдан Кари баба дигән карт җырчыны җибәрәләр. Ул, бик еректан китереп шигырьләр әйтеп, акрынлап «үлем бабы»на күчеп, бик дипломатларча гына эшне аңлата. Бу шигырьләр дә хикәянең матур җирләреннән саналырга тиешле. Габдулла хан хатыны белән, угылларын зиярәт кылыр өчен, Багдадка сәфәр кылалар. Таһмас хан аның алдына үзенең кылычын чыгарып салып, «менә, чапсагыз, кылыч, менә баш», дип, башын иеп тора. Габдулла хан галиҗәнаплык күрсәтә: «Тәкъдир Алладан, сәбәп сездән, инде эш үткән. Мәхшәр көнендә Алла сиңа хөкем итсен», дию белән канәгатьләнә. Сахибҗәмалның үзенең сөйгәнен үтертүгә сәбәпче булган карчыкны гафу итүе дә, шундый ук галиҗәнап матур бер эш булып, хикәягә гали әхлакый бер төс бирә. (Ләкин китапта турыдантуры әхлакчылык сату (мораль) бар дип уйланмасын). Төрбәнең ишеген ватып ачалар, карасалар, гашыйклар нәкъ йоклаган

[1] Тәхфиф итеп – кимсетеп.

шикелле бер-берсенә сарышып яталар, йөзләреннән нур балкып тора. Кәмин дә (бу Шәрыкның Горациосы), дустының атаанасын алып килеп, бурычын үтәгәннән соң, дөньяда үзе генә яшәргә теләмичә, төрбәгә кереп җан бирә. Төрбә ишеге кодрәт белән ябылып, өчесе дә кыяматкә кадәр шунда калалар.

«Таһир-Зөһрә» белән «Бүз егет» китапларының теле – XIX гасыр ахырының татарчасы, шул заманда чыккан хикәят китаплары язылган тел. «Йай, таңла, күзләригә, аймак, имәс, исергәмәс, торур, тиде, булгай, тайгыл, күргәли, көткем килмәс, куйгу, түрлик, катыйг, тәкый» шикелле байтак кына чыгтайчалыклар, «үбешәлем, куркар, улмак, баһадирларымызы, бусә, зира ки» күк госманлычалыклар очраса да, алар бик аз процент тәшкил итәләр. Хосусан, «Таһир илә Зөһрә»дә госманлычадан алына торып та, госманлы теле тәэсиренең бик аз булуы күзгә ташлана. Русчадан кергән сүзләрдән бары «санат» сүзе генә очрый. Уразаевның телендә әһәмият бирерлек бер нокта булса, ул да аның касдан[1] теленә казакъчалык кертүедер. Бу казакъча тәэсире нәсер белән язылган урыннарда юк хөкемендә, анда тик әллә нинди бер «утау, утагасы, чуб, үстәү, җалмавыз» шикелле аерым-аерым казакъча тәгъбирләр генә очрыйлар. Әмма көйле урыннарында, кирәк тел ягыннан, кирәк өслүб ягыннан булсын, бу тәэсир бик куәтле (бу бигрәк тә «Бүз егет»тә күзгә бәрелә). Уразаевның шигырьләрендә асыл тел татарча булса да, «килебмән, килебсән, килебте (килебди), булмасмән, чәнчәен, күрмәен, Зөһрәдәин, таңдаб, менән, канда, канча, каны, гой, алыс» шикелле казакъчалыклар аны чуарлыйлар. Бигрәк тә фигыль формалары күп истигъмаль ителә. Уразаев казакъ теле белән яхшы таныш булып, казакъ әдәбиятының мәфтүннәреннән[2] булса кирәк. Хосусан, шигырь бабында аның тәмамән казакъ тәэсирендә торганлыгы күренә. Аның шигырьләре кирәк вәзен, кирәк өслүб җәһәтеннән нәкъ казакъ җырлары, казакъ үләңләре төсле. Өслүбенә шигърият бирер өчен ул һәрвакыт ка-

[1] Касдан – белә торып.
[2] Мәфтүннәреннән – сокланучыларыннан.

закъ халык әдәбиятындагы әдәби тарызы ифадәләрене[1] куллана. Мәсәлән:

«Төя килеп бузлайды,
Бутасы[2] анның бар микән.
Бута күзле бүз егет
Бу уенда бар микән».

Кайбер бәйтләрдә татар халык җырларының да тәэсире бар төсле тоела. Мәсәлән:

«Күктә торган йолдызмын,
Суда йөзгән кондызмын», –

дигән бәйттәге тиңләштерүләр татар җырларындагыларга охшыйлар. Мулла булуына карамый, Уразаевның телендә гарәп-фарсы тәэсире бик аз. Иң авыр тел белән язылган шигырьләренә мисал итеп тә хәтта бары шушының шикелле мисрагларны гына китерергә мөмкин:

«Хакыйкать яр син, Зөһрәҗан,
Зөлфе дар[3] син, Зөһрәҗан.
Сабырым берлән карарым,
Сән алыпсән, Зөһрәҗан».

Уразаев китапларындагы шигырьләрнең күбрәге бөтен төрк халыкларында булган, безнең татарда кыска җыр вәзене дип йөртелә торган вәзен белән язылганнар. Арада сирәк кенә казакъ җырларына махсус бер вәзен белән язылган бәйтләр дә бар. Мәсәлән:

«Мин колың бу хәлне күреп әйдәм,
Чәнчәен дип гайрәтемә килеп әйдәм,
Шул заман төшә калса исемезгә,
Җарлыгы ханымызның җукти, дидем».

[1] Тарызы ифадәләрне – үрнәк аңлатмаларны.
[2] Бутасы – баласы.
[3] Дөресе – зөлефдар (зөлфидар), фарсыча «бөдрә чәчле» мәгънәсендә. *(Авт. иск).*

Нәсери өслүбтә Уразаев госманлы ривая өслүбе юлыннан бара. Әледән-әле ул хикәяне «әл-кыйсса» дип башлап китә; «чөн ахшам вакыты йиткәндә» дип башлана торган җөмләләр дә очрый. Хикәянең әһәмиятлерәк урыннарында ул сүзен туктата да «хасыйле кәлам[1], сүзне кыска кылыйк, бераз кәеф корыйк... Әмма сезләр кыйссаны бу тарафдан тыңлаңыз, әл-кыйсса равилар андаг риваять кылулар ки» дигән шикелле чит җөмләләр дә катыштырып җибәрә. Менә мондый чын-чын эпикага махсус иститрадлар (читкә чыгулар) каһвәханә публикасы алдында сөйләүче Анатулы кыйсса ханнары, госманлы мәддахлары[2] өчен характерный булган сөйләү ысулы инде. Шундый ук иститради җөмләләрне без «Сәид Баттал гази» тибындагы сугыш китапларында да күрәбез. Бу исә «Таһир-Зөһрә» шикелле хикәя-дастаннарның, башта Анатулыда авыздан сөйләүче профессиональ кыйссачылар тарафыннан эшләнеп чыгып, соңыннан халык өчен (киң даирә укучылар өчен) бастырылганын күрсәтә торган бер факттыр. Безнең кулда булган кыска госманлыча нөсхәдә бу җөмләләр юк. Уразаев аларны безгә мәгълүм булмаган озын нөсхәдән алган булырга кирәк. Гомумән, Уразаевның нәсери өслүбен шигърият ягыннан матур дип мактар хәл юк. Ул үзенең оригиналларындагы шикелле артык бизәксез, садә генә өслүб белән язган. «Корылган баш бостанда үсмәс, анагыз икенче мәртәбә сезләрне тудырмас», дигән шикеле тәкәллефле[3] җөмләләр анда сирәк очрыйлар. «Уен уйнатып, пәһлеван сайлатып, ерактан ат чаптырып, якыннан тай чаптырып падишаһымыз зур туй кыладыр» шикелле казакъларның сәҗгылы[4] нәсери өслүбенә охшаган җөмләләр дә очраштыргалый.

[1] Хасыйле кәлам – кыскасы.
[2] Мәддахлары – мактап язучылары.
[3] Тәкәллефле – ясалма.
[4] Сәҗгылы – рифмалашкан.

**«Кыйссаи Нәбрүз»**

Халык арасында «Нәбрүз бәете» дип кенә йөртелә торган бу әсәрнең тулы исеме шушылай: «Китабе кыйссаи нәбрүз кыйссаи ике былбыллар ике кызлардыр». Кечкенә кулда 24 битле бу рисалә безнең халык арасында бик күп укыла торган китаплардан иде. Ул, беренче тапкыр Казанда 1888 елда басылып, аннан соң ничә мәртәбәләр тәкрар ителгән[1]. Соңгы басмаларында, төзәтеп, «Нәүрүз» дип бастырганнар; «нәбрүз» исә – халык тәләффызынча[2]. Бу китапның мөндәриҗәсе хакында сүз башлаганчы Нәүрүзнең нәрсә икәне хакында берничә сүз әйтеп китәргә кирәксенәбез.

Нәүрүз (науруз) – фарсыча «яңа көн» мәгънәсендә. Яз көне 9 нчы мартта көн-төн тигезләнгән көнне иранлылар шулай дип атап, үзләренең ел башын шул көннән хисаплаганнар. Борынгы Иран хисабынча, елның беренче ае булган фәрвәрдиннең беренче көне «нәүрүзе гаммә» аталып, алтынчы көне «нәүрүзе хассә» атала. Иранлылар, Нәүрүзне бик зур бәйрәм хисаплап, шушы алты көнне төне-көне гыйш-гошрәт кылып, кәеф-сафа белән уздыра торган булганнар. Иранлыларда борынгыдан калган бу бәйрәм элек заманнарда дини бер бәйрәм булып, Иран мифологиясе буенча, җәйнең – кышны, кояшның – суыклыкны, яхшылык тәңресе Һәрмәзнең явызлык тәңресе Әһримәнне җиңүе хөрмәтенә ясала икән[3]. Бу борынгы дини бәйрәм, иранлылар ислам кабул иткәч тә ташланмыйча, бәйрәм ителүдә дәвам иткән. Аңар яңа дин ноктаи назарыннан карап, дини төс биргәннәр: Нәүрүз көнендә Алла галәмне һәм адәмне хәлык кылды[4], күктәге барча йолдызлар шул көннән башлап әйләнә башладылар, дигәннәр.

Иран легендасы Нәүрүзнең бәйрәм ителә башлавын Иранның мәшһүр әсатыйри (хорафи, легендарный, ярым хыялый)

[1] Тәкрар ителгән – кабат басылган.

[2] Тәләффызынча – әйтүенчә.

[3] Мәҗүсияттән калган бу шатлыклы яз бәйрәме ареалы Гыйрактан булган һәммә халыкларда бар. Яурупада аны «Карнавал», русларда «Масленница» диләр. *(Авт. иск.)*

[4] Хәлык кылды – яратты, бар итте.

шаһы Җәмшиднең исеме белән дә баглый: имеш, бик борынгы заманнарда булган Иран падишаһы Җәм, бөтендөнья йөзендә сәяхәт итеп, һәрбер өлкәләрне күргәннән соң, Азәрбайҗанга килеп, бу мәмләкәтне бик яраткан, шунда бер биек урында, кояш чыгышына каратып, биек вә зиннәтле тәхет кырдырган да, үзе, шаһларга махсус киемнәр һәм башына асыл ташлар белән бизәлгән ялтыравыклы таҗ киеп, шул тәхет өстенә утырган. Кояш туып, аның беренче нурлары падишаһның таҗына төшкәч, таҗ, гаҗәеп бер яктылык белән ялтырап, бөтен тирәякны нурга батырган. Шунда җыелган халык, бу хәлне күреп, бик шатланганнар, бу көн башка көннәрдән аерым бер көн, дип, Нәүрүз дип ат биреп, шул көнне зур бәйрәм итә торган булганнар. Падишаһның исеменә, борынгы Иран (пәһләви) телендә «нур, яктылык» мәгънәсендә булган «шид» сүзе кушылып, шул көннән бирле аны Җәмшид дип атый башлаганнар. Җәмшид исеме Иран әдәбиятында (һәм шуңар ияргән чыгтай вә госманлы әдәбиятларында) бик еш очрый. Мәсәлән, «Җами җәмдән нуш итү» (ягъни Җәмшид касәсеннән эчү) бәхеткә, идеал вә максатка ирешү, Алла белән висаль[1] мәгънәләрендә суфи шагыйрьләрнең иң яратып куллана торган истигарәләреннән[2]. Иранлылар хәзердә дә Нәүрүз бәйрәмен итәләр. Алардан ул Иран тәэсирендә булган, шигый мәзһәбендәге башка халыкларга да, мәсәлән, Азәрбайҗан татарларына күчкән.

Нинди юл белән килептер, Нәүрүз безнең салкын шимальга да әсәр[3] иткән. Гәрчә Азәрбайҗан татарларындагы шикелле чын мәгънәсе белән Нәүрүз бәйрәмен итү безнең Идел буе татарлары арасында булмаса да, аның тәэсире бездә дә булмый калмаган. Мәрҗани икенче җилд «Мөстәфад»тә, бер мулла

[1] Висаль – күрешү, кавышу.

[2] Истигарәләреннән – метафораларыннан. Легенда буенча, Җәмшиднең гаҗәеп бер кәдәхе-касәсе (җам) булган. Бу касәгә хәмер салгач, аның эчендә падишаһ ни теләсә шул җиһанның җиде икълиме гакес итеп күренә икән. *(Авт. иск.)*

[3] Әсәр – тәэсир.

хакында сөйләгәндә, шушы сүзләрне яза: «Мәзбүр[1] гасырында (моннан 100–150 еллар элек) нәүрүз әйтеп, әүвәл хәмәлдә (март башында) тирән чана хәзерләп, аның уртасына карья[2] мулласы кереп утырып, кырык-илле кеше җигелеп тартып, карьянең бер башыннан икенче башына нәүрүз әйтеп, мулла файдасына ашлык җыеп йөргәннәр. Мәмсә карьясендә[3] бу әмер бик мөрәүвиҗ[4] вә кави[5] булган вә кәзалик[6] гайре карьяләрдә шулай.

«Нәүрүз әйтә без килдек,
Котлуг җәмалыңызны күрдек.
Нәүрүз мөбарәкбад!
Батман бирсәң, күп булыр,
Подаука бирсәң, аз булыр,
Пычак бирсәң, тамандар,
Шадибад, шадибад!»

Шул кабилдән[7] сәрд итдеке[8] мәкальләре шул хосустадыр». Мәрҗанинең сүзләреннән күренә ки, шундый тантаналы рәвештә, авыл мулласын ияртеп нәүрүз әйтеп йөрү Казан тирәсендәге авылларда моннан 100–150 еллар элек бик шаигъ[9] бер эш булган икән. Бу кызык гадәт безнең татар арасында күптән беткән инде.

Әлбәттә, бу гадәт кинәт кенә бетмәгән, бәлки, акрын-акрын тәнәззел итеп[10], башка әһәмиятсез формаларга кереп киткән булырга кирәк. Әле без белгән заманнарда да авылларда (хәтта Казанда) шәкерт малайларының нәүрүз әйтеп йөрү гадәтләре бар иде.

Гадәттә, ике кечерәк яшүсмер бала, яз көнне шәкертләр мәдрәсәдән таралганнан соң, авылдан-авылга, йорттан-йортка йөреп, парлап Нәүрүз бәетләрен көйләп укыйлар, өйдәге халык,

---

[1] Мәзбүр – әйтеп узылган.
[2] Карья – авыл.
[3] Мәмсә – Казан артында бер авыл. *(Авт. иск.)*
[4] Мөрәүвиҗ – таралган, киң кулланылышта булган.
[5] Кави – көчле.
[6] Кәзалик – шулай ук.
[7] Кабилдән – төркемнән.
[8] Сәрд итдеке – кешенең игътибарын җәлеп иткән.
[9] Шаигъ – таралган.
[10] Тәнәззел итеп – әһәмияте кимеп.

күбрәк хатын-кыз, җыелып, аларны тыңлыйлар, аннан соң, аларны алып кереп ашаталар, эчертәләр, һич булмаганда берәр ашамак нәрсәсе яисә акча биреп чыгаралар иде. Нәүрүз әйтүче малайлар, күбесенчә, ата-анасы, тәрбиячесе булмаган ятим балалар булып, шул рәвешчә җәй буе ил өстендә йөреп тамак туйдыралар. Халык та бу кечкенә «трубадур»ларны[1] ярата, аларны һичбер вакыт буш кул белән чыгармый иде. Менә шулай итеп, нәүрүз әйтү борынгырак заманда муллаларның халыктан сәдака-ашлык җыеп йөрүе белән бәйләнгән булса, соңгырак заманда да, бөтендөнья өчен гам[2] булган хәер эстәүче музыкант вә җырчыларның кәсебе шикелле, «инсафлы хәерчелек»тән башка бернәрсә түгел иде. Хасыйле кәлам[3], Нәүрүз бездә һичбер вакыт үзенең чын мәгънәсендә, ягъни яз бәйрәме буларак танылмаган, бәлки, бөтенләй башка, асыл Нәүрүз белән һич мөнәсәбәте булмаган бер формага куелган булган.

Нәүрүз әйтүче малайлар шул югарыда мәзкүр «Кыйссаи Нәбрүз» дигән китаптагы Нәбрүз бәетләрен үзенә махсус садә генә бер көйгә парлап җырлыйлар иде. Бу көй дә – «Мөхәммәдия», «Йосыф китабы», «Тәкый гаҗәб китабы» көйләре шикелле, халык арасында туган көйләрдән берсе. Бу төрле дини саналган китапларны уку өчен махсус булган халык көйләре, гәрчә аларда татар музыкасының төп аһәңе яңгыраса да, чын халык көйләреннән (җыр көйләреннән) бөтенләй башка булып аерылып торалар. Бу көйләр, ихтимал, безгә башка төрк халыкларыннан күчеп үзгәртелгәннәрдер. Һәрхәлдә, бу мәсьәләне тикшереп төбенә төшү – киләчәктә музыка шинасларыбыздан[4] көтелә торган бер хезмәттер. Халык үзе бу көйләрне җыр көйләреннән аерып йөртә. Алар турысында сөйләгәндә «җырлау»

[1] Урта гасырларда Яурупада илдән-илгә йөреп, сарайларда, касырларда үзләренең йә башка шагыйрьләрнең шигырьләрен музыка аккомпонементы белән җырлап, шуның бәрабәренә кунак булып йөрүче сәйяр җырчы шагыйрьләрне «трубадур» дип атаганнар. *(Авт. иск.)*

[2] Гам – гомуми.

[3] Хасыйле кәлам – кыскасы.

[4] Шинасларыбыздан – белгечләребездән.

түгел, бәлки «уку» тәгъбирен куллана (мәсәлән, «Мөхәммәдия уку», «Тәкый гаҗәб уку» илх[1]). Халык әдәбиятыбызның аерым бер кыйсемен тәшкил итә торган бәйтләрне көйгә салып җырлауны безнең халык «бәйт әйтү» дип атый. Күбесенчә бәйтләрне җыр җырлаган шикелле җырлыйлар, бәлки бераз такмаклабрак (көйләп) «әйтәләр» генә (музыкада моның өчен речитатив[2] дигән тәгъбир истигъмаль ителә[3]). Элегрәк заманнарда нәбрүз әйтүчеләр шикелле бәйт әйтүче малайлар да йөриләр, халык бәйтләрен парлап, көйгә салып әйтәләр иде. Нәбрүз әйтү исә шул бәйт әйтүнең бер нәүгысы[4] гына булырга кирәк. Халык «Нәүрүз китабы»ндагы нәзымнарны да бәйт дип атый, «нәбрүз әйтү» тәгъбирен куллана. Түбәндәрәк без бу бәйтләрнең халык әдәбияты белән мөнәсәбәте булганлыгын күрербез.

Без тикшерә торган китаптагы Нәүрүз бәйтләренең яз бәйрәме булган Иран нәүрүзе белән һичбер мөнәсәбәте юк. Бары тик бәйтләрнең һәрбер дүрт мисрагы[5] «Нәбрүз мөбарәкбад»[6] дигән җөмлә белән тәмамлана да, һәрбер дүрт мисраглы биш бәйттән соң:

«Шәһадбәт, шәһадбәт, Нәбрүз мөбарәкбад», –

дигән сүз тәкрар ителә. Бу сүзләр белән бәйтләрнең мөндәриҗәсе арасында һич бәгланыш юк. «Шәһадбәт» язылган булса да, бу сүз «шәһадбәд» дип тәләффыз ителә[7]. Ләкин фарсычага охшаган бу сүз һичбер төрле мәгънә аңлатмый. Шуның өчен Мәрҗани аны (үз тарафыннан дөресләп булса кирәк) «шадибад» рәвешендә язган. Ләкин дөресе «шад бад» булырга тиеш; бу сүз фарсыча «шадлык булсын» дигән мәгънәгә туры килә. «Шад» сүзе фарсыда озын әлиф белән «шаад» диебрәк тәләффыз ител-

[1] Илх – һәм башкалар.
[2] Речитатив – көйләп сөйләү.
[3] Тәгъбир истигъмаль ителә – аңлатма кулланыла.
[4] Нәүгысы – төре.
[5] Мисрагы – юлы.
[6] «Нәүрүз мөбарәк булсын» мәгънәсендә. *(Авт. иск.)*
[7] Тәләффыз ителә – әйтелә.

гәнгә, татарлар аны «шәһадбад» дип үзгәрткәннәрдер. Юкса, «шәһад» фарсыча һичбер төрле мәгънәгә туры килми.

Без файдаланган «Кыйссаи Нәбрүз» китабының эчке ягында текст алдыннан шушы сәрләүхә[1] язылган: «Кыйссаи ике былбыл –ике кызларның вәгазь әйтеп йөргән сүзләредер». Китап ике кыйсемгә бүленә. Башта Нәбрүз бәйтләренең кайдан килеп чыгуы хакында нәсер белән язылган җиде битле кыйссаи-мөкаддимә дәрҗ ителгән[2]. Бәйтләр турыдан-туры шуңар ялганып китәләр. «Зәманит (?)[3] булган көннәрдә бер карьядә бер кем ирсә вар иде, аның углы, кызы юк иде. Бу кем ирсә «Сүрәи Ихлас»ны укыр иде вә «Риҗаль әл-гаиб» догасын укыр иде...» дип башланып китә торган бу кыйссаның кыскача мөндәриҗәсе шушы. Бер авылда бер кешенең бер дә баласы юк икән. Көннәрдән бер көнне «Риҗаль әл-гаиб»тән берәү моңа кунакка килә. Аның догасы бәрәкәтендә Алла бу кешегә ике игез кыз бирә. Бу кызлар, 12 яшенә җиткәч, ирләр киеме киенеп, аталары йортыннан чыгып китәләр дә, бер авылдагы зур мәдрәсәгә кереп, җиде ел шунда шәкерт булып укыйлар. Мәдрәсәдә башка шәкертләргә катнашмыйча, икесе аерым бер бүлмәдә торып, бик тырышып уку белән мәшгуль булалар. Аларның кыз икәнен берәү дә белми. Менә беркөнне мәдрәсәгә килгән бер ишан, боларның бүлмәсеннән чыккан нурны (!) күреп, кыз икәнлекләрен кәшеф итә[4] дә казыйга әйтә: «Сезнең мәдрәсәгездә ике былбыл бар икән, алар сезгә муафикъ түгел, намәхрәмнәр[5]», – ди. Серләре ачылгач, кызлар бик оялалар. Ләкин хакыйкать хәл шәкертләргә фаш ителми, кызларны шыпырт кына чыгарып җибәрәләр (әмма бәйтләрдән аңлаган буенча, аларның хәлләре мәдрәсәгә фаш була). Бу ике кыз, мәдрәсәдән чыгарылгач, кая барырга белми аптырап, белмәгән җирләрдә адашып йөриләр. Урманда каракларга очрап, аларга тоткын булып, көчкә-көчкә генә ко-

[1] Сәрләүхә – исем.
[2] Дәрҗ ителгән – бирелгән.
[3] Чыганакта шулай сорау билгесе куелган.
[4] Кәшеф итә – ачыклый, белә.
[5] Муафикъ түгел, намәхрәмнәр – яраклы, тиң түгел, башкалар.

тылып качалар; авыру да булалар, ачлык җәфасын да татыйлар, әлхасыйль[1], аларның бер дә күрмәгәннәре калмый. Шул вакытта, кызларның башына бер фикер килә: без бер дә кызлар күрми үстек, аларны белмибез дип, авылларда кызлар карарга чыгып китәләр. Авыл саен йөрергә бер бәһанә[2] булсын өчен, алар шушы Нәүрүз бәйтләрен чыгаралар. Бу бәйтләрдә вәгазь диярлек нәрсә аз булса да, мөкаддимәне язучы намәгълүм мөәллиф[3] аларны вәгазь дип атый. Менә шулай итеп, алар, үзләре тасниф кылган[4] бәйтләрне әйтеп, авылдан авылга туенып йөри башлыйлар. Төскә бик матур булганга, кызлар аларны егетләр дип белеп, гашыйк булалар. Ничә еллар шулай йөргәннән соң, көннәрдән бер көнне бер бай аларны үзенең йортына алып кереп кунак итә. Бу байның кызы безнең кыз-шәкертләргә гашыйк була. Ләкин ике игез кыз икесе дә төскә нәкъ бертөсле булганга, гашыйк булган кыз аларны бер-берсеннән аера алмый гаҗиз була. Ахырысында казыйга баралар. Бер кыз ике егеткә бер юлы гашыйк булса, икесенә дә бара алмый дигән мәсьәлә уртага куела. Казыйның шәкертләрдән: «Сезнең берегез-берегез бу кызны алырга телиме?» – дип соравына каршы аларның оялып йөзләрен каплаулары казыйның күзен ача. Ул тегеләрнең кыз икәнлекләрен белеп, кай җирнеке булганнарын сорашып, үзләренә ун алтын биреп, вилаятьләренә озата. Аталары инде болар кайтканда ак сакаллы карт булган була, кызларын башта танымый тора. Тегеләр үзләрен таныткач, картның һушы китеп егыла. Һушына килгәч кочаклашып елашалар. Әлхасыйль, хикәя нәкъ гади Шәрык хикәятләре рәвешендә тәмам була. «Сүзләр күп булды мохтәсар кылдык[5]» дигән җөмлә белән язучы сүзен бетерә.

Бәйтләрнең мөндәриҗәсенә килсәк, аларда кызларның үзләре авызыннан шул ук мөкаддимәдәге кыйсса бераз кыскартылып сөйләнә. Мәдрәсәдә укулары, кыз икәнлекләре беленеп,

[1] Әлхасыйль – кыскасы.
[2] Бәһанә – сәбәп, сылтау.
[3] Намәгълүм мөәллиф – билгесез автор, төзүче.
[4] Тасниф кылган – иҗат иткән.
[5] Мохтәсар кылдык – кыскарттык.

мәдрәсәдән качулары, юлда мәшәкать чигеп йөрүләре, караклар кулына төшүләре хакында монда кыскача гына, тәртипсез генә булса да әйтелеп узыла. Әмма кыйссаның соңгы кыйсеме, ягъни бай кызының боларга гашыйк булуы, шуның аркасында булган маҗаралары, казыйга барулары, аталары йортына кайтулары хакында бәйттә бер сүз дә юк. Кызларның башларыннан кичкән эшләре хакында да бары бәйтнең башында гына сөйләнә. Анда да хикәя тәртипле генә рәвештә сөйләнеп бармый, арага кыйссаның барышына тәгаллегы[1] аз булган бәйтләр катышып китәләр. Гомумән, бәйтләр бик рәтсез һәм тәртипсез рәвештә төзелгәннәр. Аларның төзелешендә һичбер төрле план вә система дигән нәрсә күренми. Хәтта аларны соңгы рәвештә тәртипкә салырга да мөмкин түгел. Мөндәриҗә сыек, мәгънә аз, шигърият тә юк. Мөндәриҗәнең сыеклыгы күбесенчә бер үк әйберне кырык төрле итеп тәкрар кылу белән тутырырга теләгән төсле тоела. Барысы 14 биткә җыелган бу бәйтләрнең асыл әйтергә теләгән сүзләрен генә җыйсак, аларның бөтенесе өч-дүрт биткә сыеп бетәр иде. Бигрәк тә, бәйтләрнең ахыры, яртысының мөндәриҗәсе хакында нәрсә дип тә әйтер хәл юк. Анда тыңлап торучы кызларның эротизм хисләрен[2] кузгатыр өчен генә яраклы булган мисраглар һәртөрле итеп бәйт әйтүчеләрнең сәдака сорауларын аңлата торган мисраглар белән кара-катыш буталган. Шушы ике мәүзуг[3] һәртөрле формада тәкрар ителә.

Бәйтләр никадәр вәгазь дип аталсалар да, «вәгазь әйтик сезләргә» дигән шикелле җөмләләр никадәр еш истигъмаль ителсә дә, Нәбрүз бәйтләрендә вәгазь дип атарлык бернәрсә дә юк. Андагы «вәгазьләр»нең әүвәле-ахыры менә шушы бәйтләргә кереп беткән:

«Изге булса балаңыз,
Аны яхшы караңыз.

[1] Тәгаллегы – мөнәсәбәте, бәйләнеше.
[2] Эротизм – шәһвәният белән катыш гыйшыкка маиллек. *(Авт. иск.)*
[3] Мәүзуг – сюжет, тема.

Матур булса, саклаңыз,
Нәүрүз мөбарәкбад».

«Изге туар анадин,
Матур кызлар баладин.
Тәүфикъ телә Алладин,
Нәүрүз мөбарәкбад».

Чыгышсыз, мантыйксыз һәм эчке мәгънәсе ябышмаган җөмләләр бәйтләрдә бик күп. Андыйларга мисал итеп, югарыда китерелгән ике бәйтнең соңгысын китерергә мөмкин. Моның шикелле бәйтләр аларны тәртип итүченең мәгънәгә түгел, күбрәк кафиягә[1] игътибар иткәнлеген күрсәтә.

Кыз күзләү, кыз урлау, гыйшык, кияүгә бару шикелле мәсьәләләргә кагылып, тыңларга җыелган кызларны шаяртып, комплиментлар әйтеп, аларның эротизм тойгыларын кытыклау – менә шушы мотив Нәбрүз бәйтләрендә кызыл җеп булып сузылып бара. Мисал өчен төрле урыннан чүпләгән аерым-аерым бәйтләрне китерәбез:

«Сүзем шулдыр сезләргә,
Карап торган кызларга.
Күз тиермә безләргә,
Нәбрүз мөбарәкбад».

«Сабый кызның языгы юк,
Шәкертләрнең азыгы юк.
Бер үпкәннең языгы юк,
Нәбрүз мөбарәкбад».

«Һай, һай матур күп кызлар,
Начарлары күп сүзләр[2].
Ишеткәч, эчем сызлар,
Нәбрүз мөбарәкбад».

«Гаепләмә үземә,
Күзем төшсә йөзеңә.

[1] Кафиягә – рифмага.
[2] Сөйләр, сөйләшер. *(Авт. иск.)*

Хәйран калып үзеңә,
Нәбрүз мөбарәкбад».

«Ышанмаңыз кызларга,
Оста булыр сүзләргә.
Хәйлә кылыр безләргә,
Нәбрүз мөбарәкбад».

«Карап калың безләргә,
Гашыйк булдым сезләргә,
Икенче рәт килгәндә,
Нәбрүз мөбарәкбад».

«Ачуланма безләргә,
Бән әйтәем сезләргә.
Без килдек кыз күзләргә,
Нәбрүз мөбарәкбад».

«Ниндәй икән атасы,
Чибәр икән анасы.
Гүзәл-хуп кыз баласы,
Нәбрүз мөбарәкбад».

«Йөрмәс идек мал булса,
Матуррак яр булса.
Урлар идек җай булса,
Нәбрүз мөбарәкбад».

«Урлар идем – кул булса,
Качар идем – юл булса.
Үзе матур, хуп булса,
Нәбрүз мөбарәкбад».

«Хуб, җәмалдыр баласы,
Нә хәл итеп аласы.
Алсаң, безгә яраса,
Нәбрүз мөбарәкбад».

«Гозер сүзем шул сезгә:
Кызың бирең син безгә.

Савап булыр күп сезгә,
Нәбрүз мөбарәкбад».

Менә безнең яшь трубадурлар, шундый сүзләр белән, тыңлаучы хатын-кызның күңелләрен аулыйлар. Тыңлаучыларны мактап җырлау исә галәлгомум[1] трубадурларның хосусиятеннән. Безнең нәбрүзчеләр, тыңлаучы публиканың кемнәрдән гыйбарәт булуына карап, бәйтләрне дә төрләндерәләр. Һәркем өчен аларның алдан әзерләнгән калыплары, әзер (шаблонный) бәйтләре бар. Мәсәлән алар:

«Абзый эшең уң булсын,
Теләгәнең җуш булсын,
Күңелләрең хуш булсын,
Нәбрүз мөбарәкбад», –

дип, тыңлаучылар арасына кергән абзыйларга да тәлинкә тотып алалар. Аларга шулай тәлинкә тотмый ярамый, чөнки аларны туйдыручылар – шул тыңлаучылар.

Нәбрүз әйтүчеләр башта бәһане аз сорамыйлар:

«Вәгазь хакы биш алтын,
Бирсәң ярар ике алтын,
Карама ялтын-йолтын,
Нәбрүз мөбарәкбад».

Ләкин ахырда биш тиен алтын урынына биш тиен бакырга да риза булалар:

«Һай Иш бабай, Иш бабай,
Мич башындин төш, бабай.
Биш тиен акча бир, бабай,
Нәбрүз мөбарәкбад».

Алар, акча булмаса, әйбер белән алырга да яраталар:

«Булмас булса акчаңыз,
Намусыңа тартмаңыз...»

---

[1] Галәлгомум – тулаем.

«Әгәр булса җоныңыз,
Бардыр сезнең оныңыз.
Савап булыр биреңез,
Нәбрүз мөбарәкбад».

Акча яки әйбер бирмәсәң, аларны өйгә алып кереп сыйласаң да ярый:

«Вәгаземез аз булса,
Ашар идек каз булса.
Алда сөйгән яр булса,
Нәбрүз мөбарәкбад».

«Бардыр сезнең маеңыз
Яки бардыр балыңыз.
Бары берлән куюңыз,
Нәбрүз мөбарәкбад».

Моның белән генә тукталмый, алар чын-чын хәерчеләр теле белән соранырга тотыналар:

«Хәер бирсәң безләргә,
Ходა бирер сезләргә.
Безләргә – мескинләргә,
Нәбрүз мөбарәкбад».

Ләкин аларга бернәрсә дә бирми чыгару һич мөмкин түгел эш:

«Безнең сүзләр шул сезгә:
Ни булса да бир безгә,
Юкса, үпкә зур сезгә,
Нәбрүз мөбарәкбад».

«Вәгазь хакы буш булмас,
Юкса, эшең уң булмас.
Бирмәенчә котылмас,
Нәбрүз мөбарәкбад».

Тыңлыйсы килмәгәннәргә алар шушы бәйт белән җавап бирәләр:

«Безнең күптер сүземез,
Бер әйткәнгә түзеңез.

Матур түгел кызыңыз,
Нәбрүз мөбарәкбад».

Аларның «кызлар күзли килдек» дигәннәренә каршы «бездә кызлар юк» дип үзләрен бик үк өнәмәгәнлекләрен белдергәннәргә алар әйтәләр:

«Бар булса да кызыңыз,
Юк булса да кызыңыз,
Ни булса да, түзеңез,
Нәбрүз мөбарәкбад».

Гомумән, «Нәбрүз бәйте»нең мөндәриҗәсе бик сузылмалы (эластик). Бәйтнең асыл төзелеше буенча бу сүзләр һәммәсе мәдрәсәдән куылган кыз-шәкертләр исеменнән сөйләнсә дә, шул ук вакытта алар нәбрүз әйтүче малайларның үз исемнәреннән әйтелгән булып чыгалар.

«Нәбрүз бәйте» кайчан һәм кем тарафыннан чыгарылган? Һәрхәлдә, бу бәйт бик күптәнге әйбер булырга кирәк. Югарыда күрелгәнчә, Мәрҗанинең хәбәре буенча, моннан 150 еллар элек Нәбрүз бәйтләре һәм нәбрүз әйтү гадәте булган. Мәрҗани әйткән заманда нәбрүз әйтү бик таралган гадәт булганга, бу йоланы тагын да борынгырак заманнардан килгән эш дип уйларга кирәк була. Мәрҗани «Мөстәфад»нең бер урынында (1 нче җөзьә, 15 нче бит) бу бәйтләрне, «Шәһри Болгар газилары[1] бәйте»[2] белән бергә, үзе борынгы болгарлардан калган дип уйлаган әсәрләр рәтеннән саный. Ләкин, әлбәттә, аларны Болгар халкыннан калган дип әйтү – һичбер нәрсәгә нигезләнмәгән бер гипотеза (гыйльми фараз). Мәрҗани үзе дә бу хакта һичбер төрле ышанычлы дәлил китерми; кайчан чыкканы мәгълүм булмаган борынгы әсәрләр җөмләсеннән булганга күрә генә, ул алар хакында шул фикергә килгәнгә охшый. «Нәбрүз бәйте»нең теле исә бик яңа, ягъни халык теленә якын. Борынгы сүзләр анда юк; чыгтайчалардан «калуң, йөркәймез, калмагай», госманчылардан

[1] Газилары – сугышчылары.

[2] Тәэссефкә каршы без бу бәйтләрне кулга төшерә алганыбыз юк. *(Авт. иск.)*

«дүш, дүшмәк, улсаң, бән, кеби» шикеллеләр сирәк кенә очрыйлар.

«Нәбрүз бәйте»нең каян килеп чыгуын аңлар өчен, аның ярым халык әсәре булуына күз салу җитсә кирәк. Безнең халык әдәбиятында бик мәшһүр борынгы бәйтләрдән «Җиде кыз бәйте» аталган бер бәйт бар[1]. Анда җиде байның җиде кызы, ирләр киеме киенеп, Каргалы мәдрәсәсендә унҗиде ел укыйлар (бу Каргалы Оренбург Каргалысымы, әллә башка шул исемдәге бер-бер авылмы – бәйттән аңлашылмый). Көннәрдән беркөнне, мунчага су илткәндә, аларның кыз икәнлекләрен беләләр. Аннан соң алар нишләгәннәрдер – халык бәйтенең минем кулыма төшкән таркау мисрагларыннан бу хакта аерымачык бернәрсә дә аңлап булмый. Алай да шул зәминдә[2] шәкертләр арасында скандал чыгып, кызлар мәдрәсәдән куылып, бары җиде кыз арасыннан Бәдриҗәмал исемлесенең генә хәзрәтнең углына кияүгә чыгып калганлыгын белергә мөмкин. «Җиде кыз бәйте»нең беренче мисрагысын монда күчерәбез:

«Җиде байның җиде кызы,
Җидесе дә бер манер.
Мәдрәсәгә килеп кергәч,
Хәер бирдек бер талир.
.......................................
Унҗиде ел без укыдык,
Белмәделәр кыз дип үк.

Хәзрәтнең айгырының
Шлеясы мунчала.
Кыз икәнен белделәр
Су илткәндә мунчада.

Кызлар сабак укыйдыр
Бер-беренә карашып.
Кыз икәнебезне белгәч,
Шәкертләр йөри дулашып.

---

[1] Бу бәйт Казан артында язылып алынган. *(Авт. иск.)*
[2] Зәминдә – җирлектә.

Каргалының урамында
Чәчебезне алдырдык.
Җидәү барып, алтау кайттык,
Беребезне калдырдык.

Кызарып кояш чыкканда,
Бәдри билен буадыр.
Хәзрәтнең килене
Бәдриҗәмал буладыр.

Алтын тәхет эченнән
Очып чыкты ике кош.
Сиксән шәкерт арасында
Укып чыкты ике кыз».

Менә бу – бөтен хосусиятләре белән бер халык бәйте.

Бу урында халык әдәбиятыбызның бәйт аталган кыйсеме турысында берничә сүз әйтеп узарга тиеш. Безнең бәйтләр халык әдәбияты белән язма әдәбият арасындарак торалар. Бәйт дип халык җырлары тарызында[1], җыр калыбында төзелгән, бер-бер булып үткән яки хыялый вакыйга турысында сөйли торган (эпический[2]) җырга әйтәләр. Без үзебез аны, җырдан аерып, бәйт дип атасак та, руслар, мәсәлән, барыбер җыр (песня[3]) дип атарлар иде. Вәзен җәһәтеннән бәйт, күбесенчә, «кыска җыр» үлчәвендә була. Җырлардагы шикелле бәйтләрдә дә һәрбер дүрть юлның әүвәлге икесендә асыл мәкъсуттан[4] тыш булган әйберләр хакында сөйләнә. Бәйтнең аерым-аерым (дүртәр юллы) мисраглары арасында, төп мәүзугның бер булуына карамый, мөнәсәбәт-бәйләнеш булмый. Шуның өчен дә бәйтләр халык күңелендә тулы вә бөтен буларак саклана алмыйлар, аларның әле бер, әле икенче кисәге төшеп кала; мисрагларның бер-бер артлы тезелүендә дә бәйтне әйтүчеләр һичбер төрле

[1] Тарызында – рәвешендә.
[2] Кирилл хәрефләре белән язылган.
[3] Кирилл хәрефләре белән язылган.
[4] Мәкъсуттан – нияттән.

тәртип сакламыйлар. Шуның өчен дә халык бәйтләренең мөмкин кадәр тулы нөсхәсен хасыйл итәр өчен, гадәттә, бик күп кешеләр авызыннан язылып алынган вариантларны чагыштырып, бер-берсе белән тутырырга туры килә.

Бәйтләр һәрвакыт булып тора торган, гадәттән тышрак вакыйгаларга чыгарылганга, алар безнең күз алдыбызда мәйданга киләләр. Аларны чыгаручылар, күбесенчә, укый-яза белә торган кешеләр, мәсәлән, мәдрәсә шәкертләре була. Күп вакытта бәйтләр чыгарылганда ук кәгазь өстенә беркетеләләр һәм язма нөсхәләрдә, күчерү аркылы тараладалар. Ләкин өслүб вә рух җәһәтеннән халык иҗатына якын булганга, алар бик тиз халык арасына кереп китеп, укый-яза белми торган халык гаммәсе аларны үз әдәби әсәрләре шикелле күңелендә саклый һәм үзара берәүдән берәү ишетү аркылы тарата башлый. Халык әдәбиятындагы шикелле, бәйтләрнең мөхәррирләре мәгълүм булмый; ләкин бу да беленү белән беленмәү арасында гына тора, чөнки фәлән кеше чыгарган дип атап әйтелмәсә дә, халык алар хакында сөйләгәндә «фәлән авылның мәдрәсә шәкертләре чыгарган», ди. Менә шуның өчен бәйтләрне халык әдәбияты белән язма әдәбият арасында тора дигән идек. Шәкертләр шикелле укымышлы кешеләр тарафыннан чыгарылганга, бәйтләрнең телендә китап тәэсире җырларга караганда күбрәк була. «Җиде кыз» бәйтендә, мәсәлән, без шушы мисрагны күрәбез:

«Һәфте дөхтәр[1] китап укый,
Мулла хәйран каладыр».

Менә монда «җиде кыз» диясе урынга, сөйләшүдә һич истигъмаль ителми торган фарсыча сүз – «һәфте дөхтәр» диелгән. Моның шикелле китапчалыклар бәйтләрдә еш очрый.

Гадәттә, бәйтләр булган вакыйгаларга чыгарылалар. Ләкин кызларның ирләр кыяфәтенә кереп, яшеренеп мәдрәсәдә укулары чынлап та булган бер эшме, шундый фидаилек дәрәҗәсендә гыйлемгә мәхәббәтле татар кызлары хакыйкатән бер-бер вакыт

[1] Һәфте дөхтәр – җиде кыз.

дөньяда булганмы, әллә юкса, бу халык хыялыннан гына туган бер мәүзугмы – бу хакта без төпләп бер сүз дә әйтә алмыйбыз; чөнки халык бәйтләре арасында, «Сак-Сок бәйте» шикелле сыйрыф[1] хыялый булганнары очраган күк, «Мостафа мулла (Зөлхәбирә) бәйте» шикелле хыял белән хакыйкать бер-берсенә тәмам чиктәш булганнары да юк түгел.

«Җиде кыз бәйте» белән «Нәбрүз бәйте» мәүзуг ягыннан бер-берсенә тәмам охшыйлар. Кызларның саннарында гына башкалык бар: халык бәйтендә – гомумән, халыкның яратып истигъмаль итә торган рәкымнәреннән[2] (эпическое число[3]) җиде; «Нәбрүз бәйте»ндә – ике. Ләкин югарыда күрелгәнчә, халык бәйтендә дә бер урында җиде урынына ике диелгән (әлбәттә, моның күчерүче хатасы булуы да бик ихтимал). «Носрәт[4] бирсен» дигән шикелле бәгъзы бер китап сүзләре очраса да, «Нәбрүз бәйте»нең теле саф татарча һәм халык әдәбияты теленә бик якын. Анда өслүб ягыннан чын халык җырларына охшаган урыннар бар; мәсәлән: «Сайрамагач кош булмас, кошларга ул иш булмас», «Әби, бармы төн гөлең? Бирсә безгә орлыгын», «Алма татлы бал белән, егет йөрсә яр белән», «Алма бирдем алмадың, әллә кемне сайладың, сәүсәм, алмый калмамын» шикелле. Мөндәриҗәнең тәртипсез тезелүе, таркаулыгы белән дә «Нәбрүз бәйте» халык бәйтләрен искә төшерә. Аның вәзене дә – бәйтләр вәзене. Халык та аны бәйт дип атый; аның турысында китап хакында әйтелә торган «уку» тәгъбирен түгел, бәлки «әйтү» тәгъбирен куллана. Менә шушы мөляхәзәләрне[5] күз алдына алганда, Нәбрүз бәйтләре халык бәйтләре белән нәкъ бер рәвештә, бер үк юл белән мәйданга килгән булырга кирәк, дигән фикер башка килә. Халык телендә йөргән әсатыйри (легендарный) бер мәүзугны алып, ихтимал, бер-бер мәдрәсә шәкерте бу бәйтне башлап язып чыгаргандыр. Бәйттәге:

[1] Сыйрыф – тулысынча.
[2] Рәкымнәреннән – саннарыннан.
[3] Кирилл хәрефләре белән язылган.
[4] Носрәт – ярдәм.
[5] Мөляхәзәләрне – фикерләрне.

«Моны язды талиблар
Укысыннар гарифлар[1]», –

дигән сүзләр дә шуңар дәлаләт итәләр. Соңыннан, халык арасына кергәч, һәрбер халык әдәбияты әсәрләре күк, «Нәбрүз бәйте» дә күчереп сөйләүчеләр (исполнительләр[2]) тарафыннан күп үзгәртелүләргә, арттыру вә киметүләргә очрагандыр. Шулай итеп, төрле вариантлар мәйданга килгәннәрдер дә, шуларның берсе соңыннан берәү тарафыннан язылып алынып яки турыдан-туры бер-бер язма нөсхә буенча китап итеп бастырылгандыр. «Нәбрүз бәйте»нең халык арасында сакланып калган төрле кулъязмаларында беркадәр башкалыклар очрый. Мәрҗани тарафыннан китерелгән мисраглар яки аларның охшашлары басылган нөсхәдә юк. Гомумән, бу Мәрҗани әйтә торган борынгы «Нәүрүз бәйте»нең мәүзугы хәзерге «Нәбрүз китабы»ндагы бәйтнекенә бөтенләй башка булганлыгы күренеп тора.

## Иске шагыйрьләр

XVIII, XIX гасыр эчләрендә яшәп, Шәрык мәдәнияте тәэсирендә булган нәзым төзүчеләрне без шушы исем астына җыябыз. Икенче тәгъбир белән әйткәндә, аларны мәрсияче шагыйрьләр дип тә атарга мөмкин булыр иде, ләкин бу тәгъбир, әлбәттә, хаталы вә тулы булмаячак. Бу шагыйрьләр – чын мәгънәсе белән иске заман кешеләре. Әдәбиятыбызда яңалык дәвере башлану белән, алар беттеләр, тәмамән тарих күләгесенә керделәр. Алар – бездә бөтен куәте белән иске Шәрык даирәи фикер иясе, борынгы чыгтай вә госманлы әдәбиятлары хөкем сөргән дәвердә килгән кешеләр; миллият, халыкчылык, тәрәккый уяну, Яурупа артыннан бару шикелле идеяләр белән аларның, катрә[3] кадәр булсын, мөнәсәбәте юк. Алар бөтенләй

[1] Гарифлар – укымышлылар.
[2] Кирилл хәрефләре белән язылган.
[3] Катрә – тамчы.

Шәрык тәэсирендә, динчелек вә тәсаувыф[1] тәэсире астында җитешкән адәмнәр. Алар тудырган әдәбиятның хакыйкый төсен аңлар өчен, бу шагыйрьләрнең нинди сыйныфтан чыгуларына күз салу җитә. Бу сыйныф – заманасының бердәнбер кулына каләм тотарга кадир булган[2] һәм гыйлемне үзләренә монополия итеп алган сыйныфы, ягъни муллалардыр.

Гәрчә үткән гасырлар безгә, гадәт булып киткән караш буенча, бары тик караңгылык вә торгынлык дәвере булып кына күренсә дә, бу заманнарда бездә туңган динчелек вә схоластика чуалчыгыннан башка нәрсә булмаган төсле тоелса да, иҗат, фитърәт[3] вә алга омтылу чаткылары ул вакытта да бөтенләй юк булмаган. Дин бабында Курсави вә Мәрҗани күк хакыйкатькә ирешү юлында фикерләре эшләгән затлар булганы шикелле, алар арасында, Мөндеш авылының «мөнәҗҗим»[4] дип йөртелгән Фәйзулла мулла шикелле, чын дөньяви фәннәр бабында гакыллары йөргән, риязият[5] вә һәйәт[6] белән шөгыльләнгән кешеләр[7], Кышкар Сәгыйть хәзрәт шикелле, соңгы рәвештә алтын ясау фикере белән шашкан алхимиклар[8], Шәкенең мәшһүр Яхъя мулла шикелле, спиритизм (рух чакыру, җаннарны мөсәххәр итү[9]) белән исем чыгарган шәхесләр[10] дә килеп чыккалаган.

Шулай ук әдәбият вә шигырь бабы да безнең аңлы муллаларыбызга ят нәрсә булмаган. Алар арасында гарәп һәм Иран әдәбияты белән сөеп шөгыльләнүчеләр булгалаган. Ачык фикерле шәкертләр, мәдрәсәдә укыган чакларында, гади программадагы фәннәр, сарыф-нәхү, фикъһ, кәлям, мантыйк, тәфсир,

[1] Тәсаувыф – суфилык.
[2] Кадир булган – көче җиткән.
[3] Фитърәт – яратылыштан булган үзенчәлеккә.
[4] Мөнәҗҗим – астроном.
[5] Риязият – математика.
[6] Һәйәт – хәрәкәт күренеше буларак күк йөзендә әйләнә торган Җир һәм барлык галәм һәм шул турыда фән.
[7] «Мөстәфадел-әхбар», җөзьә 2, 258 бит. *(Авт. иск.)*
[8] Шунда ук, 249 бит. *(Авт. иск.)*
[9] Мөсәххәр итү – сихерләү.
[10] Шунда ук, 243 бит. *(Авт. иск.)*

хәдис белән генә канәгатьләнмичә, Шәрыкның мәхыз[1] әдәбиятка хасланган гыйлемнәрен, гаруз, кафия, бәлягать[2], бәдигъ[3], бәян шикелле фәннәрне дә моталәга кылганнар[4]. Мәкамате Хәририләрне[5], Сәгъди вә Хафизларны укучылар булгалаган. Гыйлем тәхсил итәр[6] өчен Борынгы Шәрык мәдәниятенең ояларыннан булган Төркестанга, Бохарага бару һәм хаҗ сәфәрләре аларга борынгы ислам мәдәнияте әсәрләре белән танышырга ярдәм иткән. Газали шикелле атаклы, ләкин Шәрыкта онытылган, ислам галимнәренең әсәрләре бәгъзан, тәсадефи[7] рәвештә булса да, аларның кулларына төшеп, иң сизгер вә үткен гакыллыларының фикерләренә яшен күк тәэсир иткән (Курсави, Мәрҗани). Шулай ук Шәрык шагыйрьләре белән дә алар Урта Азиядә вә Истанбулда танышканнар[8]. Төркестанда торып укыганда алар фарсы телен өйрәнергә мәҗбүр булып, фарсыча белү аркасында аларга Иран әдәбиятының бакчасына юл ачылган. Шунда ук алар чыгтай әдәбиятының классик әсәрләре белән дә таныша алганнар. Хаҗилар аркылы безнең Русиягә госманлы шагыйрьләренең дә әсәрләре килеп эләккәләгән. Безнең муллалар бигрәк тә Фөзүлине яратып укыганнар. Бик күп муллаларның ата-бабадан калган көтепханәләрендә, байтак икенче дәрәҗәдәге борынгы төрк шагыйрьләренең диваннары белән бергә, Фөзүлинең дә диванын очратырга мөмкин.

Шул шәкертләрнең бәгъзылары күңелләренә кергән әдәбият мәхәббәтен безнең Идел буена, ерак шимальдәге Болгар иленә дә алып кайтканнар. Бохарадан кайтып та, караңгы татар авылларында надан мужикка биш вакыт намаз укытып, кечкенә генә

[1] Мәхыз – фәкать.

[2] Бәлягать – матур сөйләү сәнгате, риторика.

[3] Бәдигъ – шигырьдә рифма, сүз уйнату.

[4] Моталәга кылганнар – өйрәнгәннәр.

[5] Мәкамате Хәририләрне – Әбү Мөхәммәд әл-Хәрири иҗат иткән мәкамнәрне.

[6] Тәхсил итәр – алу.

[7] Тәсадефи – очраклы.

[8] Күп иске көтепханәләрдә «Гөлстан»ның ташбасма белән Истанбулда басылган нөсхәләре табыла. *(Авт. иск.)*

мәдрәсәдә шәкерт җыеп, дәрес әйтеп гомер уздырырга мәхкүм булган[1] бу хәзрәтләр озын, эчпошыргыч кышкы төннәрне Сәгъдинең «Гөлстан» вә «Бостан»ын[2], Фөзүлинең, Хафизның диванын, ихтимал, Нәваиның «Көллият»ен[3] укып кыскартканнардыр, мәдәни дөньядан аерылуның кайгысын абыстай белән уртаклаша алмаганга, шулар белән бүлешкәннәр; Шәрыкның шигырь диңгезләренә чумып, надан остабикәнең гаилә хәятында бирә алмаганы рухани вә гыйшкый ләззәтләрене шуннан табарга тырышканнардыр.

Менә шул бөек мисаллар, даһи сәләфләрнең[4] әсәрләре безнең әдәбият сөюче хәзрәтне иҗат юлына сәвекъ итәләр[5], аны кулына каләм алырга кыстыйлар, рухын канатландырып, шигырьләр илһам итәләр... Менә ул, борынгы заманның шагыйре, күз алдына җанлы картина булып килә: кич, тышта буран яки шатырдаган Русия салкыны. Бакчага каратып салынган мулла йортының тәрәзәләрен кар каплаган. Хәзрәтнең өендә җылы, хәтта эссе, өй эчендә тынлык хөкем сөрә. Йомшак түшәккә батып, чыбылдык эчендә рәхәт-рәхәт йоклаган абыстайның мыш-

[1] Мәхкүм булган – дучар ителгән.

[2] Мәрҗани («Мөстәфад» 2, 218 нче биттә) элек заманнарда татар мәдрәсәләрендә Шәех Сәгъдинең «Бостан»ы дәрес итеп укылганын сөйли. *(Авт. иск.)*

[3] Мәсәлән, XIX гасыр шагыйрьләреннән Чүпрәле Вәли мулладан калган язуларда аның Нәваи һәм Хөсәен Байкара белән таныш булганлыгы күренә. Вәлиулла Алкаев Сембер губернасында Яңа Чүпрәле авылының имамы булып, мәрсияче, һөҗүче (сатирик) һәм экспериментчы (ягъни күз алдында булып торган бер вакыйга мөнәсәбәте белән, шундый ук, тәвәккыфсыз (туктаусыз) шигырь әйтергә көче җитә торган шагыйрь) булган. Казанда Зәңгәр мәчет мәдрәсәсендә укып мулла булгач та, Казан белән галякасын (бәйләнешен) өзмәгән. Шул вакыттагы, казанлы һөҗүче шагыйрь Кәрәм Хафиз белән һәрвакыт шигырь белән моназара (бәхәс) һәм мөнакашә (сүз көрәштерү) кылыша торган булганнар. Мәшһүр шагыйрь вә язучы Гали Чокрый белән дә гасырдаш булып, шулай ук шигырь белән көч сынашканнар. Аның һөҗүви шигырьләре күбесенчә бик садә татарча язылган. Кулымда бу затның байтак шигырьләре, нәзым белән язылган хатлары бар. Кирәкле материал җыелып беткәч, бу кеше хакында аерым бер мәкалә язарга өмет итәм. *(Авт. иск.)*

[4] Сәләфләрнең – борынгыларның.

[5] Сәвекъ итәләр – этәрәләр.

навы да тынычлыкны бозмый, бәлки арттыра гына. Хәзрәтнең фәрзәндләре[1] – мәхзүмнәр, мәхзүмәләр[2] дә йоклыйлар. Әнә тәбәнәк аяклы өстәл янында, май шәменең зәгыйфь яктысында аягын бөкләп хәзрәт утырган. Башында сарт кәләпүше. Ул үзен шул эчендә яши торган галәменнән бөтенләй ерактa, бер мәдәни кеше, Бохара мәдрәсәләренең берсендә дәрес әйтүче, буш вакытында шигырь белән шөгыльләнергә яратучы сарт дамелласы[3], һич булмаганда, шул мәдрәсәдә хөҗрә[4] биләүче пишкадәм[5] итеп хыял итә. Хәзрәтнең кулында күркә канатыннан ясалган, бик шәпләп юнылган каурый каләм. Ул шомартылган калын саргылт кәгазь өстенә, муллаларга махсус, тәгъликътан[6] үзгәргән рәсме хатт белән шытыр-шытыр нәрсәдер яза. Фикере, хыялы белән ул әллә кайларда. Шәех Сәгъдиләр, чәйханәле, шау-шулы базарлы, балчык өйле эссе шәһәрләр, мәһабәт таш мәчетләр галәмендә.

Ул үзен, Шәех Сәгъди дәрәҗәсендә үк булмаса да, теге сарт дамелласы төсле шагыйрь итеп фараз кыла... Тәгаен, ул үзенең күптән түгел генә вафат булган остазына яисә шәехенә багышлап мәрсия яза торгандыр...

Омтылу – бер нәрсә, истигъдад[7] – икенче нәрсә. Үзләрен шагыйрь итеп фараз иткән муллалардан, әлбәттә, күбесе, әсәрләрен укып мәфтүн булган[8] шагыйрьләренә якын килү түгел, хәтта аларга азмы-күпме тәкълид тә итә[9] алмаганнар; күбрәге ничек кирәк алай нәзым оештырудан, мәрсия, мәдхия, мөнәҗәт, касыйдә язудан үтмәгәннәр.

Гомерендә бер мәртәбә һич шагыйрь булмаган кеше дә, азапланып, көчәнеп булса да, шигырь тәртип итә ала. Әгәр дә без

[1] Фәрзәндләре – сабыйлары, балалары.
[2] Мәхзүмнәр, мәхзүмәләр дә – мулла малайлары-кызлары.
[3] Дамелласы – югары укымышлысы, дәрес бирүчесе.
[4] Хөҗрә – бүлмә.
[5] Пишкадәм – укуда башкалардан алда булган шәкерт.
[6] Тәгъликътан – гарәп хәрефе белән языла торган язу төрләреннән берсе.
[7] Истигъдад – сәләт.
[8] Мәфтүн булган – сокланган.
[9] Тәкълид тә итә – иярә дә, охшата да.

Мәрҗанинең «Мөстәфад әл-әхбар»ын, Риза хәзрәтнең «Асар»ын актарып карасак, анда берничә дистәләп шагыйрьләр табабыз – бөтенләй диярлек муллалар. Алар арасында киң Русиянең һәртөрле почмакларында һәм авылларда, һәм шәһәрләрдә яшәгән кешеләр бар. Күбрәге – XIX гасыр адәмнәре, ләкин XVIII гасырда торганнары да юк түгел. Күбесенчә, алардан бер-ике шигырь сакланып калган: китап артына язылган берәр бәйт яки мәнзумә[1], аерым кәгазь парчаларында берәр мөнәҗәт яисә, берәүгә-берәүгә багышланып, икенче кешеләр кулында сакланган мәрсия яки мәдхия. Бу төрле шагыйрьләрдән тарихта исемнәре вә әсәрләре сакланганнарының саннары 30–40 лап булса, онытылганнары, әсәрләре тәләф булып[2], югалып, янып киткәннәре, яки караңгы бер авылда, һичбер нәрсә белән кызыксынмый торган надан мулланың, ата-бабасыннан калган, гомердә бер мәртәбә ачылмыйча, шүрлектә тузан җыеп ята торган иске китаплары арасында яшеренеп ятканнары, ихтимал ки, йөзләп саналырга тиештер.

Бу кешеләр, әлбәттә, фи нәфсиһи[3] шагыйрь булмаганнар. Иң элек алар мәхәлләләрендә имам, аннан соң мәдрәсәләрендә мөдәррисе яки мөрид тәрбияләүче ишан, аннан соң гына алар – шагыйрь. Шигырь язу аларның тормышында әһәмиятле бер эш түгел; ул болай гына, буш вакытны тутырыр өчен, «зиһен шаяртыр» өчен генә эшләнә. Ләкин шулай булса да, нәзым тәртип итү мәсьәләсендә виртоузлык дәрәҗәсенә килеп җиткән муллалар да булгалаган. Мәсәлән, алар бер-берсенә язган гади хатларын да нәзым белән язалар икән (Габделкаһир мулла, Чүпрәле Вәли мулла).

Шигырь язарга һәвәс иткән[4] муллаларның гади татар муллалары массасыннан аерылып тора торган кешеләр, үз сыйныфларының каймагы булулары бәдиһи[5]. Бер заманда бер халыкта гыйлем-укымыш кайсы сыйныф кулында булса, мәдәният

[1] Мәнзумә – шигъри әсәр.
[2] Тәләф булып – әрәм-шәрәм булып.
[3] Фи нәфсиһи – үзләре.
[4] Һәвәс иткән – омтылган.
[5] Бәдиһи – ачык.

тезгенен кай сыйныф үз кулында тотып алып барса, гадәттә, ул халыкның әдипләре дә шул сыйныф эченнән чыгалар. Мисал: ике йөз елга якын рус әдәбиятын русларның бердәнбер чын зыялы сыйныфы булып килгән дворяннар үз кулларында тоттылар. Безнең татарның зыялы сыйныфы исә элеккеге гасырларда бары тик муллалар-руханилар иде. Шуңар күрә әдәбият та алар кулында булды. Без монда бары нәфис әдәбиятны гына алмыйбыз. Гомумән, һәрбер кулына каләм тотып язучы шул сыйныфтан буладыр иде. «Мөстәфад әл-әхбар» вә «Асар»да борынгы муллаларыбызның тәрҗемәи хәлләрен укысак, аларның һәрвакыт язучылык белән мәшгуль булуларын күрәбез. Алар, мәдрәсәдә торганда үзләренә укыр өчен, мулла булгач моталәга итәр[1] һәм көтепханәләрендә булындырыр өчен, үз куллары белән дистәләрчә китаплар күчергәннәр. Ләкин бу эш һәрбер гади мулла өчен дә мөмкин эш булган. Моның нәтиҗәсе, әлбәттә, хәзерге заманда матбагалар әда итә[2] торган хезмәт, ягъни китап күбәйтүдән башка нәрсә булмаган. Ләкин безнең муллаларның галимрәкләре болай матбага[3] ролен уйнау белән генә канәгатьләнмәгәннәр; үзләре китап тасниф итәргә җөрьәт[4] иткәннәр. Мосаннифлекнең[5] муллалар карашында нинди зур һәм мөкаддәс эш булып танылганлыгын искә алсак, «мосанниф» дигән сүз артына һәрвакыт «рәхмәтуллаһи галәйһи» кушылып йөртелүен хәтергә төшерсәк, ни өчен монда «җөрьәт» дигән тәгъбирне куллануыбыз аңлашылса кирәк. Бу җөрьәт, күбесенчә, иске китапларга шәрех[6] язудан ары китә алмаган. Андый шәрех язучы муллаларны без бик күп очратабыз. Ләкин Курсави, Мәрҗани шикелле үзләреннән чыгарып яңа китаплар язган галимнәрнең саны, әлбәттә, бармак белән санарлык кына. Кирәк мосаннифләр, кирәк шәрехләр булсын, дини мәүзуглар-

[1] Моталәга итәр өчен– уку, өйрәнү өчен.
[2] Әда итә – үти.
[3] Матбага – типография.
[4] Тасниф итәргә җөрьәт – китап язарга батырчылык.
[5] Мосаннифлекнең – китап төзүнең, язуның.
[6] Шәрех – аңлатма.

да[1] әсәрләр язучы муллалар үзләренең китапларын җитди әсәрләр өчен бердәнбер әдәби тел итеп хисапланган гарәп телендә язганнар. Голәма өчен булган бу әсәрләрне төрки теле шикелле «әкъбәх әл-лисан»[2] булган, тупас телдә язу гадәте булган. Хәттә, гарәп теленә багыну шул дәрәҗәгә барып җиткән – «Сөбат әл-гаҗизин» шикелле төрки китапларга да гарәпчә шәрех баглаучы муллалар булгалаган. «Әфсах әл-лисан»[3] дип игътикад ителгән[4] тел – Коръән иңгән һәм оҗмах әһле сөйләшәчәк тел гарәп теле – шулкадәр рәвәҗдә[5] булгач, аны мөкәммәл[6] рәвештә белү һәрбер үзен галим дип санаган татар мулласы өчен лязим булган; һәм аны мөкәммәл белгәннәр дә. Шагыйрь-муллалар арасында гарәпчә шигырь язучыларны байтак кына очратырга мөмкин. Фарсычаны алар күбесенчә яхшы белгәннәр. Фарсы телендә дә шигырь сөйләгән һәм китаплар язган муллалар юк түгел. Бу ике шәриф[7] телдә язарлык, хосусан, шигырь тәртип итәрлек куәткә малик[8] булу, шөбһәсез, алар каршында кәмаләтнең соң дәрәҗәсе итеп хисапланган. Ихтимал, алар төркичә язуны гаҗизлектән, гарәп-фарсыны кирәгенчә белмәгәнлектән генә җаиз[9] күргәннәрдер.

Мәрсияче шагыйрьләрнең теле хакында сөйләгәндә, «төркичә» дигән тәгъбирдән башканы кулланыр хәл юк, чөнки аларның телен татарча дип әйтеп булмый. Бу – бик күп гарәби вә фарсы сүзләр, хәтта гыйбарәләр белән чуарланган, чыгтайча, госманлыча, татарчадан үстерелгән бер әдәби шивә. Анда кайда чыгтайча тәэсире башланып, кайда госманлыча яки татарчаныкы эшләнгәнен һич аңларга мөмкин түгел. Аларның әдәби теленә үзләренең ана телләренең тәэсире булганлыгы шикелле,

[1] Мәүзугларда – сюжетларда.
[2] Әкъбәх әл-лисан – пычрак тел.
[3] Әфсах әл-лисан – матур тел.
[4] Игътикад ителгән – ышанган.
[5] Рәвеҗдә – таралган.
[6] Мөкәммәл – камил.
[7] Шәриф – хөрмәтле.
[8] Малик – ия.
[9] Җаиз – яраклы.

шул заманда бик модада булган, хәтта халык арасында да укылган чыгтай вә госманлы китаплары да тәэсир итми калмаганнар. Шулай итеп, безнең борынгы әдәби телебез мәйданга килгән. Ләкин, бу тел дә бөтенләй бертөрле түгел; шул ук мәрсиячеләр дә җиңел мәүзугларга шигырь язганда (мәсәлән, һөҗүви бәйтләрдә), сөйләшү теле белән бер диярлек татарча тел кулланганнар. Авырлык вә җиңеллектә төрле шагыйрьләрнең өслүбләрендә байтак аермалар табыла. Һәрхәлдә, аларның телен – аз-маз укыган Идел буе татары аңлый алганы шикелле, Урта Азия вә госманлы төркләренә дә ул аңлашылырлык булган. Чынлап та, бу «Тәрҗеман бабай»ның гомуми тел идеалына бик якын килә торган бер тел инде!

Мөндәриҗә[1] ягына килсәк, без үзебезнең шагыйрь-муллаларыбызда зур истигъдад[2], даһилык дәрәҗәсенә ашкан шигъри ялкын тапмыйбыз. Гомуми фикер торгынлыгы, халкыбызның мәдәни түбәнлеге, икътисади изелүе әдәбиятта бөек истигъдадларның, тирән фикерләрнең даһилык мөһере сугылган әсәрләрнең мәйданга килүенә манигъ[3] булган. Үзләренең остазларына, ишаннарына, заманасындагы мәшһүр бер галимгә, аларның фикерләрне тулкынлаткан әсәрләренә багышлап язылган мәдхияләр, вафатлары мөнәсәбәте белән язылып, аларның кәмаләтләрен зикер иткән[4] мәрсияләр, пәйгамбәрне мактаулар, Ходага мөнәҗәтләр, тәсаувыфи[5] касыйдә вә мәнзумәләр – менә безнең иске заман шагыйрьләренең каләмнәрен тибрәткән мәүзуглар күбесенчә шулар. Гомумән, Шәрык әдәбиятларына тәкълид иткәнлекләреннән, аларның шигырьләрендә тәсаувыф вә тарикать фикерләре, дөньядан бизү һәм охравият[6] идеяләре хөкем сөрәләр. Бу шагыйрьләр арасында без байтак кына тәсаувыф

[1] Мөндәриҗә – эчтәлек.
[2] Истигъдад – сәләмәтлек, талант.
[3] Манигъ – киртә, сәбәп.
[4] Зикер иткән – искә алган.
[5] Тәсаувыфи – суфичыл рухлы.
[6] Охравият – ахирәтлек, мәңгелек.

вә тарикатъ әһелләрен, ишаннарны очратабыз (мәсәлән, Вәлид ишан, Һибәтулла ишан, Яхъя ишан, Мәхмүд ишан шикелле).

Шагыйрь-муллаларның күбесе соңында безгә берәр-икешәр генә шигырь сакланып калса да, араларында шигырь белән җитди рәвештә шөгыльләнгәннәре, нәзым белән язылган бөтен-бөтен рисаләләр калдырганнары да бар. Мәсәлән, Багдад шәһәрендә дөньяга килеп, соңыннан Русиядә Сәгыйть бистәсендә имам булып торган Хаҗи Багдади дип мәшһүр булган шагыйрьнең Мөхәммәд пәйгамбәрнең дөньяга килүе (мәүлид) хакында нәзым белән язылган бер китабы бар; бу китапның ахырында ул «Сәргүзәштәи[1] хаҗи» сәрләүхәсе[2] астында шигырь белән үзенең тәрҗемәи хәлен яза (Асар, 6 нчы җөзьә); Һибәтулла ишанның бик күп газәл, касыйдә вә мәрсияләреннән башка «Мәҗмәгъ әл-әдәб» һәм «Төхфәт әл-әүлад» исемнәрендә басылып таралган мәнзум[3] рисаләләре бар; Әбелмәних хаҗинең нәзым белән язылган әсәре – шулай ук басылган китаплардан; Габдерәхим Утыз Имәнинең язган әсәрләренең саны уннан артык, күбесе нәзым белән язылган; XIX гасырның соңгы яртысындагы язучылардан Чокыр авылының мулласы Гали Чокрыйның да шигырь вә нәсер белән язылган байтак әсәрләре бар. Иске шагыйрьләр арасында, мөстәсна[4] булып кына, Шәмседдин Суфи шикелле чын шигъри хиссияткә малик булган, «шагыйрь» исемен камил лияkать[5] белән күтәрерлек затлар да очрый.

Әлхасыйль[6], татар халкының үткән гасырлардагы мәдәният тарихына күз йөрткәндә, ул заманда да үзенә бертөрле әдәби хәрәкәт, әдәби хәят булганлыгы күзгә чалына. Муллаларның алгы сафта тора торган аңлы, күзе ачык булганнары әдәбият вә шигырьгә махсус фәннәрне өйрәнгәннәр, гарәп, Иран вә төрек шагыйрьләренең әсәрләрен ләззәтләнеп укыганнар; үзләре дә

[1] Сәргүзәштәи – иң зур ялганчы.
[2] Сәрләүхәсе – исеме.
[3] Мәнзум – тезмә.
[4] Мөстәсна – аерым.
[5] Лиякать белән – лаек булучылыгы белән.
[6] Әлхасыйль – озын сүзнең кыскасы.

шигырь белән шөгыльләнеп, һәртөрле мәнзум китаплар вә шигырьләр тәртип иткәннәр; бер-берсенә көйле хатлар язганнар; шигырь аркылы бер-берсен илзам итү[1] өчен, бер-берсенә каршы бәйтләр язышканнар (Чүпрәле Вәли мулла, Гали Чокрый, Кәрәм Хафиз). Һөҗү (сатира) һәм мөзахка (юмор) да өлеш чыгаручылар булган (шулар ук һәм «Фәлсәфә Шакир»).

Шагыйрьлек бер муллаларга гына хас булмаган. Мәсәлән, Казандагы XIX гасыр шагыйрьләреннән Кәрәм Хафиз мулла түгел, бәлки коръәнхафиз гына. Ул хәтта хафизлыгын да бер якка ташлап, һәртөрле юлда көчен сынап баккан (мәсәлән, балта остасы – столярлык кылган). Бу кешене бик үткен телле, һөҗүче шагыйрь булган дип сөйлиләр. Ләкин хәзергә кадәр аның шигырьләрен кулга төшерә алганыбыз юк. Казанның мәшһүр Апанаевлар нәселеннән килгән, «Фәлсәфә Шакир» ләкабе[2] белән мәшһүр булган зат шулай ук үткен вә ачы теллелеге, кешегә туры әйтүе, тормышка фәлсәфи карашы белән ат казанган, һәр туры килгән урында экспромт рәвешендә шигырь әйтә ала икән. Фәлсәфә Шакирның заманасындагы төрле кешеләрдән көлеп язган бәйтләре хәзердә дә бәгъзы бер төп казанлылар кулында табыла. Чутай Мостафа – бәгъзы бер «сәер» эшләре белән легендарный зат булып киткән бер адәм: Казанда XIX гасыр ахырында үзенең хәттатлыгы[3] белән мәшһүр булып, тәгъликъ язуында аның тиңдәше булмаган; дәрвишләр шикелле ялгыз яшәп, балаларга хөсне хат[4] өйрәтү белән шөгыльләнеп гомер кичергән; тәсаувыф шигъриятен тирәнтен аңлаучы Иран әдәбиятының мохлисе[5], фарсы теленең мөтәхассыйсы[6] булган; Хафиз, Сәгъди, Фирдәүси аның һәрвакыт укый торган шагыйрьләре икән («Мөстәфад»ның беренче җөзьенең ахырында бу кешенең Шиһаб хәзрәт вафатына багышланган бер мәрсиясе бар). Татар-

[1] Илзам итү – бәхәстә җиңеп чыгу.
[2] Ләкабе – кушаматы.
[3] Хәттатлыгы – каллиграфлыгы.
[4] Хөсне хат – матур язуны.
[5] Мохлисе – дусты.
[6] Мөтәхассыйсы – белгече.

станның төрле урыннарында мондый кешеләрнең охшашлары, әлбәттә, тагын булгандыр.

Язуда яки күңелдә сакланып калган хатирәләргә караганда, бу шагыйрьләрнең күбесенең үзләренә бертөрле сәер табигатьле (оригинал) адәмнәр булганлыгын күрәбез. Алар арасында дөньяга, байлыкка һич исләре китмәүче, әфкяре гаммә[1] белән хисаплашырга теләмәүче дәрвиш табигатьлеләре булганы шикелле, байларга тәлинкә тотып, дөньяви әүкатларын[2] шуңар бина кылучылары да булган. Соңгылары, мәшһүр байларның заказлары буенча, аларның үлгән аталарына вә кардәшләренә багышлап бик мөбаләгале[3], бөтен кагыйдәләргә туры китереп төзелгән мәрсияләр тәртип иткәннәр. Аларның эшләгән хәйрат[4] эшләрен, мәсәлән, салдырган мәчет-мәдрәсәләрен мактап, мәдхияләр язганнар. Шуның бәрабәренә, әлбәттә, «гайре рәсми гонорар» йөзеннән, «ингам-ихсан»[5] белән файдаланганнар. Заманасындагы буржуазиянең мәдәният ягыннан алдагы сафта торучылары, әһле гыйлемне[6] сөюче, зирәклек вә үткен сүзне тәкъдир итүчеләре алар өчен меценат ролен уйнаганнар. Алар, бер яктан, үзләрен мактау вә күтәрү бәрабәренә, шагыйрьләрне матди яктан күтәрсәләр, икенче яктан, аларның әсәрләрен бастырганнар, яки бастыру юлында ярдәм итешкәннәр. Шулай ук китап бастыручы һәртөрле Казан мещаннары да алар өчен шул ук рольне уйнаганнардыр.

Шулай итеп, без элек тә (хосусан XIX гасырда) Идел буе татарлары арасында, даирәне таррак алып әйткәндә, аларның югары сыйныфларының каймагы эчендә, заманасының иҗтимагый вә мәдәни әхваленә мөтәнасиб[7] рәвештә кечерәк кенә,

[1] Әфкяре гаммә –күпчелек уе, фикере.
[2] Әүкатларын – вакытларын.
[3] Мөбаләгале – күпертелгән, арттырылган.
[4] Хәйрат – изге.
[5] Ингам-ихсан – сыйлау-ярдәм.
[6] Әһле гыйлемне – гыйлем ияләрен.
[7] Мөтәнасиб – туры килгән.

чын шәрыкча, ләкин үзенә бертөрле җанлылыктан хали[1] булмаган бер әдәби хәрәкәт булганлыгын мөшаһәдә итәбез[2]. Яурупа тәэсире керә башлау белән, яңа фикерләр белән ашланган яшь буынның җитешүе белән, бу әдәби хәрәкәт туктамады. Бәлки башка, яңа формаларга гына куелып дәвам итте. Насыйри, Халиди шикелле бер аягы белән Шәрыкта, бер аягы белән Гаребтә тора торган кешеләр бу юлда күпер булдылар.

### *1. Габдерәхим Утыз Имәни*

Заманасының иң галим кешеләреннән булган Габдерәхим хәзрәт Казан губернасы Чистай өязе Утыз Имән авылында 1730 елларда дөньяга килгән. Бу зат берничә мәртәбә ислам мәмләкәтләренә сәяхәт иткән һәм шунда гыйлем тәхсил кылган[3]. Үзе шул авылда имам булып дәрес әйткән (Риза хәзрәт 6 нчы җөзьә «Асар»да аның Тимәш авылында дәрес әйткәнлеген сөйли). 1815 елда үз авылында вафат булган[4]. Каюм Насыйриның риваять итүенә күрә, Габдерәхим хәзрәт «фазыйль вә камил вә галим гаҗәб гамил муафикъ сөннәт вә мөҗтәниб әгъмаль вә әкъваль әһли һава вә бидгать»[5] бер адәм булган. Кул астындагы халыкка бары фарыз гыйбадәте генә кылдырып, сөннәт вә нәфелләрне һич эшләтми; әгәр авыл халкыннан берәүберәү мәсьәлә сораса, русчалатып: «Ышту тибә? Пашнә паши, хлиб еж дә ыстуй!»[6] – дип кенә җавап бирә икән. Габдерәхим мулла: «Русиядә тереклек кылучы мөселманнар өстенә йөкләнгән фарызлар кырык бер, кырык беренчесе русча белү», – дип әйтә торган булган. Әмма үзенең өендә тәрәзәләре кечкенә генә

[1] Хали – буш.

[2] Мөшаһәдә итәбез – күрәбез, таныйбыз.

[3] Тәхсил кылган – белем алган.

[4] Без бу зат хакындагы мәгълүматны, башлыча, Каюм Насыйриның 1877 елгы календареннән алдык. *(Авт. иск.)*

[5] Сөннәткә муафикъ гаҗәеп гамәл кылучы һәм буш эш, буш сүздән һәм яңалыктан тыелучы фазыйләтле һәм камил галим.

[6] «Нәрсә сиңа? Сука гына сукала, икмәгеңне аша да. Тора бир!» мәгънәсендә. *(Авт. иск.)*

рамкасыз тәрәзәләр икән, чөнки, аркылыга[1] охшый дип, рам куйдырмаган. Габдерәхим, үзе ишан булмаса да, тәсаувыфка мәел[2] бер кеше булган булырга кирәк – аның язган һәм әһәмият биргән китапларына карап, шул фикергә килергә мөмкин.

Габдерәхим хәзрәт гомерендә бик күп китап язган. Үзе шагыйрь кеше булып, төркичә нәзым белән язылган байтак китаплары булган. Әсәрләре башлыча шушылар:

1. Суфи Аллаһиярның «Сөбат әл-гаҗизин»енә шәрех.

2. Аның ук «Морад әл-гарифин» атлы китабына гарәпчә шәрех.

3. «Рисаләи мөһиммә» – гакаид[3] вә әхлак бабыннан халык өчен язылган көйле бер китап.

Бу – Габдерәхим хәзрәтнең бердәнбер басылган әсәре булса кирәк. Мөәллиф[4] аны «ниндидер казай илаһи башына төшеп» мәхбүс булгач[5], хибестә[6] вакытта язган, имеш. Насыйри аны «халык кулында мөстәгъмәл[7] гаҗәп бер мәнфәгатьле китап» дип атый.

4. «Тәшнигъ әс-сефаһаи» – берәүнең (билгеле бер шәхеснең?) нәмәшруг[8] эшләрен тәнкыйть вә тәхкыйр итеп[9] язылган, биш фасылдан мөрәккәб[10] төркичә нәзымлы бер китап. Дибаҗәсе[11] фарсыча шушы рәвешчә башланып китә: «Сәна улсун ки бездин ул Ходага, дөруд булсун дәхи һәм әнбияга».

5. «Тәнзиһ әл-әфкяр фи нәсаих әл-әхйар тасниф Габдерәхим мин әһел әл-Болгар» – төркичә нәзымлы вәгазь-нәсыйхәт рисаләсе. Башлануы шушы рәвешчә: «Фәсахетдин кемә-кем тиксә бәһрә, нәсаих әйләгәй әһел дийарә».

---

[1] «Аркылы»га – бу урында тәре мәгънәсендә.
[2] Тәсаувыфка мәел – суфичылыкка күңел куйган.
[3] Гакаид – ышану.
[4] Мөәллиф – китап язучы.
[5] Мәхбүс булгач – зинданга ябылгач.
[6] Хибестә – тоткынлыкта.
[7] Мөстәгъмәл – кулланылышта.
[8] Нәмәшруг – шәригать кушмаган һәм шәригать каршында дөрес булмаган эш.
[9] Тәхкыйрь итеп – хурлап.
[10] Мөрәккәб – төзелгән.
[11] Дибаҗәсе – кереше.

6. «Гавариф әз-заман» – надан суфилар хакында төркичә нәзымлы бер рисалә. «Сәна ул Тәңрийә хәллякы галәм, яратды кодрәте дин бонча адәм» дип башлана. Надан суфиларны ярат-мау Утыз Имәнинең хосусиятеннән булган.

7. «Нәшер әт-тәкъриб» – нәсер белән язылып, «вә бәгъдә мөэмин кордашлар, дин юлында юлдашлар...» дип башлана торган бу рисалә «Гавариф әз-заман»га шәрех итеп язылып, «Рисаләи мөһиммә» эчендә басылган икән.

8. «Җенах әл-фәлях фи зәмми мөбах» – шәрган мөбах[1] булган кайбер эшләрнең зарарларын сөйли торган төркичә нәзымлы бер рисалә. Түбәндәге бәйт белән башлана: «Әй мөбахдә юк зыян дигән кани, гел ишеткел бу сүзе белгел аны».

9. «Сәйф әс-сарим» – Насыйри «Габдерәхим мулланың шул исемдә фарсыча бер рисаләсе булырга кирәк», ди. Ләкин ул аны үзе күрә алмаган.

10. «Төхфәт әл-мөлүк» – 57 баблы, фарсычадан тәрҗемә кылынган «Тәгъбирнамә» (төш юрау китабы).

11. «Дөррәт әл-фахирә», яки «Ахирәтнамә» – үлгәннән соң булачак әхвәлне[2] сөйләгән бер рисалә. Насыйри аның хакында «гайре телдән тәрҗемә ителгән» дип кенә китә, әмма кайсы телдән икәнен әйтми.

Моннан башка тагы нигә истинадәндер[3], Каюм Насыйри Утыз Имәни әсәрләре рәтеннән мәшһүр «Бәдәвам китабы»н да саный. Ләкин «Бәдәвам», шөбһәсез, аныкы булмаска кирәк; Мәрҗани «Мөстәфад»та моны кат-кат тәэкид итә[4]; шаяд,[5] аның моңар дәлиле булмыйча булмагандыр. Шулай ук Бакырганиның «Ахырзаман» китабын да Габдерәхим хәзрәткә нисбәт бирүчеләр булган. Ихтимал, аның «Ахирәтнамә»сен «Ахырзаман китабы» белән буташтырганнардыр. Мөәллифе мәгълүм булма-

[1] Шәрган мөбах – шәригать буенча гамәлләр.
[2] Әхвәлне – хәлләрне.
[3] Истинадәндер – таяныптыр.
[4] Тәэкид итә – кабатлый.
[5] Шаяд – бәлки, ихтимал.

ган мәшһүр әсәрләрне атаклы язучыларга нисбәт бирү һәрбер халыкта булган гомуми бер гадәт инде ул.

Насыйри Габдерәхим мулланы «бик шагыйрь адәм иде», ди. Чынлап та, нәзым белән шулкадәр күп нәрсәләр язуына караганда, ул, һич булмаганда, шигырьнең техника ягын яхшы белгән булырга тиеш. Тәәссефкә каршы[1], аның әсәрләре белән үзебез танышырга муаффәкъ була алмадык[2]. Каюм Насыйри китергән башлангыч бәйтләргә караганда, бу шагыйрьгә Суфи Аллаһиярның зур тәэсире булганлыгын аңларга мөмкин.

Каюм Насыйриның язмалары арасында Утыз Имәнинең матбугатта чыгарылуы мөмкин булмаган оятсыз тәгъбирләр катыштырылып язылган бер шигыре булган. Насыйриның шәкертләреннән берсенең күчергечендә сакланып, бу шигырь иттифакый[3] рәвештә безнең кулга төште. Шигырьдә бер төркем кызларның бер яшь егеткә очрап, ирләрнең хатыннардан һәм билгакес[4] асыл матлублары[5] нәрсә булуы хакында моназара[6] кылулары тасвир итемә. Егетнең алдына «гыйшык өстәп йөрүче» бер кызны китерәләр. Кыз төскә ямьсез булганга күрә, егет аны рәд итә[7]. Кызлар аңар игътираз итеп[8], ирләрнең хатыннарда эзләгәннәре бары тик коры шәһвания[9] һәм хайвани теләкләрне канәгатьләндерү генә булганлыгын исбат итәргә тырышалар. Егет аларга бик матур җавап бирә; безнең хатыннардан теләгәнебез – бары матурлык, ди:

«Диде күрклү йөздә вардыр мәгънәи фал,
Аңлаяннар мәгънәсен әйтмәз җәдаль[10],

[1] Тәәссефкә каршы – үкенечкә каршы.
[2] Насыйри Утыз Имәнинең бар әсәрләре Казанда Печән базары мәзинендә булганлыгын сөйли. *(Авт. иск.)*
[3] Иттифакый – очраклы.
[4] Билгакес – киресенчә.
[5] Матлублары – теләкләре.
[6] Моназара – бәхәс.
[7] Рәд итә – кире кага.
[8] Игътираз итеп – каршы килеп.
[9] Шәһвания – азгынлык, бозыклык.
[10] Әйтмәз җәдаль – бәхәсләшмәс.

Белсәңез гәр мәгънә идәрсез бере
Бәс, лязимдер сайламак безгә сезе.
Ни сәбәбдән сөннәт улды күзләмәк,
Күрклү йөзне сәгый идүбән[1] эзләмәк».

Аларның хайвани яклары бары безне җирәндерәләр, күңелебезне генә кайтаралар, ди:

«Бәлки дөньядин күңел тәмам бизәр,
Гәр каләм сынса, кеше ничек язар
Шунда безгә каш вә һәм күрклү йөз
Хаҗәт улур күркле һәм дилфөруз[2]
Максудымыз хасил ула ул заман
Һәм хәҗаләтдән[3] улавыздыр аман».

Аннан соң, егет хатыннарның ирләреннән төп матлублары[4] аларның күркле йөзләре түгел, бәлки хайвани яклары икәнен сөйләп, кызларны мөлзәм итә[5].

Менә бу тәәссефкә каршы порнографиягә бирелеп язылган шигырьнең төп фикере-идеясе бик матур, бик шигъри. Бу – чын-чын тәсаувыф идеологиясеннән туган фикер. Анда аскетизм, каба[6]-җисмани, дөньяви хәяттан вә ләззәттән качу, чиркану һәм дөньяда Алланы изһар итә[7] торган матурлык, гармония һәм рухани ләззәт эзләү аермачык күренеп тора. Шагыйрьнең әйтүенчә, күп кешеләр «игрәнүбән тәрке дөнья кылдылар»[8], ягъни суфилар, хатыннарның хайвани атрибутларыннан җирәнеп, дөньяга кул селтәгәннәр. Әмма шул ук суфилар үзләренең Аллага булган саф, рухани гыйшыкларын матур кызларга, матур егетләргә булган мәхәббәт белән тиңләштерәләр.

---

[1] Сәгый идүбән – тырышлык белән.
[2] Күңелләрне ягучы, ягъни гүзәл кызлар. *(Авт. иск.)*
[3] Оялу. *(Авт. иск.)*
[4] Матлублары – теләгәннәре.
[5] Мөлзәм итә – туктарга мәҗбүр итә.
[6] Каба – тупас, дорфа.
[7] Изһар итә – күрсәтә.
[8] Игрәнүбән тәрке дөнья кылдылар – чирканып, дөньявилыкны читкә куйдылар.

Әлхасыйль, Утыз Имәнинең бу шигыре аның чын шагыйрь рухлы адәм булганлыгын күрсәтә. Әгәр дә аның башка һичбер әйбер язганы мәгълүм булмыйча, бары тик шушы шигыре генә сакланып калган булса да, аны шагыйрьләр рәтенә тезәр өчен җитәр иде. Шиксез, бу шагыйрьнең бу «әдәпсез» шигыре әдәби яктан аның бик күп һәм бик озын дини таснифларыннан[1] югары торадыр.

## *2. Әбелмәних Хаҗи*

Әбелмәних Хаҗи – безнең борынгы шагыйрьләребез арасында үзенең шагыйрьлеге белән зуррак урын тота торганнардан берсе. Әбелмәних Әбелфәез углы (Әбелмәних бине Әбел-Фәез) – XIX гасырның башында Оренбург Каргалысында (Сәгыйть бистәсендә) торган кеше. Ул мулла булмаган булырга кирәк. Әмма Бохарага барган. Анда шул заманның мәшһүр ишаны Ниязколый Төркмәни исемле шәехнең ханәкаһендә (тәкиясендә[2]) шул ишанның хезмәтендә бераз торган. Ләкин үзе ишан булырга иршад алу дәрәҗәсенә җитмәгән булырга кирәк. Бу ишанны Әбелмәних үзенең китабында бик мактый, аны икенче Хуҗа Баһаведдин иде, башкаларга нисбәтән солтан иде, ди. 1815–1816 елларда Әбелмәних, Мөхәммәд Йосыф исемле ниндидер бер илчегә юлдаш һәм аның хосусый имамы булып, Истанбулга сәфәр итә. Бу илче Бохара ханлыгыннан Төркия солтанына барган. Әбелмәних тә, Русиягә кайтмыйча, турыдан-туры Бохарадан бу сәфәргә чыккан булса кирәк. Бу илченең кем тарафыннан һәм нинди йомыш белән Истанбулга җибәрелүе хакында без артык нәрсә белә алмадык. Илчеләр һәйәтендә булганга күрә, безнең Әбелмәних Истанбулда вакытта Төркия хөкүмәте тарафыннан зур хөрмәтләр күргән. Ул вакытта Төркиядә солтан Мәхмүд падишаһлык сөргән заман булган. Истанбулда илле көн торганнан соң, Әбелмәних, илчеләрдән аерылып, ялгыз гына

[1] Таснифларыннан – китаплар язуыннан.

[2] Тәкиясендә – мөридләрнең ишан кул астында зекер әйтү өчен җыелып утыра торган урыннары.

хаҗ кылу нияте белән Хиҗазга сәфәр кылган. Юлда ул Мисырга да туктаган. Бу мәшһүр Мөхәммәдгали пашаның Мисырны забит иткән[1] заманнары икән. Безнең сәйях[2] аны бик мактый һәм күтәрә. Хаҗ кылганнан соң, Әбелмәних, кире Истанбулга кайтып, теге Бохара илчесенә юлыккан. Илченең үтенүе буенча үзенең сәяхәтен тасвир итеп, кыска гына бер шигырь язган. Бераздан ул үзенең ватанын сагынып, Сәгыйть бистәсенә кайткан. Кырык яшьләрендә вакытта яңадан хаҗ кылу нияте белән сәфәр кылган икән. Ләкин әҗәле ирешеп, шушы сәфәрендә милади 1824–[18]25 елларда горбәттә[3] вафат булган.

Әбелмәних Хаҗиның шигырь белән язылган, матбуг[4] бер әсәре бар. Тулы исеме «Тәрҗемәи хаҗи Әбелмәних әл-Бистәви әс-Сәгыйди» булган бу китап беренче мәртәбә Казанда 1845 елда басылган, урта кулда 51 битле бер әсәр. Мөндәриҗәсе төрле әүлияләр, суфилар тормышыннан алынган кыска-кыска хикәяләрдән гыйбарәт. Әбелмәних аларны «Тәфсире кәбир»[5] һәм «Мишкәт әл-әнвәр»[6] китапларыннан алып язган. Шуның өчен ул китабын «тәрҗемә» дип атый. Хикәяләр бәхре рәмел һәм бәхре һәзәҗ[7] вәзеннәре белән язылганнар. Сүз арасында бер урында мөәллиф, үзенең кыскача тәрҗемәи хәлен сөйләп, Истанбулга вә Хиҗазга сәяхәтенә мөфассаллырак[8] туктала. Шулай ук, иститрад йөзеннән[9], китапта аның үзенең бәгъзы бер хосусый фикерләре, бер мөнәҗәте һәм илченең үтенүе буенча язган шигыре дәрҗ ителгән[10]. Дүртенче җөзьә «Асар»да Әбелмәнихның бу китабына кермәгән янә берничә шигыре күчерелгән. Бу шигырьләрдә ул суфиларча, дөньяның фанилыгыннан

[1] Забит иткән – басып алган.
[2] Сәйях – сәяхәтче.
[3] Горбәттә – чит җирләрдә.
[4] Матбуг – басылган.
[5] «Тәфсире кәбир» – «Олы тәфсир».
[6] «Мишкәт әл-әнвәр» – «Нурлар чыганагы».
[7] Бәхре һәзәҗ – гаруз системасында рифма төрләре.
[8] Мөфассаллырак – тулырак.
[9] Иститрад йөзеннән – сүз уңаеннан.
[10] Дәрҗ ителгән – теркәлгән.

бәхәс итеп, аның хәйләләренә алданмаска өнди. Бу шигырьләр, шулай ук китабындагы хикәяләр дә Әбелмәних хаҗиның чибәр генә әдәби куәткә малик[1] булганлыгына дәлаләт итәләр. Риза хәзрәт, аның шигырьләрен күчергәннән соң: «Бу урында язган шигырьләр һичбер йирдә вә һичбер гасырда йөз кызартачак шәйләр[2] дәгелдер», – ди, һәм элеккеге заманнарда Сәгыйть бистәсендә «фәсыйх[3] шагыйрьләр вә хуш сөхбәтле зарифлар[4], мәҗлесләре җан азыгы булган саф күңелле әдипләр бик күп» булганлыгын сөйләп, хәзердә Каргалының бары тик каргаларга оя булып барганына тәәссеф итә[5]. Чынлап та, әүвәлге гасырларда Каргалы яки Сәгыйть бистәсе татарның мәдәни мәркәзләреннән берсе булган булырга кирәк. Бу бистәдән байтак шагыйрь кешеләр вә язучылар чыкканлыгы безгә мәгълүм.

### *3. Габделкаһир Сөләйман углы*

Бу кеше – Уфа янындагы Каршин-Шәриф авылындагы Сөләйман ахунд дигән галим мулланың углы. Үзе дә шул ук авылда торып, 63 яшендә 1831–[18]32 елларда вафат булган. Ул шушы авылда мулла булган булырга кирәк. Гәрчә аның имам булуы хакында «Асар»да ачык әйтелмәгән булса да, бөтен нәселләре голәма вә муллалар булганга, шулай дип тәхмин итәргә[6] мөмкин.

Габделкаһир әдип вә шагыйрь кеше булган. Аның нинди әсәрләр язганы безгә мәгълүм булмады. Тик аның иң гади хатларны да нәзым белән язуына карап, шигырьгә бик оста булганлыгын аңларга мөмкин. Вәзен һәм кафияне ул тәмамән үзенә мөсәххәр иткән[7] булырга кирәк, чөнки иң ашыгыч язылган хатларын да көйләп яза икән. Риза хәзрәт аның берничә шундый

[1] Малик – ия.
[2] Шәйләр – әйберләр.
[3] Фәсыйх – матур телле.
[4] Сөхбәтле зарифлар – оста сүзле кешеләр.
[5] Тәәссеф итә – кайгыра.
[6] Тәхмин итәргә – билгеләргә, фаразларга.
[7] Мөсәххәр иткән – буйсындырган.

мәктүбен[1] күргәнлеген сөйли; ләкин шуларның берсен генә «Асар»га дәрҗ иткән[2]. Бер-берсенә язган хатларны шигырь белән язу безнең борынгы әдипләребез арасында шаигъ[3] булган бер гадәт иде. Тәәссеф ки[4], бу шагыйрьнең башка әһәмиятлерәк әсәрләре табылмаган.

### *4. Шәмседдин Суфи Зәки*

Безнең борынгы шагыйрьләребез арасында иң парлак[5] исем – шөбһәсез, Шәмседдин Суфи. Тукай гыйбарәсе белән әйтсәк, бу – аларның тәсбих тезмәсенең «Мәрьям анасы». Әгәр дә ул булмаса иде, әгәр дә аны Мәрҗани белән Риза казый онытылу туфрагы астыннан казып чыгармаган булсалар иде, безгә бөтен мәрсияче шагыйрьләр хакында сөйләп торуның әһәмияте дә калмас иде. Чөнки мәрсияче шагыйрьләрнең бөтенесен бергә алганда да, бер Шәмседдин Суфига алмаштырырга мөмкин түгел. Шәмседдин Суфи аркылы без Суфи Аллаһияр, Ясәви шикелле чын суфи шагыйрьләргә генә түгел, бәлки турыдан-туры чыгтай әдәбиятының классикларына, Нәваиләргә тоташабыз. Ул безнең Идел буе әдәбиятын чыгтай әдәбиятының алтын гасыры белән бәйли. Шәмседдин Суфиның беренче мәртәбә «Асар»да басылып чыккан шигырьләре әдәбият сөючеләрнең күзләренә аяз көндә яшен шикелле тәэсир иткән булса, аның тәрҗемәи хәле вә мәнакыйбе[6] белән танышу да шулай ук һәрбер кешенең исен китерергә тиеш. Чынлап та, ул гадәттән тыш булган бер хадисә[7], ничә гасырда бер килә торган бер феномен. Риза казый

[1] Мәктүбен – хатын.
[2] Дәрҗ иткән – язган.
[3] Шаигъ – таралган.
[4] Тәәссеф ки – кызганыч ки.
[5] Парлак – күркәм.
[6] Мәнакыйбе – мактаулы эше.
[7] Хадисә – вакыйга.

аны гаҗаиби дөньядан саный һәм мәшһүр гарәп шагыйре вә философы Әбүл-Галә әл-Мәгарри[1] белән тиңләштерә.

Шәмседдин Ярмөхәммәд углы Оренбург өязендә Зәк суы буендагы Ишмәт авылында дөньяга килгән. Шул суга нисбәтән аны Зәки дип атаганнар. Кечкенә вакытта ук аның күзләре сукырайган; шуңа күрә, аңар бездә сукырларга әйтелә торган «Суфи» кушаматы тагылган. Элек ул Эстәрле өязендә Котлыгилде дигән кешедән, аннан соң Ашказар-Балыклысы авылында Габдерахман хәзрәт мәдрәсәсендә укып, соңыннан гыйлем төгәлләр өчен Казанга килеп, Күл буе – икенче мәчет хозурындагы Мөхәммәдкәрим хәзрәт мәдрәсәсенә кергән. Анда укып, пишкадәмлек[2] дәрәҗәсенә ирешеп, шул мәдрәсәнең иң галим шәкертләреннән булган. Ләкин шәкертләрне котыртып, моназарага[3] һәвәсләндереп, мәдрәсәдәге тормышның тыныч агымын бозганга күрә, Мөхәммәдкәрим хәзрәт аны мәдрәсәдән чыгарган. Шуннан соң ул үзенең туган авылына кайтып, мәдрәсә ачып, күп шәкерт җыеп, дәрес әйтергә тотынган. Ләкин монда да тыныч яши алмаган. Авыл халкы белән үпкәләшеп, үзенең бөтен шәкертләре белән бергә Эстәрлебаш авылына, Харис ишан хозурына күчеп китеп, шунда дәрес әйтүендә дәвам иткән. Гомерендә ике тапкыр өйләнеп, үзеннән соң ике углы калган. Шәмседдин Суфи 40 яшендә вакытта хаҗ кылу нияте белән сәфәр чыгып, 1865 елда Таганрог шәһәрендә кинәттән вафат булган.

Шәмседдин Суфиның гади кешеләрдән булмаенча, зур бер рухани көчкә малик[4] булган зат булуы аның шушы кыска гына тәрҗемәи хәленнән дә күренә. Кечкенәдән ике күзе дөм сукыр булып, инсан һәм аның кәмаләте өчен лязим булган хәвасе

[1] Әбүл-Галә әл-Мәгарри (973 ел – 1057 яки 1058) – тумыштан сукыр гарәп шагыйре һәм фикер иясе, фәнни трактатлар, фәлсәфи-гуманистик эчтәлекле шигырьләр, тезмә әсәрләр авторы. Әл-Мәгарринең иҗаты гарәп, фарсы һәм төрки, шул исәптән татар әдәбиятларына (Хисам Кятиб, Сәйф Сараи, Ш. Зәки, Дәрдемәнд, Н. Думави) зур йогынты ясый.

[2] Пишкадәмлек – иске мәдрәсәнең тулы уку курсын бетергән хөрмәтле кеше.

[3] Моназарәгә – бәхәскә.

[4] Малик – ия.

хәмсәнең[1] иң әһәмиятлесеннән мәхрүм булуына карамый, бу адәм тормышны үзе теләгәнчә борырга яраткан. Пишкадәм вә хәлфәлек дәрәҗәсенә җиткәннән соң, мәдрәсәдән сөрелү шикелле гади кешеләр, гади шәкертләр күз алдында зур хурлыкны муҗиб[2] була торган бер вакыйга да аны үзенең бер алган юлыннан туктамый. Ул тота да, күп уйлап тормастан, мәдрәсәдән чыгып, икенче бер җиргә барып мәдрәсә ачып, үзе дәрес әйтергә керешә. Күрәсең, аның киң табигате педант хәзрәтнең тоткан киртәләренә сыймаган. Аның үз теләгәнен булдыру юлында һичбер манигъ[3] алдында туктамавы искитәрлек: авыл халкы белән килешә алмавы аны, тормышын агулап, халык белән этләшеп гомер итәргә мәҗбүр итә алмый. Ул бөтен шәкертләре белән куба да, ул авылны билкөллият[4] ташлап, мәдрәсәсе белән икенче бер авылга барып урнаша. Дәрвакыйг[5], көчле бер шәхсият (сильная личность[6]). «Сукыр суфи» булуына карамый, бу кеше безнең күз алдыбызда мескен булып, аягын чак кыймылдатып, таяк белән кармаланып йөргән хәлдә килми, бәлки, башын югары күтәргән килеш, дөп-дөп басып, юлына аркылы төшкәнене кырып-җимереп, җир өстен дер селкетеп алга, үзенең максатына омтылган бер Алып батыр хәлендә килә.

Суфи дигән кеше безнең иске мәдрәсә тормышын белгән адәмнәрнең күз алдына мәгълүм һәм мөгайян[7] бер тип булып килеп баса. Суфи – мәдрәсә хәяты өстенә үскән кирәксез, ләкин лябүддәминһе[8] булган бер гөмбә иде ул. Ул, безнең иске мәдрәсәләрнең ярым дарелгаҗизин[9] булуыннан файдаланып, шунда оялаган, бушка ашап, түшәмгә төкереп, тиккә гомер уз-

[1] Хәвасе хәмсәнең – биш тойгының (күрү, ишетү, ис сизү, тәм тату, тотып белү).

[2] Муҗиб – сәбәп итүче.

[3] Манигъ – киртә.

[4] Билкөллият – бөтенләй.

[5] Дәрвакыйг – чынлап та.

[6] Кириллицада бирелгән.

[7] Мөгайян – ачык, билгеле.

[8] Лябүддәминһе – аермасы юк.

[9] Дарелгаҗизин – картлар йорты.

дырып ятучы бер сорыкорт иде. Һәрбер мәдрәсә, электән килгән традиция буенча, суфисыз булмаганга күрә, аның күз алдында булуына һәркем күнеккән була, хәтта мәдрәсәдә аны яраталар да. Суфи булмаса, мәдрәсә тормышының бер чите китек төсле тоела иде. Суфи шәкертләр арасында мөзахчы – шут ролен уйный; үзенең үткен сүзләре, көлкеләре, әкият сөйләүләре, җырлаулары, артистча кыланулары белән ул аларның күңелләрен ача. Эч пошкан чакларда бер юаныч, шәкертләрнең шаяруларына, мыскыл итүләренә калкан була. Күбесенчә ул усал, хәйләкәр, үткен вә зирәк. Аны һәрвакыт алдарга телиләр, ләкин ул алдатмый; аны һәркем котырта, ләкин тапкыр җавап белән ул һәммәсенең авызын яба. Гади мәдрәсә программасындагы гыйлемнәрне узу суфи өчен лязим түгел, ул укый икән, хәзрәтнең дәресенә утыра икән, бары тик болай гына, ирекле тыңлаучы булып кына утыра. Затән[1], сукырлыгы аңар тәртипле рәвештә укырга манигъ[2] була. Күп булса, ул Коръән бикли[3], кыйраәт иттерә, мәчеттә намаз артыннан Коръән укый. Гадәттә, суфи – мәдрәсәдә иң надан кешеләрдән берсе.

Менә гади суфи тибы шушы. Инде аның белән без Шәмседдин Суфины чагыштырып карасак, алар арасында, күз сукырлыгыннан башка, һич бер-берсенә охшаган сыйфат таба алмабыз. Күзенең дөм сукыр булуына карамый, ул бик күп күзлеләр дә ирешә алмаган кәмаләт дәрәҗәсенә ирешә. Аның кувәи хафизәсе[4] искиткеч дәрәҗәдә: ул Коръәнне генә түгел, «Шатиби», «Иттикан», «Сөлләм вә тәзһиб», «Гакаиде Нәсәфи», «Дәүвани» һәм башка шуның шикелле зур-зур китапларны күңеленнән белә. Бөтен мәдрәсәдә укыла торган гыйлемнәрне күңелдән укып, башына сеңдереп, үзе мөдәррис булып дәрес әйтерлек бер хәлгә килә. Аның кәмаләтләре моның белән генә дә чикләнми: аны белгән бер кешенең сөйләвенчә, Шәмси Суфиның дөнья һөнәрләреннән, кул эшләреннән дә һич белмәгәне булмаган.

[1] Затән – нигездә.
[2] Манигъ – киртә.
[3] Бикли – ятлый.
[4] Кувәи хафизәсе – ятлау көче, зиһене.

Мәсәлән, җөмләдән берсе, ул ватык сәгатьләрне сүтә, аннан соң бөтен механизмны кире җыеп урнаштырып, сәгатьне йөртә икән. Яурупалылар тарафыннан ачылган мәктәпләрдә тәрбияләнгән сукырларның кәрҗин үрү шикелле һөнәрләрдән артык уза алмаганнары хәлдә, безнең суфиның мәхыз[1] үз иҗтиһады белән, күзлеләр өчен дә шактый гына башваткыч булган сәгатьчелек һөнәренә хуҗа булуы, дәрвакыйг[2], искитмәслек эшләрдән түгел. Хасыйле кәлям[3], Шәмседдин Суфиның мәнакыйбе[4] белән танышканнан соң, күңелгә, ихтыярсыз, бу кеше сукыр булмаган булса, нинди булыр иде икән дигән, фикер килә.

Шуның өстенә тагы Шәмседдин Суфи тирән фикерле, гаҗәп нәзек тойгылы бер шагыйрь дә булган. Бу бабта ул тагын да артыграк кәмаләт сахибе[5] булып, бу типтагы татар шагыйрьләренең үз заманасындагыларын да, үзеннән элеккеге һәм үзеннән соңгыларын да фәрсәхләрчә[6] артта калдырган. Ихтимал, аны шагыйрьлек ягыннан үз заманында тәкъдир итүче булмагандыр. Ләкин гадәттә бит һәрбер бөек кешене үзеннән соңгылар – хәләфләре[7] тәкъдир итәләр.

Шәмседдин Суфи – тәсаувыф мәсләгендәге шагыйрь (бу җәһәттән дә «суфи» ләкабе аңар бик дөрес бирелгән булып чыга). Заманасының теләве буенча, аңар шулай булмый мөмкин дә булмаган. Шәмседдин Суфи торган вакытлар – безнең әдәбиятыбызда Шәрык әдәбиятларына тәкълидән, тәсаувыф идеяләре хөкем сөргән заман. Безнең Идел буе әдәбиятында бу шагыйрь тәсаувыф шигъриятенең иң югары нокталарына ирешә алган. Аның шигырьләренең кыйммәтен аңлар өчен, аларны берәмберәм тикшерергә хаҗәт юк, бәлки үзләрен укып чыгу җитә. Тәәссефкә каршы, аның әдәби мирасы бик кечкенә: төркичә

[1] Мәхыз – тик.
[2] Дәрвакыйг – чынлап та.
[3] Хасыйле кәлям – кыска гына әйткәндә.
[4] Мәнакыйбе – мактаулы эшләре.
[5] Кәмаләт сахибе – камиллек иясе.
[6] Фәрсәх – 6–7 км га тиң булган озынлык үлчәү берәмлеге.
[7] Хәләфләре – дәвам иттерүчеләре.

шигырьләренең саны алты-җидедән артык түгел. Вәхаләнки[1], бу кадәр шигъри куәткә малик булган кешедән аз дигәндә бер диван[2] көтәргә мөмкин иде. Шөбһәсез, аның шигырьләре болар гына булмаган, күбрәк кыйсеме тәләф булып[3] югалып беткәндер. Шулай булса да, аның шушы шигырь валчыкларына карап кына да, Шәмседдинның даһилык дәрәҗәсендә истигъдадлы[4] лирик булганлыгын бер дә тартынмыйча әйтергә мөмкин. Риза хәзрәт аның шигырьләрен бездә соңгы елларда гына шөһрәт казанып киткән борынгы гарәп шагыйре Мәгарри шигырьләре белән чагыштыра һәм үз тарафыннан аның Мәгарри әсәрләре белән таныш булуы бик ерак ихтималлардан булуын сөйли, икенче тарафтан аны мәшһүр Иран шагыйрьләренә һәм XV гасырның чыгтай әдипләренә тиңләштерәсе килә. Шиксез, ул алар белән дә, гарәп шагыйрьләре белән дә таныш булган булырга кирәк. Юкса ул бөтен Шәрыкның тәсаувыф әдәбияты өчен уртак булган бу фикерләрне, бу өслүбне, бу тарызы ифадәне[5] кайдан алсын? Шәмседдин Суфиның гарәпчә һәм фарсыча язылган шигырьләре дә бар иде. Димәк, ул бу ике телне үзенең ана теле шикелле мөкәммәл[6] белгән.

Безнең шагыйрь дә, Иран шагыйрьләренең мәшһүрләреннән Хафизлар, Җәлал Румилар, Низамилар яки төрк шагыйрьләреннән Нәваиләр, Лотфилар, Бакыйлар, Фөзүлиләр шикелле, өстән караганда халис[7] дөньяви гыйшыкка багышланган төсле шигырьләр язган. Әгәр аларны хәрфиян[8] аңлаган сурәттә, шагыйрь үзенең бер кызга булган гыйшкы турысында сөйли икән дип уйларга мөмкин. Монда асыл максатның Аллага гыйшык икәнен, бөтен сөйләнгән сүзләрнең киная икәнен, безнең башка

[1] Вәхаләнки – чынлыкта.
[2] Диван – җыентык.
[3] Тәләф булып – әрәм-шәрәм булып.
[4] Истигъдадлы – талантлы, сәләтле.
[5] Тарызы ифадәне – мәгънәне.
[6] Мөкәммәл – камил.
[7] Халис – чын.
[8] Хәрфиян – хәрефкә хәреф; сүзен сүзгә.

могтәдилрәк[1] иске шагыйрьләрдәге шикелле турыдан-туры шигырьләрнең үзләреннән аңлап булмый. Тәсаувыф әдәбиятының тарызы ифадәсе белән таныш булмаган укучыга Шәмседдин Суфиның шигырьләре чын-чын гыйшкый шигырьләр булып күренә алалар. Аның лирикасы, гомумән караганда, пессимизм рухы белән сугарылган. Гәрчә бу пессимизм дөньядан, тормыштан бизү тәсаувыф шигъриятенең хосусиятеннән булган бернәрсә булса да, шагыйрьнең кайгы-кимчелегенең (сукырлыгының) да моңар тәэсире булмагандыр дип әйтеп булмый. Аның пессимизмының артык куәтле һәм самими булуы шуны күрсәтә. Суфи шагыйрьләр арасында бик шат күңелләләрен дә очратырга мөмкин.

Шәмседдин Суфиның, шигырьләреннән башка, дини мәүзугларда берничә гарәпчә китабы да булганлыгы мәгълүм. Әсәрләрен ул, гадәттә, үзенең шәкертләреннән Заһиреддин Баими исемле кешегә имля итеп яздыра икән. Аның мәдрәсәсеннән байтак галим шәкертләр чыккан. Аларның иң атаклысы – шагыйрьлектә остазының истихкаклы[2] варисы, татар әдәбиятының яңару дәверенең беренче шагыйре Мифтахетдин бине Мөхәммәдьяр, ягъни мәшһүр Акмулладыр.

## *5. Һибәтулла Ишан*

Һибәттула Ишан дип мәшһүр булган Һибәтулла Сәидбаттал углы исемле бу зат 1794 еллар тирәсендә туып, 1867 елда 73 яшендә вафат булган. Төп нәселләре Чистай өязе Такталы авылыннан чыгып, бабасы Салих Оренбург Каргалысына (Сәгыйть бистәсенә) күчеп килгән. Атасы Сәидбаттал Чебенле авылында мулла булган. Ул үлгәч, Һибәтулла да бераз вакыт атасы урынында имам булып торган. Курсадан күчеп килгән Дәүләтша ишанның сабагына утырып, аннан ишанлыкка иҗазәт[3] алган. Ахырда Сәгыйть бистәсенең өченче мәчетенә имам булып, шунда вафатына кадәр, 15 еллап, имамәтчелек иткән һәм мөрид тәрбия

[1] Могтәдилрәк – уртачарак.
[2] Истихкаклы – лаеклы.
[3] Иҗазәт – рөхсәт.

кылган. Каргалы муллаларының интригалары аркасында бераз вакыт муллалыктан төшерелеп тә торган, имеш.

Һибәтулла Ишан гомерендә өч мәртәбә өйләнеп, ике хатыннан унлап баласы булган. Өченче хатыны Хаҗивафа белән ул ике генә ай торып калган. Бу хатынын бик ératканга күрә, ул үлгәч, бик зур кайгыга төшкән һәм шул мөнәсәбәт белән берничә газәл вә мәрсияләр язган. Бер ишанның Аллага түгел, бәлки хатыннардан бер хатынга булган гыйшкы аркасында мәйданга килгән бу шигырьләрне без, мәгаттәәссеф[1], күрә алмадык. «Асар»да бу затның тәрҗемәи хәлен язган Риза казый үзенең дә бу шигырьләрне күреп күрмәве хакында бернәрсә әйтми. Шулай ук башка шигырь вә касыйдәләренең күп булуын сөйләсә дә, «Асар»да бары мәшһүр «Тәндә җаным ничә көн миһман[2] икәндер белмәдем» дип башлана торган касыйдәсен күчерү белән канәгатьләнә. Риза хәзрәт Һибәтулла Ишанны фәсыйх[3] сүзле, туры җаваплы, тәвазыглы[4], йомшак күңелле, яхшы холыклы, йомшак вәгазьле, нәсыйхәте әсәрле бер кеше булган дип тасвир итә. Дәрвакыйг[5], ул үзенең «Мәҗмәгъ әл-әдәб»ендә дә һәрвакыт кешене йомшак сүзләр белән үгетләргә, яхшылык белән генә туры юлга күндерергә тырышырга куша.

Һибәтулла Ишан – иркен каләмле көчле назыйм[6]. Шигърият ягын кирәгенчә үлчәр өчен, тәәссеф ки[7], без аның әсәрләре белән тулы рәвештә таныша алмадык. Безнең күз алдында аның «Асар»да дәрҗ ителгән[8] бер-ике шигыре белән «Мәҗмәгъ әл-әдәб» исемле китабы гына бар. «Асар»да әйтелгәнчә, аның «Төхфәт әл-әүлад» исемле тагын бер басылган китабы һәм басылмаган таркау әсәрләре бар икән. Кулыбызда булган

[1] Мәгаттәәссеф – үкенечкә каршы.
[2] Миһман – кунак.
[3] Фәсыйх – матур.
[4] Тәвазыглы – тыйнак.
[5] Дәрвакыйг – чыннан да.
[6] Назыйм – шагыйрь.
[7] Тәәссеф ки – кызганыч ки.
[8] Дәрҗ ителгән – китерелгән.

әйберләреннән без бу шагыйрьнең тәсаувыф идеяләре белән илһамланучы ярыйсы гына лирик булганлыгын күрәбез. «Тәндә җаным» касыйдәсендә ул дөньяның фанилыгы, дөнья эшләренең файдасызлыгы, үзенең, дөньяга алданып, гомерендә кирәгенчә тагать-гыйбадәт кыла алмый калуы, муенына әллә никадәр гөнаһ йөкләп ахирәткә китәргә мәҗбүр булуы хакында пошына. «Мәҗмәгъ әл-әдәб»тә дә шул маилдарак[1] мөнәҗәтләр бар.

«Мәҗмәгъ әл-әдәб» – урта кулдан зуррак, 95 битле бер китап. Башыннан ахырына кадәр төрле вәзендә нәзым белән язылган. Мөндәриҗә ягыннан ул «Сөбат әл-гаҗизин»гә бераз охшый. Башта, берничә мөнәҗәттән соң, Аллага итагатьле һәм гөнаһлы бәндәләр хакында сөйли. Бу ике гөруһны яңадан икешәргә бүлә. (Гомумән, «икегә бүлү» бу китапта бик еш очрый.) Урыны белән, әйткән фикергә мисал йөзеннән, берәр гыйбрәтле хикәя дә сөйләп, кыйссадан чыккан хиссаны да аңлатып китә. Аннан соң бик озын итеп, «әмре мәгъруф вә нәһи ган әл-мөнкәр» (яхшылыкка өндәү, начарлыктан тыю) һәм аның әдәпләре хакында сөйли; аны бик күп кыйсемнәргә бүлә; мисал йөзеннән хикәяләр китерә. Аннан ары ишанлыкның шартлары һәм әдәпләре, шәехкә иярү вә мөридлекнең шарт һәм әдәпләре, шәех белән мөриднең мөнәсәбәте, иршад, тәкъва[2], моракабә[3], мөхасәбә[4], мөҗаһәдә[5] шикелле ишанлык вә тәсаувыф тарикатенә даир[6] мәсьәләләре хакында озын-озын сөйләп, китапны тәмам итә. Китап башыннан ахырына кадәр аять, хәдисләр белән чуарланган, мөхакәмәгә[7] куелган мәсьәләләргә карап, төрле баб вә фасылларга бүленгән. Һибәтулла Ишан, бу әсәрен язганда, мәшһүр тәсаувыф китапларыннан «Шәкаикъ эн-Ногман»нан ис-

[1] Маилдарак – тартым, охшаш.
[2] Тәкъва – диндар булу.
[3] Моракабә – уйга чуму.
[4] Мөхасәбә – санашу.
[5] Мөҗаһәдә – дин өчен сугышу.
[6] Даир – караган.
[7] Мөхакәмәгә – хөкем чыгаруга.

тифадә иткән[1] булырга кирәк – юл араларында бу китаптан байтак кына гыйбарәләр китерелә. Шагыйрь Иран әдәбияты белән дә беркадәр таныш булса кирәк, чөнки ул Җәлаледдин Руминың «Мәснәви»еннән бер хикәя күчерә. «Мәҗмәгъ әл-әдәб» артык авыр өслүб белән язылмаган, аны аңлау «Сөбат әл-гаҗизин»не аңлау шикелле читен бер эш түгел. Урыны-урыны белән авыр гыйбарәләр, чит сүзләр күп катышкан бәйтләр, хәтта бөтенләй үк гарәпчә яки фарсыча мисраглар[2] очраса да, түбәндә китерелгән бәйттәге шикелле, җиңел татарча җөмләләр дә сирәк түгел:

«Димәгел үлтерермен йә суярмын,
Асарым-кисәрем, каның коярмын.
Дисәң җаиз сугармын йә орармын
Вә йә әйтсәң, колагыңны борармын».

### *6. Мәхмүд Ширвани*

Татар арасында Мәхмүд Ширвани дип мәшһүр булган бу затның асылы Закавказьеда (Азәрбайҗан) Ширван (Шемаха) шәһәрендәге бер авылдан булып, ата-бабалары шунда торганнар. Үзе дә шунда дөньяга килгән. Бервакытны Мәхмүд, Русия хөкүмәте тарафыннан ниндидер сәяси эштә гаепләнеп, Пермь шәһәренә сөргенгә җибәрелгән. Аннан соң Казанга килеп бераз торып, ахырда Әстерхан шәһәрендә урнашып калган. 1877 елда 65 яшьләрендә вафат булган.

Мәхмүд Ширвани хакында Мәрҗани галим, фазыйль[3] вә риязый[4] кеше иде ди, һәм язуга (хөсне хатта[5]) оста булганлыгын сөйли. Казанда вакытта Казан муллалары белән зур моназаралар[6] кылган. Бу кеше Азәрбайҗан татарларыннан булганмы, әллә юкса, ерак бабалары Урта Русиядән күчеп килгән

[1] Истифадә иткән – кулланган.
[2] Мисраглар – шигъри юллар.
[3] Фазыйль – намуслы, кешелекле.
[4] Риязый – математик.
[5] Хөсне хатта – матур язуда.
[6] Моназарәләр – бәхәсләр.

булганнармы – бу хакта Мәрҗанидә бер сүз юк. Ләкин «Мөстәфад»тә китерелгән шигыренең теленә һәм шул шигырендә шәһре Болгарның күңеленә якын булуын сөйләп, аны күкләргә күтәреп мактавына караганда, ул асыл Идел буе татары булырга охшый. Аның бердәнбер безгә мәгълүм булган әсәре – шул Болгар хакындагы кыска гына шигыре. Бу шигырь болай дип башлана:

«Шәһре Болгара күңел шөйлә улыбдыр мөштак[1],
Җөмлә Болгар күренер күзебезә якын-ерак.
Шәһре Болгара күңел, кылма бәрабәр асла[2]
Мисыр, Шам, Ямәни, шәһре Хорасан, Гыйрак».

Аның шигыре шактый авыр тел белән язылган. Бу шигырьнең мәүзугы гади «мәрсияче» шагыйрьләрнең мәүзугларына башка булып, үзебезнең тарихи ганганәбезне[3] искә алганга күрә, без аның шигыренә игътибар иттек. Шөбһәсез, Мәхмүд ишан шагыйрь кеше булып, аның башка шигырьләре дә булган булырга кирәк[4].

## Габделҗәббар Кандалый

Безнең борынгы әдәбиятыбызда «мәрсияче шагыйрьләр»нең авыр китап теле белән язылган шигырьләренә башка саф татарча язылган шигырьләр дә очрый. Ул заманда татарча язуның кыйммәте ни дәрәҗә икәнен искә алганда, бу шигырьләрне язучыларга беркадәр гаҗәпләнеп карарга туры килә. Һәрхәлдә, алар үзләренең әсәрләренә артык җитди күз белән карамаганнар булырга кирәк дип уйлана. Әмма араларында, шөбһәсез, чын шагыйрь булган кешеләрне очратып була. Аларның безгә мәгълүм булганнарыннан иң әһәмият бирергә тиеш булганы –

[1] Мөштак – сагынучы.
[2] Асла – һич.
[3] Ганганәбезне – үткәнебезне.
[4] Борынгы шагыйрьләребездән Гали Чокрыйның тәрҗемәи хәле вә әсәрләре хакында тиешле мәгълүмат җыеп житкерә алмаганлыгыбыздан, бу мөһим әдип вә шагыйрьгә аерым мәкалә багышлый алмадык. Киләчәктә әсәрнең бу җитешсезлеге тутырылыр дип өмет итәбез. *(Авт. иск.)*

Габделҗәббар Кандалый исемле зат. Кандалый белән мәрсияче шагыйрьләрне тоташтыра торган күпер юк түгел. Ул да булса, мәрсиячеләрнең җиңел вә көлкеле мәүзугларда язылган һөҗүви бәйтләрдер. Андый шигырьләрен безнең иң авыр тел белән яза торган шагыйрь муллаларыбыз да нәкъ сөйләшү теле шикелле җиңел татарча телдә язганнар.

Бу кеше һәм аның әсәрләре безгә Каюм Насыйри аркылы гына таныш. Әгәр ул аны казып чыгармаган булса иде, без аның хакында бернәрсә дә белмәс идек. Насыйриның татар теле һәм әдәбияты белән шөгыльләнергә яратуы гына Кандал авылының мулласы Габделҗәббарны татар әдипләре арасына кертеп утыртты.

Габделҗәббар мулланың тәрҗемәи хәле безгә мәгълүм түгел. Аның хакта Каюм Насыйри үзенең «Фәвакиһ әл-җөләса...»сында түбәндәге сүзләр белән канәгатьләнә: «Бу мәзкүр әбйатның[1] имля вә иншасы байтак яхшы төзелгәндер, шул җәһәттән игътибар кылынды. Мәрхүм Габделҗәббар шагыйрь адәм, имеш, 1850 дә вафатдыр». Аннан соң бу кешенең Самар губернасы, сабикъ[2] Ставрополь өязе Кандал атлы авылда имам булганлыгы мәгълүм. Менә безнең Габделҗәббар Кандалый хакындагы мәгълүматыбыз шуның белән тәмам. Бу шигырьләр Насыйриның кулына ничек килеп кергәннәрдер – бу хакта ул бер сүз әйтми.

Габделҗәббар Кандалый үзенең шул ук губерна һәм өяздәге Парау исемле авылдагы Сахибҗәмал атлы бер кызга гыйшкы хакында, шул кызның үзенә хитабән[3], нәзым белән егерме битле бер әсәр язган. Бу әсәрнең күләме шактый зур булып, башыннан ахырына кадәр ул бер фикергә бина кылынган[4] булса да, анда һичбер төрле хәрәкәт (действие[5]) юк. Ул бер гыйшкый поэма түгел, бәлки аерым кисәкләре бер-берсенә турыдан-туры

[1] Әбйатның – бәйтләрнең.
[2] Сабикъ –әүвәлге.
[3] Хитабән – эндәшеп.
[4] Бина кылынган – нигезләнгән.
[5] Кириллицада бирелгән.

бәйләнмәгән хисси шигырьләр (лирические излияния[1]). Үзенең саф татарча теле, һичбер төрле суфилык радиларына[2] төренмичә, ачыктан-ачык дөньяви гыйшык хакында язуы белән Габделҗәббар Кандалый безнең борынгы мәрсияче шагыйрьләрдән бөтенләй аерым бер урын тота. Шуның белән ул безнең өчен әһәмиятле, шуның белән ул безнең өчен кадерле.

Габделҗәббар мулланың гыйшкы рухани-идеальный бер мәхәббәт түгел. Бу гыйшыкның артык җисмани, артык тәнгә хасланган булуы аерымачык күзгә бәрелә. Дөрес шагыйрьнең гыйшкы бик каты: ул яна, көя, «кичә, көндез хәсрәт чигә», ни хәл итәсен белми, ләкин Сахибҗәмал турысында уйлаганда, һәрвакыт аны үзенең хатыны итеп кенә уйлый ала. Дөрес, ул бәгъзан шигъриятнең югары нокталарына күтәрелергә дә омтыла:

«Сәба йиле, исәр булсаң
Парау атлыг нәфис җайга,
Сәламемне тикергәйсән
Сахибҗәмал абыстайга!»

Яисә:

«Төшемдә Парау илендә
Ки сәйран итдем очмакда,
Барып, анда сәнең илән
Ки сәйран итдем оҗмахда».

шикелле гүзәл мисраглар аның каләменнән түгеләдер. Ләкин күп тә үтми, берничә юл аркылы, шагыйрь мәгъшукасының шундый яшерен урыннары хакында ачыктан-ачыкка сөйләргә керешә, яисә һәрнәрсәне үз исеме белән атап, шундый тупас гыйбарәләр ычкындырырга тотына ки, чын назик[3] хисле гашыйклар, әдәб сахибе[4] булган шагыйрьләр үзләренең ши-

[1] Кириллицада бирелгән.
[2] Радиларына – дәрвишләрнең киемнәре.
[3] Назик – нечкә.
[4] Сахибе – иясе.

гырьләрендә (бахосус[1], мәгъшуканың үзенә тәкъдим ителгән шигырьләрдә) андый нәрсәләрне телгә алу түгел, хәтта алар хакында ялгыш кына исләренә төшсә дә, оялуларыннан кызарырга тиешләр. Әгәр Сахибҗәмал туташ үзе дә гашыйгы Габделҗәббар мулладан андый шигырьләрне ишетсә, авыл кызы булуына карамый, колагын тотып, битен каплап качар иде. Әлхасыйль[2], безнең Габделҗәббар мулланың гыйшкы белән мәдрәсәдә үзенең нәфесен тыеп ятарга мәҗбүр булган монахшәкертнең юрган астында ятканда үзенең булачак бикәче хакында уйлаган уйлары арасында артык зур аерма юк. Аның өслүб вә гыйбарәсе дә бик тәкәллефсез[3] һәм татарча гына. Хәтта анда үзенең язган әдәпсез сүзләренең килешмәвен дә аңламаслык дәрәҗәдә балаларча сәдадлык[4] бар дип әйтәсе килә.

Габделҗәббар мулланың шигырьләреннән аның мәхәббәте хакында без никадәр мәгълүмат ала алабыз? Аның мәгъшукасы – Парау авылының Сахибҗәмал исемле бер кыз. Шагыйрь һәрвакытта аның матурлыгы хакында сөйләп тора. Аны «матурым, чибәрем, гүзәлем» дип атый.

«Йөзнең нур хури гыйльмандан,
Сүзнең хуб хури вилдандан,
Үзең сылу йәшь угландан[5],
Матур кылмыш ушал Алла!», –

дип, аны күкләргә күтәрә. Бу кыз, чынлап та, шулай искиткеч матур булганмы, әллә юкса, гашыйк мулланың кызган кувәи хыялиясе[6] генә аны рәтләп күрмәстән үк, бары ишетмеш буенча гына шулай матур итеп тәсаувыр итәме[7] – бу, әлбәттә, безгә

[1] Бахосус – атап.
[2] Әлхасыйль – нәтиҗәдә.
[3] Тәкәллефсез – ясалма түгел.
[4] Сәдадлык – дөреслек.
[5] Мәгъшукасын «яшь углан» белән тиңләштерүенә игътибар итегез. *(Авт. иск.)*
[6] Кувәи хыялиясе – хыял куәте.
[7] Тәсаувыр итәме – сурәтлиме, гәүдәләндерәме.

мәгълүм түгел. Затән[1] гашыйкларның үзләренең сөйгәннәрен идеал дәрәҗәсенә менгерүләре бик гади эш инде. Әлхасыйль, менә шушы кызга безнең хәзрәт дүрт елдан бирле гашыйк; аның хакында уйлый-уйлый ул саргайган, кипкән, төн йокыларын качырган, ашау-эчүдән калган. Ләкин Сахибҗәмал ярларның иң вафасызларыннан булып чыккан. Хәзрәтнең ничә мәртәбә яучылавына, үзенең ничә тапкыр Парауга барып аны соравына карамастан, кыз аны һич сәбәп фәлән күрсәтмәстән рәд итә[2]:

«Сәңа гыйшык төшеп, җанкәм,
Тотып шәүкате зәүкатлар[3],
Тәмам дүрт ел елап-сыктап,
Ки заегъ итдем әүкатлар[4].
И бу дүрт ел, и бу дүрт ел,
Ки һәр сәгате дә дүрт ел!
Җаныма йибәрә ут ул,
Китәрә җөмлә тәкатьләр[5]!
Бу дүрт елдан бирле аслан[6]
Күрешкәнең дә юк фәслан[7]
Йә бер хат язубән фәслан,
Хатыңда юк мөлякатлар[8]».

Ул никадәр хатлар язган, никадәр «Мөхәммәдия кеби хуб-тыр» шигырьләр язган дәфтәрләр җибәргән – ләкин кыздан җавап юк та юк. Шуннан ул еларга тотына:

«И-и, и генә лә, и генә,
Ни булды мәңа, ни генә?
Эшемдә юк лә көй генә,
Никадәр язамын хатлар!»

[1] Затән – нигездә.
[2] Рәд итә – кире кага.
[3] Тотып шәүкате зәүкатлар – зәвыклы сөешүчеләр.
[4] Ки заегъ итдем әүкатлар – бушка вакытлар уздырдым.
[5] Тәкатьләр – көч, чыдамлык.
[6] Аслан – һич тә.
[7] Фәслан – өлешләп.
[8] Мөлякатлар – кавышулар, очрашулар.

Хәтта ахырда ул, хатларым тапшырылмый микән әллә дип, «пушты»ны[1] гаепләүгә кадәр барып җитә. Әмма мәгъшукасыннан һаман өмет өзәсе килми. Ләкин аның иң курыккан эше – Сахибҗәмалнең башка бер-бер кешегә барып куюы.

Сахибҗәмал бер-бер баерак мужик кызы булырга кирәк, чөнки Габделҗәббар мулла аны, үзенә хатынлыкка барырга үгетләгәндә, мужикка барып мужик хатыны булу белән, каты кара эш эшләү белән куркыта. Әгәр дә Сахибҗәмал мулла-мәзин кызы булса, аның мужикка бирелү ихтималы булмас иде; ярлы кеше кызы булса да, хәзрәт аны кара эш белән куркыта алмас иде. Сахибҗамалнең ни өчен бу муллага барырга теләмәгәнлеге аерымачык мәгълүм түгел. Ләкин бер урында шагыйрьнең: «Тутам бар, ди-ди уйнама», – диюенә караганда, кыз аңар бармавының сәбәбе итеп, үзенең тутасы кияүгә китмәгәнлеген күрсәткән булырга кирәк дип уйлана. Әмма чын сәбәбе нәрсә булгандыр, анысын шигырьләрнең үзләреннән аңлар хәл юк. Ихтимал, безнең шагыйрь бик ямьсез булгандыр да, кыз аны һич яратмагандыр; ихтимал, ярлы булгангадыр да, шуңа күрә барасы килмәгәндер; ихтимал ки, үзеннән һич бертөрле гаеп тапмаса да, бары тик аның ялкынлы хисләренә каршы үзенең күңелендә иҗаби[2] тойгы тапмаганга күрә, рәд белән[3] җавап биргәндер; ләкин кызның аңа бармавында, шөбһәсез, башка кешеләрнең катнашы булырга кирәк. Шагыйрь ул кешеләрне рәҗәпләр[4] дип йөртә. Аларның үзенә дошман икәнлеген, Сахибҗәмалны үзенә бармаска алар котыртканлыгын сөйли, «рәҗәпләр сүзенә оедың[5]», дип, мәгъшукасына үпкәли. Ихтимал, бу – бары шагыйрьнең вәсвәсәле булуыннан гына килгән бер шөбһәдер. Менә ул рәҗәпләр хакындагы сәтырлар[6]:

[1] Пуштыны – почтаны.
[2] Иҗаби – уңай.
[3] Рәд белән – тискәре.
[4] Рәҗәпләр – Рәҗәп авылы кешеләре мәгънәсендә. Рәҗәп – Татарстанның Спас районындагы Иске Рәҗәп авылы.
[5] Оедың – иярдең.
[6] Сәтырлар – юллар.

«Ошасам үзеңә ярап,
Рәҗәпләр сүзенә карап,
Була күрмәсәнә харап,
Сүземне тот, и җанкай лә.
Рәҗәпләр сүзенә оедың,
Ки бар мәхәббәтең җуйдың,
Булып йиткән эшең куйдың,
Гафил булып, и җанкай лә.
Бу елдан бирле вә бу кышдан
Рәҗәпләр кауме һәм хишман[1]
Бәңа бик булдылар дошман,
Сәбәб бер лә, и җанкай лә!»

Менә моңар караганда, Сахибҗәмал, башта Габделҗәббар муллага бармакчы булып (бәлки аның белән бераз мөнәсәбәттә булып), соңыннан кире кайткан төсле тоела. Вәгъдәсе булуы хакында башка урыннардан да аңларга мөмкин.

Тагын икенче җирдә гүяки аның бару-бармавы үзеннән түгел, бәлки, анасыннан булган төсле, шагыйрь аңар шушы сүзләр белән хитаб кыла[2]:

«Бу сүзне әнкәңә сөйлә,
Сахибҗәмал, и җанкай лә;
«Бәне шул меллага биреп,
Йәрәшсәнә, и әнкәй лә!
Үзе галим, үзе мелла,
Үзе бик сөядер, валлаһ!
Ничек итим лә, ух Аллаһ!
Сөямен бик, и әнкәй лә!
Ярамам, әнкәй, суярга,
Итем тозлап да куярга.
Шул ук да бәне бер ярга
Ярәшерсез, и әнкәй лә!».

[1] Хишман – ачулы, үчле.
[2] Хитаб кыла – мөрәҗәгать итә.

Ләкин вафасыз мәгъшука Сахибҗәмал туташның (аны шагыйрь, бик картайтып, абыстай дип атый) анасына бу сүзләрне әйтергә уйлап та караганы юк, ахры. Ул үзенең гашыйгын фирак[1] утында яндыруына дәвам итә. Ихтимал, аның бу җүләр гыйшкыдан көлә дә торгандыр әле, әмма мулла аңар чын күңелдән гашыйк. Ул аның җансыз сурәте белән дә канәгатьләнергә хәзер:

«Йә сурәтең ясатырга
Барыйм микән лә нәккашка?» –

ди. Хәтта ул бу гыйшкын онытырга, бу җүләрлекне башыннан чыгарырга да тырышып баккан булырга кирәк, ләкин, муаффәкъ булмагач[2], бу кыз мине сихерләмәдеме икән, дигән фикергә килеп җитә:

«Йә тылсымләме сөйдерден?
И яндырдың лә, көйдердең!
Кырык төенме төйдердең,
Катып бирдеңме йә ашка?!
Ничек тә бер дә сизмәдем,
Ки сәндин бер дә бизмәдем», –

ди. Ул үзенең гыйшкын никадәр яшерергә тырышып караса да, бөтен әтрафка[3] фаш булган:

«Ки гыйшкың эчдә гизләдем,
Алай да чыкды бик фашка».

Татарлар булган шәһәрләрдән һичберсендә бу гыйшыклыкның чабы таралмый калмаган. Бу калаларны шагыйрь һәммәсен берән-берән санап чыга. Үзенең Сахибҗәмалын шул фаш булу аркасында халык арасында яманаты чыгу белән дә куркытып бакмакчы була ул:

«Бу гыйшыклык чабы китде
Уфа, Казан да, Сенбергә.

[1] Фирак – аерылышу.
[2] Муаффәкъ булмагач – булдыра алмагач.
[3] Әтрафка – якка.

Бу гыйшыклык яманатын
Күтәрдең сән дәхи бергә».

Әлхасыйль, безнең гашыйк мулла, мәгъшукасын үзенә барырга күндерер өчен, нинди-нинди генә чараларга керешеп бакмый. Бу мәсьәләдә ул чын-чын йөдәткеч бер «Парау хәерчесе»нә әверелә. Яхшылык белән дә, яманлык белән дә кызны үзенә килергә кыстый. Яхшы сүзләргә илтифат[1] булмагач, ул кайбер вакыт, ачуланып, «күтәреп торма бик борының» дигән шикелле тупас җөмләләр дә ычкындыра, каргыш белән дә куркыта. Хәтта аннан да арттырып җибәреп, иман мәсьәләсенә кадәр кагыла:

«Корытканың өчен теңкәм,
Ахирәтдә ки һәм, җанкәм,
Газабың булмасын бик ким,
Сәңа булсын тәмуг җай лә.
Димә бу сүзне, и җаный:
«Бу кадәр каргыйсың бәни,
Ки бән соң нишләрем сәни?»
Исем китде лә, ай-вай лә.
Мәнем бар ихтыярым, дип,
Теләсәм кемгә барым, дип,
Мажик булса да – ярым, дип
Ниятләнмә, абыстай лә.
Өзелеп калса бер галим,
Яр итсәң бер надан залим,
Иманың калмагай салим[2],
Ишет, бик бел, абыстай лә.
Вафасыз гаһед-пәймансыз[3],
Калырсән динсез, имансыз,
Бу сүзне бел ки гөмансыз[4]
Дийүб бел ки, абыстай лә».

[1] Илтифат – игътибар.
[2] Салим – сәламәт.
[3] Вафасыз гаһед-пәймансыз – ышанычсыз, вәгъдә-антсыз.
[4] Гөмансыз – шөбһәсез.

Габделҗәббар мулланың иң курыкканы – Сахибҗәмалның бер-бер авыл егетен яраткан булуы ихтималы булырга кирәк. Шуның өчен ул мужикны яманлауга, аның тормышының авырлыгын тасвирга үзенең бөтен шигъри куәтен сарыф итә. Бу мәсьәләләргә килгәндә, ул һичбер төрле ямьсез буяуларны җәлләми, аның өслүбе чын-чын тасвири өслүбкә әйләнә, тәүсыйфлар, тәмсилләр[1] берсе артыннан берсе явалар. Ул мужик тормышының һәммә начар вә шакшы якларын актара, бар нәрсәне үз исеме белән атый. Сүз һәм гыйбарә турысында үзенең телен һичбер әйбер белән чикләми. Тасвир ягыннан иң кызыклы булган бу урыннарны, тәәссефкә каршы[2], әдәп даирәсеннән тыш булганлыктан, монда китереп булмый. Аныңча, мужик шакшы, чисталыкның, юынуның ни икәнен дә белми, тиргә, балчыкка, нәҗескә батып сасып йөри; аның бөтен гомере кара эштә уза, ул эшеннән арып-талып кайта да ята да йоклый; хатыны белән адәм төсле өлфәт итә дә белми, сөюшүнең ни икәне аңар мәгълүм түгел, аның бөтен хәрәкәт вә кыланышлары Сахибҗәмал шикелле нәфис кызларны тәхкыйрдан[3] гыйбарәт булачак; хатынын ул ачлы-туклы тота, аның өстенә әнваг[4] төрле кара, авыр эшләр эшләтә; җитмәсә тагын ул шуның өстенә кыйный да. Мужикта дин тоту юк, намаз-нияз юк, ул наданнан туган балалар да фасикъ[5], начар кешеләр булачаклар, ахирәттә дә аларның һәммәсенең урыны тәмугта булачак. Әмма муллага барса, Сахибҗәмалның тормышы бөтенләй башка булачак. Ул аны һәрвакыт иркәләп, сөеп, кадер-гыйззәт эчендә генә тотар, авыр эш эшләтмәс, аңар җәй көннәрендә гаҗиз булып, эссе кояш астында тиргә манчылып урак урырга да туры килмәс. Галим кешегә барса, аның гыйлеменең файдасы һәр ике дөньяда тояр, галимнән галим балалар туар. Алар дөньялыкта ата-аналарына догачы, ахирәттә дә шәфәгатьче булырлар. Менә

[1] Тәүсыйфлар, тәмсилләр – сыйфатлаулар, чагыштырулар.
[2] Тәәссефкә каршы – кызганычка каршы.
[3] Тәхкыйрдан – хурлаудан.
[4] Әнваг – төрле.
[5] Фасикъ – тәртипсез, бозык.

шулай итеп, безнең Габделҗәббар мулла үзенең мәгъшукасына надан мужикка иргә бару белән галим муллага хатын булуның аермасын күрсәтергә тырыша. Аның бөтен сүзләреннән гавам[1] белән руханилар арасындагы сыйнфый аерма, хәтта сыйнфый дошманлык аерымачык күренеп тора. Ул үзенең «пахытный мужик»ка караганда бөтенләй башка җенестән булуы белән мәгърур[2]; үз нәселенең җиде бабадан бирле мулла булып килүе белән мактана; мужикка үз кул көче белән эшләп көн күрүче булганлыгы өчен хәкарәт[3] күзе белән карый; аны кешегә дә санамый, әнваг төрле начар, ямьсез сүзләр белән аны сүгә. Әлхасыйль, Кандалыйның шигырьләре, гомумән, муллалар сыйныфының гавамга карашы ничек булганлыгын көзге шикелле үзендә гакес иттергән[4].

Хәзер безнең күз алдыбызда бер мәсьәлә тора: чынлап та, бу Сахибҗәмал исемле кыз дөньяда булганмы? Безнең шагыйрьнең аңар булган ниһаясез[5], басылмас гыйшкы хакыйкый бер нәрсәме? Әллә юкса, болар һәммәсе гади бер әдәби уйдырма, шагыйрьнең хыялыннан туып, аңар үзенең йөрәгендә булган тойгыларны мәйданга куяр өчен кирәк булган әдәби форма гынамы? Дөрес, әдәбият белән хыял, шагыйрьлек белән хыялпәрәстлек – һичбер вакыт бер-берсеннән аерылмый торган нәрсәләр. Ләкин шуны икърар итәргә кирәк ки, никадәр хыял күп катышмасын, әдәби әсәрләрдә һәрвакыт хыял астына өртелгән хакыйкый тормыш орлыгы яшеренеп ятмый калмый. Язганы самими булсын өчен, шагыйрь аңар асыл нигез итеп үзенең күз алдындагы тормышны, иҗат иткән типлары өчен дә күз алындагы җанлы, тәнле кешеләрне алырга мәҗбүр. Бу сүз бигрәк тә хисси шагыйрьләр хакында дөрес. Лирик шагыйрьгә хыял дәрьясында теләгәнчә гизәргә ирек бирелә; ләкин хисси әсәрләре самими булып, укучының рухына тиешле тәэсирне бирсен өчен, ул,

[1] Гавам – халык.
[2] Мәгърур – горурлана.
[3] Хәкарәт – түбәнсетү, хурлау.
[4] Гакес иттергән – чагылдырган.
[5] Ниһаясез – ахыр чиктә, соңгы дәрәҗәдә.

әлбәттә, шигырьләрендә үзенең йөрәгендә булган чын хисләрне генә кәгазь өстенә забит итәргә[1] тиеш. Шуның өчен дә лирик һәрвакытта үзенең әсәрләренә материалны үз рухы галәменнән ала. Юкса, берәү, мәсәлән, һич гашыйк булмый торып, гыйшык хакында шигырьләр язса, аның шигырьләре, шөбһәсез, рухсыз вә сонгый[2] булып чыгарлар иде. Без югарыда Габделҗәббар Кандалыйның лирик шагыйрь икәнлеген әйтеп киткән идек. Әгәр аның калдырган әсәрләре шигърияттсез, салкын нәзымнардан гына гыйбарәт булса, без аның хакында сөйләп тә тормас идек. Кандалый – шөбһәсез, үзенең хиссиятен укучыга да бирә вә аңлата ала торган көчле бер шагыйрь. Аның шигырьләреннән шулкадәр самимият аңкый ки, аларны бары тик шигырь язу максаты белән генә баштан чыгарылган әйбер дип уйларга һич мөмкин түгел. Шиксез, аның гыйшкы – хакыйкый бер гыйшык, мәгъшукасы да җанлы, тәнле бер кыз булган булырга кирәк; ихтимал, ул бу шигырьләрен башта мәхыз[3] мәгъшукасына җибәрү өчен генә язгандыр. Шигырьләрдә «рәҗәпләр» шикелле кем икәнлекләре укучыга бөтенләй мәгълүм булмый кала торган кешеләрнең телгә алынуы да бу гыйшыклыкның чын булуына безне ышандыра.

Югарыда Кандалыйның гыйшкы бик үк сәмави[4] булмаганлыгы хакында әйтелеп узылган иде. Шулай ук аның бу мәхәббәте беренче һәм актыккы мәхәббәте дип тә уйланмасын. Шул ук «Фәвакиһ әл-җөләса...»да, «Вә ләһу Бәдига», «Вә ләһу Фәрхи»[5] сәрләүхәләре[6] астында Кандалыйның тагын ике кызга игъланы гыйшык итеп язган шигырьләре дәрҗ ителгән. Бәдига белән Фәрхи исемле бу ике кызның кемнәр булуын без белә алмыйбыз. Ләкин шигырьләренә караганда (гәрчә алар Сахибҗәмалга

[1] Забит итәргә – төшерергә.
[2] Сонгый – ясалма.
[3] Мәхыз – фәкать.
[4] Сәмави – күкнеке.
[5] «Вәлә» гарәпчә «аныкы» («ему же принадлежит») мәгънәсендә. *(Авт. иск.)*
[6] Сәрләүхәләре – исемнәре.

багышланганга караганда күп кыска, бер-ике генә битле булсалар да), Габделҗәббар мулланың бу кызларга булган гыйшкы Сахибҗәмалга булган гыйшкына караганда бер дә ким төсле түгел, шулай ук Сахибҗәмалга язган шигырьләреннән без бу мулланың, Борнай авылындагы тагын бер кызга гашыйк булып, шулай ук үзенә барырга кыстаганлыгын аңлыйбыз. Габделҗәббар мулла бу кызның кыйссасын Сахибҗәмалга мисал өчен сөйли. Ул да, хәзрәтнең соравын кире кайтарып, башка бер кешегә, мужикка барган; ире бик әшәке кеше булып чыгып, көне-төне талашып, моны кыйнап, үзе аермыйча, ахырысында көчкә «мир»гә мөрәҗәгать итеп кенә аерылырга муаффәкъ булган[1]. Бу мисал белән шагыйрь Сахибҗәмалга, әгәр үзенә бармаса, каргыш төшеп, аның да шулай булачагын күрсәтергә тели. Ихтимал ки, бу кыз «Фәхри» яки «Бәдига»ның берсе-берседер. Ләкин мәсьәлә анда түгел. Мәсьәләнең әһәмиятле ягы шунда ки, без Габделҗәббар мулла өчен гашыйк булуның табигый бер халәт булуын күрәбез. Бу хәзрәтнең, ихтимал, берничә хатыны булгандыр, ихтимал ки, ул өйләнмәгәндер. Ләкин аның гомере буенча әле берәүгә, әле берәүгә гашыйк булмыйча тора алмый торган типлардан булуы аерымачык күренеп тора. Бу – безнең татарның Дон Жуаны. Гарби Яурупа әдәбиятының бик мәшһүр мөкәррәр[2] типларыннан булган Дон Жуан шикелле үк, безнең мулла да бертуктаусыз әле бер кызга, әле икенче кызга гашыйк; Дон Жуанныкы шикелле үк аның гыйшкы да шагыйрәнә, ләкин шуның белән бер үк бик җисмәни вә дөньяви. Чынлап та, бик кызыклы ишетелә: Дон Жуан – мулла! Үзенең гыйшкый эшләрендә бу мулла активный фәгалият изһар иткәндерме[3], әллә аның гыйшыклары коры, «Габделбасыйр гыйшкы» шикелле, шәкерт фаразы гына булып, фикрән генә Дон Жуан булгандырмы – бусы мәгълүм түгел. Әмма югарыда тикшерелгән әсәренең

[1] Муаффәкъ булган – ирешкән.
[2] Мөкәррәр – кабатланучы.
[3] Фәгалиять изһар иткәндерме – эшчәнлеген күрсәткәнме.

гаҗәп бәлягатьле[1] булган шушы дүрт юллы бәйтенә караганда, гыйшык дигән нәрсәнең аның каршында, коры һава-һәвәстән туган, эш юктан кәеф өчен генә уйлап чыгарылган җуаныч булмаенча, зур рухани газапларга сәбәп булган җитди бер нәрсә булганлыгы аңлашыла:

«И белсәң ирде хикмәтне:
Гыйшыклык – дәрдме, рәхмәтме?
Вә йа каһәрме, зәхмәтме –
Салыбдырмы залял Алла?!»[2]

Мәкаләбезнең башында ук Габделҗәббар Кандалыйның теле хакында әйтеп узган идек. Чынлап та, аның теле үзенең заманасы өчен бик артык татарча. Дөрес, ул үзенең заманасына тиешле бурычын түләгән: аның әсәрләрендә «бән, бәнең, бирү, кемсә, ил, анларның, утларә, гизләмәк, чалышмак, гүзәл, түзәлем, калмамыш, кеби» шикелле госманлычалыклар, «ушал, ите, игаҗ, атлиг, илирсә, тигүргәнсен, айгөл, чишүбән, кани, суҗ, калгусы» шикелле чыгтайчалыклар, хәтта бәгъзан «Мөхәммәдия»дәге шикелле «булисәр»ләр[3] дә очрыйлар. Ләкин бу әҗнәбилекләр[4] асыл телнең татарчалыгын капларлык дәрәҗәдә түгел, өслүб һаман да татарча сөйләшү теленә бина кылынган[5]. Ул «мәрсияче шагыйрь»ләр өслүбенә караганда халык җырлары өслүбенә якынрак. Тел ягыннан гына түгел, хәтта өслүб ягыннан да аның шигырьләренең бәгъзы урыннары халык җырларына охшыйлар. Мәсәлән:

«Йөзең алсу кызыл гөлтик,
Йаңакың кызыл алматик;
Кызыл алма кеби кызны
Насыйб итәр микән Алла?»

[1] Бәлягатьле – матур, төзек.

[2] Вә йа каһәрме, зәхмәтме / Салыбдырмы залял Алла – Бәла-каза салган микән Алла? / Юлдан язу (тәкъдире) салган микән Алла?!

[3] «Булисәр»ләр – «булачак»лар.

[4] Әҗнәбилекләр – чит сүзләр.

[5] Бина кылынган – нигезләнгән.

«Парау илендә төш күрдем,
Ки бер кош тотдым, ук атдым,
Парау илендә бер матур
Өчен йокымны югалтдым».

Әгәр Кандалый үзенең шигырьләрен халык җырлары вәзенендә язган булса, тагын да яхшы иткән булыр иде. Ләкин ул вакытта бу гадәт булмаган. Ул күбрәк бәхре һәзәҗ (мөфагыйлен), бәгъзан бәхре рәмел (фагыйләтен) вәзеннәре белән язган. Насыйри аның вәзенен «Мөхәммәдия көе» дип атый. Чынлап та, «Мөхәммәдия»нең Кандалыйга зур тәэсире булганлыгы күренә. Мәүзугларының бөтенләй башка булуына карамый, ул һәрвакыт тышкы формада Язычы углына[1] тәкълид итә[2]. Бу тәкълид бер вәзен бабында гына түгел. Мәсәлән кафияләрне ул кайбер вакыт «Мөхәммәдия»дәге шикелле бер вәзендәге төрле гарәп сүзләреннән җыярга ярата: бәгъзан бер үк сүз һәрбер бәйтнең ахырында кафия итеп истигъмаль итеlә[3]. Әмма Кандалыйның шигырьләре күбрәк дүрт юллы бәйтләрдән гыйбарәт булып, әүвәлге өч юл үзара кафиядәш, бәйтләрнең соңгы дүртенче юллары бер-берсе белән кафиядәш булалар. Бу тарызда язу аңар бәйтләрнең әүвәлге өч юлларының кафияләрендә матур-матур тәҗнисләр[4] ясарга да юл ача. «Мөхәммәдия»дәге шикелле монда да тәҗнисләр бик еш очрый. Мәсәлән:

«Бу нидән булды чи генә?
Эшем дә җитде чигенә,
Сахибем кире чигенә,
Исем китәр, и җанкәй лә!»

бәйтендәге шикелле. Гомумән, Кандалый кафиягә бер дә аптырамый, бәлки, ул алар белән уйный да. Аның шигырьләрендә

[1] Сүз төрек шагыйре Мөхәммәд Чәләби Язычы улы (?–1451/1452) хакында бара.
[2] Тәкълид итә – охшатып яза.
[3] Истигъмаль ителә – кулланыла.
[4] Тәҗнисләр – тәҗнис дип, әйтелү рәвеше (тәләффызы) бер төсле булып, мәгънәләре башка булган сүзләрне кафияләүгә әйтәләр. *(Авт. иск.)*

гаҗәп муаффәкыятьле[1] кафияләрне бик күп очратып була. Аның ничек итеп кафияләр белән җиңел уйнаганын күрсәтү өчен, түбәндәге сәтырларны китерәбез:

«И-и, и генә лә, и генә!
Ни булды мәңа, ни генә?
Буласы кеше би генә –
Булып калдым ла кол гына.
Ки барсам иде бигә лә,
Эшем китәрди игә лә,
Бу надан иргә нигә лә
Барып, калдым ла тол гына?»

Кандалыйның өслүбе хакында сөйләгәндә, аның фарсыча, «ки» кушымтасы белән сүи истигъмаль итүен[2] дә әйтеп узарга кирәк. Ул бик күп вакытта җөмләләрне «ки» белән ялгый. Җөмләне бу рәвешчә төзү гәрчә өслүбнең татарчалыгына зыян итсә дә, кыска юллы шигырьләрдә кысынкы җөмләләр белән күп мәгънә аңлатырга шагыйрьгә бик зур ярдәм итә. Гарәп-фарсы сүзләрен Кандалый чамадан тыш күп истигъмаль итми. Урыны-урыны белән алар күп кенә очрасалар да, күбесенчә ул бер дә кушымтасыз саф татарча язып китә. «Лөэлөэ мәкнүн»[3], «гамгүсар», «мәэҗүр»[4], «мәһҗүр»[5] шикелле татарчада истигъмаль ителми торган гарәп-фарсы сүзләренең шактый гына күп булуы, бердән, заманадан, икенчедән, шагыйрьнең муллалыгыннан, өченчедән, «Мөхәммәдия» тәэсиреннән күрелергә тиеш. Кандалыйның тагын бер кимчелеге – рус сүзләрен урынлы-урынсыз күп куллануыдыр. Ул русча сүзләрне күп вакыт һич кирәксезгә, мәсәлән, кафия өчен яки сөйләшкәндәге шикелле ифадәне[6] куәтләндерү өчен кертә. Гарәпчә, төрекчә сүзләрне дә ул бәгъзы вакыт бары кафия яки вәзен ягыннан уңае туры килгәнгә күрә

[1] Муаффәкыятьле – уңышлы.
[2] Сүи истигъмаль итүен – урынсыз куллануын.
[3] Лөэлөэ мәкнүн – энҗе муенса.
[4] Мәэҗүр – саваплы.
[5] Мәһҗүр – онытылган.
[6] Ифадәне – аңлатуны.

генә истигъмаль итә. (Без Кандалыйның өслүбендә һәрвакыт кафия дигән нәрсәнең бик зур роль уйнаганын күрәбез). Рус сүзләренә килгәндә, ул, кайвакыт бигрәк тә арттырып җибәреп, бөтен-бөтен сәтырларны русча сүзләрдән тезә. Мисал өчен, без аның шигырьләреннән чүпләнгән беркадәр рус сүзләрен китерәбез: «могу, гуринча, дурак, дура, сублак, дублак, чис, лис, пуштовой, вечнай, проклятый, собаки, пёс». Ләкин, һәрбер төрле кимчелекләренә күз йомып, шагыйрь Габделҗәббар Кандалыйны без татар әдәбиятында татарча шигырьнең беренче карлыгачларыннан дип исәпләргә тиешбез.

**Бәетләр**

Әдәбиятыбызның борынгы дәвереннән сакланып калган парчалардан безнең күз алдыбызда берничә бәетләр бар. Иске әдәбиятыбызны тикшергәндә, без бу азмы-күпме татарча язылган әсәрләр яныннан игътибарсыз гына узып китә алмыйбыз. Бу бәетләрнең өчесе («Мәхбүбләргә сәламнамә», «Чәй бәете», «Килен бәете»), Каюм Насыйри тарафыннан җыелып – «Фәвакиһ әл-җөләса»да, дүртенчесе – «Кәҗә бәете» – Габделгалләм Фәезхановның «Хикәят вә мәкаләт» исемле кечкенә халык әдәбияты мәҗмугасында дәрҗ ителгәннәр[1]. Безнең халык арасында йөргән бу төрле бәетләр, әлбәттә, болар гына булмагандыр. Аларның йә бик мәшһүрләре, йә иттифакый[2] кулга төшкәннәре генә сакланганнардыр. Гомумән, безнең халыкта мондый әдәбиятка җитди күз белән карау булмаган. Аларны язучылар да болай гына, кызык өчен генә, каләм шаяртыр өчен генә язганнардыр. Аларның күбесенчә көлкеле мәүзугларга язылган булулары да шуны күрсәтә. Моның шикелле әсәрләр күбрәк шәкерт халкы арасында берәүдән-берәү күчереп алу васитасы[3] белән таралган.

[1] Дәрҗ ителгәннәр – кертелгәннәр, теркәлгәннәр.
[2] Иттифакый – очраклы.
[3] Васитасы – ысулы.

1. «Әбъят[1] мәхбүбләргә[2] сәламнамә» – бу кыска гына гыйшкый шигырь. Югарыда мәзкүр дүрт бәет арасында иң авыр тел белән язылганы. Аның теленең мәрсияләр теленнән күп аермасы юк. Теле чыгтайчага тартым; гарәп, фарсы сүзләре бик күп. Ләкин бу бәетне мәрсияче шагыйрьләрнең әсәрләреннән аера тора торган нәрсә – аның мөндәриҗәсе. Мәрсияче-суфи шагыйрьләр, гыйшык хакында язсалар, бары тик Аллага булган гыйшык турысында гына яза алалар; бу шигырьнең намәгълүм шагыйре исә, шул ук материалны башкача истигъмаль итеп[3], чын җир мәгъшукасына хитап итеп яза.

2. «Чәй бәете» – безнең татарның иң яраткан эшләреннән берсе булган чәй эчүгә багышланып, аның хасиятләрен, шартларын бәян кыла торган бу мәдхия бәхре һәзәҗ вәзене[4] белән («Мөхәммәдия» көенә) язылган. «Мөхәммәдия» өслүбе шикелле тантаналы, бик күп гарәп-фарсы сүзләре катышкан госманлы теленә якын бер телдә язылып та, мәүзугысы шундый әһәмиятсез бер әйбер булуы тәнакыз[5] кагыйдәсе буенча бик көлкеле булып чыга. Тыштан караган вакытта аның бик җитди тонда язылуы аның көлкелеген арттыра гына. Бу рәвешчә «Мөхәммәдия»гә тәкълид-пародия язуы бу бәетнең мөхәрриренең яхшы гына кувәи һөҗүягә малик[6] кеше булуына дәлаләт итә. Бу кешенең кем булуы мәгълүм түгел. Ләкин бәетнең ахыргы юлларыннан аның бер мулла булуы аңлашыла. Җәмалетдин Вәлиди үзенең «Татар әдәбиятының барышы» дигән китабында «Чәй бәете» белән «Килен бәете»н Габделҗәббар Кандалыйга нисбәт бирмәкче була. Дәлил итеп, гүяки аларның өслүбләре белән Кандалыйның өслүбенең бертөрле булуын китерә. Әмма дәгъваның асылсыз булуында һич шөбһә юк. Кандалый өслүбе белән «Чәй бәете»нең өслүбе бер-берсенә бөтенләй башка

[1] Әбъят – бәетләр.
[2] Мәхбүбләргә – яратылган ирләргә.
[3] Истигъмаль итеп – кулланып, файдаланып.
[4] Вәзене – ритмы.
[5] Тәнакыз – бер-берсенә каршы кую, контрастлык.
[6] Кувәи һәҗүягә малик – көчле сатирага ия.

булганлыгы шикелле, «Чәй бәете» белән «Килен бәете»нең өслүбләре арасында да һичбер төрле охшау вә мөнәсәбәт юк. Моны аңлар өчен, аларны игътибар белән укып чагыштыру җитсә кирәк дип беләбез.

3. «Килен бәете» саф татарча сөйләшү телендә язылган. Бу һөҗүви[1] бәет уңмаган киленнәрдән көлә. Бу бәет «Бәдәвам» көенә язылып, һәрбер дүрт юлының әүвәлге өч юлы үзара кафияләшәләр[2]. Дүртенче юлларының ахырлары, «Ярым алма» шигырьләрендәге шикелле, «тидия» дигән сүз белән тәмамлана. Мөхәррире мәгълүм түгел.

4. «Кәҗә бәете» – «Хикәят вә мәкаләт»тә бу бәетнең бер шәкерт тарафыннан чыгарылганы язылган. «Йосыф китабы»на тәкълидән[3] язылып, һәрбер дүрт юлы «имди» белән бетә торган бу бәет – татар тормышында шактый зур роль уйнаучы йорт хайваннарыннан булган кәҗәнең явызлыкларына багышланган булып, халык арасында бик мәшһүр булган көлкеле бәетләрдәндер. Теле «Килен бәете»неке шикелле саф татарча.

[1] Һөҗүви – юмористик, сатирик.
[2] Кафияләшәләр – рифмалашалар.
[3] Тәкълидән – охшатып.

# ТЕКСТЛАРНЫ ГАМӘЛДӘГЕ ЯЗУГА КҮЧЕРҮЧЕЛӘР ҺӘМ ШӘРЕХЛӘҮЧЕЛӘР

*Ахунов А.М.* – филология фәннәре кандидаты, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре.

*Гомәров И.Г.* – филология фәннәре кандидаты, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре.

*Гарипова Л.Ш.* – филология фәннәре кандидаты, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре.

*Хөснетдинова Г.А.* – филология фәннәре кандидаты, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының текстология бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре.

## ЭЧТӘЛЕК

**Икенче бүлек** *(дәвамы)* . . . . . . . . . . . . . . . . 5
Идел буенда чыгтай әсәрләре *(дәвамы)* . . . . . 5
«Рәүнәкъ әл-ислам» . . . . . . . . . . . . . . . . . . 5
«Мәхзән әл-әсрар» . . . . . . . . . . . . . . . . . . .13
«Кыйссаи Сәйфелмөлек» . . . . . . . . . . . . . . .17
«Сөбат әл-гаҗизин» . . . . . . . . . . . . . . . . . .29
«Кисекбаш китабы» . . . . . . . . . . . . . . . . . .41
«Йосыф китабы» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .44
Идел буенда госманлы әсәрләре . . . . . . . . . . .53
«Мөхәммәдия» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .53
Сугыш китаплары . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .62
«Сәид Баттал» китабы . . . . . . . . . . . . . . . . .73
Кыйсса китаплары . . . . . . . . . . . . . . . . . . .92
1. «Тутыйнамә» . . . . . . . . . . . . . . . . . . .93
2. «Дастане Хатәм Тай» . . . . . . . . . . . . . .97
3. «Әбү Гали Сина китабы» . . . . . . . . . . 100
4. «Кырык вәзир» . . . . . . . . . . . . . . . . 105
«Ләтаифе Хуҗа Насретдин» . . . . . . . . . . . 107
Госманлыча дини вә фәнни китаплар . . . . . 113
**Өченче бүлек**. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 121
XVII, XVIII һәм XIX гасырларда иске әдәбият. . . . . . . . 121
Мөкаддимә урынына . . . . . . . . . . . . . . . . 121
«Тәварихе Болгария» . . . . . . . . . . . . . . . . 124
«Җәмигъ әт-тәварих» тәрҗемәсе . . . . . . . . 138
«Галикәй аталык васыятьнамәсе» . . . . . . . . 150
«Әхвәле Чыңгыз хан вә Аксак Тимер» . . . . . . . 151
Вәкаигънамәләр. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 167

Исмәгыйль ага сәяхәтнамәсе . . . . . . . . . . . . . . . . . . 170
«Бәдәвам китабы» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 177
Догалык, фалнамә, йолдызнамә вә төш тәгъбирләре . . . 184
«Иман шарты» яисә «Шәраят әл-иман». . . . . . . . . . . . 191
«Рисаләи Газизә» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 193
«Фәзаилеш-шөһүр» китабы . . . . . . . . . . . . . . . . . . 197
Хикәят китаплары . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 201
«Таһир илә Зөһрә» һәм «Бүз егет» кыйссалары . . . . . . 212
«Кыйссаи Нәбрүз» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 230
Иске шагыйрьләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 248
1. Габдерәхим Утыз Имәни . . . . . . . . . . . . . . . . . 260
2. Әбелмәних Хаҗи. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 265
3. Габделкаһир Сөләйман углы . . . . . . . . . . . . . . . 267
4. Шәмседдин Суфи Зәки . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 268
5. Һибәтулла Ишан . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 274
6. Мәхмүд Ширвани . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 277
Габделҗәббар Кандалый . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 278
Бәетләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 294
Текстларны гамәлдәге язуга күчерүчеләр
һәм шәрехләүчеләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 297

**ДУХОВНОЕ НАСЛЕДИЕ**
**поиски и открытия**
Выпуск 16

Редактор Л. Г. Шарифуллина
Компьютерная верстка Н. Т. Абдуллиной
Дизайн обложки А. В. Булатова

Подписано в печать: 08.12.2022 г.
Бумага офсетная. Формат 60×84 1/16. Гарнитура «Таймс».
Усл.-печ. л. 17,4. Уч-изд. л. 14. Тираж 300 экз. Заказ

Оригинал-макет подготовлен
в Институте языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ
420111, Казань, ул. К. Маркса, 12

Издательство Академии наук Республики Татарстан
420111, Казань, ул. Баумана, 20